

# ИЗГЕ ЯЗМА СӘХИФӘЛӘРЕ

ТӘҮРАТ • ПӘЙГАМБӘРЛӘР • ЗӘБУР • ИНҖИЛ

# Изге Язма сәхифәләре

Тәүрат • Пәйгамбәрләр • Зәбур • Инҗил

Изге Китапны тәрҗемә итү институты
Мәскәү
2023

**Изге Язма сәхифәләре**
Тәүрат, Пәйгамбәрләр, Зәбур, Инҗил

Рус телендәге басманы төзүче: Б. Арапович

Изге Язма (Библия) текстларының татар телендәге электрон һәм аудио версияләре белән Изге Китапны тәрҗемә итү институты сайтында танышырга мөмкин: https://ibt.org.ru/ru/media?id=TTR.

ISBN 978-5-93943-331-0

Рәсемнәр Classic Bible Art, LLC. рөхсәте белән бирелә

© Институт перевода Библии, 2023

# Кереш сүз

Хөрмәтле укучылар!

«Изге Язма сәхифәләре» исемле әлеге китапта сез Тәүрат, Зәбур, Инҗил язмаларының төп эчтәлеге белән танышырсыз. Китап һәркемгә – олыларга да, балаларга да аңлаешлы, гади тел белән язылган. Кайбер милли басмаларда китапның исемен турыдан-туры «Балалар өчен Изге Язма» дип тә атаганнар. Ул инде илледән артык телгә тәрҗемә ителгән, төрле телләрдәге басмаларның гомуми тиражы бүгенге көндә якынча тугыз миллион тәшкил итә.

Тәүрат, Зәбур, Инҗил китапларыннан гыйбарәт булган «Изге Язма» (Библия) дигәнебез – гади китаплар җыелмасы гына түгел. «Изге Язма» Аллаһы Рухы белән сугарылган изге затлар тарафыннан язылган. Аның ярдәмендә без белемебезне тирәнәйтәбез, үткәнебез, чал тарихыбыз турында күп мәгълүмат алабыз, борынгы дөньяның бөек шәхесләре белән танышабыз, әмма иң мөһиме – шушы дөньяны бар иткән, тереклекнең, кеше язмышларының Хакиме һәм Хөкемчесе булган Аллаһыга, Аның Рухына якынаябыз, Ул кушканча яшәргә өйрәнәбез. «Изге Язма»да, әлбәттә, кешене борчыган яки кызыксындырган барлык сорауларга да җавап юк, әмма анда Аллаһы белән кеше арасындагы рухи мөнәсәбәтләр, адәм баласының Аллаһыга сыгыну зарурлыгы, тәүбә иткән гөнаһлы кешенең дә Аңардан ярлыкау, күңел тынычлыгы табуы турында ышандырырлык итеп сөйләнә.

«Изге Язма» тупланмасы – дөньяда иң күп тәрҗемә ителә һәм укыла торган китап. Китап басу станогы уйлап табылгач та, анда басылган беренче әсәр нәкъ менә «Изге Язма» текстлары була. Хәзерге заманда «Изге Язма» турында бөтенләй дә ишетеп белмәгән кеше юктыр. Китап үзе яки аның аерым өзекләре дөньяның бик күп телләренә тәрҗемә ителгән. Мәсихчеләр (христианнар) «Изге Язма»ны үзләре өчен төп рухи-дини чыганак һәм яшәү рәвешенең нигезе дип саныйлар. Диннән ерак торган кешеләр дә «Изге Язма»га еш мөрәҗәгать итәләр. Пәйгамбәрләр Ибраһим, Йосыф, Давыт патша, Гайсә Мәсих һәм башка шәхесләрнең тормыш сәхифәләрен гәүдәләндергән күп санлы мәшһүр картиналар, сыннар-скульптуралар һәм сәнгать әсәрләре шул турыда сөйли.

«Изге Язма»дагы күп кенә сүзләр һәм гыйбарәләр дә мәкаль булып халык телендә яши.

«Изге Язма» ике зур өлешкә бүленгән: Тәүрат, Зәбур һәм пәйгамбәрләрнең язмаларын үз эченә алган беренче өлеше – Иске Гаһед*, ә икенче өлеше Яңа Гаһед дип атала.

Иске Гаһед текстлары Аллаһы Тәгаләнең сүзе-боерыгы белән дөньяның һәм Җирдә беренче кешенең яратылуы (барлыкка килүе) турындагы хикәядән башлана. Үзе бар иткән кешегә Аллаһы ихтыяр иреге бирә һәм кеше, Аңа буйсынырга теләмичә, җирдә үз тормышын үзенчә корып яши башлый. Шулай булуга карамастан, Аллаһы аны кайгыртып һәрчак игътибар үзәгендә тота, ярдәм сораучыларга рәхим-шәфкатен күрсәтә. Дөньядагы барлык халыклар арасыннан Аллаһы Исраил кавемен, ягъни яһүдиләрне, Үз халкы дип игълан итә һәм аның белән мәңгелек килешү төзи. Исраил халкының тарихын хикәяләү Иске Гаһед китабының төп эчтәлеген тәшкил итә.

Стиль-язылыш мәсьәләсенә килгәндә, Иске Гаһед төрле характердагы китапларны берләштерә. Аларның беришләре Исраил дәүләтенең тарихы, аның юлбашчы-җитәкчеләре, патша һәм пәйгамбәрләре, башка халыкларга бәйле тарихи вакыйгалар турында сөйли. Болары тарихи китаплар рәтендә йөри. Арада тәнкыйди, үгет-нәсыйхәт яки киләчәккә фараз кылу рухында язылган пәйгамбәрлек китаплары да бар: аларда Исраил халкының Аллаһы юлыннан читкә тайпылуы тәнкыйтьләнә, Аллаһыга тугрылык саклау – бердәнбер дөрес юл икәнлеге раслана, кинаяләп, киләчәктән серле-шомлы вакыйгалар телгә алына. Иске Гаһедтә шулай ук тапкыр, хикмәтле сүз (мәсәлән, Сөләйман патшаның гыйбрәтле сүзләре), мәдхия-дога (Зәбур) тупланмалары да бар.

Яңа Гаһед (татарлар аны Инҗил-шәриф дип тә йөртә) хәзерге ел исәбе белән беренче гасырның икенче яртысында борынгы грек телендә иҗат ителгән. Анда кешелек дөньясының яңарыш дәверенә нигез салучы Гайсә Мәсихнең тууы, Аның хезмәте, үлеме һәм үледән терелүе, Ул оештырган мәсихчеләр бердәмлегенең беренче адымнары бәян ителә. Гайсә Мәсихнең кешелек тарихындагы урынын рәсүл Яхъя берничә сүз белән болай дип билгеләгән: «Аллаһы дөньяны шулкадәр яратты ки, Углына ышанган беркем һәлак булмасын, ә бәлки мәңгелек тормыш алсын өчен, Ул Үзенең бердәнбер Углын бирде» (Яхъя 3:16). Гайсә

* Гаһед – килешү.

Мәсих аша Аллаһы безгә юллаган Яхшы хәбәрнең асылы әнә шуннан гыйбарәт («яхшы хәбәр» гарәп теле аша безгә «инҗил» формасында килеп җиткән). Инҗилнең беренче дүрт китабы Гайсә Мәсихнең җирдәге тормышына һәм Аның өйрәтүләренә (тәгълиматына) багышланган. Әлеге китаплар Маттай, Марк, Лүк һәм Яхъя исемле рәсүлләр тарафыннан язылган. Лүк тарафыннан язылган бишенче китап исә (Рәсүлләрнең эшләре) беренче мәсихчеләр турындагы хикәяләрне, Яхшы хәбәрнең таралуы һәм Мәсих бердәмлегенең үсү-киңәюе хакындагы мәгълүматларны үз эченә ала.

Яңа Гаһедтә шулай ук Паул һәм башка рәсүлләрнең, ягъни Яхшы хәбәрне халык арасында тарату, вәгазь сөйләү өчен җибәрелгән Мәсих шәкертләренең хатлары да урын алган. Аларның эчтәлеген үгет-нәсыйхәтләр, чын мәсихчегә хас яшәү кагыйдәсе турындагы язмалар тәшкил итә. Бу үгет-нәсыйхәтләр, кагыйдәләр бүгенге көндә дә тәрбияви әһәмиятен югалтмаган.

Яңа Гаһед тупланмасының соңгы өлешендә (Ачылыш китабында) Яхъя, образлы тел кулланып, дөньяның хөкем ителүен һәм ахырда булачак вакыйгаларны тасвирлап кына калмыйча, барлык бәла-каза һәм борчу-хәсрәтләрдән арынганнан соң кешелек дөньясын көткән яхшырак һәм тынычрак мәңгелек тормыш турында бәян итә.

Кыскасы, кулыгыздагы әлеге китап аерым хикәяләр тупланмасы рәвешендә төзелде һәм хикәяләрнең тематикасына карап рәсемнәр белән бизәлде. Һәр хикәянең «Изге Язма»дагы төгәл урыны күрсәтелде. Китап ахырындагы кушымтада географик карта һәм схемалар, «Изге Язма»да телгә алынган кайбер географик урыннарның фоторәсемнәре урнаштырылды.

Әлбәттә, әлеге китап «Изге Язма»ның кыскартып, сайлап алынган бер өлеше генә, шуңа күрә «Изге Язма»да тасвирланган бик күп вакыйгалар биредә урын алмады. Укучыларыбыз шушы басма ярдәмендә «Изге Язма» белән танышкач, аны инде кулларыннан төшермәсләр дигән өметтә калабыз.

*Изге Китапны тәрҗемә итү институты*

# ИСКЕ ГАЂЕД

## Дөньяның яратылышы

Иң башта һичнәрсә юк иде – болытлар томалаган айсыз төндәге сыман, әйләнә-тирә дөм караңгылыкка чумган, һәм беркайда бернинди яктылык әсәре күренми иде. Ул чакта әле күк йөзе дә, яктылык та, үсемлекләр дә, һичнинди тереклек иясе дә, шушы караңгылыкны күреп багардай адәм заты да юк иде. Әмма Аллаһы әйләнә-тирәнең гомер бакый шушы кыяфәттә калуын теләмәде һәм шуңа күрә әлеге дөньяны бар итте. Бер генә нәрсә дә үзеннән-үзе барлыкка килми: тирә-ягыбыздагы искиткеч матур һәм төзек-камил бу дөнья йөзе дә Бар итүченең бөеклеге һәм акылы-зирәклеге хакында сөйли. Изге Китапта Аллаһының ни рәвешле Үз сүзе белән дөньяны яратуы хакында бәян ителә.

Иң әүвәл Аллаһы күкне һәм җирне яратты.

Җир йөзе башта әле бик тә күрексез һәм буп-буш – төпсез упкын, караңгылык эченә чумган иде; Аллаһының рухы-сулышы сулар өстендә гизә иде.

Аллаһы: «Яктылык булсын», – дип боерды, һәм яктылык булды.

Аллаһы яктылыкның яхшы булуын күрде һәм аны караңгылыктан аерды.

Яктылыкны Аллаһы «көн» дип, караңгылыкны «төн» дип атады. Кич җитте, таң атты: беренче көн үтте.

Аллаһы: «Суларның уртасында бер гөмбәз булсын һәм суларны бер-берсеннән аерсын», – дип боерды.


Нәкъ шулай булды: Аллаһы гөмбәзне яратты. Гөмбәз астындагы суларны гөмбәз өстендәге сулардан аерды.

Аллаһы гөмбәзне «күк» дип атады. Кич җитте, таң атты: икенче көн үтте.

Аллаһы: «Күк астындагы сулар бер урынга җыелсын да су астыннан туфраклы ялан калкып чыксын», – дип боерды, һәм нәкъ шулай булды.

Аллаһы туфраклы яланны «җир» дип, җыелган суларны «диңгез» дип атады. Аллаһы боларның яхшы булуын күрде.

Аллаһы: «Туфрактан яшеллекләр үсеп чыксын, төренә күрә орлык бирә торган үләннәр, җимешендә үз төренең орлыгын өлгертә торган җимеш агачлары үссен», – дип боерды, һәм нәкъ шулай булды.



Җир өстендә яшеллекләр, төренә күрә орлык бирә торган үләннәр, җимешендә үз төренең орлыгын өлгертә торган җимеш агачлары үсеп чыкты. Аллаһы моның яхшы булуын күрде.
Кич җитте, таң атты: өченче көн үтте.

*Яратылыш 1:1–13*

## Дөньяның яратылышы (дәвамы)

Аллаһы: «Күк гөмбәзендә җир йөзен яктырта вә көнне төннән аера торган яктырткычлар булсын, алар вакытны, ел фасылларын һәм дә көн исәбен күрсәтеп торсыннар», – дип боерды. Һәм нәкъ шулай булды.

Аллаһы ике бөек күк җисемен – зурысы көн белән, кечесе төн белән идарә итүче яктырткычларны һәм йолдызларны яратты. Җир йөзен яктыртып, төн вә көн белән идарә итсеннәр һәм яктылыкны караңгылыктан аерып торсыннар өчен Аллаһы аларны күк гөмбәзенә урнаштырды. Һәм моның яхшы булуын күрде.

Кич җитте, таң атты: дүртенче көн үтте.

Аллаһы: «Сулар терек җан ияләре белән тулып ашсын, җир йөзе өстендә һәм күк гөмбәзе астында кошлар очып йөрсен», – дип боерды.

Һәм Аллаһы зур диңгез җанварларын, төрләренә карап суда кайнашкан барлык җан ияләрен, барлык төр очар кошларны яратты. Моның яхшы булуын күрде.

Аллаһы аларга Үзенең фатихасын бирде: «Үрчегез, ишәегез, диңгез суларын тутырыгыз, җир йөзендә кош-корт үрчегәннән-үрчесен», – диде.

Кич җитте, таң атты: бишенче көн үтте.

Аллаһы: «Җир йөзе үзендә төрле токымдагы җан ияләрен – кыргый хайваннарны, терлек һәм хәшәрәтләрне булдырсын», – дип боерды. Һәм нәкъ шулай булды.

Аллаһы җир йөзендә төрле токымдагы җан ияләрен – кыргый хайваннарны, терлек һәм хәшәрәтләрне яратты. Моның яхшы булуын күрде.

Чиксез кодрәткә ия булган Бар итүченең сүзе белән яратылган һәм рәхәт-талгын тынлыкка чумган җир йөзе искиткеч гүзәл иде. Әмма яратылыш әле тәмамланмаган иде. Шушы матур дөньяда яшәп, үзләренең Бар итүчесе белән аралашып көн күрсен өчен Аллаһы җирдә кешеләрне яратырга карар кылды.

*Яратылыш 1:14–25*



## Беренче кешеләрнең барлыкка килүе

«Кешене Үз сурәтебездә, Үзебезгә охшатып яратыйк, – диде Аллаһы. – Кеше диңгездәге балыклар, күктәге кошлар, җирдәге хайваннар, бөтен җир йөзе, җирдә хәрәкәт итүче барлык тереклек ияләре өстеннән хакимлек итсен».

Һәм Аллаһы кешене Үз сурәтендә, Аллаһыга охшатып яратты.

Кешеләрне ир һәм хатын-кыз итеп яратты.

Аларга фатихасын биреп: «Үрчегез һәм ишәегез, – дип әйтте, – җир йөзен тутырыгыз, аны буйсындырыгыз; диңгездәге балыкларга, күктәге кошларга, җир йөзендә хәрәкәт иткән барлык җан ияләренә хуҗа булыгыз», – диде. Аллаһы әйтте: «Җир өстендә үскән барлык үлән-яфракларны, барча агачларның җимешләрен сезгә тапшырам: алар сезгә ризык булсын; җир йөзендәге һәрбер хайванга, күктәге һәрбер кошка, үзендә тереклек сулышын тойган һәрбер җанварга исә азык итеп яшел үлән насыйп кылам». Һәм нәкъ шулай булды. Аллаһы Үзе яраткан нәрсәләрне күздән кичерде һәм һәр нәрсәнең гаять яхшы икәнлеген күрде.

Кич җитте, таң атты: алтынчы көн үтте.

Күкнең һәм җирнең, андагы бөтен нәрсәнең ятатылышы әнә шулай тәмамланды. Аллаһы Үз эшен җиденче көнгә бетерде һәм, бөтен эшләрен тәмамлап, ул көнне ял итте.

Аллаһы кешеләрне матур һәм бәхетле итеп яратты. Алар үзләренең Бар итүчесенә һәм бер-берсенә мәхәббәтле мөнәсәбәттә булдылар. Ир кешенең исеме – Адәм, хатын-кызның – Һава иде.

Үзе яраткан җирне кайгыртсыннар өчен Аллаһы җирне аларның кулына тапшырды. Раббы Алла көн чыгышы тарафында, Гадәндә, оҗмах бакчасы булдырды һәм, Адәм белән Һавага Үзенең фатихасын биреп, аларны шунда урнаштырды. Раббы Алла аларга бакчаны саклау һәм эшкәртү вазифасын йөкләде.

*Яратылыш 1:26–31; 2:7–22*



## Адәм белән Һаваның оҗмахтан куылуы

Ләкин Адәм белән Һава Аллаһы сүзеннән чыктылар, һәм Ул аларны оҗмахтан куып җибәрде. Бу хәл болай булды.

Раббы аларга яхшылыкны һәм яманлыкны таныта торган белем агачыннан гайре бакчадагы һәммә агачның җимешен ашарга рөхсәт бирде һәм: «Әгәр шушы әмеремне бозсагыз, үләчәксез», – дип кисәтеп куйды.

Әмма иблис – Раббыга каршылык күрсәтүче зат – Адәм белән Һаваны харап итәргә ниятләде. Бервакыт ул, елан кыяфәтенә кереп, Һава янына килде дә: «Аллаһы сезгә, чыннан да, бакчадагы һичбер агачның җимешен ашамагыз, дидеме?» – дип сорады. «Бакчадагы агачларның җимешен ашарга безгә рөхсәт бар, – дип җаваплады хатын, – әмма Аллаһы әйтте, бакча уртасындагы агачның җимешләренә кагылмагыз, аларны ашамагыз, юкса үләрсез, диде». Елан исә аңа: «Юк, үлмисез, – диде, – чөнки Аллаһы белә: ул агачның җимешен ашаган көнне сезнең күзләрегез ачылачак һәм сез, яхшылык белән яманлыкның ни икәнен белеп, Аллаһының Үзе кебек булачаксыз».

Әлеге агачның карап торышка гүзәл, җимешенең ризык өчен хуш булуын күреп, белем бирү хасиятенә ия булган агачның җимешенә кызыгып хатын агачтан җимеш өзеп ашады, иренә дә өзеп бирде – ул да ашады. Раббы Алла шуннан соң Адәмгә болай диде: «Хатыныңның сүзен тыңлап, Мин „ашама“ дип кисәткән агачның җимешен ашаган өчен җир туфрагына Минем ләгънәтем төште; син гомереңбуе тамагыңа ризыкны җәфа чигеп табарсың. Яратылмыш туфрагыңа кире әйләнеп кайтканчыга кадәр ашар икмәгеңне маңгай тирен түгеп табарсың; чөнки син үзең – туфрак, туфрактан яратылдың һәм янә туфракка әверелерсең». Шулай итеп, Адәм белән Һаваны Раббы оҗмах бакчасыннан куды, һәм алар инде башкача анда әйләнеп кайта алмады.

Беренче кешеләрнең, гөнаһ эш кылып, бозыклыкка бирелүе әнә шулай булды.

*Яратылыш 3:1–23*



## Кабил белән Һабил

Адәм белән Һаваның ике углы туды. Аларның берсе, Һабил, сарыклар көтүче, аның абыйсы Кабил исә игенче булды.

Бервакыт Кабил җир җимешләре уңышыннан Раббыга бүләк китерде. Һабил дә үз көтүендә беренче булып туган сарык бәрәннәренең берничәсен Раббыга алып килде. Раббы Һабилне һәм аның бүләген кабул итте, Кабилне һәм аның бүләген исә кире какты. Кабил бик нык рәнҗеде, ачуыннан башын түбән иде. Шунда Раббы Кабилгә: «Нигә шулай рәнҗисең һәм ни өчен башыңны түбән идең? – диде. – Яхшылык кылгач, башны югары тотып йөриләр. Инде яман эш кыласың икән – гөнаһ ишек төбендә посып торыр, сине сагалар. Ә син аңардан өстен бул». Әмма Кабилнең күңеленә көнчелек кереп оялады. Бервакыт шулай абыйлы-энеле кырга чыккач, Кабил, энесе Һабилгә һөҗүм итеп, аны үтерде. Һабилнең каныннан туфрак кара-кызыл төскә керде.

Кылган гөнаһы өчен Кабилне Раббы җәзага тартты һәм ул, туган җиреннән сөрелеп, гомере буена горбәттә* каңгырып йөрергә мәҗбүр булды.

*Яратылыш 4:2–12*

* *Горбәттә йөрү* – туган җирдән еракта, читтә каңгырып йөрү.



## Туфан. Нух көймәсе

Ничәмә-ничә гасырлар узды. Адәм белән Һавадан туа килгән кешеләр җир йөзендә үрчегәннән-үрчи бирде. Баштагы мәлләрдә аларның күбесе, Аллаһыдан куркып, Аның юлында йөрде, әмма тора-бара адәм балалары Аллаһы ихтыярына буйсынмый башлады. Бары тик Нух исемле бер кеше генә, Раббысына тугрылык саклап, Аның ихтыярына буйсынып яшәде. Рәсүл Петер аны соңыннан «тәкъва тормышка өндәүче» дип атады *(II Петер 2:5)*. Нухның йөрәгендә Аллаһының Рухы бар иде.

Раббы күрде ки, җир йөзендә яшәүче адәм балаларын азгынлык басты, кешенең бөтен күңеле һәм уй-фикере һәрвакыт явызлыкта булды, Аллаһы юлында йөрүче һичкем калмады. Шуннан Аллаһы әйтте: «Җир йөзендә яшәүче адәмнәрнең һәммәсен юк итәчәкмен, чөнки Мин аларны бар итүемә үкенәм», – диде.

Раббы күңеленә фәкать Нух кына хуш килде. Аллаһы Нухка болай диде: «Бөтен кешелек дөньясын юк итәчәкмен, чөнки кешеләр аркасында җир йөзе явызлык белән тулды. Гофәр агачыннан* үзеңә көймә яса; аның эчен-тышын сумалалап, көймәнең эчендә бүлмәләр булдыр. Шуннан соң Мин җир йөзен туфан суына батырачакмын, күк астындагы барлык җан ияләрен юк итәчәкмен. Әмма синең белән Мин килешү төзим, һәм син угылларың, хатының, киленнәрең белән бергә көймәгә кереп урнашырсың».

*Яратылыш 6:5–18*

* *Гофәр агачы* – кипарис сыман, сумалалы һәм ылыслы агач.



## Туфан

Аллаһының барлык боерыкларын Нух җиренә җиткереп үтәде. Көймә әзер булгач, Раббы аңа: «Бөтен гаиләң белән бергә көймәгә кер, – диде, – чөнки шушы буын кешеләре арасында бары син генә Минем хозурымда тугры булдың. Җир йөзендә токымнары сакланып калсын өчен чиста хайваннардан ата һәм ана җенестәге җиде парны, чиста булмаганнардан* шулай ук ата һәм ана җенестәге берәр парны, бар төр кошлардан исә җидешәр парны үз яныңа ал. Чөнки җиде көннән соң Мин җир йөзенә кырык көн һәм кырык төн тоташтан яңгыр яудырачакмын; Үзем бар иткән бөтен нәрсәне җир йөзеннән юк итәчәкмен».

Нух һәммәсен дә Раббы кушканча эшләде: хатыны, угыллары һәм киленнәре белән бергә көймәгә керде. Аллаһы кушканча, чиста хайваннардан ул җидешәр пар һәм чиста булмаганнардан берәр пар җан иясен үзе белән көймәгә алды. Һәммәсе көймәгә урнашып беткәч, Раббы Үзе алар артыннан ишекне япты. Җиде көннән соң туфан купты – җир йөзен томалап яңгыр коя башлады; ул кырык көн һәм кырык төн тоташтан яуды. Су ташкыны арткannan-арта барды, тора-бара бөтен җирне каплап алды, һәм көймә су өстеннән йөзеп китте. Су шулкадәр артты ки, хәтта иң биек тау түбәләре дә су астында калды, сулышы булган бөтен җан иясе – кешеләр дә, терлек тә, барлык җәнлекләр һәм кошлар да һәлак булды, җир йөзендәге бар нәрсә юкка чыкты. Фәкать Нух һәм аның белән бергә көймәдә булганнар гына исән калды.

*Яратылыш 7:1–23*

* *Чиста хайван* – ашарга ярый торган, чиста булмаган – ашарга ярамый торган хайван.



## Туфан суларының кайтуы

Йөз илле көн дәвамында су һаман күтәрелә бирде. Ахырда Аллаһы, Нухны һәм аның белән бергә көймәдә булган барлык хайваннарны исенә төшереп, җир өстенә җил истерде. Коеп яуган яңгыр туктап, сулар әкренләп кими башлады. Көннәрдән беркөнне Нухның көймәсе Арарат тавының түбәсенә килеп утырды. Кырык көн үткәч Нух, җир өстеннән су китеп беткәнме-юкмы икәнен белер өчен, көймәнең тәрәзәсен ачып бер козгынны тышка очырды. Җир өсте сулардан арынганга кадәр козгын шулай әле очып китеп, әле кабат кайтып йөрде. Аннары Нух бер күгәрченне очырды, әмма күгәрчен аның янына көймәгә әйләнеп кайтты, чөнки җир өстеннән су китеп бетмәгән иде әле. Нух тагын җиде көн узганны көтеп торды да күгәрченне янә тышка очырды. Кичен, томшыгына яшь зәйтүн яфрагы эләктереп, күгәрчен кире кайтты. Шуңардан Нух җир өстендәге суларның кимегәнлеген белде.

Яңадан да җиде көн үткәннән соң, Нух күгәрченне тагын очырды. Бу юлы күгәрчен кире әйләнеп кайтмады. Шуннан Нух көймәнең түбәсен ачып карады һәм җирнең коры икәнлеген күрде. Нухка Аллаһы: «Хатының, угылларың һәм киленнәрең белән көймәдән чык, – диде, – үзең белән көймәдәге барлык хайваннарны да алып чык; алар җир йөзенә таралсыннар, үрчеп-ишәеп җир өстен тутырсыннар».

*Яратылыш 7:24 – 8:17*



## Салават күпере һәм Аллаһының кеше белән килешү төзүе

Нух үзенең гаиләсе белән көймәдән чыкты һәм барлык төр җан ияләрен – хайваннарны да, кошларны да чыгарды. Җан ияләре җир йөзе буйлап таралышты, кошлар да төрлесе төрле якка очып китте.

Шуннан соң Нух таштан бер мәзбәх* корды да, чиста саналган хайван һәм кошлар арасыннан берничәсен сайлап алып, ут өстендә яндырып корбан китерде. Нухның корбан китерүен Раббы хуш күрде һәм: «Кешеләр аркасында җир йөзенә кабат ләгънәтем төшмәс, – диде. – Кеше йөрәгендә туа торган явызлыклар аның балачагыннан ук килә; инде тереклек дөньясын кабат үлемгә дучар итмәм. Дөньяның киләчәк яшәешендә чәчү дә, уру да булыр, суык та, эссе дә булыр, җәй дә, кыш та булыр, көн дә, төн дә булып торыр».

Нухка һәм аның угылларына фатихасын биреп, Аллаһы әйтте: «Мин сезнең белән һәм сездән соң туачак нәсел-нәсәбегез, шулай ук сезнең белән көймәдән чыккан барлык җан ияләре белән килешү төзим: моннан соң бернинди җан иясе дә туфан суларында һәлак булмаячак, җир йөзен суга батырган туфан бүтән беркайчан да кабатланмаячак. Минем белән җирдәге барлык җан ияләре арасында төзелгән килешүемнең билгесе итеп Мин болыттан җиргә таба салават күпере сузам. Җир йөзенә яңгыр болыты җибәреп, болыттан җиргә таба салават күпере сузылуга, Минем белән тереклек җан ияләре арасындагы мәңгелек килешүемне хәтеремә төшерермен. Җир йөзендәге барлык җан ияләре белән төзегән килешүемнең билгесе әнә шул салават күпере булыр».

*Яратылыш 8:18–22; 9:8–17*

---

* *Мәзбәх* – Аллаһы хөрмәтенә корбан китерү яисә хуш исле сумала-майлар көйрәтү өчен ясалган махсус урын-корылма.



## Бабил манарасы

Нух угыллары нәселеннән чыккан һәм кавем-кабилә булып җир йөзенә сибелгән халыкларның барысы да дөньяга туфаннан соң туды. Әмма туфаннан соң дөньяга килгән кешеләр дә яхшы якка һич тә үзгәрмәгән булып чыкты.

Ул заманнарда бөтен җир йөзендә халык бер генә телдә сөйләшә иде. Бервакыт алар, бөтенесе бергә җыелышып, бер-берләренә: «Җир йөзе буйлап сибелешеп бетмик һәм исемебезне данга күмик дисәк, үзебезгә бер шәһәр төзеп, башы күкләргә тиярдәй биек манара салыйк», – диделәр. Адәм балалары төзи башлаган шәһәрне һәм манараны күрү өчен Раббы күктән иңде һәм болай диде: «Менә, болар барысы да бер телдә сөйләшүчеләр, бер кавем кешеләре һәм алар инде уйлаган эшләреннән кире кайтмаячак. Яннарына иңеп телләрен буташтырыйк әле, сөйләшкәндә берберсен аңламас булсыннар». Шуңа күрә әлеге шәһәр Бабил, ягъни «буталу» дип атала да инде.

Шулай дип, Раббы адәм балаларын җир йөзе буйлап чәчте, һәм алар бу шәһәрне төзүдән туктадылар.

*Яратылыш 11:1–9*



## Ибраһим

Әлеге рәсемдә Ибрам сурәтләнгән. Соңрак Аллаһы аңа «бик күп халыкларның атасы» дигән мәгънәне аңлатучы «Ибраһим» исеме бирә. Ибраһим, бар өметен Аллаһыга баглап, Аңа тугрылык саклый һәм Аның сүзеннән чыкмый торган бер адәм була. Аллаһы аны Үзенең дусты дип атый. «Изге Язма»да Аллаһы безгә дә: «Минем әмерләремне үтәсәгез, Минем дусларым булырсыз», – дип әйтә *(Яхъя 15:14)*.

Бервакыт Ибраһимга Раббы болай диде: «Торган җиреңне, туганнарыңны, атаң йортын калдыр да Мин күрсәтәчәк җиргә күчеп кит. Мин синнән бөек халык тудырачакмын, сине мөбарәк кылачакмын, исемеңне шөһрәтле итәчәкмен, син фатиха-бәрәкәт иясе булачаксың. Сиңа игелек теләгәннәргә Мин игелек кылачакмын, сине каһәрләгәннәргә ләгънәтемне яудырачакмын. Җир йөзендәге кавемнәрнең һәммәсе синең аша фатиха алачак».

Раббысы боерганча, Ибраһим юлга чыкты, үзе белән хатыны Сараяны, бертуган энесенең улы Лутны, туплаган бар мал-мөлкәтен, кул астындагы барлык хезмәтчеләрен алды да Раббы күрсәткән тарафка – Кәнган җиренә юнәлде.

Кәнган җиренә килеп җитеп, Мөре имәнлеге дигән урынга туктауга, Ибраһимның каршысында Раббы пәйда булып: «Менә бу җирләрне Мин синең токымыңа бирәм», – диде.

*Яратылыш 12:1–7*



## Ибраһим һәм Лут

Ибраһим һәм аның белән бергә юлга кузгалган кешеләр Раббы күрсәткән Кәнган җире буйлап бара бирделәр. Бәйт-Эл дигән урынга килеп җиткәч алар туктарга булдылар.

Ибраһим мал-туарга һәм алтын-көмешкә бик бай иде. Бертуган энесенең углы Лутның да чатырлары, эре һәм вак мал-туары күп иде. Һәркайсының мал-туары артык күп булганлыктан, икесе бер урында сыешып яши алмый башладылар. Аларның көтүчеләре арасында әледән-әле низаглар чыга иде. Беркөнне Ибраһим Лутка әйтте: «Моннан ары минем белән синең арада, синең көтүчеләрең белән минем көтүчеләрем арасында низаг-бәхәскә урын калмасын, – диде. – Чөнки без кардәшләр. Әнә, бөтен җир йөзе синең күз алдында – аерылып кит син миннән. Син сулга китсәң, мин уңга китәрмен. Син уңга китсәң, мин сулга китәрмен».

Лут тирә-ягына күз ташлады. Үрдүн елгасы буйлары хәйран уңдырышлы һәм сугарыла торган җирләр иде. Лут үзенә әнә шул җирләрне сайлап алды һәм, Ибраһимнан аерылып китеп, Сәдүм шәһәренә кадәр җәелеп яткан тигезлектә үзенең чатырларын корды. Бу төбәктә явыз холыклы һәм Раббы каршында бик тә гөнаһлы халык яши иде.

*Яратылыш 13:1–18*



## Аллаһының Ибраһимга биргән вәгъдәсе

Лут аерылып киткәннән соң, Раббы Ибраһимга әйтте: «Басып торган җиреңнән көн ягына һәм төн ягына, көн чыгышы һәм көн батышы якларына карашыңны юнәлт, – диде. – Күз карашың иңләп алган бу җирләрнең һәммәсен Мин мәңгегә сиңа һәм синең нәсел варисларыңа бирәм. Киләчәк буын кешеләреңне Мин ком бөртекләре санынча ишәйтәчәкмен. Кем дә кем җир йөзендәге ком бөртекләрен санап бетерә алса, шул кеше генә синең нәсел варисларыңның санын белә алыр».

Ибраһим Мәмре имәнлеге дигән җиргә килеп төпләнде һәм шунда Раббы хөрмәтенә мәзбәх корды.

Күпмедер вакытлар үткәч, Ибраһим янына кабат Раббы иңеп болай диде: «Мин – синең калканың; аласы бүләгең синең зур булыр». Ибраһим исә, Раббыга җавап итеп: «Хуҗам-Раббым, Син миңа нәрсә бирмәкчесең? – диде. – Бала атасы булалмадым инде. Син миңа бала насыйп итмәдең, шуңа күрә өемдәге бер хезмәтче минем мирасчым булыр». Аның бу сүзләренә каршы Раббы: «Синең мирасчың булмаячак ул; синнән туган үз балаң мирасчың булыр», – дип җавап бирде. Аннары Раббы Ибраһимны чатырыннан һавага алып чыкты һәм: «Башыңны күтәреп күк йөзенә кара да, булдыра алсаң, андагы йолдызларны санап чык, – диде. – Синең нәсел варисларың әнә шул йолдызлар санынча булачак».

Ибраһим Раббыга ышанды һәм Раббы моны Ибраһимның тугрылыгы итеп кабул кылды.

Раббы Ибраһимга әйтте: «Хатыныңа бүтән Сарая дип дәшмә. Моннан соң аның исеме Сара* булыр. Мин аны мөбарәк кылам. Аңардан синең бер углың туар. Хатыныңны шулкадәр мөбарәк кылам ки, ул күп халык-кавемнәрнең анасы булыр, аның нәсел варислары арасыннан патшалар чыгар».

*Яратылыш 13:14–16; 15:1–6; 17:15–16*

* *Сара* – яһүдчә «байбикә», «ханым» мәгънәсендә.



## Аллаһының өч фәрештәсе Ибраһим янында

Беркөн көндезге челлә вакытында Ибраһим үзенең чатыры янында утыра иде. Шулчакны каршысында басып торган өч юлчыны күрде. Ибраһим аларның Раббы тарафыннан җибәрелгән фәрештәләр булуын аңлап алды. Ул, юлчыларны кабул кылып, аларга табын әзерләде. Ашап-эчкәннән соң юлчы адәмнәрнең берсе Ибраһимга: «Киләсе елны нәкъ менә шушы вакытта яныңа кабат киләчәкмен, – диде. – Ул вакытны инде хатының Сараның бер углы булыр». Сара әлеге сүзләрне ишетеп үзалдына елмаеп куйды. «Картлык көнемдә кая инде миңа андый бәхет-юаныч насыйп булсын», – дип уйлады ул.

Әмма Раббы Ибраһимга: «Сара нигә көлемсереп куйды? Раббы өчен мөмкин булмаган эш бармыни? Киләсе елны билгеләнгән вакытта Мин синең янга килгәндә Сараның бер углы булыр», – диде.

Вакыты җиткәч, Раббы Үзенең сүзләрен гамәлгә ашырды, чөнки биргән вәгъдәсен Ул һәрвакыт үти, һәм Аның өчен мөмкин булмаган эш юк.

*Яратылыш 18:1–19; 21:1–3*



# Сәдүм белән Гамураның һәлакәте

Сәдүм, Гамура, Адма һәм Сәбоим – шушы дүрт каланы күктән иңгән ут-ялкын беркөн тәмам юкка чыгарды. Чөнки әлеге шәһәрләрдә көн күрүче азгын халыкка Раббының ачуы чиксез иде. Аллаһы Ибраһимга Сәдүмне юк итәргә җыенганын әйткәч, Ибраһим Аңардан, гөнаһка баткан ошбу каланы харап итмә, дип ялварды. Раббы аңа, әгәр анда ун гына тәкъва кеше табылса да, шәһәрне юк итмәячәкмен, дип вәгъдә бирде. Әмма Сәдүмдә саф-изге ун кеше дә табылмады.

Шуннан менә нәрсәләр булды: Сәдүм каласында хатыны һәм ике кызы белән тәкъва адәм Лут яши иде. Адәм кыяфәте алган ике фәрештәсен Аллаһы шушы шәһәргә җибәрде. Кич җитеп килә иде. Кунакчыл Лут, юлчыларның фәрештә икәнен белмичә, аларны өенә чакырды.

Кунаклар әле йокларга да ятмаганнар иде, шулвакыт Сәдүмнең бөтен тарафыннан җыелган ир халкы, олысыннан алып кечесенә кадәр, Лутның өен чолгап алды. Лутны чакырып, алар: «Сиңа төн кунарга кергән адәмнәр кайда? – дип сорадылар. – Безнең янга чыксыннар әле». Лут, алар янына чыгып, үз артыннан өенең ишеген бикләп куйды. «Кардәшләрем, зинһар, бу адәмнәргә яманлык кылмагыз, чөнки алар минем кунакларым», – диде ул. Ләкин сәдүмлеләр: «Син үзең дә читтән килгән бер килмешәксең, җитмәсә безне гаепләмәкче буласың. Хәзер без сине кунакларыңа караганда да яманрак эшкә дучар итәбез», – дип, Лутка таба якынлаштылар һәм өйгә бәреп кермәкче булдылар. Әмма фәрештәләр, ишектән кулларын сузып, Лутны өй эченә тартып керттеләр дә ишекне эчтән бикләп куйдылар. Ә ишек каршына җыелганнарны, олысыннан алып кечесенә кадәр, һәммәсенең күзләрен күрмәс иттеләр. Лутка исә фәрештәләр: «Без бу шәһәрне юк итәчәкбез. Монда яшәүче халыкның явызлыклары Раббыга барып ишетелде», – диде. Шуннан алар Лутны һәм аның хатыны белән ике кызын култыклап алдылар да шәһәр читенә алып чыктылар. Шәһәр читенә чыгып җиткәч, фәрештәләрнең берсе Лутка: «Җаныңны коткарыйм дисәң, артыңа борылып карамыйча тизрәк таулар арасына кач», – диде.

Җир йөзенә кояш чыгып килгән вакытта Лут Согарга барып җитте. Һәм Раббы Сәдүм белән Гамура өстенә күктән ут яңгыры



яудырды. Бу шәһәрләрне, анда яшәүчеләрне, бөтен тирә-юньне туфрактагы үсемлекләре белән бергә юк итте. Лутның хатыны исә юлда барганда артына борылып караган иде – шундук тоз баганасына әверелде.

*Яратылыш 19:1–26; Канун 29:23*

## Ибраһимнең Исхакны корбанга китерүе

Ибраһим янында Аллаһының өч фәрештәсе булып киткәннән соң бер ел узгач, Сара ир бала тудырды. Ибраһим аңа Исхак дип исем кушты.

Исхак үсә төшкәч, Раббы Ибраһимнең иманын һәм тугрылыгын сынап карарга булды. «Бердәнбер сөекле улың Исхакны ал да Мориа җиренә юл тот, Мин күрсәткән тауга барып җиткәч, корбанлык учагы өстендә улыңны корбанга китер», – диде аңа Аллаһы.

Аллаһы кушканны үтәү Ибраһим өчен гаять авыр эш иде. Әмма Раббыга ул һичбер каршы сүз әйтмәде, таңнан торып корбанлык учагы өчен утын әзерләде, аны ишәгенә төяп, ике хезмәтчесе белән улы Исхакны ияртте дә Раббы күрсәткән җиргә карап юлга чыкты.

Атасының нинди малны корбан итәргә җыенганын белмәгән Исхак аңардан: «Әтием! Менә утын да, ут та бар, ә корбанлык бәрәне кайда соң?» – дип сорады. «Корбанлык бәрәнен Аллаһы Үзе боерыр, улым», – дип җавап бирде аңа Ибраһим.

Аллаһы күрсәткән урынга килеп җиткәч, Ибраһим үзенең хезмәтчеләрен тау итәгендә калдырды һәм, Исхак белән югары күтәрелеп, корбанлык учагы өчен урын әзерләде, шул урынга утын агачларын тезеп өйде дә кул-аякларын бәйләп Исхакны утын өеме өстенә яткырды. Әмма шулчак Раббының фәрештәсе күкләрдән өн салып аңа: «Ибраһим! Ибраһим! – дип endәште. – Сузылган кулыңны кире ал, улыңа берни дә эшләмә, инде Мин белдем: син Аллаһыдан куркасың, Аны хөрмәт итәсең һәм Минем хакка үзеңнең бердәнбер улыңны да корбан итәргә әзерсең икән. Мин сиңа фатиха өстенә фатиха бирәчәкмен; нәсел варисларыңны күктәге йолдызлар һәм диңгез ярындагы ком бөртекләре санынча ишәйтәчәкмен. Минем өн-авазымны ишетеп, Мине тыңлаганың өчен җир йөзендәге халыкларның һәммәсе синең токымың аша фатиха алачак», – диде.

*Яратылыш 22:1–18*



# Рәбика

Гомер уза торды. Ибраһим инде олы яшьләргә җитеп бик картайды, аның улы Исхак үсеп җитте. Көннәрдән беркөнне Ибраһим, үзенең тугры бер хезмәтчесен чакырып алып, туган җире Хараннан (Месопотамиядән) улы Исхакка хатын алып кайтырга боерды. Кол хезмәтче Харанга, Ибраһимның ир кардәше Нахор яшәгән шәһәргә юл алды.

Барып җиткәч әлеге хезмәтче, Исхакка тәгаенләнгән кызны табарга ярдәм итсен дип, Раббыга дога кылырга тотынды: «Йа Раббы, хуҗам Ибраһим әфәндегә мәрхәмәтеңне күрсәт, мине Исхакка дигән кыз белән очраштыр, – диде. – Менә мин кое янында басып торам, шәһәр кешеләренең кызлары хәзер монда су алырга килер. Шуларның берсенә мин, чүлмәгеңне янтайта төш әле, су эчимче, дигәч, ул, эч-эч, мин синең дөяләреңә дә эчәргә су бирермен, дисә, Исхак колыңа Син насыйп иткән хатын әнә шул булыр. Шуннан мин хуҗам әфәндегә Синең нинди мәрхәмәтле булуыңны белермен».

Юлчы адәм үзалдына шулай сөйләнеп торган арада кое юлында Рәбика күренде. Төскә-биткә чибәр бу кыз, чүлмәгенә су чумырып алып, кайтыр юлына борылды. Ибраһимның хезмәтчесе, кыз каршына йөгереп килеп: «Чүлмәгеңнән бераз су эчимче», – диде. «Эч, әфәндем», – дип җавап кайтарды кыз. Мосафир адәм эчеп туйгач, кыз аңа: «Коедан ташып, дөяләреңә дә туйганчы су эчерим әле», – диде. Хезмәтче, үзенең бу сәфәре Раббының ихтыяры белән эшләнгәнме-юкмы икәнен аңларга теләгәндәй, кызның дөяләр өчен су ташыганына карап, дәшмичә уйланып торуында булды. Аннары ул: «Әйт әле, кем кызы син? Төн кунып чыгар өчен атаң өендә безгә урын булмасмы икән?» – дип сорады. «Ибраһимның кардәше булган Нахор улы Бетуилнең кызы мин», – диде Рәбика. Бу сүзләрне ишеткәч мосафир адәм, җиргә кадәр башын иеп, Ибраһимның кардәше яшәгән йортка китереп җиткергән өчен Раббыга шөкрана кылды.

Бетуилнең өенә килеп җиткәч, хуҗасы Ибраһимның ничек итеп аны, бердәнбер улына хатын алып кайтыр өчен, үзенең туган җиренә, кардәшләре янына сәфәргә җибәргәнен сөйләп бирде. Ата-аналары, кызны чакырып, аңардан: «Син бу кеше белән ки-



тәргә ризамы?» – дип сорадылар. Рәбика риза булды. Шулай ук кызның бөтен гаиләсе дә ризалыгын бирде һәм, Рәбикага үзенең фатихасын күндереп, аны юлга озатты.

*Яратылыш 24:1–60*

## Исхак һәм Рәбика

Ибраһимның хезмәтчесе белән Рәбика, дөяләргә утырып, бик озын юл үттеләр һәм, ниһаять, Исхак яшәгән илгә кайтып җиттеләр.

Беркөнне кичкә таба кырда йөргән чакта Исхак үзенең кәләше килгән кәрванның якынлашуын күреп алды. Рәбика да Исхакны күреп дөя өстеннән җиргә төште, хезмәтче адәмнән: «Кыр буйлап каршыбызга килүче кем ул?» – дип сорады. «Минем хуҗам», – дип җавап бирде хезмәтче, аннары үзе башкарган эшләрне түкми-чәчми Исхакка сөйләп бирде.

Рәбика Исхакның хатыны булды. Раббы аларга ике угыл бүләк итте, аларның берсенә Эсау, икенчесенә Ягъкуб дип исем куштылар. Алар игезәкләр иде, әмма Эсау дөньяга алданрак килде, шуңа күрә беренче бала булу хокукы аңа тиде.

Игезәкләр үсеп җитеп, Эсау кыр-дала кешесе, киек-җәнлек аулауда оста сунарчы булды, ә Ягъкуб чатыр тереклеге белән көн күрүче тыйнак бер адәм иде. Исхак Эсауны яратарак төште, чөнки Эсауның аудан алып кайткан кош итләре бик тәмле була иде. Рәбика исә Ягъкубны якынрак күрде.

*Яратылыш 24:63–67; 25:24–28*



## Ягъкубның Исхактан фатиха алуы

Өлкән яшькә җитеп тәмам картайгач, Исхакның күзләре күрмәс булды һәм ул, әҗәле алдыннан үзенең беренче углы Эсауга фатихасын биреп калдырырга ниятләп, аны үз янына чакыртып алды. Углыннан берәр киек-кош атып кайтуын һәм атасы яраткан ризыкны әзерләп ашатуын сорады. Шуннан соң аңа фатихасын биреп калдырырга вәгъдә итте.

Исхакның әлеге сүзләрен ишетеп калган Рәбика, Ягъкубны чакырып, боларның һәммәсен аңа сөйләп бирде. Яраткан углы Ягъкубның Эсау урынына фатиха алып калуын теләгән Рәбика Исхакны алдарга уйлады: Эсау ауга дип кырга чыгып китүгә, көтүдән ике көр-симез кәҗә бәтие алып кайтырга Ягъкубны җибәрде дә шулардан Исхакның яраткан ризыгын әзерләде. Аннары кече углы Ягъкубка Эсауның затлы киемнәрен кидерде. Эсау бик йонлач адәм булганга күрә, күзләренең нуры кимегән Исхак алай-болай орына калса дип, Ягъкубның төксез-шома beләкләренә һәм муен тирәсенә кәҗә бәтиенең тиресен урады.

Аннары Ягъкуб, Рәбика әзерләгән ризыкны кулына тотып, атасы янына керде һәм: «Атам! Мин бөтенесен дә син кушканча эшләдем. Менә, сунар ите ризыгыннан авыз ит, аннан соң җаның теләгән фатихаңны бирерсең», – диде. «Углым, якынрак килче, капшап карыйсым килә, Эсаумы син, әллә түгелме?» – диде аңа атасы.

Ягъкуб атасының каршына килеп басты. Исхак аны куллары белән капшап: «Тавышы Ягъкубныкы, ә куллары менә Эсауныкы», – дип куйды. Ул аны танымады, чөнки Ягъкубның кәҗә бәтие тиресе чорналган куллары кардәше Эсауныкы кебек үк йонлач иде. Атасы шуннан соң Ягъкуб алып кергән ризыкны сорап алды, ашап туйганнан соң углына фатихасын бирде.

Шул рәвешле, Эсауга тиешле фатиханы хәйлә юлы белән Ягъкуб үзенә алды. Әлеге хәлләрдән соң Эсау, үзенең кардәшен күрәлмас булып, аның гомерен кисәргә ният кылды.

*Яратылыш 27:1–41*



## Ягъкубның төше

Олы углы Эсауның үз туганы Ягъкубны үтерергә җыенганын белгәннән соң Рәбика бу хакта Ягъкубка сөйләп бирде һәм аңа Харанга, бертуганы Лабан янына качып китәргә киңәш итеп, Эсауның ярсуы басылганчы берникадәр вакыт шунда яшәргә кушты.

Ягъкуб юлга кузгалыр алдыннан Исхак аны үз янына чакырып: «Үзебез яшәгән яктан, Кәнган кызларыннан хатын алма, кәләшне Харан якларыннан, әниеңнең туган җиреннән сайлап ал», – дип кисәтеп куйды. Аннары ул, улын фатихалап: «Аллаһы синең юлыңны мөбарәк кылсын, Ибраһимга биргән фатихасын сиңа һәм синнән соң килгән нәсел токымнарыңа да бирсен – син горбәттә гизеп йөргән һәм Аллаһы Ибраһимга тапшырган бу җирләр һәммәсе сиңа мирас булсын», – диде. Шулай итеп, Ягъкуб Харанга карап сәфәр чыкты.

Ягъкуб шулай байтак көннәр юлда булды. Бервакыт ул, ачык һавада төн кунарга тукталып, баш астына бер таш куйды да йокларга дип җиргә сузылып ятты. Һәм төнлә ул Аллаһы кодрәте белән бик матур төш күрде: җир өстеннән югарыга таба бер баскыч сузылган имеш, аның очы күк гөмбәзенә үк тиеп тора. Баскыч буйлап бер менеп, бер төшеп Аллаһының фәрештәләре йөри. Менә баскычта Раббы Үзе күренде һәм әйткән сүзләре ишетелде: «Мин – Раббы, бабаң Ибраһим һәм Исхакның Алласымын! – диде Ул. – Син ятып йоклаган бу җирне Мин сиңа һәм синең нәсел токымнарыңа бирәчәкмен. Мин – синең яныңдамын, кая таба юл тотсаң да, Мин сине саклап барачакмын».

Ягъкуб, йокысыннан уянып, әйтте: «Чыннан да, Раббы шушы җирдә бит, ә мин шуны белмәгәнмен. Хактыр, Аллаһы Йортыдыр бу, күк капусы шушындадыр». Шуннан ул баш астына куеп яткан ташны һәйкәл сыман итеп җиргә утыртты да, Раббыга нәзер әйтеп, болай диде: «Аллаһы, һәрчак минем янда булып, сәфәрем юлында мине саклап барса, ашарыма – ризык, кияремә кием биреп, мин атам йортына исән-имин кабат кайта алсам, шул чакны Раббы минем табынган Аллам булыр, һәйкәл итеп мин куйган бу таш Аллаһы йортына әверелер һәм Син миңа насыйп итәчәк һәр нәрсәнең уннан берен Сиңа бирермен».

*Яратылыш 27:41–46; 28:1–5, 10–22*



## Ягъкубның Рахилә белән очрашуы

Ягъкуб Харан тарафына карап юлын дәвам итте һәм, ниһаять, бик мул көтүлек җирләре, коесы булган урынга килеп җитеп, зур бер таш белән томалап куелган кое авызы янында туктап калды. Көтүләр кое янына тәмам җыелып беткәч, көтүчеләр кое авызындагы ташны бер кырыйга этәреп сарыкларны сугаралар, аннары ташны кабат үз урынына куеп кое авызын томалыйлар иде.

Кое тирәли өч урында тупланган сарык көтүен күреп, көтүчеләрдән Ягъкуб: «Сез Нахор углы Лабанны беләсезме?» – дип сорады. «Беләбез, – дип җавап бирде тегеләр. – Әнә аның кызы Рахилә үзенең көтүе белән бире килә». Ул арада Рахилә үзенең сарык көтүе белән килеп җитте. Атасы Лабанның сарыкларын көтә иде ул.

Әнисенә абый тиешле Лабанның кызын һәм Лабанның сарык көтүен күргәч, Ягъкуб кое янына килде дә, ташны кырыйга этәреп, абзасының сарыкларына су эчерде. Аннары ул, Рахиләне үбеп, шатлыгыннан елап җибәрде һәм кызның якын туганы булуын әйтте. Рахилә исә, өенә йөгереп кайтып, боларны атасына сөйләде. Сеңлесе Рәбиканың углы килгәнне ишеткәч, Лабан тиз генә өйдән чыгып кунакны каршыларга китте, аны кочагына алып үпте, өенә алып кайтты.

Ягъкуб, үзенең абзасы янында яшәп калып, аңарда көтүче булып хезмәт итә башлады. Кызы Рахиләне үзенә хатынлыкка бирсен өчен, Ягъкуб Лабанга җиде ел хезмәт күрсәтте. Рахиләгә гашыйк булганлыктан, бу җиде ел аңа берничә көн кебек кенә тоелды. Лабан Ягъкубка үзенең ике кызын – Лия белән Рахиләне хатынлыкка бирде. Бирeдә, Харанда, Ягъкубның унбер углы һәм бер кызы туды, соңрак Кәнганда аның тагын бер углы дөньяга килде.

Тора-бара Ягъкуб шактый мул тормыш белән яши башлады. Ул инде үз хатыннары һәм балалары белән аерым йорт-гаилә булып гомер итә иде. Хәзер аның бик күп коллары, хезмәтче хатын-кызлары, шулай ук сарыклары, дөяләре һәм ишәкләре бар иде.

*Яратылыш 29:1–28*



## Ягъкубның Аллаһы белән көрәшүе

Көннәрдән беркөнне Ягъкубка Раббы: «Хараннан китеп, үзеңнең туган җиреңә – Кәнган иленә кайт», –дип боерды. Шуннан ул, хатыннарын һәм балаларын ияртеп, бар булган мал-мөлкәтен җыйды да юлга кузгалды. Эсауның ачуы басылганмы, юкмы икәнен белмәгәнгә күрә Ягъкуб, бертуганының күңелен йомшартмакчы булып, аңа байтак кына бүләк җибәрергә карар кылды.

Туган иленә кайтып барышлый Ягъкубның кәрваны беркөн елга буена килеп тукталды. Ягъкуб, сай урында елганы кичеп, бөтен гаиләсен аргы якка күчерде дә берьялгызы бу як ярда торып калды. Шул төнне таң атканчыга кадәр бер адәм аның белән көрәшеп чыкты. Көрәшкәндә әлеге Зат Ягъкубның бот буынын каймыктырды. Таң атып килгәндә, Ягъкубка Ул: «Яктыра инде, җибәр Мине», – диде. Ягъкуб исә Аңа җавап итеп: «Юк, җибәрмим, иң элек Син миңа фатихаңны бир», – диде. Әлеге Зат аңардан: «Исемең ничек синең?» – дип сорады. «Ягъкуб», – дип җавап бирде Ягъкуб. Аның белән Көрәшүче шуннан: «Моннан соң синең исемең Ягъкуб түгел, ә бәлки Исраил* булыр, чөнки син Аллаһы белән көрәштең, кешеләр белән көрәшкәндә син җиңүче булырсың», – диде.

Ягъкуб Аңардан: «Исемең кем соң Синең?» – дип сорады. Әмма Көрәшүче аңа: «Нәрсәгә сиңа Минем исем, ник сорап торасың?» – дип җавап кайтарды, ләкин кем булуын әйтмәде, аннары Ягъкубка Үзенең фатихасын бирде.

*Яратылыш 32:9–31*

* *Исраил* – яһүдчә «Аллаһы белән көрәшкән» мәгънәсендә.



## Ягъкуб белән Эсауның татулашуы

Кәнган җиренә якынлаша башлагач, Ягъкуб каршыга килүче Эсауны һәм аның дүрт йөз кешесен күреп алды. Шуннан Ягъкуб төркемнән аерылып чыкты да туган кардәше Эсауга таба атлады һәм җиде тапкыр җиргә кадәр иелеп итагатен белдерде. Эсау, аның каршысына йөгереп килеп, муенына сарылды, һәм алар икесе дә елап җибәрделәр. Аннары Ягъкубның хатыннары, балалары, хезмәтчеләре Эсау каршына килеп баш иделәр.

«Ни өчен син миңа шуның кадәр күп бүләк җибәрдең?» – дип сорады Эсау Ягъкубтан. «Моннан ары син миңа ачу сакламасын өчен», – дип җавап кайтарды аңа Ягъкуб. «Миндә мал болай да җитәрлек, кардәшем, үз малың үзеңә булсын», – диде Эсау. «Әгәр син күңелеңдә миңа карата ачу сакламасаң, бүләкләремне кабул итеп ал, – дип каршы төште аңа Ягъкуб. – Аллаһы миңа күп игелекләр насыйп итте, минем бар нәрсәм дә җитәрлек». Эсау бүләкне кабул иткәнчегә кадәр ул шулай кыставыннан туктамады.

Аннары Эсау үз йортына әйләнеп кайтты. Ягъкуб исә, Кәнган җирендәге Шәкем шәһәренә исән-имин килеп җитеп, шәһәргә якын урында җир кисәге сатып алды да шунда чатырларын корды; шул җирдә үк Раббы Аллаһыга багышлап корбанлык урыны ясады.

Шулай итеп, Ягъкуб үзенең ир кардәшеннән качып Харанга китеп барган чакта төшендә аңа Аллаһы биргән фатиха тормышка ашты. Раббы аңа биргән вәгъдәләренең барысын да үтәде, шулай ук Ягъкуб та Аңа үзенең рәхмәтләрен күндерергә онытмады.

*Яратылыш 33:1–20*



## Йосыф – Ягъкубның яраткан угылы

Шул рәвешле, Ягъкуб яңадан Кәнган җирләренә кайтып төпләнде. Биредә Рахиләнең Беньямин исемле тагын бер углы дөньяга килде. Хәзер инде Ягъкубның унике углы (Рубин, Шимун, Леви, Яһүдә, Дан, Нәптали, Гәд, Ашер, Исәсхәр, Зәбулун, Йосыф һәм иң кечесе – Беньямин) һәм Динә исемле бер кызы бар иде. Йосыфны исә Ягъкуб бүтән барлык угылларыннан артыграк яратты, чөнки Йосыф аның картлык көнендә туган баласы иде.

Унҗиде яшьлек углы Йосыф үзенең агалары белән берлектә сарыклар көтә һәм агаларының кырын эшләре турында аталарына хәбәрләр җиткереп тора иде. Бервакыт Ягъкуб Йосыфка төрле төстәге тукымадан тегелгән затлы кием бүләк итте. Аталарының Йосыфны ныграк яратуын күргән агалары Йосыфка нәфрәт белән карый башладылар.

*Яратылыш 37:1–4*



## Йосыфның төшләре

Бервакыт Йосыф төш күрде һәм төшен агаларына сөйләде. «Тыңлагыз, мин сезгә күргән төшемне сөйлим, – диде. – Имеш, без барыбыз да кырда көлтә бәйлибез икән. Шулчак мин бәйләгән көлтә җир өстенә туп-туры калкып утырды, ә сез бәйләгән көлтәләр, минем көлтәне уратып алып, аның алдында сәҗдә кылдылар».

Агалары Йосыфка: «Син безнең өстән хаким булмакчымы, безне үзеңә буйсындырмакчымы?» – дип ризасызлык белдерделәр һәм аны тагын да ныграк күрәлмас булдылар.

Йосыф тагын бер төш күрде, аны да агаларына сөйләде: «Менә, мин тагын бер төш күрдем, – диде. – Имеш, кояш, ай һәм унбер йолдыз миңа баш иделәр».

Төшен агаларына гына түгел, атасына да сөйләгәч, атасы ачуланып әйтте: «Нәрсәне аңлата синең бу төшең? Мин, анаң һәм агаларың синең алдыңа килеп баш ияргә тиеш дисеңмени?»

Агаларының Йосыфка ачуы чыкты, аталары исә бу сүзләрне күңеленә салып куйды.

Бервакыт Йосыфның агалары ерак кырларга көтү көтәргә киттеләр, һәм Ягъкуб, агаларың авырмыймы, терлекләр исән-иминме икәнен белеп кайт, дип Йосыфны алар янына җибәрде. Йосыф шатланып юлга кузгалды.

Кырда агаларын эзләп ул бик озак йөрде, аннары, ниһаять, аларны тапты. Агалары исә, Йосыфның якынлашып килүен ерактан ук күреп алып, аны үтерү өчен үзара киңәш-табыш итә башладылар. «Әнә төш хастасы килә, – диеште алар усалланып. – Үтерик тә мәетен берәр чокырга илтеп ташлыйк. Аны ерткыч хайван ашады, дип әйтербез. Шуннан карарбыз, күргән төшләре рас килерме икән!»

*Яратылыш 37:5–20*



## Агаларының Йосыфны коллыкка сатуы

Агалары арасында иң өлкәне, Рубин исемлесе, кардәшләренең кара ниятен ишетеп, Йосыфны алар кулыннан коткарып калырга һәм аны исән-имин хәлдә атасына кайтарып тапшырырга уйлады. Шуңа күрә ул кардәшләрен Йосыфның җанын кыймаска, аны чүлдәге берәр чокырга ташлап калдырырга үгетли башлады. Тегеләр Рубинның сүзенә күнделәр һәм, яннарына Йосыф килеп җитүгә, аның өстендәге төсле-чуар киемен салдырып алдылар да, култыгыннан тотып, сусыз-коры бер коега төртеп төшерделәр. Шулчак товар төяп Мисырга баручы сәүдәгәрләр кәрванын күреп алдылар. Кардәшләрнең берсе, Яһүдә дигәне, Йосыфны сәүдәгәрләргә сатып җибәрергә тәкъдим итте. Бүтәннәр дә аның бу сүзләренә риза булдылар. Кәрванчылар алар янына якынлашкач, Йосыфны коедан чыгарып, сәүдәгәрләргә сатып җибәрделәр.

Сәүдәгәрләр Йосыфны Мисырга алып киттеләр, агалары исә көтүдәге бер кәҗә бәтиен тотып суйдылар да, аның канына Йосыфның киемен манчып, аталарына китерделәр: «Без менә нәрсә таптык, – диде алар. – Кара әле, бу синең углыңның киеме түгелме икән?» Ягъкуб, киемне танып: «Бу – минем углымның киеме, – диде. – Йосыфымны ерткыч хайван ботарлаган булса кирәк!» Угылларының ялган сүзләренә ышанып, яраткан кече углы өчен Ягъкуб күз яше коюдан туктамады.

*Яратылыш 37:21–35*



# Йосыф – сарай хезмәтчесенең йортында идарәче

Мисыр иленә килеп җиткәннән соң сәүдәгәрләр Йосыфны Мисыр фиргавененең сарай хезмәтчесенә, җансакчылар башлыгына коллыкка саттылар. Аллаһы беркайчан Йосыфны Үзенең ярдәменнән ташламады. Шуңа күрә хәтта коллыкта да Йосыфның һәр эше уң булды.

Йосыф алынган һәр эшнең Раббы ярдәме белән көйле баруын хуҗасы Потифар да сизеп алды һәм, Йосыфны үз йортының идарәчесе итеп билгеләп, бар булган мал-мөлкәтен аның карамагына тапшырды. Йосыф хакына дип Аллаһы сарай түрәсенең йортын мөбарәк кылды. Йосыф исә фиргавен хезмәтчесенең йорт-җирендә зирәклек белән идарә итте, шул сәбәпле хуҗасы һичнинди борчу-мәшәкать белмәде.

Күркәм йөзле, мәһабәт буй-сынлы Йосыфка Потифар хатынының гыйшкы төште. Пот-сынга табынучы бу хатын Аллаһыны һәм Аның кушканнарын танымый иде, шуңа күрә Йосыфны ул зина кылырга күндермәкче булды. Әмма хуҗасының хатынына Йосыф: «Хуҗам бар булган мал-мөлкәтен ышанып минем кулга тапшырды, һәм мин нишләсәм дә иреклемен, ләкин сиңа кагыла алмыйм, чөнки син – аның хатыны. Ничек итеп мин Аллаһы каршында шундый зур гөнаһ кыла алыйм?» – дип, аның гыйшкын кире какты.

Читкә тибәрелгән хатын Йосыфтан үч алырга ниятләде һәм иренә: «Йортыбызга син алып кайткан кол гыйбри*, мыскыл итмәкче булып, яныма керде. Әмма мин тавыш куптаргач, кулымда киемен калдырып чыгып качты», – дип, егеткә нахак бәла якты. Бу сүзләрне ишеткәч, Потифарның ачуы соң чиккә җитте, һәм Йосыфны ул патша тоткыннарын яба торган зинданга ташлады.

*Яратылыш 39:1–20*

* *Гыйбри* – еврейләрнең борынгы атамасы.



## Йосыф зинданда

Йосыф зинданга ябылса да, Раббы аның юлдашы булды, мәрхәмәтен ирештереп, зинданбашы күңелендә Йосыфка карата рәхимле караш уятты. Зинданбашы Йосыфны төрмәдәге барлык тоткыннар өстеннән күзәтче итеп куйды. Үзе исә Йосыф кул астында кылына торган эшләрнең һичберсе белән кызыксынмады, чөнки Раббы, Йосыфның юлдашы булып, аның һәрбер эшен уңышлы кыла иде.

Йосыф яткан әлеге зинданга патшаның ике хезмәтчесен дә япкан иделәр. Элек аларның берсе мәҗлесләрдә фиргавен касәсенә шәраб коючы, икенчесе фиргавен табынына ризык китерүче икмәкче булып хезмәт иткән. Мисыр патшасы алдында гаепләре чыгып, алар икесе дә зинданга ябылган иде.

Әлеге шәрабчы белән икмәкченең һәр икесе бер төндә үзенә аерым мәгънәдәге төш күрде, ләкин алар аны ничек дип тә юрарга белмәде. «Төш юрау Аллаһы иркендә түгелме? – диде аларга Йосыф. – Күргән төшегезне сөйләгез әле». Беренче булып үзенең төшен шәрабчы сөйләде. Ул бер йөзем агачы күргән, аның өч ботагы бар икән. Шуннан агачта чәчәкләр күренгән, тиздән җимешләре дә өлгереп җиткән. Шәрабчы агачтан йөзем тәлгәшен алып касәгә сыккан да фиргавенгә биргән.

Йосыф шундук шәрабчының төшен юрап бирде: «Өч ботак – өч көн ул. Өч көннән фиргавен сине элекке урыныңа кире кайтарачак. Электә фиргавеннең шәрабчысы булган кебек, син янә фиргавен касәсен аның кулына биреп тора башлаячаксың. Эшләрең җайлангач, мине дә хәтереңә төшер, игелек күрсәтеп, миңа бу йорттан чыгарга булыш».

Аннары шулай ук икмәкче дә үзенең төшен сөйләп бирде. Аның баш түбәсенә өсте-өстенә өч үрмә кәрзин куелган, имеш. Иң өстәге кәрзин фиргавен өчен төрле нигъмәтләр белән тулган. Әнә шул ризыкларны кошлар чукып-чукып алып китә икән.

Икмәкченең төшен тыңлаганнан соң Йосыф әйтте: «Өч кәрзин – өч көн ул. Өч көннән сине фиргавен чакырып алыр да агачка асып куярга боерыр, һәм күк кошлары килеп синең тәнеңне чукыр».



Раббысы Йосыфка белдергәнчә, өч көн үтүгә һәммәсе нәкъ шулай булды. Тик Йосыфның үзен генә хәтергә төшерүче булмады, баш шәрабчы аны оныткан иде инде.

*Яратылыш 39:21–23; 40:1–22*

# Йосыфның фиргавен күргән төшләрне юравы

Ничектер шулай фиргавен бер төш күрде. Ул елга ярында басып тора, имеш. Шулчак елга суыннан көр-симез бәдәнле җиде сыер чыкты да яр буе камышлыгында утлап йөри башлады. Ул да булмады – алар артыннан судан янә җиде сыер чыкты. Болары гәүдәгә бик тә арык-ябык сыерлар иде. Алар яр буенда утлап йөргән көр-симез сыерлар янына килеп бастылар да тегеләрне ашарга керештеләр Арык-ябык җиде сыер теге көр-симез сыерларны ашап бетергәндә, фиргавен йокысыннан уянды. Аннан ул тагын йоклап китте һәм бу юлы башка бер төш күрде. Имеш, бер сабактан тук-симез орлыклы җиде башак үсеп чыкты. Шуның артыннан ук ач орлыклы, җилләрдән тәмам куырылып беткән янә җиде башак үсеп чыкты да әлеге тук-симез орлыклы җиде башакны йотып-ашап бетерде.

Йокысыннан уянуга фиргавеннең күңеленә шик-шөбһә кереп оялады. Мисырның барлык акыл ияләрен чакыртып, ул аларга үзенең күргән төшләрен сөйләп бирде, ләкин төшләрнең мәгънәсен юрардай кеше табылмады.

Шулчак баш шәрабчы, сүз сорап, зинданда утырган чакта Йосыф атлы яшь бер гыйбри егетнең аңа һәм икмәкчегә төш юрап бирүен һәм юраганнарының дөрескә чыгуын фиргавенгә сөйләп күрсәтте. Фиргавен шундук, Йосыф артыннан кеше җибәреп, аны үз янына чакыртты һәм: «Син төш юрый беләсең дип ишеттем», – диде. Йосыф исә фиргавенгә җавап итеп: «Бу – минем кодрәтемдә түгел. Фиргавенгә хәерле җавапны Аллаһы Үзе ирештерер», – диде. Фиргавен үзе күргән төшләрнең һәр икесен сөйләп биргәч, Йосыф аңа болай дип җаваплады: «Аллаһы алда кыласы эшенең хәбәрен фиргавенгә ирештерә. Җиде симез сыер һәм җиде тук башак – бөтен Мисыр җирендә җиде ел дәвамында бөек муллык чоры булачак дигән сүз. Ә инде җиде арык сыер һәм ач орлыклы җиде башак – җиде ел муллыктан соң киләсе җиде еллык кытлык чоры турында сөйли. Төшнең фиргавенгә ике тапкыр кабатлануы исә Аллаһының әмере хак икәнне күрсәтә, һәм Ул аны тиздән гамәлгә ашырачак».

Аннары, фиргавенгә киңәш итеп, Йосыф болай диде: «Уңдырышлы җиде ел дәвамында Мисыр илендә җитештерелгән бар



азык-төлекнең күпмедер өлешен саклык урыннарында туплый барыр өчен зирәк акыллы бер кешене идарәче итеп билгеләү мәслихәттер».

*Яратылыш 41:1–36*

## Йосыф – Мисыр идарәчесе

Йосыфның юраулары фиргавеннең күңеленә хуш килде. Фиргавен үзенең хезмәтчеләренә: «Аллаһының Рухын үзендә йөрткән мондый кешене тагын кайдан табарга мөмкин?!» – дип әйтеп куйды. Йосыфка исә фиргавен: «Аллаһы сиңа боларның һәммәсен ачып биргән икән, димәк, синдәй зирәк акыллы адәм бүтән юктыр, – диде. – Син минем ил-йортымның идарәчесе булырсың. Бөтен халкым синең сүзне тыңлап эш итәр. Синнән тик минем тәхетем генә бөегрәк булыр. Мин сине бөтен Мисыр җирләре өстеннән идарәче итеп куям!»

Шулай дип, фиргавен үзенең бармагыннан мөһер* йөзеген салып Йосыфның бармагына кигезде; аңа нәфис җитеннән тегелгән киемнәр бирде, муенына алтын чылбыр муенса такты. Аннары ул Йосыфны бөтен Мисыр җире буйлап йөртеп чыгарга боерды. Юлда барганда халык Йосыфны сәламләсен өчен, фиргавен аны дәрәҗәсе буенча икенче саналган арбасына утыртырга кушты.

Йосыф шундук үзенә йөкләнгән вазифаларны башкарырга кереште. Кытлык чоры җиткәч Мисыр халкы ачтан кырылып бетмәсен өчен, җиде ел эчендә һәртөрле игеннән мул уңыш җыеп, шәһәрләрнең саклык урыннарына ул хисапсыз күп азык-төлек туплады.

*Яратылыш 41:37–48*

* Мөһер – печать, штамп.



## Җиде елга сузылган кытлык

Мисыр җирләрендә җиде ел дәвам иткән муллык чоры тәмам булып, алмашка җиде еллык кытлык чоры килде. Бөтен дәүләтләрдә ачлык хөкем сөрде. Йосыфтан икмәк сатып алырга өметләнеп, халык төрле илләрдән Мисырга агыла башлады. Чөнки Йосыф Мисырның бөтен калаларында мул итеп азык-төлек тупларга өлгергән иде.

Мисырда икмәк барлыгын белгәннән соң Ягъкуб, үз янында кече улы Беньяминне генә калдырып, башка угылларының унысын да шунда икмәк сатып алырга җибәрде.

Йосыф исә, Мисырның баш түрәсе сыйфатында, килгән бар халыкка икмәк сата иде. Йосыфның хозурына килгәч ун кардәше итагать белән аңа баш иделәр, аларга икмәк сатуын үтенделәр. Йосыф үзенең агаларын бер күрүдә танып алса да, тегеләр аны танымады. Чөнки Йосыфны коллыкка сатып җибәргәннән бирле аңардан һичнинди хәбәр алганнары булмады; Йосыф шундый дәрәҗәгә ирешкәндер, дигән уй исә аларның башына да килмәде.

Йосыф, кардәшләрен танымаганга салышып, аларга: «Сез монда чик буеның ачык урыннарын күзләргә килгән шымчылар!» – дип гаеп ташлады. Кардәшләре исә аңа: «Без – намуслы кешеләр, бер атаның балалары, безнең әле кече энебез дә бар, ул әтиебез янында калды», – диделәр. Йосыф аларны сак астына алырга боерык бирде. Өч көннән соң агаларына ул болай диде: «Әгәр сез дөрестән дә намуслы кешеләр икәнсез, арагыздан берәү монда калсын, башкаларыгыз ачлыктан интеккән гаиләләрегез өчен моннан икмәк алып китәр. Ә инде сүзегезнең хаклыгын исбатлар өчен кече энегезне минем хозурыма китерегез, шул чагында мин сезнең бу илгә явыз ният белән килмәвегезгә ышанырмын».

Ир туганнар, бу сүзләрне ишетеп, бер-берсенә: «Кардәш энебезгә кылган эшебезнең җәзасын татыйбыз ахры, – диештеләр. – Без аның газапланганын күреп тордык, ул бездән ялвара-ялвара үтенде, әмма без тыңламадык. Инде шул эшебез өчен безгә дә кайгы килде». Йосыф белән тылмач аша сөйләшкәнгә, кардәшләр хәзер Йосыфның бу сүзләрне тыңлап-аңлап торганын белмәделәр. Йосыф, кардәшләре яныннан читкә китеп, елап алды. Аннары янәдән алар янына килде, араларыннан Ши-



мунны аерып алып, аны Мисырда калдырды, башкаларының йөк капчыкларына икмәк тутырттты һәм өйләренә кайтарып җибәрергә боерды.

*Яратылыш 41:54–57; 42:1–25*

## Кардәшләренә Йосыфның үзен танытуы

Өйләренә әйләнеп кайткач, Йосыфның кардәшләре үз башларыннан үткән хәлләрне аталарына сөйләп бирделәр. Картлык көнендә үзенең бердәнбер юанычы булган Беньяминне өлкән угыллары белән бергә Мисырга җибәрергә Ягъкуб һич кенә дә ризалык бирмәде.

Әмма Мисырдан алып кайткан икмәк озакламый ашалып бетте, һәм Ягъкуб үзенең угылларына: «Мисырга барып, аннан тагын бераз икмәк сатып алып кайтыгыз», – диде. Угыллары исә аңа: «Мисыр җиренең идарәчесе безне, янызда кече энегез булмаса, хозурыма килеп тә күренмәгез, дип кисәтте», – диделәр. Беньяминне җибәрергә Ягъкуб һич кенә дә ризалашырга теләмәде. Әмма ачлык көчәйгәннән-көчәя барды. Һәм ул, балаларына хәерле юл теләп, аларга фатихасын бирде. «Кодрәтле Алла ул адәмнең күңелендә рәхим-шәфкать уятсын да, анда тоткарланган кардәшегезне дә, Беньяминне дә ул адәм сезнең белән бергә кайтарып җибәрсен иде», – дип теләкләрен теләде Ягъкуб.

Шулай итеп, кардәшләр, Беньяминне алып, Мисыр җиренә килеп җиттеләр. Беньяминне күргәч, йортындагы икенче бүлмәгә чыгып Йосыф елап алды. Аннары, бит-күзләрен юып, хезмәтчеләренә кунакларны бик шәпләп сыйларга кушты. Йосыфның шулай хөрмәт күрсәтүенә туганнар каушап калдылар. Йосыф исә, күңелендә ташыган уй-хисләрдән үз-үзен тыя алмыйча, кычкырып елап җибәрде һәм кардәшләренә: «Мин – Йосыф бит! – дип белдерде. – Әтием исән-саумы?» Ләкин кардәшләре авыз ачып бер сүз әйтә алмадылар, чөнки алар тәмам аптырап калганнар иде. «Яныма якынрак килегез әле», – диде аларга Йосыф. Кардәшләре якынлашкач: «Сезнең тарафтан Мисырга сатылган Йосыф мин! – дип сүзен дәвам итте. – Ләкин мине монда сатып җибәрүегез өчен хәсрәт чигеп, үкенеп газапланмагыз. Чөнки сезнең гомерләрне саклап калу өчен Аллаһы мине монда фиргавенгә киңәшче ата, аның ил-йорты белән идарә итүче хуҗа, бөтен Мисыр мәмләкәте җирләренә хөкемдар итеп кылды. Тизрәк атам янына кайтыгыз да аңа: „Угылың Йосыф болай диде: Аллаһы мине бөтен Мисыр дәүләтенең җирләренә хөкемдар кылды, вакытны сузмыйча яныма килеп җит; сине монда карап-ризыкландырып торырмын, чөнки



әле тагын биш ел кытлык дәвам итәчәк“, – диегез». Шулай дип, энесе Беньяминне кочагына алып Йосыф елап җибәрде. Аннары, күз яшьләрен түгә-түгә, кардәшләренең һәрберсен кочаклап үпте.

*Яратылыш 42:36–38; 43:1–34; 45:1–15*

# Йосыф янына атасының һәм кардәшләренең килүе

Йосыф янына кардәшләренең килүен ишеткәч, фиргавен аларга юл азыгы, кием-салым, аларның үзләре һәм балалары, шулай ук аталары Ягъкуб өчен җигүле арбалар бирде, чөнки ул аларның барысына да Мисырга күченеп килергә тәкъдим итте.

Өйләренә әйләнеп кайту белән ир туганнар аталары Ягъкубка Йосыф хакында күргән-белгәннәрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр. Яраткан угылы Йосыфның исән булуын ишетүгә аталарына җан керде, һәм угылы белән күрешер өчен ул Мисыр җиренә барырга карар кылды. Шушы хәлләрдән соң Ягъкубка төшендә Аллаһы күренеп: «Ягъкуб! Мин – Аллаһы, атаңның Алласымын! Курыкма, Мисырга күчеп кит! Мин анда синнән бөек бер халык тудырачакмын. Мин Мисырга синең белән бергә барам. Соңра сине аннан алып чыгучы да Мин булырмын», – диде.

Ягъкуб үзенең бөтен балаларын һәм оныкларын ияртеп, бар булган мал-мөлкәтен алып Мисыр тарафына кузгалды. Йосыф та, арбасын җиктереп, атасын каршыларга юлга чыкты. Атасын күрүгә ул атлыгып аның муенына барып сарылды һәм кочагында үксеп-үксеп бик озак елады.

Йосыф янына туганнары күченеп килгәнне ишеткән фиргавен, Йосыфны үз хозурына чакырып алып: «Атаң белән кардәшләрең монда синең янга килгәннәр икән. Бөтен Мисыр иле синең каршыңда – туганнарыңа илнең иң әйбәт җирләрен бир», – диде.

Йосыф шулай үзенең кардәшләрен Мисырда урнаштырды, аларга илнең иң яхшы өлешеннән җир биләмәсе бирде. Йосыф үзенең кардәшләрен һәрдаим икмәк һәм башка кирәк-ярак белән тәэмин итеп торды.

Ягъкуб Кәнган җирләренә кабат әйләнеп кайтмады, шунда Мисыр илендә калды. Әҗәле якынлашкач ул, Йосыф угыллары Менашше белән Эфраимны, аннары үзенең башка угылларын да мөбарәк кылып, һәркайсына үзенең фатихасын бирде. Ягъкубның угыллары аталары әйтеп калдырган боерык-васыятьне җиренә җиткереп үтәделәр: аның җәсәден Кәнган җиренә алып кайтып, Махпела кырында урнашкан ата-бабалар мәгарәсенә, Ибраһим һәм Сара, Исхак һәм Рәбика янәшәсеннән дәфен кылдылар.

*Яратылыш 45 – 50*



## Исраил халкының Мисырда коллыкта яшәве

Байтак еллар узды. Ягъкуб үзе дә, аның барлык угыллары да дөнья куйды.

Кайчандыр, Хараннан Кәнган җиренә таба барган чакта, Ягъкуб Аллаһы белән көрәшә һәм Раббы аңа, Үзенең фатихасын күндереп, Исраил дип, ягъни «Аллаһы белән көрәшкән кеше» дигән мәгънәне аңлатучы яңа исем куша. Шул заманнардан алып Ягъкубның токымын – гыйбриләрне – бүген дә Исраил угыллары дип атый бирәләр.

Вакытлар үтү белән Мисыр тәхетенә Йосыфның зирәклегеннән, ул башкарган игелекле эшләрдән бихәбәр булган фиргавен утыра. Әлеге яңа патша, Мисыр җирендә яшәүче исраилиләрнең күбәеп китүен һәм аларның шактый көчле булуын күреп, үзенең халкына болай дип әйтә: «Әйдәгез исраилиләргә каршы берәр хәйлә корыйк. Югыйсә исраилиләр, тагын да ишәеп, яу-фәлән булган очракта дошманнарыбызга кушылып безгә каршы сугышырга һәм бездән аерылып китәргә мөмкиннәр».

Шуннан фиргавен, исраилиләрне авыр эш белән интектерү максатыннан, алар өстеннән күзәтчеләр билгеләде. Әмма исраилиләрне нинди генә авырлыкларга дучар итсәләр дә, алар артканнан-арта барды. Шуңа күрә мисырлылар аларны рәхимсез рәвештә авыр эшкә җиктеләр, аларның тормышын тоташ газапка әйләндерергә тырыштылар.

Ләкин Аллаһы, Үз халкының зар елавын һәм ачыргаланып кычкыруын ишетеп, алар янына коткаручыны җибәрде.

*Чыгыш 1:6–14*



## Кәрзиндәге сабый

Чамасыз авыр эштән исраилиләр хәлсезләнер, дип өметләнгән фиргавен, аларның тагын да ныграк ишәя һәм ныгый баруын күреп, ир җенесендәге һәрбер яңа туган исраил баласын суга ташларга әмер бирде.

Менә бер исраил хатынының угылы туды. Өч ай дәвамында ул аны яшереп асрады, әмма шуннан ары сабыйны яшереп тотар чара калмагач, бер кәрзинне сумалалап баланы шуңа салды да Нил елгасы буенда үскән камышлар арасына илтеп яшерде. Хатынның олы кызы исә, сабый белән ни-нәрсә булыр икән дип, читтән генә күзәтергә калды.

*Чыгыш 2:1–4*



## Фиргавен кызының Мусаны табуы

Шулвакыт елга буена су коенырга дип үзенең хезмәтче кызлары белән фиргавен кызы килде һәм, камышлар арасындагы кәрзинне күреп алып, бер хезмәтчесенә кәрзинне китерергә боерды.

Кәрзин эчендә елап яткан сабыйны күрүгә үк фиргавен кызы аның исраилиләрдән булуын аңлады һәм, баланы кызганып, аны үзенә уллыкка алырга карар кылды. Шулчак аның янына әлеге сабыйның апасы килеп җитте һәм фиргавен кызыннан, баланы карау-багу өчен сөт анасы кирәк түгелме, дип белеште. Андый хатын кирәк булыр, дигән җавапны ишеткәч, кызый үзенең әнисен алып килде, һәм фиргавен кызы аңа: «Шушы баланы миңа имезепүстереп бир, мин сиңа әҗерен түләрмен», – диде. Хатын, үзенең баласын алып, күкрәк сөтен имезде, аны карады-бакты. Малай бераз үсә төшкәч, ул аны фиргавен кызына алып килде, һәм бала аның углына әйләнде. Фиргавен кызы аңа Муса дип исем кушты.

Муса фиргавен сараенда үсте; мисырлыларча тәрбия алуына карамастан, ул үзенең исраили булуын һичкайчан исеннән чыгармады. Инде үсеп егет булганнан соң Муса бервакыт исраилиләр арасына килеп эләкте һәм аларның ни дәрәҗәдә изелеп яшәвен күрде. Бермәлне ул мисырлы адәмнең үз халкы кешесен – бер гыйбрине кыйнавын күрде һәм, яман ачуы чыгып, теге мисырлыны үтерде дә мәетен комга күмеп куйды.

Икенче көнне Муса, ике гыйбринең сугышуын күреп, аларның берсеннән: «Нигә дип син үзеңнең якыныңны кыйныйсың?» – дип сорады. Теге аңа: «Безне хөкем итәргә синең ни хакың бар? Мисырлы адәмне үтергән сыман мине дә үтерергә җыенмыйсыңдыр бит?» – диде. «Күрәсең, бу хакта кешеләргә мәгълүм булгандыр», – дип уйлады Муса куркуга калып. Әлеге вакыйга турындагы хәбәр фиргавенгә килеп ирешкәч, Мусаны ул үтерергә карар кылды, әмма Муса аңардан качып Мидьян җиренә юл алды. Анда ул, Итеро исемле бер руханины очратып, аның гаиләсендә яшәп калды. Рухани Итеро үзенең Сиппора исемле кызын Мусага кияүгә бирде.

*Чыгыш 2 – 3*



# Янып торган күгән куагы

Байтак еллар дәвамында Муса шулай хатынының атасы Итероның сарыкларын көтте. Бервакыт ул терлекләрне ерак чүлгә алып китте дә Хореб дип аталган Аллаһы тавының итәгенә килеп чыкты. Шунда аның каршында янып торган күгән куагы арасыннан Раббы фәрештәсе пәйда булды. Ялкын телләре чорнап алган куакның янып торуын, әмма янып бетмәвен күреп Муса: «Барып карыйм әле, нинди сәер нәрсә икән ул, ни өчен куак янып бетми икән?» – дип уйлады.

Муса якынрак килде һәм янып торган куак эченнән Раббының: «Муса! Муса! Якын килмә. Аяк киемеңне сал – чөнки син басып торган урын изге җирдер. Мин – синең ата-бабаларың Ибраһим, Исхак һәм Ягъкубның Алласымын», – дигән тавышын ишетте. Муса, Аллаһыга карарга куркып, йөзен каплады.

«Халкымның Мисырда ничек җәфа чигүен күрәм һәм дә аның елау-сыктавын, күзәтчеләрнең газаплавыннан сыкрануын ишетәм, – диде аңа Раббы. – Халкымның авыр кайгысын беләм Мин, шуңа күрә аларны мисырлылар кулыннан азат итәргә барам, аларны шул җирдән алып чыгып, сөт вә бал агып торган уңдырышлы, иркен җирләргә ияртеп китәчәкмен. Исраил угылларының аһ-зарын ишетәм Мин, мисырлыларның аларны ничек изүен дә күреп торам. Шулай итеп, бар: Мин сине фиргавен янына җибәрәм. Син Минем халкымны – Исраил халкын – Мисыр җиреннән алып чыгарсың».

Әмма Муса икеләнеп калды, чөнки андый бөек бурычны үтәргә ул үзен лаек түгел дип саный иде. Шуңа күрә Аллаһыга ул: «Фиргавен катына барып, Исраил халкын Мисыр җиреннән алып чыгар өчен ул кадәр кем соң мин?» – диде. Әмма Аллаһы аңа: «Мин синең янында булырмын», – дип җавап бирде.

*Чыгыш 3:1–12*



## Муса белән Һарун фиргавен янында

Раббы Мусага: «„Аллаһы халкын илеңнән җибәр!” дигән таләп белән Мин сине фиргавен янына озатам», – дигәч, Муса Аңа: «Раббым! Мин телгә оста түгелмен, матур итеп сөйли белмим. Минем урынга башка берәүне җибәр!» – дип җавап кайтарды. «Синең Һарун атлы ир туганың бар түгелме соң? – диде аңа Раббы. – Аның сүзгә оста булуы мәгълүм Миңа. Ни сөйләргә, нәрсәләр эшләргә икәнен исә Мин сезгә Үзем өйрәтермен. Синең урыныңа халык белән ул сөйләшер. Син аның өчен Аллаһы кебек булырсың, ә ул синең исемнән сөйләүче булыр».

Шулай итеп, Муса белән Һарун фиргавен янына килделәр дә болай диделәр: «Исраил Алласы, Раббы: „Минем хөрмәткә бәйрәм ясар вә Миңа багышлап корбаннар китерер өчен халкыма чүлгә чыгарга рөхсәт ит“, – дип әйтте». Әмма фиргавен аларга: «Кем соң ул Раббы, һәм нишләп әле мин аны тыңларга тиеш? Нишләп мин исраилиләргә китәргә рөхсәт бирергә тиеш? Мин Раббыны белмим һәм исраилиләргә китәргә рөхсәт итмим. Ни өчен сез, Муса белән Һарун, халыкны эштән биздереп йөрисез? Барыгыз, эшегездә булыгыз!» – дип җавап кайтарды. Шушы сөйләшүдән соң фиргавен исраилиләргә карата тагын да рәхимсезрәк булды, аларны тагын да күбрәк эшләтергә күзәтчеләргә боерык бирде.

Фиргавеннең күз алдында Раббы байтак могҗизалар кылды, әмма фиргавеннең күңеле йомшармады, Аллаһы халкын ул чүлгә җибәрергә теләмәде.

Раббы бөтен Мисыр халкын тугыз тапкыр коточкыч авыр газапларга дучар итте: Нил елгасының сулары канга әйләнде; бөтен Мисыр җирен гөберле бака басты; тузан бөртеге черкигә әверелде; Мисырда бихисап күп чебен үрчеде; халык вә мал-туар ике куркыныч авырудан – эренле чуан һәм түләмә зәхмәтеннән кырылды; игеннәрне боз сукты; бөтен Мисыр җирен саранча чирүе каплап, басуларны тәмам корытып бетерде; ниһаять, Мисыр иле тоташ караңгылыкка чумды. Әмма фиргавен торган саен рәхимсезләнә генә барды, әлеге бәла-казалардан үзе дә байтак җәфа чигүгә карамастан, Исраил халкына ул китәргә рөхсәт бирмәде. Шул чагында Муса белән Һарун аңа унынчы – иң соңгы җәза белән яный башладылар.

*Чыгыш 4 – 10*



## Котылу бәйрәменә чалынган бәрән каны

Аллаһы кылган искиткеч бөек могҗизаларны һәм Ул җибәргән бөтен бәла-казаларны үз күзләре белән күрүгә карамастан, фиргавеннең күңеле йомшармады. Шул чагында Муса аңа болай диде: «Раббы: „Төн уртасы җиткәч, Мин бөтен Мисыр җире буйлап үтәрмен, һәм һәрбер Мисыр гаиләсендә беренче булып туган ир баланың – тәхеттә утыручы фиргавеннең беренче углыннан башлап ярма тартучы кол хатынның өлкән углына кадәр – һәммәсе үләчәк. Шулай ук терлек-туарның да беренче булып дөньяга килгәне юк ителәчәк“, – дип әйтә».

Ә Исраил халкына исә Раббы, Муса аша, шушы төндә һәр гаиләдә таза-сау һәм кимчелексез сарык бәрәнен суярга кушты. Исраилиләр шул төнне, учакта кыздырылган бәрән итен төче күмәч һәм тәмләткеч үләннәр белән ашап, корбан бәрәненең канын, Аллаһы кушуы буенча, үз йортларының ишек яңакларына вә ишек өстендәге аркылы борыска сөртергә тиеш булалар. «Сезнең йортларга сыланган кан Минем өчен билге булыр. Канны күрүгә Мин сезнең йортларны читләтеп үтәрмен, Мисыр җирен тар-мар китергәндә сезгә бу афәт янамас», – диде аларга Раббы.

Исраил угыллары Аллаһының боерыгын төгәл үтәделәр. Мисырлылар исә кич җитүгә, гадәттәгечә, йокларга ятты, ә төн уртасында һәммәсенең беренче углы дөнья куйды. Шуннан бар кеше төн уртасында йокысыннан уянып аягына торып басты – фиргавен үзе дә, аның барча хезмәтчеләре һәм Мисыр халкы да. Бөтен Мисыр иле ачы күз яшьләре түкте, чөнки әҗәл аяк басмаган бер генә йорт та калмады.

Шул вакыттан башлап Раббы исраилиләр өчен Котылу бәйрәмен (яһүдчә «пейсах») гамәлгә кертә. «Пейсах» дигән сүз «читләтеп үтү» дигәнне аңлата – чөнки мисырлыларны җәзага хөкем иткән чакта исраилиләрнең йортын Раббы читләтеп үтә. Елның елында үткәрелә торган әлеге бәйрәм көннәрендә исраилиләр, үзләренең котылып калуын искә алып, төче күмәч белән бәрән ите ашарга тиеш булалар.

*Чыгыш 11; 12:1–17, 30*



## Раббының исраилиләрне Мисырдан алып чыгуы

Шул ук төнне фиргавен, Муса белән Һарунны чакыртып алып: «Сез үзегез дә, бөтен Исраил халкы да җыенып бездән аерылып китегез, – диде. – Барыгыз, үзегез әйткәнчә, Раббыга гыйбадәт кылыгыз, үзегез белән вак һәм эре терлегегезне дә алып китегез. Юлыгызда булыгыз, ә миңа хәер-фатихагызны бирегез».

Исраилиләр тизрәк җыенып китсен өчен, мисырлылар: «Югыйсә без барыбыз да кырылып бетәчәкбез», – дип, аларны ашыктырып торды.

Исраил халкы Мисыр чикләренә таба юл алды – балаларны исәпләмәгәндә, җәяүле ирләрнең саны алты йөз мең чамасы иде. Алар белән бергә Мисырдан башка халыклардан да бик күп кеше, шулай ук шактый гына вак һәм эре терлек тә китте.

Мисырдан чыкканда үзләре белән алган камырдан исраилиләр төче көлчә пешерделәр – зур ашыгычлык белән киткәнгә күрә, юлга башка төрле ризык әзерләп торырга аларның вакытлары булмады.

Исраил халкы Мисыр илендә барлыгы дүрт йөз дә утыз ел гомер итте.

Аллаһы исраилиләрне Кызыл диңгезгә илтүче сахра юлы белән алып китте. Үзенең халкын кай тарафларга алып барганлыгы бер Раббыга гына мәгълүм иде. Шуңа күрә Ул көндезләрен болыт баганасы рәвешендә алар алдыннан барды, төннәрен исә утлы багана рәвешендә алар барасы юлны яктыртып торды. Болыт баганасы тукталуга исраилиләр чатырларын корып ял итә, багана кузгалуга алар да юлларын дәвам итә иде. Көндезләрен – болыт баганасы, ә төннәрен ут баганасы Аллаһы халкын беркайчан ташлап китмәде.

*Чыгыш 12:31–40; 13:20–22*



## Исраилиләрнең Кызыл диңгезне кичүе

Исраилиләрнең Мисырдан үз Алласына корбан китерү өчен генә түгел, ә бәлки бөтенләйгә китүен аңлагач, фиргавен үзенең бөтен җайдакларын, сугыш арбаларын һәм барча гаскәрен җыеп алар артыннан куа чыкты.

Кызыл диңгез ярына килеп җиткәч, исраилиләрнең барыр урыны калмады, чөнки эзләренә басып диярлек артларыннан мисырлылар килә иде. Каршыларында җәйрәп яткан диңгезне һәм артларыннан куа килүче мисырлыларны күреп, Аллаһы халкы, безне чүл дәрьясында харап итәр өчен генә Мисырдан алып чыккансың икән дип, Мусага гаеп ташлады. Ләкин Муса аларга җавап итеп: «Курыкмагыз! Нык булыгыз һәм шул чагында Раббының сезне ничек итеп коткаруын күрерсез. Эзегезгә басып килүче мисырлыларны исә сез бүтән беркайчан күрмәссез. Сезнең өчен Раббы Үзе көрәшәчәк, тынычланыгыз», – диде.

Аллаһы шунда Мусага диңгез өстенә кулын сузарга кушты. Муса диңгез өстенә кулын сузуга Раббы, көнчыгыш тарафыннан көчле җил кузгатып, диңгез суларын кире чигендерде, һәм исраилиләр каршында диңгезнең бер өлеше коры җиргә әйләнде: диңгез сулары икегә аерылган кебек булды. Исраил халкы диңгезне коры җир буйлап кичте, аларның уң ягында да, сул ягында да диңгез сулары дивар сыман булып торды.

*Чыгыш 14:5–22*



## Мисыр гаскәренең Кызыл диңгездә һәлак булуы

Исраил халкын куа барган мисырлылар шулай ук диңгезгә кереп киттеләр. Аларның гаскәре зур авырлык белән барды, чөнки иртәнге якта Раббы, сугыш арбаларының тәгәрмәчләрен ватып, мисырлылар арасында шактый зур ыгы-зыгы тудырган иде. Шушы хәлне күреп торган гаскәриләр бер-берсенә: «Әйдә исраилиләрдән качыйк, чөнки Раббы алар ягында безгә каршы сугыша», – диештеләр.

Аллаһы халкының һәммәсе, коры җирдән барган сыман диңгезне кичеп чыкканнан соң, Мусага Раббы: «Кулыңны диңгезгә таба суз, барча арбалары вә җайдаклары белән бергә мисырлылар су астында калсын», – диде. Муса Раббы кушканча эшләде, һәм диңгез сулары әүвәлге хәленә кайтып, мисырлыларның барысы дулкын эчендә үзенең әҗәлен тапты.

Әнә шулай итеп Раббы ул көнне Үзенең халкын коткарды. Мисырлыларны һәлакәткә дучар иткән Аллаһының кодрәтен үз күзләре белән күргән исраилиләр, Раббыдан куркып, Аны олыладылар һәм Аңа да, Аның хезмәтчесе Мусага да чынлап торып ышандылар. Шуннан Муса, бөтен халык белән бергә бөек Коткаручыны данлап, тантаналы җыр башкарды:

> Раббы – миңа көч бирүче һәм минем даным; Ул мине коткарды. Ул – минем Аллам, һәм мин Аңа дан җырлыйм. Синең кулың, Раббы, үзенең көче белән дан яулады; Синең кулың, Раббы, дошманны тар-мар итте. Тиңдәшсез зур шөһрәтең белән Син Үзеңә каршы күтәрелгән адәмнәрне юк иттең. Аллаларның кайсысы Синең белән тиңләшә ала, и-и Раббы?! Кем Синең кебек могҗизалар кыла ала, Раббым?! Кем шулай Синең кебек изге?! Һәм кемнең даны шулай куркуга төшерә ала?! Раббы шулай мәңге хакимлек итәчәк.

*Чыгыш 14:23–31; 15:1–18*



## Күктән яуган икмәк

Шуннан соң исраилиләрнең Синай чүле буйлап озакка сузылган сәяхәте башланды, һәм бу сәфәрдә аларны Раббы Үзе әйдәп барды. Әмма озакламый бар халык Муса белән Һаруннан зарланырга тотынды, шушы чүлдә ач үлемнән харап булганчы, Раббы кулыннан Мисыр җирендә һәлак булуың күпкә яхшырак, дип сукранды алар. «Раббыдан зарлануыгызны Ул ишетте. Без нәрсә эшли алабыз соң? Сез бит бездән түгел, ә бәлки Раббыдан зарланасыз», – диде Муса халыкка. Шуннан Мусага Раббы болай диде: «Мин Исраил угылларының аһ-зарын ишеттем. Син аларга Минем сүзләремне әйт: „Кичтән ит ашарсыз, ә иртәгесен туйганчы икмәк белән тукланырсыз һәм шул чагында Мин – сезнең Раббы Аллаһыгыз икәненә төшенерсез“, – диген».

Кичке якта исраилиләр тукталган урынга бер көтү бүдәнә очып төште. Аларны тоту бик җиңел булды, һәм халык туйганчы тәмле ит ашады. Иртәнге якта исә әйләнә-тирәдә мул итеп чык төшкән иде. Чык күтәрелүгә, җир өстендә бәскә охшаган ап-ак бөртекләр ятып калды. Үзенең халкына дип Раббы күктән төшергән икмәк иде бу. Исраилиләр «манна»* дип исем кушкан әлеге ризыкның тәме бал ягылган көлчәне хәтерләтә иде. Раббы аларга икмәкне бер көнгә күпме кирәк булса, шуның кадәр генә җыярга кушты. Әгәр инде кемдер кирәгеннән артык җыя калса, төн эчендә ризык бозыла торган иде. Җомга көнне исә Аллаһы әлеге икмәкне ике көнгә җитәрлек итеп җыярга боерды, чөнки шимбә Раббы тарафыннан билгеләнгән ял көне булып, ул көнне беркем бернинди эш башкармый иде. Бары тик җомга көнне генә ике көнгә дип җыелган ризык бозылмады.

*Чыгыш 16:1–31*

* *Манна* – яһүдчә «нәрсә ул?» дигәне аңлата.



## Мусаның кыядан су чыгаруы

Исраилиләр Рефидим дигән урынга килеп җиткәч, анда эчәргә яраклы суның булмавы ачыкланды. Халык, ачуланып, Мусадан су таләп итәргә тотынды. «Нишләп әле сез мине гаеплисез? Ни өчен сез Раббыны сынайсыз?» – диде аларга Муса; аннары, Аллаһыдан ярдәм сорап, дога кылырга тотынды. Раббы аңа юл таягы белән таш кыяга сугарга әмер бирде. Муса Аллаһы кушканча эшләде, һәм, таш кыядан су бәреп чыгып, бар халык туйганчы су эчте.

Соңыннан Муса әлеге урынны «Массаһ һәм Мериба»* дип атады, чөнки биредә Исраил халкы Мусага гаеп ташлады һәм Раббыны сынап: «Раббы безнең беләнме әллә түгелме?» – диде.

*Чыгыш 17:1–7*

---

* *Массаһ* – яһүдчә «сынау», *Мериба* – «гаепләү» мәгънәсендә.



## Канунның ун кагыйдәсе

Муса – Аллаһы тарафыннан сайланган, Аның тугры һәм тыңлаучан ярдәмчесе булганга күрә, Раббы халык белән һәрчак аның аша сөйләшә торган иде.

Исраил халкы Синай тавы буена килеп тукталгач, Муса тау башына күтәрелде. Анда аңа Раббы зур булмаган ике таш такта тапшырды. Әлеге таш такталарга Аллаһы халкы төгәл үтәргә тиеш булган Ун канун язылган иде:

> Мин – сине Мисырдан, коллык йортыннан коткарган Раббы Аллаһың. Миннән башка синең һичнинди аллаң булмаска тиеш.
>
> Күкләр киңлегендә, җир өстендә яки су астында булган әйберләрнең сурәтләреннән потлар ясама; аларга баш имә һәм табынма.
>
> Раббы Аллаңның исемен кирәксезгә кулланма; әгәр кемдер Раббы исемен урынсызга куллана икән, Раббы аның гөнаһын кичермәс.
>
> Шимбә көннең изге көн булуын исеңдә тот. Алты көн буе эшлә һәм бөтен эшләреңне башкар, җиденче – шимбә көнне исә Раббы Аллаһыңа багышла.
>
> Раббы Аллаһың сиңа бирәсе җирдә гомерең озын булсын дисәң, ата-анаңны хөрмәт ит.
>
> Кеше җанын кыйма.
>
> Зина кылма.
>
> Урлашма.
>
> Якыныңа каршы ялган шаһитлык бирмә.
>
> Якыныңның йортына, хатынына, ир яки хатын-кыз колына, үгез яисә ишәгенә, гомумән, аның малына нәфесеңне сузма.

*Чыгыш 20*



## Алтыннан ясалган үгез бозау сыны

Раббы Синай тау башында Муса белән байтак көннәр сөйләште. Мусаның һаман да таудан төшмәвен күреп, кешеләр Һарун тирәсенә җыелдылар һәм аңа: «Һәрчак безнең белән булсын һәм безне әйдәп алдан барсын өчен безгә алла сыны яса. Чөнки безне Мисырдан алып чыккан Муса белән нәрсә булганын белмибез», – диделәр. Шунда Һарун аларга: «Колактагы алтын алкаларыгызны салып миңа бирегез», – диде. Һәммәсе, алкаларын салып, аңа китереп бирде һәм Һарун, алтыннан үгез бозау сыны коеп, аны кискеч белән эшкәртте. Әлеге үгез бозау сынын күрүгә исраилиләр шатланып: «Менә, Исраил, сине Мисыр җиреннән алып чыккан аллаң шушы булыр!» – дип кычкырып җибәрделәр. Икенче көнне алар таң белән тордылар да үгез бозауга багышлап корбан китерделәр, аны үзләренең илаһы дип атадылар. Аннары халык ашарга-эчәргә, шау-гөр килеп күңел ачарга тотынды.

Тау башындагы Мусага исә Раббы: «Бар, тизрәк түбән төш, чөнки син Мисыр җиреннән алып чыккан халык юньсезләнде. Минем әмерләремне алар бик тиз онытты», – диде. Аллаһы әлеге миһербансыз һәм үҗәт халыкны кырып бетерергә ниятләде, әмма Муса: «Үзеңнең бөек кодрәтең һәм нык кулың белән Мисыр җиреннән алып чыккан халкыңа ачуланма, Раббы. Югыйсә мисырлыларга, тау-таш арасында җаннарын кыяр, җир йөзеннән юк итәр өчен Ул аларны Мисырдан алып чыкты, дияргә юл калдырасың. Ярсуыңны онытып, мәрхәмәт кыл, Үз халкыңны харап итмә», – дип, Аңа ялварырга тотынды.

Мусаның гозеренә колак салып, Раббы Үзенең халкын җәзага тарту ниятеннән кире кайтты.

Муса исә, ачуына түзә алмыйча, кануннар язылган таш такталарны җиргә алып томырды, һәм алар чәлпәрәмә килеп ватылды. Аннары Муса алар ясаган бозау сынын утка салды һәм, алтынны көл хәленә китереп, су өстенә сипте, шуннан соң Исраил халкын шул суны эчәргә мәҗбүр итте.

*Чыгыш 32:1–20*



## Очрашу чатыры

Исраилиләр килеп туктаган урыннан читкәрәк китеп, Муса бер чатыр корды һәм аны Очрашу чатыры дип атады. Раббы белән сөйләшергә теләгән һәр кеше шунда килеп гозерен әйтә алды.

Муса Очрашу чатырына юнәлә калса, бар кеше, үзе яшәгән чатырдан чыгып, Муса чатырга кереп киткәнче аның артыннан карап кала торган булды. Муса чатыр эченә аяк басуга, күкләрдән болыт баганасы төшә иде дә чатыр ишеге төбендә туктап кала иде. Әнә шул вакытта Раббы Муса белән сөйләшә иде. Чатыр ишеге төбендә тукталган болыт баганасын күрүгә, бар халык үзе яшәгән чатыр янында йөзтүбән җиргә каплана иде.

Муса белән Раббы дуслар сыман, йөзгә-йөз карап сөйләшә иде. Муса станга кайтып киткәннән соң, аның яшь ярдәмчесе Нун углы Ешуа һәрчак шул чатырда кала иде.

*Чыгыш 33:7–11*



## Гыйбадәтханә төзү өчен китерелгән бүләкләр

Бервакыт Раббы, Муса аша Үзенең халкына мөрәҗәгать итеп, икенче бер чатыр корырга боерды. Исраилиләр шунда Аллаһы хөрмәтенә корбан китерсен һәм дә Раббы шунда Үзен һәрчак белгертеп торсын өчен кирәк иде бу чатыр.

Муса, бөтен Исраил угылларын җыеп, болай диде: «Раббы менә нәрсә боерды: хәленнән килгәнчә һәркем Раббыга бүләк китерсен. Ул бүләкләр: алтын, көмеш һәм бакыр, зәңгәр, җете кызыл вә кызгылт төстәге йон җеп, нәфис җитен тукыма вә кәҗә мамыгы, кызылга вә зәңгәргә манылган сарык тиресе, сәрви агачы, лампа мае, изгеләндерү мае һәм көйрәтү өчен хуш исле сумала-майлар, руханиларның киемен бизәү өчен ахак һәм башка кыйммәтле ташлар булсын. Шулай ук һәркем, гыйбадәтханә өчен Раббы нәрсә эшләргә боерган булса, хәл кадәре шуны башкарсын».

Муса сөйләгәннәрне тыңлап бетергәннән соң, исраилиләр кирәкле әйберләрне китерергә тотындылар. Очрашу чатырын кору һәм руханилар киемен әзерләү өчен кирәк булган бар нәрсәне кешеләр, йөрәк кушуына буйсынып, Раббыга бүләккә алып килде. Барча ир-ат һәм хатын-кыз Раббыга багышлап үз теләге белән алтын балдакларын, алкаларын, йөзекләрен, төрле бизәнү әйберләрен һәм алтыннан эшләнгән башка әйберләрен бүләк итте. Зәңгәр, җете кызыл вә кызгылт төстәге йон җебе, нәфис тукымасы вә кәҗә мамыгы, кызыл һәм зәңгәр төскә манылган сарык тиресе булган адәмнәр исә шуларны китерде. Күбесе Раббыга бүләккә көмеш һәм бакыр китереп бирде; сәрви агачы булган һәркем, төзелештә шул агачны файдалану өчен, шулай ук аны Раббыга алып килде.

*Чыгыш 35:4–29*



## Чатырны изгеләндерү

Очрашу чатыры тирәли озынлыгы – илле, киңлеге егерме биш метр булган ишегалды ясадылар. Ишегалды бакыр йөгертелгән баганалар белән әйләндереп алынып, аларга пәрдәләр эленде. Озынлыгы – унбиш, иңе – биш һәм биеклеге биш метр булган турыпочмаклы чатырның ишеге көнчыгыш тарафка карый иде.

Эчке яктан чатыр икегә бүленеп, Изге дип аталган зур бүлмәдә хуш исле сумала-майлар яндыру өчен алтын мәзбәх куелды. Мәзбәхнең янәшәсенә алтын өстәл урнаштырып, аның өстенә унике данә икмәк куйдылар. Әлеге икмәкләр Аллаһыга багышланган икмәк, яки изге икмәк дип аталды. Шул ук бүлмәгә алтыннан җиде яктырткычлы кечкенә шәмдәл эшләп куелды. Алгы яктан пәрдә белән аерылган икенче бүлмәгә капкачында ике алтын фәрештә сыны урнашкан алтын сандыкны куйдылар. Әлеге сандыкка Ун канун язылган таш library такталар салынган булып, сандык куелган бүлмә Иң изге бүлмә дип аталды.

Изге бүлмә дип аталган алгы якка руханилар гына керә алса, Иң изге түр бүлмәгә исә елга бер тапкыр баш рухани гына аяк баса алды.

Чатыр төзелеп бетүгә, Муса аны һәм дә анда хезмәт күрсәтергә тиешле руханиларны изгеләндерде. Шуннан соң Раббы шөһрәтенең балкышы чатыр эчен тутырды һәм, чатырны тоташ болыт камап алып, төннәрен ул ут булып янып торды. Чатыр һаман шулай болыт эчендә кала бирде. Кайвакыт болыт аның өстеннән югары күтәрелә иде. Бу исә Аллаһыдан билге булып, халык гүзәл Кәнган җиренә карап юлга кузгала иде, чөнки Раббы аларны Мисырдан шул тарафка таба әйдәп алып барды.

Чатыр тирәсенә халык гыйбадәт кылу өчен җыелганлыктан, Изге Китапта әлеге чатыр шулай ук шаһитлык чатыры һәм очрашу чатыры дип тә атала.


*Чыгыш 40:17–38*



## Күзәтчеләрнең Кәнганга килүе

Бара торгач, исраилиләр, ниһаять, Кәнган җиренә якынлаштылар. Паран чүлендә ял итәргә туктагач, Муса: «Илнең көньягына барып, аның нindirәк җир икәнен, анда нинди халык яшәвен, аның куәтлеме, юкмы икәнен, яшәгән шәһәрләренең ниндилеген белеп-күреп кайтыгыз. Шул җирдә үскән җиләк-җимешләрне алып кайтырга тырышыгыз», – дип, Исраилнең унике ир-егетен Кәнган якларына озатты. Шул рәвешле, унике күзәтче юлга кузгалды һәм кырык көн дәвамында Кәнган җирен карап-күзәтеп йөрде. Кире әйләнеп кайтканда үзләре белән анар һәм инҗир җимеше, башка төрле җиләкләр һәм дә бик зур йөзем тәлгәше алып кайттылар – ул тәлгәшне таякка элеп ике кеше күтәргән иде. Күзәтчеләр әлеге илнең, дөрестән дә, «сөт вә бал агып торган» җирдә урнашуын, андагы халыкның хәйран көчле булуын һәм аларның зур, ныгытылган шәһәрләрдә яшәвен сөйләде. «Без аларга каршы сугышыр хәлдә түгелбез, чөнки әлеге халык бездән көчлерәк», – диде алар.

Аллаһының аларга ярдәм кулы сузарга вәгъдә итүен онытып, күзәтчеләр Кәнган иле турында ялган хәбәр тараттылар, һәм исраилиләр күңелендә курку оялады. Күзәтчеләрдән бары ике кеше, Нун углы Ешуа белән Кәлеб кенә, Раббыга тугрылыгын саклады, халыкны куркуга төшерергә теләмәде. «Без, барып, әлеге илне яулап алырга тиешбез, чөнки безнең кулдан килердәй эш бу», – диде Кәлеб. Әмма халык аның сүзенә колак салмады, һәммәсе еларга, аларны Мисырдан алып чыккан өчен Муса белән Һарунны битәрләргә тотынды. Аннары алар бер-берсенә: «Үзебезгә башка юлбашчы сайлыйк та кабат Мисырга әйләнеп кайтыйк», – диешә башладылар. Нун углы Ешуа белән Кәлеб исә, өсләрендәге киемнәрен ертып ташлап, халыкка болай диде: «Әгәр Раббы безне мәрхәмәтеннән ташламаса, әлеге илгә алып кереп, сөт вә бал агып торган җирләрне безнең кулга тапшырыр. Раббыга каршы килмәгез һәм әлеге җирләрдә яшәүче халыктан курыкмагыз, чөнки алар безнең кулга төшәчәк: аларның яклаучысы юк, ә Раббы исә – безнең якта, курыкмагыз алардан». Муса белән Һарун, халыкның вәсвәсәле сүзләрен ишетеп, борчуга калды. Исраилиләрнең үҗәтлеген һәм ышанмаучанлыгын күрү аларга бик авыр иде. Шуннан Мусага Раббы болай диде: «Тагын кайчанга кадәр бу халык Минем ачуымны китерер икән? Күпме могҗизалар вә төрле галәмәтләр кылуымны



күреп тә, тагын кайчанга кадәр алар Миңа ышанмаслар икән?» Шуннан Раббы, исраилиләрне кырып бетереп, Мусаның үзеннән яңа халык тудырырга әзер булуын әйтте. Әмма Муса, ялынып-ялварып, исраилиләрнең бу зур гөнаһын кичерүен үтенде. Муса хакына дип Аллаһы әлеге буйсынмас халыкны тагын гафу итте. «Әмма, – диде Ул, – Миңа ышаныч күрсәтмәгән өчен исраилиләрнең киләчәк буыны гына, вәгъдә ителгән Кәнган җиренә аяк басып, шунда яши башлар. Хәзерге буыннан исә бары тик Нун улы Ешуа белән Кәлеб кенә анда яши алыр, чөнки алар Раббыга тугрылыгын саклап калды».

*Саннар 13:1–34; 14:1–30*

## Корах, Датан һәм Абирамның җәзага тартылуы

Халык белән идарә итәр өчен Мусаны Үзе сайлап куйганлыктан, Раббы Исраил халкына Муса сүзеннән чыкмаска һәм бөтен нәрсәне ул кушканча эшләргә боерды. Әмма бервакыт исраилиләр арасында чуалыш башланып, Корах, Датан һәм Абирам җитәкчелегендә ике йөз илле кеше Мусага каршы баш күтәрде. Моннан ары алар Мусага буйсынырга теләмәде һәм аны үзен башкалардан өстен куюда гаепләде.

Шушы сүзләрне ишеткәннән соң Муса, Раббы кушканча, бөтен исраилиләргә Корах, Датан, Абирамның чатырларыннан читкәрәк китәргә һәм аларның һичбер нәрсәсенә орынмаска боерды. Аннары Муса болай диде: «Шул рәвешле, мин башкарган бөтен эшнең үз белдегем белән түгел, ә бәлки Раббы кушуы буенча эшләнүен күрерсез: әгәр миңа каршы баш күтәргән бу адәмнәр нинди дә булса гайре табигый хәлгә тарымыйча, барча кешеләр сыман гадәти рәвештә дөньядан китсә, димәк, мине Раббы җибәрмәгән булыр. Әмма Раббы могҗизасы белән әлеге бәндәләрнең аяк астында җир, убылып, аларны барлык мал-мөлкәте белән бергә йота калса, һәм алар тереләй туп-туры үлеләр дөньясына барып эләксә, димәк ки бу кешеләр Раббыдан йөз чөергән, дигән сүз булыр».

Муса шушы сүзләрне әйтеп бетерүгә, Корах яклы булган барлык адәмнәрнең аяк астында җир убылып, аларның һәммәсен йорты-ние, бар мал-мөлкәте белән упкын йотты, һәм алар үзләренең маллары белән бергә тереләй үлеләр дөньясына олакты, җир астында күмелеп калып һәлак булды. Әйләнә-тирәдәге исраилиләр, тегеләрнең сөрәнләп кычкыруын ишеткәч, безне дә җир йотмагае дип, котлары алынып йөгерергә тотынды. Калган ике йөз илле фетнәче өстенә Раббы күкләрдән ут төшереп, алары да дөнья куйды.

*Саннар 16:1–3, 23–35*



## Бакыр елан

Чүл буйлап юлларын дәвам итә торгач халык, төшенкелеккә бирелеп, тагын Аллаһыдан зарланырга тотынды. Кешеләр Мусаны ачуланып: «Нәрсәгә дип Мисырдан алып чыктыгыз безне? Чүлдә әҗәлебезне табар өченме? Монда ни икмәге, ни суы юк, ашарга яраксыз бу ризыктан тәмам гарык булдык инде», – дип сукранды. Аларның аһ-зарын ишетеп, Раббы исраилиләр өстенә агулы еланнар җибәрде, һәм алар кешеләрне чагып үтерә башлады. Исраилиләрнең күбесе, Мусага килеп: «Аллаһыдан һәм синнән зарланып гөнаһ эш кылдык без. Раббыдан ялварып сора, алсын Ул бездән еланнарны», – дип үтенде.

Муса халык өчен ялынып-ялварып сорады, һәм Раббы аңа болай дип җавап бирде: «Бакырдан елан сыны ясa да биек колга башына беркетеп куй, шул чагында елан чаккан һәркем, сурәткә карап, исән калачак». Муса бакырдан зур бер елан сурәте ясады да, колгага беркетеп, югары күтәрде. Елан чаккан һәркем әлеге сурәткә караганнан соң исән кала торган булды.

*Саннар 21:4–9*



## Билгам пәйгамбәр һәм фәрештә

Көннәрдән беркөнне исраилиләр, Үрдүн елгасы буена килеп җитеп, суның аръягындагы Әрихә шәһәре каршында туктап калдылар. Бу җирләрдә мәаб халкы яши иде. Исраилиләрнең күплеген күреп мәабиләр курка калды, һәм аларның патшасы Бәлак, ярдәмгә Билгам пәйгамбәрне алып килергә дип, үзенең илчеләрен җибәрде. Илчеләре аша пәйгамбәргә ул болай дип әйтергә кушты: «Мисыр җиреннән бер халык чыгып янәшәбезгә килеп тукталды; әйләнә-тирәдәге бар җирне басып алган бу халыкның исәбе-хисабы юктыр. Бездән күпкә көчлерәк шул исраилиләргә килеп ләгънәт укы, әгәр син ләгънәтләсәң, мин аларны җиңә һәм үзебезнең җирдән сөреп чыгара алырмын. Син фатиха биргән адәмнең – мөбарәк, син ләгънәтләгән бәндәнең каргалган булуы мәгълүм миңа».

Үзе белән ике хезмәтчесен алып, ишәгенә атланып Билгам юлга чыкты. Кинәт аның ишәге, ялан кылыч тотып юл өстендә басып торган фәрештәне күреп, басуга кереп китте. Ишәген кабат юлга чыгармакчы булып, Билгам аны кыйнарга тотынды. Аннары Раббы фәрештәсе дивар белән әйләндереп алган йөзем бакчалары арасындагы тар юлга килеп басты. Фәрештәне күреп, ишәк диварга килеп терәлде дә Билгамның аягын кысты – Билгам тагын ишәген кыйный башлады. Шуннан фәрештә алгарак узды һәм ишәк уңга да, сулга да борыла алмаслык тар урынга килеп басты. Әмма ишәк фәрештәне кабат күрде дә җиргә сузылып ятты, пәйгамбәр исә малкаен таяк белән кыйный башлады.

Шулчак Раббы ишәккә тел бирде, һәм ул адәм тавышы белән хуҗасына: «Син шулай кыйнарлык нишләдем мин?» – диде. Раббы шунда Билгамның күзләрен ачты, һәм пәйгамбәр дә кылыч тоткан фәрештәне күреп алды. Билгам, иелеп, йөзе белән җиргә капланды. «Нигә син ишәгеңне кыйныйсың? – дип сорады аңардан фәрештә. – Мин бирегә сине туктатыр өчен килдем, чөнки барган юлың Минем алда гадел-хак түгел». «Гөнаһ эш кылдым, мине туктатыр өчен юлга чыгып басканыңны белмәдем. Мин башкарырга җыенган эшне ялгыш гамәл дип табасың икән, кайтыр юлга борылам», – дип җавап бирде Билгам. Фәрештә исә аңа: «Шушы кешеләр белән бар, ләкин Мин сиңа нәрсә әйтсәм, аларга шуны гына сөйлә», – диде.



Билгам килер дә, исраилиләргә ләгънәт укып, алар өстенә төрле бәла-казалар яудырыр, дип өметләнде мәабиләр. Әмма Билгам аларга: «Әгәр Аллаһы Исраилне каһәрләми икән, ничек итеп мин аңа каргыш яудыра алыйм? Әгәр Аллаһы алар өстенә бәла-казалар яудырырга теләми икән, ничек итеп мин Исраилгә хәвеф-хәтәр чакыра алыйм?» – диде. Шуннан Билгам, Исраилгә каргыш укыйсы урында, аны өч тапкыр фатихалады.

*Саннар 22:3–35; 23:7–20*

## Нун углы Ешуа – Мусаның эшен дәвам итүче

Муса шактый өлкән яшькә җиткәннән соң, Аллаһы аның озакламый вафат буласын үзенә алдан әйтеп куйды. Аллаһы халкы көтүчесез калган сарык сыман йөрмәсен өчен, дөнья куяр вакыты җиткәч Муса Раббыдан үз эшен дәвам итәрдәй кеше билгеләвен үтенде.

Раббы Мусага: «Ул кеше – Нун углы Ешуа булсын, аңарда Минем Рухым бар, – диде. – Ешуа өстенә кулларыңны куй да, аны рухани Элгазар вә бар халык каршына бастырып, бөтенесе алдында җитәкчелекне аңа йөклә. Исраил халкы Ешуага буйсынсын өчен вәкаләтеңнең бер өлешен аңа бир. Ешуа бөтен эшне рухани Элгазар белән киңәшеп башкарсын. Элгазар исә жирәбә салып Минем ихтыярымны белер, һәм Ешуа үзе, барлык Исраил угыллары вә бөтен җәмәгатьчелек рухани кушканча гамәл кылыр». Муса һәммәсен Раббы әмер иткәнчә эшләде.

Нун углы Ешуа исә, Аллаһы исраилиләргә Кәнган җиренә аяк басарга ярдәм итәчәк, дип ышаныч белдергән теге ике күзәтченең берсе иде. Ул вакытны алар: «Раббы безнең белән, бу җирдә яшәүче халыктан курыкмагыз!» – дип исраилиләрнең рухын күтәрергә тырышкан иде. Шул вакыйгалардан соң инде байтак гомерләр үтте. Исраил халкы кырык ел буе чүл гизеп йөрде. Мисыр җирен ташлап киткән өлкән буын, шул вакыт эчендә дөнья куярга өлгереп, вәгъдә ителгән Кәнган җирләрен күрми калды. Барысы да нәкъ Аллаһы әйтеп куйганча булды: «Миннән зарланган өчен, яше егермедән узган һәркем, Ифунни углы Кәлеб белән Нун углы Ешуаны санамаганда, шушында – чүлдә әҗәлен табар һәм Мин вәгъдә иткән җирләргә аяк баса алмас. Балаларыгыз турында сез: „Дошман өчен алар җиңел табыш булачак“, – дидегез, әмма Мин аларга шул илгә аяк басарга ярдәм итәрмен, һәм алар сез баш тарткан илне күрерләр. Кылган гөнаһларыгыз өчен сез, шул җирне карап-күзәтеп йөргән кырык көн санынча, кырык ел дәвамында җәфа чигәрсез, бер көн өчен – бер ел. Сездән йөз чөерүемнең нәрсә икәнен аңласын дип эшлим Мин моны».

*Саннар 14:29–31, 34; 27:12–23*



## Киләчәк буыннарга васыять: Раббыны онытмагыз

Муса халыкка болай дип үгет-нәсыйхәт бирде: «Карагыз аны, Раббы Аллагыз кушканча эш итегез: уңга да, сулга да тайпылмагыз. Мирас итеп аласы җирегездә исән-имин озак гомер итәсегез килсә, Аллаһыгыз Раббы кушкан юлдан йөрегез. Исраил халкы, сүземә колак салып тыңла: Раббы, бары Раббы гына безнең Аллаһыбыз. Һәм шул Раббы Аллаһыгызны бөтен йөрәгегез, җаныгыз белән, бар көчегезгә яратыгыз».

«Мисыр җире һәм дә чүл буйлап каңгырып йөргән чагыгызда сезнең хакка Раббы кылган бөек һәм могҗизалы галәмәтләр турында үзегезнең нәсел варисларыгызга сөйләп калдырыгыз», – дип исраилиләрне Муса алдан кисәтеп куйды. Аннары ул балаларны Аллаһының әмерләрен, кануннарын, кушканнарын үтәргә өйрәтергә һәм, чүлдә йөргән чакта исраилиләр сынаган сыман, Раббыны сынамаска кушты. «Карагыз аны, сезне коллык йорты – Мисыр җиреннән алып чыккан Раббыны онытмагыз. Аллаһыгыз Раббыдан куркыгыз һәм бер Аңа гына хезмәт итегез. Әйләнә-тирәгездә яшәгән халыкларга ияреп, аларның илаһларына табынмагыз, юкса Аллаһыгыз Раббының көнчелеге уяныр. Карагыз аны, Аллаһыгыз Раббының ярсуы кузгалып, сезне җир йөзеннән юк итәрлек булмасын. Аллаһыгыз Раббының әмерләрен, сезгә җиткергән кануннарын һәм кушканнарын төгәл үтәгез, Раббы яхшы вә гадел дип тапкан гамәлләр генә кылыгыз».

*Канун 5:32–33; 6:4–25*



## Корбан китерү

Исраил халкына мөрәҗәгать итеп, Муса болай диде: «Раббы Аллаң сиңа мирас итеп биргән җиргә килеп урнашкач, шул җирдән җыеп алган уңышның беренче җимешләрен тырысыңа сал да Раббы Аллаң Үз исеме өчен сайлаган урынга алып бар. Шул көнне анда хезмәт башкаручы руханига килеп: „Сезгә бирермен дип, ата-бабаларыбызга Раббы вәгъдә иткән җиргә мин аяк бастым һәм бүген шул хакта үземнең Раббы Аллама белдерәм. Һәм менә мин, Раббы, Син биргән җирнең уңышыннан беренче җимешләрне китердем“, – дип әйт тә тырысыңны Раббы Аллаң каршына китереп куй, аннары Аңа сәҗдә кыл.

Шуннан соң Аллаһы каршында хезмәт итү өчен сайланган левиләр һәм килмешәкләр белән бергә Раббы Аллаң сиңа вә синең гаиләңә биргән муллыкка куан. Һәр өч ел саен үз җиреңнән алынган бөтен уңышның уннан бер өлешен левиләргә, килмешәкләргә, үксез-ятимнәргә һәм тол хатыннарга бүлеп бир – туйганчы ашасыннар.

Шул көннән Раббы Аллаң сиңа Аның бөтен кушканнарын һәм кануннарын үтәргә боера: аларны ихлас йөрәктән, бөтен күңелеңне биреп башкар. Шул көннән Раббы синең Аллаһың булыр һәм син, Аның юлында йөреп, Аның бөтен кушканнарын, әмерләрен һәм кануннарын үтәргә, Аның сүзеннән чыкмаска Аңа вәгъдә бирдең. Һәм бу көнне Раббы, әгәр син Минем әмерләрне төгәл үтәсәң, Мин, алдан вәгъдә иткәнемчә, сине Үземнең халкым дип игълан итәчәкмен, дип әйтте. Син Аңа дан, хөрмәт вә шөһрәт китерсен өчен, Ул сине Үзе бар иткән бөтен халыклардан өстен куяр һәм, Үзе вәгъдә иткәнчә, син Раббы Аллаң каршында изге халык булырсың».

*Канун 26:1–19*



## Мусаның вафаты

Раббы Мусага Мәаб җирендәге Нәбу тавының Әрихә шәһәренә караган ягына күтәрелергә кушты. Ул аңа, шул тауда үләрсең, дип алдан әйтеп куйган була. Муса тау башына күтәрелгәч, Раббы: «Мин, ант итеп, Ибраһимга, Исхакка һәм Ягъкубка „синең нәсел варисларыңа бирәм“ дигән җир – менә ул. Мин сиңа аны үз күзләрең белән күрергә мөмкинлек бирдем, ләкин син аңа аяк басмассың», – диде.

Раббы колы Муса, Раббы әйткәнчә, шунда җан бирде. Аны Мәаб җирендә, Бәйт-Пигур шәһәре янындагы үзәндә гүргә иңдерделәр, әмма Мусаның кайда җирләнгәнен бүгенге көнгә кадәр берәү дә төгәл белми. Йөз егерме яшенә җитеп дөнья куйган Мусаның әле күзләре дә яхшы күрә, һәм ул элеккечә көчле дә иде.

Мусаны югалткан кайгыдан Исраил угыллары Мәаб тигезлегендә утыз көн дәвамында күз яшьләре түкте. Шул заманнардан башлап Исраилдә, Муса кебек, Раббы белән йөзгә-йөз сөйләшкән, Раббы кушуы буенча Мисыр фиргавене һәм аның хезмәтчеләре, аның бөтен иле каршында төрле могҗизалы галәмәтләр кылган башка бер пәйгамбәр дә булмады. Бүтән бер генә пәйгамбәр дә бөтен Исраил халкының күз алдында Муса кебек шундый кодрәтле һәм гаҗәеп эшләр башкармады.

Нун углы Ешуа исә, Муса аңа кулларын куйганлыктан зирәклек рухы белән сугарылып, Мусаның эшен дәвам итте. Исраил угыллары, аңа буйсынып, һәммә нәрсәне Муса аша Раббы кушып калдырганча башкаруда булдылар.

*Канун 34:1–12*



## Рәхәбнең күзәтчеләрне коткаруы

Муса дөньядан киткәннән соң, Нун углы Ешуага Раббы: «Колым Муса вафаттыр; шулай булгач, әйдә тор да, бөтен халык белән бергә Үрдүн елгасын кичеп, Мин сезгә – Исраил угылларына – тәгаенләгән җирләргә таба юнәл, – диде. – Мусага вәгъдә иткәнчә, аягыгыз баскан бар җирне Мин сезгә бирәм. Беркем беркайчан сиңа каршы тора алмаячак. Һәрчак Муса янында булып, аны саклаган сыман, сиңа карата да шул ук мөнәсәбәттә калып, синнән ваз кичмәм һәм мәрхәмәтемнән аермам. Нык һәм кыю йөрәкле бул, колым Муса калдырган кануннарның һәммәсен җиренә җиткереп, төгәл үтә; кылган гамәлләрең акылга ятышлы булсын, һәр эштә уңышка ирешим дисәң, шушы кануннардан уңга да, сулга да тайпылма».

Исраилиләр үзләре яулап аласы Кәнган җиренә якынайганнан-якыная бардылар. Менә инде зур, ныгытылган Әрихә каласының диварлары да күренде. Нун углы Ешуа үзенең ике күзәтчесен әлеге шәһәргә җибәрде. Алар, Әрихәгә килеп җитеп, Рәхәб исемле хатынның йортында төн кунарга калды. Әрихә патшасына, исраилиләрдән ике күзәтче килеп Рәхәб йортында тукталды, дип хәбәр җиткергәч, патша үзенең хезмәтчеләренә аларны кулга алырга боерды.

Аллаһының исраилиләр хакына төрле могҗизалы гамәлләр кылуын Рәхәб ишетеп белә иде; Әрихә шәһәре исраилиләргә вәгъдә ителгән җирдә урнашканга күрә, Раббының әлеге каланы исраилиләргә бирәсенә Рәхәбнең иманы камил иде. Шул сәбәпле, Аллаһыга өметләрен баглап, күзәтчеләрне ул үз йортында яшерде, ә патша хезмәтчеләренә исә: «Исраилиләр кич белән йортымнан чыгып китте», – диде. Шуннан патша хезмәтчеләре Үрдүн буена илтә торган юлдан аларны куа чыктылар. Рәхәб исә төн җиткәч шәһәр диварында урнашкан йортының тәрәзәсеннән исраилиләрне бау белән аска төшерде. Исраилиләрне эзәрлекләп киткән хезмәтчеләргә тап булмас өчен Рәхәб аларга, тауга күтәрелеп, өч көн буе шунда яшеренеп ятарга киңәш итте.

*Ешуа 1:1–7; 2:1–16*



## Үрдүн елгасын кичү

Әрихәгә барып җитәр өчен Исраил халкы Үрдүн елгасын кичәргә тиеш иде.

Шулвакыт Ешуага Раббы болай диде: «Һәрчак Муса янында булып аны саклаган сыман, сиңа карата да шундый ук мөнәсәбәттә икәнемне исраилиләр күрсен өчен, бүген Мин бөтен Исраил халкының күз алдында синең исемеңне данлы итәм. Аллаһы Килешүе салынган сандыкны күтәргән руханилар Үрдүн суына аяк басуга, аларга туктарга әмер бир». Шуннан Ешуа: «Ошбу җирләрдә көн күрүче кәнгани, хитти, хивви, фәризи, гиргәши, амори вә явүси халкын яшәгән урыннарыннан куып җибәрәчәк Аллаһының сезне ташламаячагын менә ничек белерсез: бөтен җир йөзенең Хуҗасы булган Раббының Килешү сандыгын сездән алда Үрдүн аша алып чыга башларлар; сандыкны күтәреп баручы руханилар елгага аяк басуга Үрдүн сулары, агудан туктап, дивар сыман булып туктап калыр», – диде. Сандыкны күтәргән руханилар Үрдүн суына керә башлаганнар иде (уракка төшкән бу көннәрдә Үрдүн елгасы һәрвакыттагыча гаять мул сулы булып, хәтта ярларыннан ташып чыккан иде), елганың югары агымындагы сулар туктап калды, ә шул урыннан түбәнрәк, Адама шәһәренә кадәр шактый зур арадагы сулар диңгезгә агып бетте.

Шуннан Исраил халкы корып калган елга төбеннән Үрдүн аша чыга башлады. Халык елганы кичкән чакта руханилар, кулларына Аллаһы Килешүе салынган сандыкны күтәргән килеш, сусыз калган елга уртасында басып тора бирделәр. Әлеге могҗизаның истәлеге итеп Нун углы Ешуа исраилиләрнең уникесенә руханилар басып торган җирдән берәр таш алырга кушты. Бар халык Үрдүнне кичеп чыкканнан соң, Ешуага Раббы: «Сандыкны күтәргән руханиларга елгадан чыгарга әмер бир», – диде. Руханилар ярга чыгуга, су кабат үз юлыннан агып китте.

Үрдүннән алынган унике ташны исә Ешуа Гилгәл дип аталган җиргә куйдырды.

*Ешуа 3:7–17; 4:1–24*



# Әрихәне яулап алу

Исраилиләр Әрихә каласы янына килеп җиткәч, Әрихә патшасы шәһәр капкаларын ябарга әмер бирде. Әмма Нун углы Ешуага Раббы: «Әрихә үзе, аның патшасы һәм сугышчылары – һәммәсе синеке булыр, – диде. – Синең коралланган ир-егетләреңнең бөтенесе, Аллаһы Килешүе салынган сандыкны күтәреп, көн дә бер тапкыр шәһәр диварлары тирәли әйләнеп чыксын; алты көн дәвамында шулай кабатлансын. Сандык алдыннан быргы күтәргән җиде рухани барсын. Җиденче көнне руханиларның быргы тавышлары астында шәһәр тирәли җиде кат әйләнеп чыгыгыз. Иң зур быргы тавышын ишетүгә, бар халык сөрән салып кычкырырга тотынсын – шулвакыт кала дивары нигезенә кадәр җимерелеп төшәр, һәм сез шәһәргә керерсез».

Төркем алдыннан кораллы сугышчылар барды, алар артыннан исә, быргыларын кычкыртып, руханилар атлады; төркемнең азагында да кораллы сугышчылар иде. Ешуа: «Сөйләшмәгез, беркем бер сүз катмасын, мин „Кычкырыгыз!“ дип әйткәнгә кадәр берегезнең дә тыны чыкмасын. Рөхсәт биргәннән соң – сөрәнләгез», – дип халыкны алдан кисәтеп куйды. Шулай итеп, исраилиләр Аллаһы Килешүе салынган сандыкны күтәреп шәһәр тирәли бер тапкыр әйләнеп чыктылар да станнарына әйләнеп кайттылар. Икенче көнне дә нәкъ шул рәвешле дивар тирәли әйләнеп чыктылар. Алты көн дәвамында алар шулай эшләделәр. Ә инде җиденче көнне, сандыкны җиденче мәртәбә шәһәр тирәли алып китеп, руханилар быргыларын кычкырта башлауга, Ешуа халыкка: «Кычкырыгыз, Раббы шәһәрне сезнең кулга тапшыра!» – дип боерды. Быргы тавышларын ишетүгә, бөтенесе бар көченә кычкырырга тотынды, һәм кала дивары нигезенә кадәр җимерелеп төште. Халык төрле яклап шәһәргә керде, һәм кала яулап алынды.

Теге вакытта Әрихәгә күзәтче булып килгән ике исраили үзләрен качырган Рәхәбне, аның туган-тумачасын коткарырга вәгъдә иткән була. Исраилиләр шәһәргә аяк басуга, Рәхәб тәрәзә борысына кызыл төстәге бау бәйләп куярга тиеш дип килешәләр. Рәхәб нәкъ шулай эшли дә: аны туганнары белән бергә шәһәрдән алып чыгалар, Әрихә каласына исә ут төртәләр.

*Ешуа 6:1–24*



## Аморилəр белəн сугыш

Бервакыт Гибгон дип аталган җирдə исраилилəр белəн дошманнары аморилəр арасында зур бəрелеш булды. Сугыш башланыр алдыннан Нун углы Ешуага Раббы: «Курыкма син алардан, чөнки аларның язмышын Мин синең кулга тапшырдым: алар арасыннан берəү дə сиңа каршы тора алмаячак», – дип əйтеп куйды. Ешуа җитəкчелегендəге Исраил гаскəрлəре, төн куенына сыенып, станнан чыкты да һич көтмəгəндə аморилəргə һөҗүм итте. Исраилилəрне күрүгə аморилəр, Раббы ихтыяры буенча, тəмам каушап калдылар. Əлеге бəрелештə исраилилəр, аморилəрне тар-мар китереп, Бəйт-Хорун тавына илтүче юл буйлап аларны Азыка һəм Маккеда шəһəрлəренə кадəр куа бардылар.

Əмма җиңү аларга тиз һəм җиңел генə бирелмəде: ул көнне сугыш озакка сузылды. Шуны күреп Нун углы Ешуа, кояш баеп көн тəмамланмасын өчен, Раббыга ялварырга тотынды һəм исраилилəр күз алдында: «Кояш, Гибгон өстендə туктап тор! Ай, син дə Айалун үзəнендə туктап кал!» – дип кычкырып җибəрде. Кояш белəн ай туктап калды һəм исраилилəр үзлəренең дошманнарын тар-мар иткəнчегə кадəр урыныннан кузгалмады. Сугыш беткəннəн соң Нун углы Ешуа гаскəре, җиңү яулап, үзенең станына əйлəнеп кайтты.

Адəм баласының гозеренə җавап итеп, Раббы кодрəте белəн шулай кояшның, көнбатышка таба барышы тукталып, күк йөзендə хəрəкəтсез калганы моңарчы да, аннан соң да булмады. Ул көнне Үзенең халкы өчен Аллаһы Үзе көрəште.

Нун углы Ешуага Аллаһы: «Мин сиңа нык вə кыю йөрəкле булырга боерам, бернəрсəдəн курыкма һəм һичнəрсəдəн котың алынмасын, чөнки кай тарафка юнəлсəң дə, Раббы Аллаң янəшəңдə булыр», – дип əйтеп куйган була; əлеге сүзлəрне Ул шулай ук Аңа иман китергəн һəрберебезнең колагына төбəп əйтə.

*Ешуа 1:9; 10:6–15*



# Исраил хөкемчеләре

Исраилиләр килгәнчегә кадәр Кәнганда төрле мәҗүси халыклар: хиттиләр, гиргәшиләр, аморилəр, кәнганиләр, фәризиләр, хиввиләр һәм явүсиләр яши. Әлеге халыкларны кайвакыт кәнганиләр дип кенә атыйлар. Бихисап күп гөнаһлары өчен Раббы әлеге кәнганиләрне кырып бетерергә карар кыла. Кәнганиләрнең төп илаһлары Багал һәм Аширә булып, Багалга табыну, гадәттә, әдәпсез, котырынкы мәҗлесләр белән тәмамлана торган була. Багалга табына торган калкулыкларда корбан китерү йолалары башкарыла, анда хәтта кешеләрне дә корбанга китерә торган булалар.

Шулай итеп, исраилиләр Кәнган җирләренә килеп урнашалар, әлеге илнең чикләре үз эченә хәзерге Фәләстин (Исраил дәүләте) һәм Үрдүн елгасыннан көнчыгыштарак булган кайбер җирләрне ала. Муса шушы җирләрне Исраилнең унике нәсел тармагына – Ягъкубның унике угылының унберенә бүлеп бирә. Болар: Рубин, Шимун, Яһүдә, Дан, Нәптали, Гәд, Ашер, Исәсхәр, Зәбулун, Йосыф (Йосыф ыругы үз чиратында тагын икегә – аның угыллары Эфраим белән Менашше ыругына бүленә) һәм Беньямин нәселләренең варислары. Тагын бер ыругка – левиләргә җир өлеше бирелми: чөнки алар, Аллаһы каршында хезмәт итәр өчен сайланган нәсел булып, Исраилнең башка ыруглары урнашкан шәһәрләрдә яшиләр.

Кәнганга килеп урнашканнан соң 300–400 ел дәвамында әле бу унике Исраил ыругында бердәм хакимият булмый. Әлеге халыкны күк һәм җирне яраткан, бар вә бер Аллаһыга булган иман гына берләштереп тора. Шулай булуга карамастан, вакыт-вакыт алар пот-сыннарга табыналар, күрше халыкларның илаһларына баш иеп, Аллаһы әмерләреннән тайпылалар. Кылган җинаятьләре һәм башка илаһларга табынган өчен Раббы, исраилиләргә ачуланып, аларны әледән-әле җәзага тарта: Исраил белән һаман сугышып торган дошманнары – мәабиләр, аммониләр, амалыкыйлар, пелештиләр, кәнганиләр, мидьяниләр – Исраил халкын талый һәм коллыкка алып китәләр. Әлеге халыкларның кул астында калган исраилиләр, байтак җәбер-золымнарга дучар булып, коткаруын сорап Аллаһыга мөрәҗәгать итәләр. Раббы, мәрхәмәтен күрсәтеп, аларның үзләре арасыннан хөкемчеләр билгели һәм әлеге хөкемчеләр халыкны дошман кулыннан азат итәләр. Әмма хөкемчеләр дөньядан китүгә, халык яңадан пот-сыннарга табына, әүвәлгегә



караганда да яманрак гамәлләр кылып, тагын Раббының ачуын чыгара торган була.

Исраил хөкемчеләре вазифасын түбәндәге кешеләр башкара: Отниел, Эһуд, Шамгар, пәйгамбәр хатын Дебора, Барак, Гидеон, Әбумәлик, Тола, Яһир, Ифтах, Ивсан, Элон, Абдун, Шимшон һәм Шемуил. Ошбу китапта без аларның кайберләре турында гына сөйләп үтәрбез.

Шулай итеп, ул вакытларда Исраилдә патша булмаган, һәркем бар нәрсәне үзе дөрес дип тапканча эшләгән.

*Хөкемчеләр*

## Гидеон

Нун углы Ешуаның вафатыннан соң исраилиләр, пот-сыннарга табынуларын дәвам итеп, һаман саен Аллаһының ачуын чыгара тордылар. Бервакыт Раббы шуның өчен аларны җәзага тартты: Исраил халкы ул чакны мидьяниләргә коллыкка төшкән иде. Мидьяниләр кул астында җәбер-золым күреп яшәү исраилиләргә гаять авыр иде, һәм коллыкка төшүләренең җиденче елында исраилиләр, коткаруын сорап, Аллаһыга мөрәҗәгать иттеләр. Аларның сүзе Раббыга килеп иреште, һәм Ул аларга җитәкче итеп Гидеон исемле бер адәмне билгеләде.

Гидеон үзен көчлеләрдән санамый иде, ләкин Аллаһы аңа: «Мин янәшәңдә булырмын, һәм син мидьяниләрнең бөтенесен бер кешене җиңгән сыман кырып салырсың», – диде. Шуннан Раббы Гидеонга атасының Багал илаһ хөрмәтенә салдырган корбанлык урынын җимерергә боерды. Гидеон үзенең ун хезмәтчесе белән бергә Багал илаһ хөрмәтенә корылган корбанлык урынын җимерде һәм аның янәшәсендәге изге дип аталган агачны чабып ташлады. Аннары Раббыга багышлап яңа корбанлык урыны төзеде һәм Аллаһы хөрмәтенә шунда корбан китерде. Шуннан соң, Гидеонга Раббы Рухы иңеп, ул Исраил дошманнарына каршы күп санлы гаскәр тупларга кереште. Сугышка керер алдыннан Гидеон, исраилиләрне коткару өчен Аллаһының дөрестән дә аны сайлавын белмәкче булып, Аңардан берәр билге бирүен үтенде. Һәм Раббы Гидеон сораган дәлилләрне күрсәтте: төнгелеккә ындырда җәеп калдырган сарык йонына иртәнге якта чык төшеп, әйләнә-тирәдә бөтен җир коры калган иде; ә икенче төнне, киресенчә, бөтен җир чык белән капланып, йон коры калган иде.

Гидеон үзенең сугышчылары белән мидьян гаскәрләре каршына килеп баскач, Раббы аңа әйтте: «Синең сугышчыларың артык күп, һәм исраилиләр соңыннан: „Без җиңдек“, – дип масаеп китмәсен өчен, мидьяниләрне алар кулына тапшыра алмыйм. Кыскасы, халыкка: „Куркаклар һәм йөрәксезләр өйләренә кайтсын“, – дип әйт». Гидеон нәкъ шулай эшләде, һәм егерме ике мең гаскәри өенә кайтып китте, ун меңе – калды. Әмма Раббы халыкның әле дә күп булуын әйтте һәм Гидеонга, сугышчыларны елга буена алып килеп, кемнең ничек су эчүен күзәтергә кушты. Гаскәриләрнең күбесе ярга килеп тезләнде дә туп-туры елгадан эчәргә тотынды. Бары тик өч



йөз кеше генә суны кушучына алып эчте. «Кушучыннан эчкән әнә шул өч йөз сугышчы сезгә котылу алып килер – мидьяниләрне Мин сезнең кулга тапшырырмын», – диде Гидеонга Аллаһы.

Бөтенесе нәкъ шулай булды. Раббы гаҗәеп бер могҗиза кылды: өч йөз Исраил сугышчысы саранча чирүедәй бихисап күп мидьяниләр белән амалыкыйларны җиңеп чыкты.

*Хөкемчеләр 6 – 7*

## Шимшон баһадир

Аллаһы күрсәткән могҗизаларга, Аның мәрхәмәтенә һәм ярдәменә карамастан, исраилиләр, Раббы юлыннан тагын читкә тайпылып, Аның күзенә ятышсыз күренгән гамәлләр кылдылар. Шуның өчен алар, бу юлы инде пелештиләргә әсир төшеп, кырык ел дәвамында аларга буйсынып яшәделәр. Исраилиләр әсирлектә гомер сөргән заманда Раббы алар өстеннән хөкемче итеп Шимшон дигән бер кешене билгеләде. Әлеге адәм гаҗәеп көчкә ия булып, аның бар гайрәте чәчендә тупланган иде. Шимшон әле анасының карынында чакта ук Аллаһы аның ата-анасын, баланың чәченә пәке тидермәгез, чөнки ул Аллаһы нәзире («Аллаһыга багышланган») булачак, һәм нәкъ менә ул Исраилне пелештиләрдән азат итәр өчен көрәш башлаячак, дип кисәтеп куйган була.

Шимшондагы көч-куәт шулкадәр зур иде ки, бервакыт ул каршысына килеп чыккан арысланны кәҗә бәтиедәй ботарлап ыргытты. Икенче бер вакытны ишәкнең казналык сөяге белән бер көн эчендә мең пелештинең башына җитте. Иң нык арканнарны һәм богауларны ул җиңел генә өзә торган иде.

Беркөнне Шимшон, Газа шәһәренә килеп, шунда төн кунарга калды. Аның шәһәргә килгәнен белеп алган пелештиләр шәһәр капкасын бикләделәр дә, аны үтерергә ниятләп, яшеренеп таң атканны көтә башладылар. Төн уртасында Шимшон уянды һәм шәһәрдән китәргә уйлады. Бикләп куелган шәһәр капкасын ул баганасы-биге белән бергә җирдән умырып чыгарды да җилкәсенә салып тау башына менгереп куйды.

*Хөкемчеләр 13:1–5; 14:5, 6; 15:14, 15; 16:1–3*



# Шимшонның һәлакәте

Шимшон егерме ел дәвамында Исраил хөкемчесе булып торды. Шул гомер эчендә ул үз халкының дошманы булган пелештиләргә байтак борчу-мәшәкать китерде. Пелештиләр Шимшонның җанын кыярга теләсәләр дә, аның көче нәрсәдә икәнне белмәгәнгә баһадирга һични кыла алмадылар.

Бервакыт алар Шимшон яратып йөргән Далила исемле хатыннан Шимшонның көче нәрсәдә икәнне белешергә үтенделәр. Далила аңардан өч тапкыр сорашып караса да, Шимшон аңа чын дөресен әйтергә теләмәде. Далила, көннең-көнендә аңардан серне ачуын ялварып, үзенең сораулары белән Шимшонны тәмам интектереп бетерде. Күңелен басып торган авырлыкка түзә алмыйча Шимшон, ниһаять, аңа серне ачты: «Әгәр чәчемне кырсалар, минем көчем бетәчәк, һәм мин башка кешеләр сыман булып калачакмын», – диде ул.

Әлеге сүзләрне ишеткәннән соң, Далила аны йокларга яткырды да пелештиләрне чакырды. Тегеләр Шимшонның чәчен кырып алдылар, һәм чәч белән бергә баһадирның Раббыдан бирелгән көче дә китте.

Шуннан пелештиләр аны, ике бакыр зынҗыр белән богаулап куеп, күзләрен чокып чыгардылар да тоткыннар йортында ашлык тартырга мәҗбүр иттеләр. Әмма вакытлар узу белән Шимшонның чәче үсә башлады, һәм чәче белән бергә аңа әкренләп көч-гайрәте дә әйләнеп кайтты.

Бервакыт шулай пелештиләр үзләренең илаһларына корбан китерергә җыйналып: «Күпме кешебезне харап иткән, җирләребезне бөлдереп-корытып бетергән дошманыбыз Шимшонны безгә илаһларыбыз тотып бирде», – дип илаһларына мактау яудырырга тотындылар. Кәефләре күтәрелеп киткәч алар: «Шимшонны чакырыгыз! Күңелебезне ачсын әле!» – дип кычкырырга керештеләр. Шимшонны китерделәр һәм аны бинаның урта бер җиренә, баш өстендәге түбәне тотып торган ике багана арасына китереп бастырдылар. Шунда Шимшон: «И-и Раббы Аллам! Мине хәтереңә төшереп, тагын бер генә мәртәбә көч-куәт бирче, и-и Аллам! Ике күзем өчен берьюлы пелештиләрдән үч алыр идем!» – дип Аллаһыга ялварып дәште һәм йортны тотып торган баганаларның икесен дә урыныннан кузгатып: «Пелештиләр белән бергә



үзем дә үлим!» – дип кычкырды һәм баганаларны бөтен көченә этеп җибәрде; йорт, тоташтан җимерелеп төшеп, һәммәсе шунда әҗәлен тапты.

*Хөкемчеләр 16:14–30*

## Рут белән Нагомия

Яһүдә җире белән хөкемчеләр идарә иткән бер заманда илгә зур кытлык килде, һәм шул сәбәпле Әлимәлик атлы бер исраили, хатыны белән ике углын ияртеп, үзе яшәгән Бәйт-Лехем каласыннан Мәаб җиренә күченеп китте (мәабиләр Үле диңгездән көнчыгыштарак яши иде). Аның хатыны – Нагомия, угыллары исә Махлон һәм Кильйон исемле иде.

Көннәрдән беркөнне Әлимәлик вафат булып, Нагомия үзенең ике угылы белән тол калды. Угыллары үзләренә хатынлыкка Мәаб кызларын алды: аларның берсе – Өрпә, икенчесе Рут исемле иде. Алар шулай бергәләп ун ел чамасы гомер кичергәннән соң, Нагомиянең угыллары да дөнья куйды, һәм ул бөтенләй ялгыз калды. Аллаһының, Үз халкын кайгыртып, Яһүдә илендә мул уңыш үстергәнен һәм кешеләрнең икмәккә туенганын ишеткәннән соң, Нагомия үзенең туган җиренә кайтырга ниятләде.

Шулай итеп ул, Мәаб җирен калдырып, туган якларына юл алды, аның артыннан ике килене дә иярде. Кайтып барганда Нагомия үзенең киленнәренә: «Барыгыз, ата-аналарыгыз янына әйләнеп кайтыгыз. Угылларыма һәм минем үземә карата сез игелекле булдыгыз, шуның өчен Раббы сезне рәхмәтеннән ташламасын. Раббы кушып, сезнең һәр икегезгә үз тиңе белән яңа тормыш корырга язсын», – дип аларны үпте. Аның бу сүзләрен ишетеп, киленнәре елый башлады. «Юк, без синең белән халкың янына барабыз», – диде алар. «Юк, кызларым, кирәкмәс; мин сезне кызганам, чөнки Раббы миңа бер-бер артлы бәла-казалар җибәрә», – дип, Нагомия үз дигәнендә торды. Киленнәре яңадан еларга тотынды; шуннан Өрпә, кайнанасы белән хушлашып, китеп барды, Рут исә Нагомия янында калды. «Сине калдырып кире әйләнеп кайтырга үгетләмә мине, – диде ул, – син кайда барсаң – мин синең белән барачакмын, син кайда яшәсәң – шунда яшәячәкмен. Синең халык – минем халкым, синең Аллаң – минем Аллам булыр. Син кайда вафат булсаң, мин дә шунда үләрмен, һәм мине шунда җирләрләр. Раббы миңа нинди генә җәзалар җибәрсә дә, мине синнән бары әҗәл генә аера алыр». Килененең үз дигәнендә нык торуын күреп, Нагомия аны үгетләүдән туктады.

*Рут 1:1–17*



## Рутның Богаз басуына килүе

Нагомия белән Рут, ниһаять, Бәйт-Лехемгә килеп җиттеләр, һәм аларны күреп шәһәр халкы хәйран калды, бар кеше бер-берсеннән: «Чынлап та Нагомияме соң бу?» – дип сорашты. Нагомия исә аларга болай дип җавап бирде: «„Мөлаем“ дигәнне аңлатучы Нагомия урынына миңа „аянычлы“ мәгънәсен белдергән Мара исеме белән дәшсәгез иде, чөнки Кодрәт иясе мине зур хәсрәткә дучар итте: мин биредән күпме мал-мөлкәт белән чыгып киткән идем, Раббы исә мине буш кул белән кайтарды».

Беркөнне Рут, Нагомиягә туган тиешле Богазның басуына барып, уракчылар артыннан коелып калган башакларны җыярга тотынды.

Басу хуҗасы, әлеге яшь хатынның кайнанасы Нагомияне карап-багар өчен чит җиргә күченеп килүен белгәч, Рутны чакырып алды һәм аңа көн дә басуына килергә рөхсәт бирде, үзенең хезмәтчеләренә исә урган чакта башакларны күбрәк калдырырга һәм Рутны кыерсытмаска кушты.

Аннары Богаз Рутка болай диде: «Ата-анаңны калдырып, кайнанаң белән бергә аның халкы янына килгән өчен Раббы сиңа яхшылык белән җавап кайтарсын. Җаныңа тынычлык табарга өметләнеп, Исраил Алласы Раббының шәфкать канаты астына сыенырга дип килгән өчен Раббы сине бүләкләсен!»

Игелекле һәм сабыр Рут аңа: «Мәрхәмәтеңнән ташламасаң иде, әфәндем! – дип җавап бирде. – Син мине тынычландырдың, кол хатыннарыңнан да түбәнрәк затны күңелгә хуш сүзләрең белән юаттың».

Озакламый Богаз Рутны хатынлыкка алды, һәм ул аңа ир бала табып бирде. Бәйт-Лехем хатыннары Нагомиягә: «Шөкер, Раббы сине оныксыз калдырмады! Исраил җирендә бу баланың исеме данга күмелсен! Картаймыш көнеңдә ул синең шатлыгың һәм туендыручың булыр, чөнки аны ихлас күңелдән сине яраткан, сиңа җиде углыңнан да артык кадер-хөрмәт күрсәткән киленең тапты», – дип әйтә торган булды. Нагомия сабыйны кулларында күтәреп йөртте, аны карады-бакты, шуңа күрә күрше хатыннары: «Нагомиянең углы туды», – дип әйтә торган булып китте. Балага Обид дип исем куштылар. Обид – Ишайның, ә Ишай – Давытның



атасы буладыр. Давыт соңыннан Исраилнең бөек патшасына әйләнде. Аның турында әле китапның алдагы битләрендә сүз булыр.

*Рут 1:19–21; 2:1–16; 4:13–17*

## Хөннәнең догасы

Исраил җирендәге Рама каласында Элкана атлы бер адәм белән аның хатыны Хөннә гомер кичерә иделәр. Әлеге Хөннә бала табу бәхетеннән мәхрүм иде, шуңа күрә аның күңеленнән һичкайчан сагыш-хәсрәт китмәде. Бу гаилә тиешле көннәрендә Раббыга сәҗдә кылып корбан китерү өчен һәр елны үз шәһәреннән Шилоһка бара, һәм дога кылган вакытта Хөннә һәрчак елый-елый үзенең зарын белдерә торган иде. Элкана исә, хатынын ратканга күрә, аны бик кызгана иде.

Бервакыт шулай Шилоһтагы Раббы йортына килгәч Хөннә тагын еларга тотынды. «Хөннә, нигә елыйсың син? Нигә йөрәгең сыкрый синең? Синең өчен ун угылдан да яхшырак түгелмени мин?» – диде аңа Элкана.

Хөннә, ачы күз яшьләре түгеп, Раббыга дога кылды һәм Аңа нәзер итеп болай диде: «И Күкләр Хуҗасы Раббым! Колыңның өзгәләнүенә күз салсаң иде дә, шул колыңны онытмыйча исеңә төшереп, аңа ир җенесеннән бер бала насыйп итсәң иде! Мин аны, башындагы чәченә пәке дә тидертмичә, гомерлеккә Раббыга тапшырыр идем!»

Раббысына Хөннә озаклап дога кылды, ишек төбендә утырган рухани Эли күз алмыйча хатынга карап торуында булды. Хөннә бөтен күңелен салып дога кылганга, аның иреннәре генә кыймылдый, ә тавыш-тыны ишетелми иде. Шул сәбәпле Элигә ул исерек хатын кебек күренде. «Күпме исереп йөрергә мөмкин? Эчкән шәрабыңнан айны инде!» – диде аңа рухани. «Юк, әфәндем, – дип җавап бирде Хөннә, – шәраб эчмәдем мин, ә бәлки Раббым каршында күңелемне бушатуым. Колыңны азгын хатынга санама, йөрәгемне басып торган авыр кайгымны һәм олы хәсрәтемне белдерүем бу». «Юлың имин булсын, – диде аңа Эли, – Исраил Алласы Раббы гозереңне үтәр синең, сораганыңны бирер». «Колыңны мәрхәмәтеңнән ташламасаң иде!» – дип, Хөннә үз юлында булды. Раббы йортыннан кайтканда аның йөзе инде әүвәлгечә кайгылы түгел иде.

Хөннәнең догалары Раббы колагына барып ирешеп, бераздан ул ир бала тапты.

*I Патшалар 1:1–18*



## Хөннәнең Шемуилне Аллаһыга багышлавы

Хөннә үзенең углына Шемуил дип исем кушты. Бала бераз үсә төшкәч, ул аны Раббы йортына, рухани Эли янына алып килде. «Кайчандыр шушында, синең янда, Раббыга дога кылып торган хатын мин. Аллаһы миңа ир җенесеннән угыл насыйп итсен иде, дип дога кылган идем мин. Раббым теләгемне үтәде – сораганымны бирде. Менә минем улым, һәм мин аны гомере буена Раббыга, Аңа хезмәт итәр өчен тапшырам», – диде Хөннә Элигә. Аннары Хөннә, мәрхәмәтле Аллаһыга догаларында рәхмәтләр яудырып һәм Аны данлап, Аның алдында сәҗдә кылды:

> Раббым аша йөрәгемә чиксез шатлык иңде, Аллаһы миңа ныклык бирде. Чөнки мине коткаруыңа куанам. Раббыдан изгерәк бүтән берәү юктыр, чөнки Синең кебек башка һичкем булмас. Аллабыздан башка сыенып урыныбыз да юктыр. Һавалы әңгәмәләр куертмагыз, дорфа сүзләрегез эчегездә калсын, чөнки Раббы бар нәрсәдән хәбәрдар Аллаһы, Ул барлык эш-гамәлләрне үлчәүгә сала. Үзенә тугрыларның һәр адымын Ул дөрес юлда тота, явызларны исә караңгылык йотачак. Чөнки адәмдәге ныклык аның көч-гайрәтендә түгел. Үз дошманнарын Раббы тар-мар итә.

Хөннә кечкенә Шемуилне Раббы йортында, рухани Эли янында калдырды, һәм ул шунда үсә бирде; Раббы да, кешеләр дә аны яратты. Анасы аңа ел да яңа кием алып килде, һәм Шемуил шул киемнәрдән Раббы алдында хезмәт итте.

*I Патшалар 1:25–28; 2:1–10, 18, 19, 26*



## Раббының Шемуилгә дәшүе

Үсмер яшенә җитеп килгән Шемуил һаман ныгый, үсә барды. Ул әүвәлгечә Аллаһы йортында хезмәт итүендә булды.

Ул көннәрдә Раббы нинди дә булса сүз белән бик сирәк мөрәҗәгать итә, илаһи күренешләр дә еш булмый иде. Бервакыт шулай төнлә Эли үзенең ятагында йокымсырап киткән иде. Аллаһы чырагы дип аталган яктырткыч әле янып тора, һәм Шемуил Раббы йортында, Аллаһы сандыгы торган бүлмәдә үз урынында ята иде. Шул чакны Шемуилгә Раббы дәште. «Мин монда!» – дип җавап бирде Шемуил һәм Эли янына йөгереп килде. «Мин монда! Син чакырдыңмы мине?» – диде ул. Әмма тегесе аңа: «Чакырмадым мин сине, бар, урыныңа ят», – диде, һәм Шемуил үзенең ятагына барып ятты.

Әмма Раббы Шемуилгә тагын дәште. Үсмер, торып, кабат Эли янына килде. «Мин монда! Син чакырдыңмы мине?» – диде. «Чакырмадым мин сине, улым, бар, ят», – диде аңа кабаттан Эли. Моңарчы Раббының мөрәҗәгать иткәне булмагач, Шемуил әле Аның тавышын танымый иде.

Раббы Шемуилгә өченче кат дәшкәч, үсмер бала, торып, өченче тапкыр Эли янына килде. «Мин монда! Син чакырдыңмы мине?» – диде ул аңа. Шунда Эли аңлап алды: димәк, Шемуилгә Раббы Үзе дәшә. «Урыныңа барып ят, – диде ул Шемуилгә. – Сиңа дәшкән тавыш кабат ишетелсә: „Сүзеңне әйт, Раббым, колың ишетә Сине“, дип әйт». Һәм малай үз урынына барып ятты. Раббы әүвәлгечә аңа исеме белән дәште. Эли өйрәткәнчә, Шемуил: «Сүзеңне әйт, Раббым, колың ишетә Сине», – диде. Шуннан Раббы аңа киләчәктә Элинең гаиләсе белән ни-нәрсә кылырга җыенганын сөйләп бирде: «Угыллары кылган яман эшләрне белә торып, аларны туры юлга күндермәгән өчен рухани Элине җәзага тартачакмын».

*I Патшалар 3:1–14*



## Рухани Элинең үлеме

Пелештиләр белән сугышканда Исраил гаскәрен җиңелүгә дучар итеп, кылган гөнаһлары өчен Раббы шул рәвешчә исраилиләрне кабат җәзага тартырга уйлады. Әлеге бәрелештә исраилиләр дүрт меңләп сугышчысын югалтты. Җиңелгән гаскәр үзенең станына әйләнеп кайткач, Исраил өлкәннәре: «Ни сәбәпле Раббы пелештиләр гаскәренә безне җиңәргә ирек куйды икән? Шилоһтан Раббы сандыгын алып килик, яу кырында сандык безнең арада булса, ул безне дошман кулыннан саклап кала алыр», – дип, Шилоһка кешеләр җибәрделәр һәм Күкләр Хуҗасы Раббының сандыгын китерттеләр. Элинең угыллары Хөпни белән Пинхәс тә сандыкны озата килгән иде. Әмма пелештиләр белән булган чираттагы бәрелештә исраилиләр яңадан җиңелүгә дучар булдылар; әлеге яуда аларның утыз мең җәяүле сугышчысы кырылды, исән калганнары исә сугыш кырын ташлап качты. Аллаһы сандыгын пелештиләр тартып алды, ә Элинең угыллары Хөпни белән Пинхәсне үтерделәр.

Сугыш кырыннан чабып кайткан хәбәрче, Эли яшәгән Шилоһка килеп җитеп, Исраил халкы дучар булган коточкыч җиңелү турында сөйләп бирде. Әлеге хәбәрне ишетеп, шәһәр халкы кычкырып еларга тотынды. Бу вакытны Эли шәһәр капкасы төбендә утыра иде. Елаган-сыктаган авазлар килеп ирешкәч, хәбәрчедән Эли: «Ни булды?» – дип сорады. «Пелештиләр белән сугышта Исраил гаскәре тар-мар ителде. Аллаһы сандыгы кулдан ычкынды, синең ике углың да шунда әҗәлен тапты», – дип җавап бирде аңа хәбәрче.

Аллаһы сандыгын искә алуга, Эли капка төбендә утырган җиреннән чалкан авып төште дә шундук җан бирде. Эли кырык ел дәвамында Исраилдә хөкемче булып торган кеше иде, дөньядан ул туксан сигез яшендә китте.

Шул рәвешле, Раббының төнлә Эли нәселе турында Шемуилгә әйткән сүзләре дөрескә чыкты.

*I Патшалар 4:1–18*



## Шаул – Исраил патшасы

Шемуил исә Исраилнең бөек пәйгамбәренә әйләнде. Үзенең халкын ул, чит-ят илаһларга һәм пот-сыннарга табынудан туктап, тере Зат булган Аллаһыга йөзләре белән борылырга өндәде. Картлык баса башлагач, Исраилнең хөкемчеләре итеп Шемуил үзенең угылларын билгеләде. Әмма аның угыллары, атасы юлыннан тайпылып, күбрәк үз файдаларын кайгыртты. Алар халыктан бүләк-ришвәт тә алдылар, ялган хөкемнәр дә чыгардылар. Шуннан Исраил өлкәннәре, Шемуил янына килеп: «Үзең олыгайдың инде, угылларың исә синең юлыңнан тайпылды, шуңа күрә безнең өстән патша билгеләсәң, башка халыклардагы сыман безнең белән ул идарә итәр иде», – диделәр. Ил агаларының әлеге үтенече Раббыга ошамасын Шемуил белә иде. Аның догаларына җавап итеп, Раббы: «Халык теләгәнчә эшлә, – диде. – Аларның бу гамәлләре синнән түгел, ә бәлки Миннән баш тартулары турында сөйли. Димәк, алар Минем патшалык итүемне теләми. Мисырдан алып чыккан көннән башлап бүгенгәчә алар һаман үзенекен эшли – Мине читкә тибәреп, башка илаһларга табына, синең белән дә нәкъ шулай эш кылалар. Димәк ки, аларның гозеренә колак сал, әмма алар өстеннән идарә итәчәк патшаны Мин Үзем сайлыйм. Ә син патшаның хокуклары турында аларны алдан ук кисәтеп куй».

Раббының әлеге сүзләрен Шемуил халыкка җиткерде: «Әгәр сезнең өстән патша хакимлек итсә, ул сезне тулысынча үзенә буйсындырачак, шулвакыт сез патшадан котылу эзләп зар еларсыз, әмма Раббы сезнең аһ-зарыгызга битараф калыр», – диде. Ләкин халык Шемуилнең сүзләрен игътибарга алмады, үзенә патша таләп итүдә булды.

Беркөн Раббы Шемуил янына озын буйлы, күркәм кыяфәтле бер егетне җибәрде, аның исеме Шаул иде. «Мин сиңа әйткән кеше шушы булыр. Минем халкым белән ул идарә итәр», – диде Шемуилгә Раббы. Шемуил, зәйтүн мае салынган савытын алып, Шаулның башына май сөртте; аннары аны үбеп: «Раббы Үзенең халкы белән идарә итүне сиңа тапшыра», – диде. Шулай итеп, Шаул Исраил патшасы булды.

*I Патшалар 8:1–22; 9:2, 17; 10:1*



## Көтүче Давыт – Раббы билгеләгән патша

Шемуил, май сөртеп, патша тәхетенә утырткан Шаул берваkыт зур гөнаһ кылды: пелештиләргә каршы сугышка чыгар алдыннан аның гаскәре янына Шемуил пәйгамбәр килеп Раббы хөрмәтенә корбан чалу йоласын башкарырга тиеш иде; Шаул аны җиде көн дәвамында көтте, әмма Шемуил һаман килмәде, Шаулның сугышчылары исә әкренләп таралыша башлады. Шунда Шаул, көтеп-көтеп тә Шемуил килмәгәч, корбан китерү йоласын үзе башкарырга карар кылды. Әмма әлеге йоланы руханилар гына үтәргә тиеш иде. Йола тәмам булуга, Шемуил килеп җитте. «Аллаһың Раббы тарафыннан бирелгән боерыкны үтәмичә син зур ялгышлык кылгансың, югыйсә синең гаиләң, Аллаһы кушуы буенча, Исраил илендә мәңге патшалык итә алган булыр иде. Хәзер исә синең патшалык итүеңә чик куелыр. Раббы Үз күңеленә хуш килердәй икенче бер кешене табар һәм аңа Үз халкының юлбашчысы булырга боерыр, чөнки син Раббы кушканны үтәмәдең», – диде ул Шаулга.

Күп тә үтми, Раббы Шемуилнең игътибарын якты карашлы, мәһабәт кыяфәтле, битләре янып торган Давыт исемле бер үсмергә юнәлтте. Әлеге егет, яхшы көтүче булып, әтисенең сарыкларын көтә, һәрдаим маллары турында кайгыртып, аларны ерткыч җанварлардан саклый иде.

Шемуил Давытның башына май сөртте, һәм Раббының кушуы буенча Давыт киләчәктә Исраил халкы өстеннән идарә кылачак патша итеп билгеләнде. Шул көннән башлап Аллаһының Рухы һәрчак Давыт белән булды. Ә Шаулдан исә Раббы Рухы китеп, аны явыз рух җәфалый башлады. Шул сәбәпле Шаул, гөсләдә уйнап аны тынычландырсыннар өчен, хезмәтчеләренә берәр оста уенчы эзләп табарга боерды. Хезмәтчеләре аның янына Давытны табып китерделәр, һәм ул, шулай итеп, патша сараенда хезмәт итә башлады. Давыт Шаулның күңеленә бик тә хуш килде, һәм Шаул аны үзенең корал йөртүчесе итеп билгеләде. Теге явыз рух Шаулны интектерә башлауга, Давыт кулына гөсләсен ала да уйнарга тотына, һәм явыз рух Шаулны калдырып китеп, патшаның күңеле тынычлана торган иде.

*I Патшалар 13:8, 13–14; 16:11–33*



# Давыт һәм Галиат

Бервакыт пелештиләр, Исраилгә каршы яу чабарга җыенып, гаскәр туплый башладылар. Шаул патша җитәкләгән исраилиләр дә, пелештиләр гаскәре тукталган калкулык каршында урнашып, алышка әзерләнде. Давытның өч абыйсы Шаул гаскәре сафында иде. Күпмедер вакыттан соң, абыйларына икмәк илтер, шулай ук аларның хәл-әхвәлләрен һәм кирәк нәрсәләре юк микән дип белешер өчен Давытны атасы исраилиләр станына җибәрде.

Исраил сугышчылары янына җитеп, абыйлары белән сөйләшеп торган чакта Давыт пелештиләрнең Галиат исемле үтә дә озын буйлы бер баһадирын күрде. Әлеге Галиатның өстендә җиз көбә, башында очлым* булып, кулында искиткеч зур сөңге белән калкан иде. Галиат, Исраил сугышчыларының каршына басып, Аллаһы халкын мәсхәрәләргә, Аллаһыны мыскыл итәргә тотынды. «Исраилиләрдән кем дә булса алышта мине җиңеп чыкса, пелештиләр сезнең колыгыз булырга әзер», – дип көлде ул исраилиләрдән. Галиатның кыяфәтен күреп тә котлары очкан сугышчылардан һичкем аның белән көрәшкә чыгарга базмады. Галиатның Аллаһыны һәм Исраил гаскәрен мәсхәрәләвен ишеткән Давыт шулчак Шаул патша янына килде дә аңа Галиат белән көрәшергә рөхсәт бирүен үтенде. Әмма Шаул: «Син әле үсмер егет кенә, ул исә тәҗрибәле сугышчы», – дип каршы төште. Шуннан Давыт аңа сарык көткән вакытта Аллаһының ничек итеп арысланнарны һәм аюларны җиңәргә ярдәм иткәнен сөйләп бирде. Шаул аңа көрәшкә чыгарга рөхсәт итте һәм егеткә көбә белән җиз очлым кигертте. Әмма Давыт андый киемгә ияләнмәгән иде, шуңа күрә хәрби киемнәрен салып кулына юл таягы алды да, елга буеннан биштәренә биш шома таш салып, таш ата торган озын-нәзек күн каешын тотып пелештиләр баһадирына таба атлады.

Каршысына килүче Давытны күреп, Галиат аңардан көләргә тотынды. «Нәрсә син миңа каршы таяк күтәреп чыгасың? Эт түгел бит мин сиңа!» – диде ул. «Син миңа каршы кылыч тотып, сөңге-калканнан киләсең, мин исә син мәсхәрәләгән Исраил сугышчыларының Алласы, Күкләр Хуҗасы Раббым хакына киләм», – дип җавап кайтарды аңа Давыт, аннары кулын биштәренә тыгып бер таш алды

* *Очлым* – сугышчыларның баш киеме; шлем.



да ташаткыч каеш ярдәмендә Галиатка томырды. Таш нәкъ тегенең маңгаена туры килеп, баһадир йөзтүбән җиргә ауды һәм шундук җан бирде. Галиатның җан биргүен күреп, пелештиләрнең кайсы кая кача башлады, һәм Исраил гаскәрләре бу орышта җиңеп чыкты.

*I Патшалар 17:1–53*

# Йонатан

Давыт пелештиләр баһадиры Галиатның башын Шаул патшага китергәч, Шаул аңардан: «Кем углы буласың син?» – дип сорады. «Бәйт-Лехемдә яшәүче Ишай углы мин», – дип җаваплады Давыт. Әлеге әңгәмә вакытында Шаулның углы Йонатан да патша янында иде. Кыю йөрәкле, тәвәккәл егет Йонатан Давытны ихлас күңелдән яратты һәм аның белән дуслашып китте. Дуслык билгесе итеп ул аңа үзенең өс киемен, бил каешын, кылыч белән җәясен бүләк итте. Шулай ук Давыт та Йонатанны үз итте.

Әмма аларның шулай дус булуы Шаулга бер дә ошамады. Пелештиләр гаскәрен җиңеп, өйләренә кайтып баручы Исраил сугышчыларын халык: «Шаул меңне җинде, ә Давыт – ун меңне!» – дип такмаклый-такмаклый шатланып каршылады. Бу сүзләрне ишетеп Шаулның бик нык хәтере калды. Давытның шулай дан-шөһрәт яулавы аның күңеленә бер дә ятмады. Шул көннән Шаул, чын-чынлап Давыттан көнләшеп, аны үтерергә җай чыгуын көтә башлады.

Бервакыт Шаулга тагын явыз рух иңеп, Давыт аңа гөсләдә уйный башлагач, Шаул сөңгесен алды да егеткә томырды, әмма Давыт читкә тайпылып, сөңге аңа тими үтте. Йонатан исә атасының ачуыннан Давытны һаман яклый килде; Шаулның явыз ниятен сизенеп, атасына ул болай диде: «Патша үзенең колы Давытка гаеп якмасын иде, чөнки аның һичбер гөнаһ эш кылганы юк, синең өчен ул бик файдалы эшләр башкарды; үз тормышын куркыныч астына куеп, пелештиләр баһадиры белән көрәшкә чыкты, һәм Раббы бөтен Исраилгә бөек җиңү җибәрде. Моны күреп син үзең дә сөендең. Ни өчен соң син, бер сәбәпсезгә гаепсез Давытның канын коеп, жаныңа гөнаһ алырга җыенасың?» Углының сүзләренә колак салып, Шаул Давытка каршы золым кылмаска вәгъдә итте.

*I Патшалар 17:57–58; 18:1–11; 19:1–6*



## Давытның йоклап яткан Шаул янына килүе

Давытка булган нәфрәт Шаул күңелендә көннән-көн үсә барганлыктан, егетне үтерү нияте патшада кабат уянды. Бу хакта белгәч, Йонатан якын дустын кисәтеп куйды, һәм Давыт, үзенә тугрылык саклаган кешеләрне туплап, тау-ташлар арасына качты. Шаул исә үзенең гаскәре белән аны эзәрлекли чыкты, әмма Аллаһы Давытны Үзенең мәрхәмәтеннән ташламау сәбәпле, Шаул аны берничек тә куып тота алмады. Шаулның гомерен кисәргә Давытка берничә тапкыр җай чыкса да, Аллаһыны яратканга һәм Аңардан курыкканга күрә, Шаулга карата ул һичнинди явызлык кылмады.

Бервакыт Шаул өч мең исраилидән торган гаскәр туплады да Давытны эзәрлекләп тауларга таба юнәлде. Шаул белән сугышчыларының төн кунарга калкулыкларның берсендә урнашуын белгәннән соң, Давыт үзенең дусты Әвишәйне ияртте дә төнлә Шаул станына төште. Гаскәриләрнең һәммәсе тирән йокыга талган иде. Давыт белән Әвишәй йоклап яткан Шаул янына килделәр; Шаулның баш очында җиргә кадап куелган сөңгене күреп, Әвишәй: «Шушы сөңге белән Шаулны үтерергә рөхсәт ит», – диде. Әмма Давыт, вакыты җиткәч аның гомеренә Раббы Үзе чик куяр дип, Аллаһы тарафыннан куелган патшага кул күтәрергә рөхсәт итмәде; һәм алар, Шаулның сөңгесе белән су чүлмәген алып, станнан китеп бардылар.

Аннары Давыт үзәннең икенче ягына чыкты да, Шаул урнашкан калкулык каршындагы тау битләвенә басып, каты итеп Шаулга кычкырды һәм аның әйберләрен күрсәтте. Давытка күпме явызлык кылып та, аның үч алмавын күргән Шаул: «Әйе, гөнаһ эш кылдым мин, – диде. – Давыт углым, кайт минем янга, башкача һичнинди җәбер-золым күрмәссең миннән, чөнки бүген син, минем җанны аяп, гомеремнең синең өчен кадерле икәнлеген расладың. Байтак ахмаклыклар эшләп, күп гөнаһлар кылдым мин». Ләкин, сине башкача эзәрлекләмәм, дип антлар эчсә дә, Шаул күңелендә Давытка карата нәфрәт яши бирде.

*I Патшалар 20:1–43; 26:2–21*



## Давытның бөтен Исраилдә патшалык итә башлавы

Пелештиләр белән булган чираттагы бәрелештә исраилиләр җиңелеп, Шаул патша үзе дә, угыллары да һәлак булды. Патша гаскәрендә хезмәт итүче бер яугир, сугыш кырыннан туп-туры Давыт янына кайтып, Шаулның һәм аның углы Йонатанның пелештиләр белән орышта һәлак булуын хәбәр итте. Әлеге кеше, дошманы Шаулның әҗәле турында әйтеп Давытны сөендерермен, дип уйлаган иде. Әмма Шаул кылган явызлыкларны Давыт искә алмады: киресенчә, Шаул белән Йонатанның вафаты аны тирән кайгыга салды һәм ул, алар истәлегенә багышлап, үзенең кайгы җырын башкарды:

> Шаул белән Йонатан тормышта бер-берсен яратып, үзара килешеп яшәделәр, аларны хәтта әҗәл дә аера алмады. Бөркеттән җитезрәк, арысланнан көчлерәк иде алар. И-и Исраил кызлары! Сезгә зиннәтле киемнәр кидергән һәм киемнәрегезне алтыннар белән бизәгән Шаулны искә алып ачы күз яшьләре коегыз. Нинди көчле кешеләр яу кырында ятып калды! Туганым Йонатан, синең хакта хәсрәтем чиксездер: минем өчен син ифрат кадерле идең; синең мәхәббәтең минем өчен хатын-кыз мәхәббәтеннән өстенрәк булды.

Аларның вафатыннан соң Давыт әнә шулай ачы күз яшьләре түкте. Аннары ул, Раббы кушуы буенча, Хебрунга барып төпләнде. Бераздан шунда Яһүдәдән кешеләр килделәр һәм, Давытны Исраилнең көньяк өлеше Яһүдә өстеннән патша итеп билгеләп, башына зәйтүн мае сөрттеләр. Җиде ел ярым үтүгә, Давыт инде бөтен Исраил өстеннән патшалык итә башлады. Аллаһы, шул рәвешле, Шемуил пәйгамбәр аша вәгъдә ителгәннең һәммәсен тормышка ашырды.

*II Патшалар 1:1–4, 23–27; 2:1–4*



# Аллаһы сандыгы Иерусалимдә

Давыт бөтен Исраил җирендә патшалык итә башлагач, үзенең тәхетен ул Иерусалимдә урнаштырырга карар кылды. Аллаһы аны зирәклек һәм кодрәт иясе иткәнлектән, Давыт Исраилнең бөтен дошманнарын кырып бетерә алды. Аллаһыны ратканга күрә, Аның изге сандыгын ул үз шәһәренә алып кайтырга булды. Заманында пелештиләр, сугыш кырында әлеге сандыкны кулларына төшереп, үзләре белән алып киткән булалар. Соңрак аны исраилиләргә кабат кайтарып бирәләр, һәм шуннан соң сандык Кыръят-Ягарим дип аталган урында Абинадаб исемле бер кешенең йортында калган була. Давыт аны Иерусалим каласына күчерергә хәл кыла.

Әлеге сандыкны алып кайтыр өчен Давыт үзе белән утыз мең кеше ияртеп барды. Аллаһы сандыгын Иерусалимгә алып кайтып, Сион тавына урнаштырган мәлдә Давытның күңеле тантана итте! Гөсләдә уйнап ул мәрхәмәтле Аллаһыга дан-шөһрәт яудырды, шатлыгыннан Раббы алдында биеде. Аның белән бергә халык та Аллаһыны данлады, бар җирдә шатлык авазлары яңгырап торды, быргылар уйнады. Махсус эшләткән чатыр эченә Аллаһы сандыгын алып кереп урта бер җиргә урнаштырганнан соң, Раббы каршында Давыт күп санлы корбаннар китерде; корбан китерү йоласын башкаргач, Күкләр Хуҗасы Раббы исеме белән халыкны фатихалап, исраилиләрнең барысына икмәк, көлчә һәм кыздырган ит өләшеп чыкты.

Раббы, Давыт токымының киләчәк язмышын кайгыртырга вәгъдә итеп, аның нәсел варисы хакында болай диде: «Мин аның атасы булырмын, һәм ул Минем углым булыр. Әгәр ул гөнаһ эш кылса, Мин аңа җәзаны башкалар кулыннан бирдерермен. Ләкин, Шаулдан йөз чөереп карашымны сиңа төбәгән кебек, углыңны Мин беркайчан Үземнең рәхим-шәфкатемнән ташламам. Синең нәселең какшамас булыр, синең патшалыгың вә тәхетең Минем каршыда мәңге торыр». Раббының бу сүзләрен Давытка Натан пәйгамбәр җиткерде. Әлеге сүзләрне ишеткәннән соң Давыт, Раббы каршына килеп, болай диде: «И-и Раббым минем, Раббы, син шулай күтәрерлек кем әле мин ул кадәр? Минем нәселем дә Сиңа ни өчен шулай бик мөһим? Кайсы гына яктан алсаң да, бөек Син,



Раббым минем, Раббы! Синең белән тиңләшердәй зат юк, Синнән башка бүтән Алла да юк. Ә хәзер, Раббы Аллам, Үзеңнең колың вә аның гаилә-йорты хакында әйткән сүзләреңне мәңгегә ныгытып куй һәм әйткәннәреңне тормышка ашыр».

*II Патшалар 6:2–19; 7:14–16, 18–29*

## Давытның мәдхияләре

Әле көтүче булып йөргән чакларында ук Давыт, гөсләдә уйнап, үзе чыгарган мәдхияләрне* җырларга ярата торган була. Данлыклы патшага әйләнгәч тә ул җырлар язудан туктамый. Изге Китапта Давыт тарафыннан иҗат ителгән мәдхияләр бик күп урын алып тора. Аларны язарга Аллаһыга булган мәхәббәте илһам биреп, мәдхияләрнең һәммәсендә Аның исеменә дан җырлана.

Сарыкларга әйбәт көтүче кирәклеген белгән Давыт мәдхияләрнең берсендә Раббы хакында болай җырлый:

Раббы – минем көтүчем,
Ул мине мохтаҗлыкта калдырмас.
Мул-куе үләнле болыннарда йөртер,
талгын сулы елгалар буенда ял иттерер.
Җаныма ныклык бирер,
Үз исеме хакына мине хак-туры юллардан җитәкләр.
Караңгы үзәнгә барып керсәм дә,
хәвеф-хәтәрдән курыкмам,
чөнки янымда Син бар!
Көтүче таягың вә юл таягың кулыңдадыр,
шуңа күрә җаным тыныч минем.
Дошманнарым күз алдында Син миңа табын җәйдең,
башыма хуш исле май сөрттең;
мөлдерәмә тулы минем касәм.
Шулай, Синең игелегең, мәрхәмәтең
хәятем дәвамынча мине җитәкләп йөртер.
Раббы йорты гомер бакый минем йортым булыр.

*22 нче мәдхия*

---

* Мәдхия – мактау сүзе, ода.



## Натан пәйгамбәр – Давыт каршында

Давыт, ихлас күңелдән Раббыны яратып, һичкайчан Аның сүзеннән чыкмады. Ләкин бервакыт ул гөнаһ эш кылды. Ничектер шулай кич белән сараеның түбәсенә йөрергә чыккач, югарыдан бер хатынны күреп, аңа күңеле төште. Әмма әлеге Батшеба ир хатыны булганлыктан, Давыт аңа өйләнә алмады. Шуннан Давыт Батшебаның ире Урияне сугышка җибәрде дә, теге ир сугыш кырында әҗәлен табып, Давыт Батшебаны үзенә хатынлыкка алды.

Күпмедер вакыттан соң Раббы Давыт янына Натан пәйгамбәрне җибәрде, һәм патшага пәйгамбәр мондый хикәя сөйләде: «Бер шәһәрдә ике кеше яшәгән, аның берсе – бай, икенчесе – ярлы булган. Байның вак һәм эре терлеге бихисап күп икән. Ярлының исә үзе сатып алган кечкенә генә сарык бәрәненнән гайре башка нәрсәсе булмаган. Әлеге бәрән аның балалары белән бергә үскән. Сарык бәрәне хуҗасы ашаганны ашаган, аның савытыннан эчкән, аның күкрәгендә йоклаган, хуҗасы аны кызы урынына баккан. Беркөн бай янына бер юлчы килгән дә, бай кеше, әлеге юлчыга ашарга әзерләр өчен үзенең сарыгын яисә үгезен суярга кызганып, теге ярлының бәрәнен чалган һәм бусагасына аяк баскан кунакка ризык хәстәрләгән».

Хикәяне тыңлап бетергәннән соң Давыт ачуыннан кычкырып җибәрде: «Моны эшләгән кеше үләргә тиеш! Бәрән бәясен дә аңардан дүртләтә түләтергә кирәк, чөнки бик зур шәфкатьсезлек бу».

Натан пәйгамбәр шунда Давытның гөнаһ эшен фаш итеп: «Әлеге кеше – син ул», – диде, һәм Давыт, тәүбәгә килеп: «Раббы каршында гөнаһлымын мин», – диде. Давытның тәүбә итүен күреп, Натан аңа болай диде: «Раббы гөнаһларыңны кичерә синең, җаныңны кыймый. Ләкин шушы ялгыш гамәлең белән син дошманнарыңа Раббыны санламаска юл куйдың; шуңа күрә синең яңа туган углың үләр». Шул рәвешле Давытның гөнаһы кичерелде, әмма ул җәзасыз калмады.

Тәүбәгә килгән Давыт соңыннан үзенең кайгы җырын язды. Анда мондый сүзләр бар иде: «И Аллаһы, ...чиксез рәхим-шәфкатең хакына минем бозык эшләремне сызып ташла... коендыр мине – кардан ак булырмын... мине саф йөрәкле кыл, какшамас яңа рух хасил ит күңелемдә».

*II Патшалар 11:2–17; 12:1–14; Зәбур 50:3, 9, 12*



## Абшалумның һәлак булуы

Давыт патша угылларының берсе Абшалум чамасыз тәкәббер, әмма йөз-кыяфәткә күркәм бер егет иде. Аның озын, куе чәчләре аеруча матур иде. Тәхетне яулап алу теләге белән янган Абшалум үзенең атасы Давытны өнәми иде. Исраил халкы Абшалумны үз итте, яратты, чөнки ул төрлечә алдап-йолдап, икейөзлеләнеп, ясалма кайгыртучанлык һәм кешелеклелек күрсәткән булып аларның күңелен үз ягына аудара алды. Көннәрдән беркөнне Давыт патшага, углы Абшалумның эзәрлекләвеннән качып аулаграк урында яшеренер өчен, гаскәре белән бергә Иерусалимдәге сараен ташлап китәргә туры килде.

Атасының кайда тукталганын белгәннән соң, Абшалум күп санлы гаскәр белән яуга кузгалды. Давыт патша да аңа каршы үзенең сугышчыларын җибәрде, әмма углы Абшалумга һичнинди зыян-зарар китермәскә, аның гомерен саклап калырга боерык бирде. Улы бихисап күп кайгы-хәсрәт китерсә дә, Давыт аны барыбер ярата иде.

Гаскәриләр арасында бәрелеш урман эчендә булды. Әлеге яуда Аллаһының ярдәме белән Давыт сугышчылары җиңеп чыкты, ә Абшалум тарафдарлары сугыш кырын ташлап качты. Абшалум исә качырына атланып котылырга уйлады. Әмма качыры, җәелеп үскән зур бер имән ябалдашы астына чабып кереп, Абшалум чәче белән имән ботаклары арасында буталды да күк белән җир арасында асылынып калды, атланган качыры исә китеп барды. Давытның гаскәр башлыгы, моны күреп, патша углына ук атты, һәм Абшалум шунда җан бирде.

Бу турыда белгәннән соң, Давыт тәмам кайгыга батты. «Абшалум углым! И-и углым, углым, и-и Абшалум! Синең урыныңа мин генә үлгән булсамчы, Абшалум углым, и-и углым!» – дип ачы күз яшьләре түкте. Аллаһы, шул рәвешле, Абшалумның гөрләп торган тормышына чик куйды.

Изге Китапта мондый сүзләр бар: «Ата-анасына яман телләнүченең гомер шәме дөм караңгылык эчендә пыскып сүнәр».

*II Патшалар 14:25–26; 15:1–6; 18:2–14, 32–33;*
*Гыйбрәтле сүзләр 20:20*



## Зирәк Сөләйман патша

Давыт дөнья куйганнан соң, Исраилнең патшасы итеп Раббы аның углы Сөләйманны куйды. Бервакыт Сөләйманга төшендә Раббы күренеп, теләгәнеңне сора, нәрсә генә сорасаң да, гозереңне үтәрмен, диде. Шунда Сөләйман үзенең күп санлы халкы белән идарә итәр өчен Раббыдан зирәк акыл бүләк итүен сорады. Аңа җавап итеп Раббы: «Үзеңә озын гомер, байлык йә булмаса дошманнарыңа әҗәл сорамыйча, һәммә нәрсәне дөрес аңлап, дөрес хөкем итәргә зирәк акыл сораган өчен Мин синең гозереңне үтим һәм сиңа зирәк акыл бирәм. Шулай ук Мин сиңа үзең сорамаган байлык белән дан-шөһрәтне дә бирәм; үзең исән чакта сиңа тиңләшердәй бүтән патша булмаячак. Минем юлдан тайпылмыйча, Мин кушканнарны һәм Минем әмерләрне бозудан атаң Давыт сыман саклансаң, Мин синең гомер сөрешеңне дә озайтырмын», – диде.

Бервакыт Сөләйман патша хозурына бәхәстә булган ике хатын килеп керде, аларның кулында сабый бала да бар иде. Хатыннарның һәр икесе, бу – минем бала, дип кабатлавында булды. Хакыйкатьне белер өчен, Сөләйман баланы икегә чабарга да бер яртысын – берсенә, икенче яртысын икенчесенә бирергә тәкъдим итте. Чынлыкта исә баланы һәлак итәргә җыенмый иде ул, хатыннарны сынар өчен генә шулай дип әйтте. Шунда хатыннарның берсе: «Чабыгыз, миңа да, аңа да булмасын», – диде. Икенчесе исә: «Бала җанын кыймагыз, бирегез аны теге хатынга», – дип кычкырып җибәрде.

Шул рәвешле Сөләйман хатыннарның кайсысы баланың анасы икәнен ачыклады, чөнки ана булган кеше, баласын югалтуга караганда, аны чит кешегә бирүне өстенрәк күрер.

*III Патшалар 3:5–28*



# Аллаһы йорты

Аллаһы Давыт патшага: «Синең углың Сөләйман Аллаһының шөһрәте балкып торган Раббы йортын төзиячәк», – дип әйткән була.

Раббының боерыгын үтәп, Сөләйман Аның өчен күз явын алырдай гүзәл бина төзетте. Аллаһы йортының диварлары эчке яктан саф алтын белән капланган булып, яктырткычлар нурында бар нәрсә балкып-җемелдәп торды. Аллаһы йорты тирәли Сөләйман таш дивар белән әйләндереп алынган ишегалды ясатты. Ишегалдына, корбанлык малны юар өчен, бакырдан коелган ун зур чан куйдырды. Әлеге чаннарның берсе, башкаларыннан шактый күләмле булып, бакырдан коелган унике үгез сыны өстендә тора иде. Чанның монысы руханилар коеныр өчен куелды. Корбан китерү өчен ишегалдында шулай ук бакырдан зур итеп махсус урын-корылма эшләнде. Йорт эчендә исә Аллаһы сандыгын урнаштырыр өчен саф алтын белән каплап алынган Иң изге бүлмә булдырылды. Хуш исле сумала көйрәтү өчен Изге йортның алгы бүлмәсендә алтыннан коелган махсус өстәл урнашты. Иң изге саналган түр бүлмәгә, зәйтүн агачыннан юнып, алтын йөгертелгән ике зур фәрештә сыны куелды. Аларның канатлары як-якка җәелгән булып, берсенең бер канат очы бүлмәнең бер диварына, икенчесенең дә бер канат очы икенче диварга орынып тора, ә икенче канатларының очлары исә бүлмә уртасында бер-берсе белән килеп тоташа иде.

Аллаһы йортының диварлары фәрештәләр, хөрмә агачлары һәм ачылып килүче чәчәк сурәтләре белән бизәлде. Аллаһы йортының идәне шулай ук алтын белән капланды.

*III Патшалар 6:14–36*



## Сөләйманның Аллаһы йортындагы догасы

Аллаһы йорты төзелеп беткәннән соң, руханилар Аллаһының Килешү сандыгын йортның түр бүлмәсенә, Иң изге дип аталган бүлмәгә кертеп урнаштырдылар. Ишеген зур пәрдә каплап торган әлеге бүлмәгә керергә баш руханидан гайре берәүгә дә рөхсәт булмый. Баш рухани исә бирегә елына бер тапкыр – үзе һәм дә Раббы алдында гөнаһ эш кылган халкы өчен корбан китерергә керә иде.

Аллаһы сандыгын йорт эченә урнаштырып, руханилар белән җырчылар Бар итүчегә дан-хөрмәт яудырганнан соң, Раббы шөһрәте болыт булып Раббы йортына кереп тулды. Шуннан Сөләйман мәзбәх алдына килеп басты һәм җыелган халык каршында кулларын күккә ашырып болай диде: «И-и Раббы, Исраил Алласы! Югарыда, күкләр киңлегендә, түбәндә, җир йөзендә Синә тиң булырдай бүтән алла юк; Син, Килешүгә тугры калган хәлдә, Сиңа ихлас күңелдән инанган колларыңны рәхим-шәфкатеңнән аермыйсың. Дөрестән дә, Аллаһының урыны җирдәмени?! Очсыз-кырыйсыз күкләр киңлеге дә Сине сыйдырып бетерә алмаганны, мин салган бина гына ничек сыйдырсын! Тик колыңның дога-гозерләренә колак салсаң иде, Раббы Аллам; колыңның догасын, аның ялваруын ишетсәң иде. „Минем исемем шушында сакланачак“ дигән урынны – әлеге йортны көндез дә, төнлә дә күз уңында тотсаң иде; колыңның ошбу урын турындагы догалары Сиңа килеп ирешсә иде. Колыңны, халкың Исраилне мәрхәмәтеңнән аермасаң иде һәм дә Сине ярдәмгә чакырган вакытта аларның сүзләрен һәрчак ишетсәң иде».

*III Патшалар 8:3–11, 22–52*



## Сөләйман һәм Шеба мәликәсе

Шеба мәликәсенең биләмәләре көньяк тарафтагы ерак бер илдә урнашкан иде. Раббы исемен данлаган Сөләйман патша хакында ишеткән мәликә, авыр-четерекле сораулар белән сынар өчен, аның хозурына килде. Иерусалимгә ул исәпсез-хисапсыз мал-мөлкәт алып килгән иде: дөяләргә хуш исле сумала-майлар, әйтеп бетергесез күләмдә алтын һәм кыйммәтле-затлы асылташлар төялгән иде. Ул, Сөләйман янына килеп, күңелендә йөрткән һәммә нәрсә турында аның белән уртаклашты. Сөләйман аның бөтен сорауларына җавап бирде, һәм әңгәмә барышында патшага билгесез яисә ул ачыклык кертә алмаган бер генә нәрсә дә очрамады.

Шеба мәликәсе Сөләйманның зирәк акылын да, ул салган йортны да күрде. Патша өстәлендәге ризык-нигъмәтләрне, колларының яшәү рәвешен, хезмәтчеләренең сын-кыяфәтен, өс-башларын, патшаның шәрабчыларын, Раббы йортына патша китергән яндыру корбаннарын күргәннән соң, Шеба мәликәсе түзмәде, болай дип сүз башлады: «Үз илемдә чакта синең эш-гамәлләрең, акыл-зиһенең турында ишеткәннәрем хак дөрес икән. Бирегә килеп үз күзләрем белән күрмичә мин ул сүзләргә ышанып бетмәгән идем, баксаң, синең хакта мин күргән кадәрнең яртысын да әйтмәгәннәр икән. Синдәге акыл-зиһен вә мал-мөлкәт мин ишеткәнгә караганда байтакка күбрәк. Синең кешеләрең һәм көннең-көнендә синең гакыллы сүзләреңне ишетүче хезмәтчеләрең нинди бәхетле! Сине Исраил тәхетенә ихтыяр кылган Раббы Аллаң мөбарәк булсын! Раббы, Исраил җиренә булган чиксез мәхәббәтен раслап, гаделлек белән хөкем кылсын өчен сине патша итеп куйган икән». Шуннан ул патшага бүләккә йөз егерме данә кисәкле алтын, күп итеп хуш исле сумала-майлар һәм зиннәтле ташлар тапшырды. Сөләйман патшага Шеба мәликәсе бүләк иткән күләмдә хуш исле сумала-майларның моңарчы әле Иерусалимгә килгәне булмый. Сөләйман патша да Шеба мәликәсенә бүләкләрне мулдан тапшырды; үз кулы белән биргән әйберләрдән тыш Шеба мәликәсенең күзе төшкән һәм ул сораган һәммә нәрсәне аңа бүләк кылды. Шуннан мәликә үзенең хезмәтчеләре белән үз иленә юл алды.

*III Патшалар 10:1–13*



## Сөләйманның Аллаһыдан читләшүе


Сөләйман патша Аллаһы йортын төзегән вакытта Аллаһы аңа: «Әгәр кагыйдәләрем буенча яшәп, кануннарымны төгәл үтәсәң, Минем кушканнарны санлап, шулар буенча гамәл кылсаң, синең хакта атаң Давытка биргән вәгъдәмне үтәрмен: исраилиләр арасында яшәп, Үземнең Исраил халкын һичкайчан мәрхәмәтемнән ташламам», – дигән була; һәм Сөләйман ихлас күңелдән Аллаһының әмерләрен үтәп килде.

Әмма байтак еллар узып олыгая төшкәч, Сөләйман патша Аллаһыдан читләшә башлады. Сөләйманның күп санлы хатыннары арасында бердәнбер Аллаһыны танымаган, пот-сыннарга табынган мәҗүси хатыннар байтак иде. Әнә шул мәҗүси хатыннар Сөләйманның күңелен башка илаһларга аударды, һәм патша чит мәмләкәт хатыннарының илаһларына багышлап гыйбадәт кылу, корбан китерү урыннары булдырды.

Сөләйман патша янына ике мәртәбә иңеп, Үзеннән гайре башка илаһларга табынмаска боерган Раббыдан йөз чөергән өчен Раббының Сөләйманга ачуы чыкты. Шуннан Раббы Сөләйманга болай диде: «Минем белән төзегән килешүне сакламаган һәм Минем кагыйдәләремне үтәмәгән өчен, сараеңда кылына торган ялгыш гамәлләр өчен Мин, патшалыкны синең кулдан алып, синең хезмәтчеңә тапшырырмын. Ләкин атаң Давыт хакына Мин моны син исән чакта эшләмәм – патшалыкны Мин синең углың кулыннан тартып алырмын. Мин аңардан бөтен патшалыкны алмам, колым Давыт хакына һәм Үзем сайлап алган Иерусалим хакына синең углың кулында Исраилнең бер генә ыругын калдырырмын».

Һәм нәкъ шулай булды да. Патша кылган гөнаһлар аркасында ил, ике кисәккә аерылып, алар арасында ызгыш-низаглар башланды.

*III Патшалар 6:12–13; 11:1–13*



## Патшалыкның бүленүе

Данлы Исраил патшалыгы бары йөз егерме ел яшәп калды. Анда һәрберсе кырыгар елдан өч патша: Шаул, Давыт һәм Сөләйман идарә итте. Сөләйман патшаның вафатыннан соң патшалык икегә – Исраил белән Яһүдәгә бүленде. Бу исә болай булды: Сөләйман дөнья куйгач, аның углы Рехабгамны тәхеткә утыртыр өчен бөтен Исраил халкы Шәкемгә җыелды. Җыелган халык Рехабгамга: «Синең атаң иңнәребезгә авыр йөк салды, безнең өскә салган шушы авыр йөкне җиңеләйт, шул чагында без сиңа хезмәт итәрбез», – диде.

Рехабгам патша исә атасы Сөләйман заманында сарайда хезмәт иткән өлкәннәр белән киңәште, алар аңа: «Әгәр син бүген шушы халыкның хезмәтчесе булып, аларның гозерләренә колак салып, аларга ярарга тырышсаң, күңелләрен күтәреп, тәмле телеңне кызганмасаң, алар мәңгегә синең хезмәтчеләреңә әйләнер», – дип җавап бирде. Тик Рехабгам өлкәннәр киңәшенә колак салмады, үзе белән бергә үскән яшьтәшләренә мөрәҗәгать итте. Алар исә аңа начар киңәш бирде: «Әлеге халыкка син болай дип әйт, – диде алар, – минем чәнти бармагым атамның билемнән калынрак. Әгәр минем атам сезнең иңнәргә авыр йөк салган булса, мин әлеге йөкне тагын да арттырырмын; әгәр атам сезне камчы белән суктырган булса, мин биргән җәза исә чаян чагуына тиң булыр».

Исраил дәүләте Ягъкубның унике углы санынча унике ыругка бүленгән иде. Яңа билгеләнгән Рехабгам патшаның халык сүзенә колак салмавын күреп, әлеге ыругларның унысы аңа каршы баш күтәрде һәм, калган ике ыругтан аерылып, үзләренә патша итеп Рехабгамның дошманы Яробамны сайлады. Яңа барлыкка килгән бу патшалык Изге Язмада Исраил патшалыгы дип атала. Исраилнең төньягында урнашканга аны шулай ук Төньяк патшалык дип тә йөртәләр. Әүвәл аның башкаласы итеп Шәкем билгеләнә, аннары башкала Тирсага күчә, аннары инде, ниһаять, Самарея каласы сайлана. Исраил дәүләте, ике йөз елдан артык гомер итеп, безнең эрага кадәр 721 елда Ашшур патшасы Шалманесер тарафыннан тар-мар ителә.

Сөләйман патшаның угылы Рехабгамга исә бары тик Яһүдә белән зур булмаган Беньямин ыругы гына тугрылык саклап калып, шушы ике ыруг Яһүдә патшалыгын тәшкил итә. Әлеге патшалык



Исраилнең көньягында урнашканга күрә аны Көньяк патшалык дип тә йөртәләр. Аның башкаласы Иерусалим була. Яһүдә патшалыгы чама белән өч йөз илле ел яши һәм Мәсих туарга биш йөз сиксән алты ел кала Бабил тарафыннан тар-мар ителә.

*III Патшалар 12*

## Яһүдә – Көньяк патшалык

Яһүдә, яисә Көньяк патшалык, чама белән өч йөз илле ел яшәде. Төньяк патшалык тар-мар ителеп, йөз утыз биш ел узганнан соң Көньяк патшалык та җимерелде. Көньяк патшалыкта бер-бер артлы егерме патша алышынды, аларның исемнәре түбәндәгеләр: Рехабгам, Абия, Аса, Еһошафат, Яһорам, Ахазея, мәликә Аталия, Йоаш, Амасия, Уззия (Азария), Иотам, Ахаз, Хизәкыйя, Менашше, Амон, Йошия, Яһүәхәз, Яһоякыйм, Якөнья һәм Сәдыкыйя.

Көньяк патшалыкның патшалары күбесенчә Раббыдан читләшеп, пот-сыннарга табынып гөнаһлы тормыш белән яшәсә дә, алар арасында кайберләре шулай да Аллаһыга тугрылыгын саклап калды. Мәсәлән, Хизәкыйя һәм Йошия патшалар идарә иткән чор Көньяк патшалык өчен яңу дәвере булды: ул заманнарда патшалар чит илаһларның гыйбадәтханәләрен җимерделәр, халыкка Аллаһы сүзен санларга, явыз гамәлләр кылудан сакланып, Аллаһы кануннарын, Аның әмерләрен, кушканнарын һәм йолаларын үтәргә боердылар.

Яһүдә патшалыгында яшәүче халыкның саны Исраил халкына караганда якынча алты тапкырга кимрәк иде. Әмма әйләнә-тирәдәге халыклар белән чагыштырганда бу патшалыкларның икесе дә кечкенә иде. Бу ике патшалык үзара һаман сугышып яшәсә дә, мәҗүси халыклар икесенең дә төп дошманы булып кала килде, болар: төньяк тарафта – Арам иле (Сүрия), көнчыгышта – көчле дәүләтләр Ашшур һәм Бабил, көньяк-көнбатышта – пелештиләр, көньяк-көнчыгышта – мәабиләр иде.

Раббыга тугрылык саклап яшәгән заманда Яһүдә белән Исраил сугышларда һаман җиңеп чыга, ә инде аларның халкы һәм патшалары гөнаһка баткач, Раббы җәза бирү йөзеннән аларны дошман кулына тапшыра торган иде.

*III Патшалар 12*



## Исраил – Төньяк патшалык

Әлеге патшалык ике йөз елдан артыграк яшәде. Шул чорда тәхеттә бер-бер артлы унике патша алышынды: Яробам, Надаб, Багша, Элаһ, Зимри, Омри, Ахаб, Ахазея, Яһорам, Еһу, Яһүәхәз, Йоаш, Яробам II, Зәкәрия, Шаллум, Менахем, Пекахья, Пеках һәм Һошея. Бу патшалыкның тарихы буеннан-буена кан коешлы булды. Исраил әле Яһүдә патшалыгы белән, әле башка халыклар белән һәрдаим сугышып торды. Тәхеткә утырыр өчен гамәлдәге патшаларны һаман угыллары яисә якыннары үтерә торды, патшалыкны кулга төшергәннән соң аларның да җанын кыя иделәр. Төньяк патшалыкның тәхетендә, шул рәвешле, тугыз нәсел алышынды. Көньяк патшалыкта исә һаман Давыт патша йорты идарә итте.

Төньяк патшалыкның патшалары Раббы күзенә ятышсыз күренгән гамәлләр кылдылар, Аллаһы юлыннан читкә тайпылып, мәҗүсиләргә әйләнделәр, аларның патшалыгында әхлаксызлык һәм пот-сыннарга табыну чәчәк атты. Төньяк патшалыкның бозылып беткән патшалары үзләренең бар халкын гөнаһ юлына алып кереп китте. Патшаларның беренчесе – Яробам тәхеткә утыруга, халык пот-сыннарга табына башлады. Бу хәл менә ничек булды. Яробам патша болай уйлады: «Әгәр бу халык корбан китерер өчен әүвәлгечә Иерусалимгә, Раббы йортына йөрсә, халыкның күңеле кабат Яһүдә патшасы Рехабгамга берегеп куярга мөмкин. Ул чагында патшалык яңадан Давыт йортына күчәр һәм халык, минем җанымны кыеп, үзенең хакименә, Яһүдә патшасы Рехабгамга йөзе белән борылыр». Шуннан Яробам алтыннан ике бозау сыны койдырып алды да халыкка: «Гыйбадәт кылыр өчен сезгә Иерусалимгә йөрүнең хаҗәте юк. Сезне Мисыр җиреннән алып чыккан илаһлар менә шушыдыр», – дип белдерде һәм сыннарның берсен – Бәйт-Элдә, икенчесен Дан шәһәрендә урнаштырырга боерык бирде. Бу исә гөнаһның башы булды: әлеге алтын бозау сыннарыннан тыш халык мәҗүсиләр илаһы Багалга да табына башлады.

Ул заманда Исраил патшалыгында Ахия исемле Аллаһы пәйгамбәре яшәп, аңа вәхи ителмеш сүзләр* Яробам патшага һәм аның патшалыгына каршы юнәлтелгән иде: «Исраил Алласы Раббы менә нәрсә дип әйтә: башка илаһлар, пот-сыннар ясатып син Минем

* *Вәхи ителмеш сүз* – пәйгамбәрләргә Аллаһыдан ирешкән хәбәр.



ачуымны чыгардың, әлеге гамәлләрең сиңа кадәр булган барча патшаларныкыннан яманрак. Син Миннән йөз чөердең. Шуның өчен Мин Яробам йортын җәзага тартачакмын». Соңыннан һәммәсе нәкъ пәйгамбәр әйткәнчә булып чыкты.

*III Патшалар 12; 14*

## Ильяс пәйгамбәр

Еллар уза торды. Бер патшаны икенчесе алыштырды, һәм бервакыт Исраил тәхетенә Ахаб утырды. Әлеге Ахаб үзенә кадәр булган Исраил патшалары арасында иң бозыгы иде. Аның хатыны Изебел, мәҗүсиләрдән булып, Ахаб патшаны Багал сынына табынырга, Багалга багышлап гыйбадәтханә төзергә күндерде; күңеленнән Изебел Аллаһыга тугрылык саклаучыларның һәммәсен кырып бетерергә өметләнеп яшәде.

Ахаб патшалык иткән чорда Исраил халкын Аллаһы юлына өндәүче – Аллаһының тугры пәйгамбәре Ильяс булды. Ул вакытларда исраилиләр, Раббы юлыннан тайпылып, пот-сыннарга табына башлады. Шушы ятышсыз гамәлләре өчен Аллаһы аларны җәзага тартты: Ильяс пәйгамбәр игълан иткәнчә, өч ел ярым буена Исраил җиренә бер тамчы яңгыр төшмәде, һәм илдә корылык урнашты. Шуннан Раббы Ильяс пәйгамбәргә Ахабның эзәрлекләвеннән инеш буендагы аулак урында яшеренергә кушты. Аллаһы җибәргән козгыннар иртә-кичен пәйгамбәргә ипи белән ит китерделәр, ә сусынын ул инештән су эчеп басты.

*III Патшалар 16:29 – 17:6*



## Тол хатынның углына яңадан җан керү

Күпмедер вакытлар үтүгә әлеге инеш кипте. Шуннан Аллаһы аңа, Сидун Сарепатына китеп, бер тол хатынның йортында тукталырга кушты. Аллаһы әйткән хатынның өенә килеп җиткәч Ильяс аңардан эчәренә бераз су һәм ашарына бер телем икмәк сорады. Тол хатын үзенең углы белән генә яши һәм бик каты мохтаҗлык кичерә иде. Бер уч он белән чүлмәк төбендәге майдан башка аның бүтән ризыгы юк иде. Хатын шул турыда Ильяска әйткәч, тегесе аңа: «Борчылма, Раббы җиргә яңгыр яудырган көнгә кадәр кисмәгеңдә – он, чүлмәгеңдә май бетмәс», – дип җавап бирде.

Шул рәвешле, Ильяс пәйгамбәр тол хатынның йортында яши башлады, һәм Раббы могҗизалы эш кылды: Ильяс пәйгамбәр алдан әйтеп куйганча, алар көн саен мичтә икмәк пешерсәләр дә, май белән оннары һич кимемәде.

Бервакыт һич көтмәгәндә әлеге хатынның углы авырып китеп вафат булды. Кара кайгыга баткан хатын, кылган гөнаһларым өчен Аллаһының җәзага тартуыдыр дип уйлап, җансыз баласын кулына алды да ачы күз яшьләре түгеп Ильяс пәйгамбәр янына килде. «Бир әле миңа углыңны», – диде Ильяс һәм, хатынның кулыннан үле баланы алып, үзе яшәгән бүлмәдәге ятагына кертеп салды. Аннары Раббыга мөрәҗәгать итеп: «И-и Раббы, Аллаһым минем! Мине сыендырган шушы тол хатынны бәлагә салып, углының җанын кыярсың микәнни?» – диде һәм, өч тапкыр рәттән бала өстенә капланып, тагын Аллаһыга ялварды: «И-и Раббы, Аллаһым минем! Баланың җанын тәненә кайтарсаң иде!» Тугры пәйгамбәренең гозере Раббы колагына иреште һәм, баланың җаны кабат тәненә әйләнеп кайтып, бала үледән терелде. Баланы күтәреп Ильяс аның анасы янына чыкты. «Менә, кара, углың исән!» – дип баланы әнкәсенә тапшырды. Хатын, шатланып, Ильяс пәйгамбәргә: «Хәзер инде мин синең Аллаһы бәндәсе булуыңа да, син җиткергән Раббы сүзләренең хак булуына да чын-чынлап ышанам», – диде.

*III Патшалар 17:7–24*



## Багал пәйгамбәрләре һәм Ильяс

Раббы бервакыт Ильяс пәйгамбәргә Ахаб патша янына барырга һәм аңа: «Багал пәйгамбәрләрен вә мәҗүсиләрнең башка пәйгамбәрләрен, шулай ук бар халыкны Кәрмил тау башына җый», – дип әйтергә кушты. Патша әмере буенча барысы да тау башына җыелганнан соң, Ильяс аларга болай дип мөрәҗәгать итте: «Сез кайчанга кадәр шулай икеләнеп йөрерсез икән? Әгәр сез Раббыны Аллаһы дип таныйсыз икән – Аның юлына басыгыз; әгәр инде Багалны алла дип беләсез икән – аның артыннан иярегез». Әмма пәйгамбәргә җавап итеп һичбер сүз әйтүче табылмады. Аннары Ильяс җыелган халыкка болай диде: «Мин – Раббының бердәнбер исән калган пәйгамбәре, Багал пәйгамбәрләренең саны исә дүрт йөз илледер. Хәзер безгә ике үгез бозау китерсеннәр һәм Багал пәйгамбәрләре аларның берсен сайлап суйсын да утын өстенә салсын, әмма учакны кабызмасын; мин исә бозауның икенчесен утын өстенә салам, ләкин учакны кабызмыйм. Шуннан сез үзегезнең илаһыгызга гыйбадәт кылырсыз, ә мин үземнең Аллаһым Раббыга догаларымны багышлармын. Безнең догалар кабул кылынганны белдереп учакка ут салган алла – хак дөрес Алла». Халык аның сүзләре белән ризалашты.

Багал пәйгамбәрләре бозауның берсен утын өстенә салдылар да: «И-и Багал! Сүзебезгә колак салчы!» – дип кычкырырга тотындылар. Алар шулай акылдан шашар дәрәҗәгә җиткәнче көнозын аның исемен кабатладылар, әмма җавап ишетелмәде. Шуннан Ильяс җыелган халыкны үз янына чакырды һәм, Исраилнең унике ыругы санынча унике таш алып, шулардан мәзбәх төзеде дә бозауны суеп утын өстенә урнаштырды. Аннары корбанлык мал өстенә өч тапкыр дүртәр чиләк су салырга кушты, һәм мәзбәх тирәли казылган чокыр су белән тулды. Шуннан Ильяс дога кыла башлады: «И-и Раббы – Ибраһим, Исхак һәм Исраил Алласы! Синең Исраил җирендә бердәнбер Аллаһы булуыңа һәм мин, Синең колың, боларның һәммәсен Синең кушуың буенча эшләгәнгә менә хәзер шушында бөтенесе дә ышансыннар иде. Минем догаларымны ишет, и-и Раббы, ишет! Шушы халык, Раббы, Синең Аллаһы булуыңа инанса иде, шул чагында Син аларның йөрәген кабат яулап алыр идең». Раббы Үз пәйгамбәренең догаларын ишетте һәм шул мәлне, күктән ут иңеп, корбан малын да, утынны да, әйләнә-тирәдәге ташларны



да яндырып бетерде, чокырдагы суны да киптерде. Шушы хәлне күреп, һәммәсе йөзтүбән җиргә капланды һәм: «Раббы – бердәнбер Аллаһы, Раббы – бердәнбер Аллаһы!» – дип тәкрарларга тотынды. Шул рәвешле, Раббы Үзенең бердәнбер Аллаһы булуын раслады, ә Багал пәйгамбәрләренең ялганчы икәнлеген фаш итте.

*III Патшалар 18:18–39*

## Су һәм май белән булган могҗиза

Ильясның дәвамчысы Элиша, Аллаһының ихтыяры белән бөек пәйгамбәргә әйләнеп, Аллаһы аның аша гаҗәп күп могҗизалар башкарды. Бервакыт Әрихә шәһәрендә тукталгач, Элиша янына шунда яшәүче берничә кеше килеп: «Шәһәребез бик әйбәт җирдә урнашкан, тик биредә су начар, шул сәбәпле җиребез кысыр», – диде. Шунда Элиша алардан төбенә тоз салынган чүлмәк сорап алды да, чишмә буена барып, тозны суга сипте һәм әйтте: «Раббы болай ди: Мин әлеге суны сафландырдым, ул сезгә башкача үлем дә китермәс, җирне дә уңдырышсыз итмәс». Шушы хәлдән соң, дөрестән дә, чишмәнең суы сафланды.

Беркөн Элиша янына бер тол хатын елап килде дә үзенең хәсрәте турында сөйләде. Иренең вафатыннан соң әлеге хатын бурычын түли алмаганга, бурычка биреп торган кеше хәзер шуның өчен аның ике улын да үзенә коллыкка алып китмәкче икән. Бичара хатынга ярдәм итмәкче булып, Элиша аңардан: «Әйт әле, синең өеңдә нәрсәләр бар?» – дип сорады. «Бер чүлмәк майдан башка бернәрсәм юк», – дип җавап бирде хатын. «Бар, бөтен күршеләреңне йөреп чыгып буш савыт җый да, ишегеңне бикләп, угылларың белән бергә үзеңнең чүлмәгеңнән әлеге буш савытларның бөтенесенә май тутыр», – диде аңа пәйгамбәр.

Теге хатын, Элиша яныннан китеп, барысын да ул кушканча эшләде: күршеләреннән чүлмәкләр, савытлар җыеп керде дә, өй ишеген бикләп, угыллары белән бергәләп үзенең чүлмәгеннән бөтен буш савытларга май тутырырга кереште. Савытларның һәммәсе тулып беткәч, улыннан тагын берәр буш чүлмәк сорады, әмма улы аңа: «Буш савытлар бүтән юк», – дип җавап бирде, һәм май шуннан соң агудан туктады.

Бөтен савытлар май белән тулганнан соң, әлеге хатын, Элиша янына килеп, бу могҗиза турында сөйләп бирде. «Бар, майны сатып бурычыңны түлә; калганы сиңа һәм угылларыңа җан асрарга җитәр», – диде аңа Элиша.

*IV Патшалар 2:19–22; 4:1–7*



## Арам иленең гаскәрбашы Нагаман

Арам патшасының Нагаман исемле гаскәрбашы бик тә могтәбәр һәм танылган бер кеше иде. Әмма ул яман авырудан – махау* зәхмәтеннән интегә иде.

Кайчандыр бервакыт арамиләр, Исраил җиренә басып кергәч, кечкенә бер кызны әсир алган булалар, шуннан әлеге кыз Нагаман хатынында хезмәтче булып кала. Пәйгамбәр Элиша аша Раббы кылган могҗизалар турында ишетеп белгән әлеге кыз көннәрдән беркөнне үзенең хуҗабикәсенә: «Әгәр минем хуҗам Нагаман Самареядәге пәйгамбәр янына барып килсә, ул аны махау зәхмәтеннән савыктырыр иде», – диде. Исраил җиреннән килгән кыз менә нәрсә әйтә дип, Нагаман үзенең хуҗасы патшага җиткергәч, Арам патшасы аңа : «Исраилгә барырга җыен, Исраил патшасына миннән хат алып барырсың», – диде.

Хатыны белән хушлашып, Нагаман Исраил тарафына юл алды. Исраил патшасына килеп җиткәч ул: «Ошбу хатым белән бергә синең хозурыңа хезмәтчем Нагаманны җибәрәм, аны махау зәхмәтеннән дәвала», – дигән сүзләр язылган хатны патшага тапшырды. Исраил патшасы хатны укыганнан соң өстендәге киемнәрен ертып ташлап: «Үтерер яисә терелтер өчен Аллаһы түгел бит мин! Нәрсә ул минем янга, махау зәхмәтеннән коткар, дип кеше җибәрә? Күрәсезме, минем белән дошманлашыр өчен сәбәп эзли ул!» – диде.

Элиша исә бу хакта ишеткәч: «Нәрсә дип син өстеңдәге киемеңне ертасың? Минем янга җибәр аны, Исраилдә пәйгамбәр барлыгын күрсен», – дип әйтергә патша янына кеше җибәрде.

*IV Патшалар 5:1–8*

* Махау – йогышлы тире авыруы; русчасы: проказа.



## Нагаманның савыгуы

Шуннан Нагаман, Элиша янына юнәлеп, ат-арбалары белән аның ишек төбенә килеп туктады. Элиша: «Бар, җиде кат Үрдүн суында коенып-юынып чык – тәнең яңарыр һәм авыруыңнан чистарынырсың», – дип әйтер өчен Нагаман янына үзенең хезмәтчесен чыгарды. Әлеге сүзләрне ишетеп, Нагаман ачуланып китеп барды. «Яныма чыгар да үз Алласын, Раббыны, ярдәмгә чакырып, авырткан урынга кулын салыр һәм мине махау зәхмәтеннән арындырыр, дип уйлаган идем. Дәмәшкътәге Абана белән Парпар сулары Исраилнең барлык елгаларыннан яхшырак түгелме әллә? Шул суларда коенып чистарына алмый идеммени мин?» – дип ярсый бирде ул.

Ләкин хезмәтчеләре аңа: «Атабыз, әгәр пәйгамбәр сиңа ифрат та әһәмиятле башка бер эш кушкан булса, әллә үтәмәс идеңме? „Коенып чык, чистарынырсың“ дигәнне генә башкарырсың инде», – диделәр. Нагаман, алар белән ризалашып, пәйгамбәр кушканча Үрдүнгә җиде кат чумып чыкты; шуннан соң тәне сабый баланыкы сыман яңарып-чистарып калды.

Аннары Нагаман кабат Аллаһы кешесе Элиша янына әйләнеп килде һәм аңа: «Хәзер инде миңа төгәл мәгълүмдер – җир йөзендә яшәүче барча халыклардан бары тик Исраил генә Аллаһыны бар дип белә. Ә хәзер хезмәтчеңнең бүләген кабул итеп ал», – диде. Нагаман күпме кыстаса да, Элиша бүләкне алырга ризалашмады. Хушлашкан вакытта Нагаман моннан ары Раббыдан башка һичбер илаһка яндыру корбаны да, башка төр корбан да китермәскә вәгъдә бирде.

*IV Патшалар 5:9–17*



# Күзләре сукырайган баскынчылар

Арам иле белән Исраил арасында сугыш барган чакта, Элиша арамиләр гаскәренең кайларда урнашуы турында Исраил патшасына җиткерә торды, чөнки аңа бу хакта Аллаһы хәбәр бирә иде. Шуңа күрә Исраил җиңү артыннан җиңүләр яулады. Арам патшасының исә бу хәлгә эче пошты; күңеленнән ул, минем гаскәриләр арасында, мөгаен, исраилиләргә хәрби серләрне җиткереп торучы хыянәтче бардыр, дип уйлады. Әмма хезмәтчеләренең берсе аңа: «Безнең арада хыянәтче юк, патша әфәндем, әмма Исраилдәге Элиша пәйгамбәр хәтта йокы бүлмәндә сөйләгән сүзләреңне дә Исраил патшасына җиткерә ала», – диде.

Элиша пәйгамбәрнең кайсы шәһәрдә яшәгәнен белгәннән соң, Арам патшасы, аны әсир төшерергә ниятләп, бик зур гаскәр җибәрде. Алар, төнлә килеп җитеп, шәһәрне камап алдылар. Ләкин арамиләр якынлаша башлагач, Элиша, Раббыга дога кылып: «Күзләрен күрмәс ит шуларның», – диде, һәм Элишаның сүзләре буенча Раббы аларның күзләрен күрмәс итте. Шуннан Элиша пәйгамбәр, күзләре сукырайган арамиләрне үз артыннан ияртеп, ул заманда Төньяк патшалыкның мәркәзе булган Самарея тарафына юнәлде. Самареягә килеп җиткәч Элиша: «Раббы! Күрә алсыннар өчен ач боларның күзләрен», – диде, һәм Раббы аларның күзләрен ачты: баксаң, тегеләр Самареянең урта бер җирендә басып торалар икән. Исраил патшасы, арамиләрне күреп, Элишадан: «Атам, кырып бетеримме аларны?» – дип сорады. «Тимә син аларга, – диде Элиша, – кылычың һәм угың белән аларны әсир итүче синме әллә? Аларга икмәк һәм су бир; ашап-эчсеннәр дә үзләренең хуҗалары янына кайтып китсеннәр». Патша аларга мул итеп табын әзерләде, тегеләр ашады-эчте. Аннары ул аларны кайтарып җибәрде, һәм арамиләр үз хуҗаларына әйләнеп кайтты. Шуннан соң Арам сугышчылары Исраил җиренә йөрмәс булды.

*IV Патшалар 6:8–23*



## Тәхеткә Йоашның килүе

Ахазея – Яһүдә патшаларының берсе иде. Ахазея сугыш кырында һәлак булганнан соң, аның имансыз һәм явыз анасы Аталия, тәхеткә үзе утырырга өметләнеп, патшаның бөтен нәсел-нәсәбен кырып бетерергә ният итте. Әмма Ахазеянең сеңлесе Яһошеба, Ахазеянең Йоаш атлы улын Аталиядән яшереп калып, Яһүдә илендә Аталия патшалык иткән алты ел дәвамында аны Раббы йортында качырып тотты.

Йоашка җиде яшь тулгач, рухани Еһояда, бөтен сугышчыларны, йөзбашларын, җитез аяклы чабышчыларын һәм патшаның җансакчыларын Раббы йортына чакырып, аларга патша углын күрсәтте. Шуннан алар Йоашны патша тәхетенә утыртырга карар кылдылар. Сугышчылар, кулларына корал тотып, Аллаһы йортын әйләндереп алдылар; рухани Еһояда, патша углы Йоашны алып килеп, аңа таҗ кигезде, башына зәйтүн мае сөртте. Йоашны сәламләп бөтенесе: «Яшәсен патша!» – дип кычкыра башлады. Бу хакта ишетеп белгән Исраил халкы рәхәтләнеп күңел ачты. Аталияне исә кылычтан уздырдылар.

Рухани Еһояда кул астында тәрбия алган мәлдә яшь патша Йоаш Раббы күзенә ятышлы күренгән гамәлләр кылды. Үсеп җитеп балигъ булганнан соң Йоаш Аллаһы йортының җимерелгән урыннарын төзекләндерергә боерык бирде. Әмма Еһояда дөнья куйгач, Йоаш яман киңәшчеләрнең сүзләренә колак сала башлады һәм, бердәнбер Аллаһыдан йөз чөереп, пот-сыннарга табына торган булып китте, шул рәвешле, Раббы ихтыярына каршы килә торган гамәлләр кылды.

Бервакыт Йоаш, халык кылган яман гамәлләрне Еһояда углы Зәкәриянең фаш итүен ишетеп, аны Аллаһы йорты ишегалдында үтерергә әмер бирде. Шушы хәлләрдән соң ил өстенә бер-бер артлы афәтләр килә башлады; арамиләр, Иерусалимне тәмам бөлгенлеккә төшереп, Аллаһы йортындагы бөтен хәзинәне үз илләренә алып китеп бетерделәр. Йоаш патшаны исә, түшәктә авырып яткан чакта, ике хезмәтчесе үтереп чыкты.

*IV Патшалар 11; 12; II Елъязма 24:1–25*



## Тәкәббер Уззия патшаның җәзага тартылуы

Яһүдә патшалыгында Уззия унынчы патша булды. Тәхеткә утырганда аңа нибары уналты яшь иде, һәм Иерусалимдә ул илле ике ел дәвамында идарә итте.

Уззия патша Раббы күзенә ятышлы күренгән гамәлләр кылды. Рухани Зәкәрия исән чакта ул Аллаһыга тугры булды, әлеге Зәкәрия аны Аллаһыдан куркырга өйрәтте; Аллаһыга иман китереп яшәгән көннәрдә Аллаһы аның юлдашы булды. Уззия Иерусалим каласында да, чүлләрдә дә ныгытмалар төзетте, тау итәкләрендә, үзәнлекләрдә аның бихисап күп маллары утлап йөргәнгә, ул байтак кына коелар казытты; күңеле игенчелеккә ятканга күрә, тау битләрендә һәм уңдырышлы җирләрдә аның күп санлы игенчеләре, бакчачылары эшләде. Уззиянең өч йөз җиде мең дә биш йөз сугышчыдан торган гаскәре булып, аларның һәммәсе өчен ул калкан, сөңге, очлым, көбә кием, җәя һәм ташаткыч өчен таш әзерләде. Аннары ул, Иерусалимдә гаҗәеп оста җайланмалар эшләтеп, югарыдан таш һәм ук атар өчен аларны манара башларына, дивар почмакларына куйдырды. Шулай итеп, Уззиянең даны еракларга таралды, чөнки ул, үзенең патшалыгын ныгытып, кодрәтле бер патшага әйләнде.

Әмма көч-куәте арткан саен аның йөрәгендә тәкәбберлек тә үсә барды, һәм шул нәрсә аны һәлакәткә китерде: ул үз Раббы Алласының канунын бозды. Уззия патша, һаваланып китеп, хуш исле сумала-майлар көйрәтү нияте белән Раббы йортына аяк басты. Рухани Азария, аның белән бергә Раббының сиксән рухание, Уззия патшаны туктатмакчы булып, аның артыннан иярделәр. «Раббы хөрмәтенә хуш исле сумала көйрәтү синең эш түгел, Уззия; шушы эшкә Аллаһы тарафыннан билгеләнгән руханиларның, Һарун угылларының вазифасы ул; син хилаф эш кыласың, чык изге урыннан, бу эшең өчен Раббы Алла сиңа мәртәбә өстәмәс!» – диде алар. Сумала-майлар көйрәтү савытын тотып торган Уззиянең аларга бик нык ачуы кабарды; һәм шул вакыт, руханиларның күз алдында, Раббы йортының сумала-майлар көйрәтү мәзбәхе каршында Уззия патшаның маңгаена махау зәхмәте бәреп чыкты. Баш рухани Азария һәм бүтән руханилар, Уззия маңгаендагы махау зәхмәтен күреп, аны Раббы йортыннан чыгарга мәҗбүр иттеләр; Раббының каргышы төшкән патша үзе дә тизрәк китү ягын карады. Уззия патша




соңгы көннәренә кадәр махау зәхмәтеннән арына алмыйча аерым йортта яшәде, аңа Раббы йортына керү тыелган иде. Патша сарае белән дә, халык белән дә аның углы Иотам идарә итте.

*II Елъязма 26*

## Исраилнең Аллаһыдан баш тартуы

Исраил угылларына килгән бәланең сәбәбе шунда иде: үзләрен Мисыр җиреннән алып чыккан, фиргавен кулыннан азат иткән Раббы Аллалары каршында алар гөнаһ эшләр кыла башладылар – чит-ят илаһларга табындылар, Раббы тарафыннан сөрелгән мәҗүси халыкларның гореф-гадәтләренә иярделәр; Исраил патшаларының хаталарын кабатлап, Раббы күзенә ятышсыз күренгән гамәлләр кылып, күзәтү манаралары торган урыннарда да, ныгытылган шәһәрләрдә дә, үзләре яшәгән бөтен авыл-калаларда илаһларга багышлап корбан китерү урыннары төзеделәр, һәр калку җирдә, күләгәле һәр агач ябалдашы астында изге ташлар һәм алиһә Аширә хөрмәтенә сыннар урнаштырдылар; аларның күз алдыннан Раббы сөреп җибәргән халыклар сыман, сумала көйрәтү гадәтенә керешеп киттеләр. Раббы Аллалары: «Алай эшләмәгез», – дип әйтә торса да, исраилиләр, пот-сыннарга табынуларын дәвам итеп, Аның ачуын чыгардылар. Раббы Үзенең пәйгамбәрләре һәм гаиптән хәбәр бирүчеләре аша: «Яман юлыгызны ташлап, ата-бабаларыгызга әйтеп калдырган һәм Үземнең колларым – пәйгамбәрләрем – аша сезгә җиткергән боерык вә кагыйдәләремне, Канунымда әйтелгәннәрне төгәл үтәгез», – дип, Исраил белән Яһүдәне һаман кисәтеп килде. Әмма алар бу сүзләргә колак салмадылар, үз Аллалары Раббыга иман китермәгән тискәре ата-бабалары сыман, үҗәтләнүдә булдылар; Аның кагыйдәләрен, ата-бабалары белән төзегән Килешүен, Аның күрсәтмә-кисәтүләрен санга сукмадылар, ниндидер буш нәрсәләргә ияреп китеп, үзләре дә буш, рухсыз кешеләргә әйләнделәр. Раббы аларны мәҗүси халыкларга иярүдән кисәтеп куйса да, әйләнә-тирәдә яшәгән шул халыклар юлыннан киттеләр. Үз Аллалары Раббының әмерләреннән йөз чөереп, үзләренә ике бозау сыны койдырып алдылар, алиһә Аширәгә багышлап гыйбадәтханәләр төзеделәр, йолдызларга табындылар, мәҗүсиләр илаһы Багалга баш иделәр, үзләренең кыз-угылларын ут-ялкын аша уздырдылар, күрәзәлек иттеләр, сихер кылдылар; Раббы алдында явызлыклар эшләп, Аның ачуын китерделәр.



Шулай итеп, Раббының исраилиләргә бик нык ачуы чыкты, һәм Ул алардан йөз чөерде; Яһүдә ыругыннан башка Аның хозурында беркем калмады, ләкин алар да үзләренең Раббы Алласының әмерләрен үтәмәде.

*IV Патшалар 17:7–18*

## Ашшурның Исраилне яулап алуы

Төньяк Патшалыкның патшасы, ягъни Исраилнең соңгы патшасы Һошея тугыз ел дәвамында – 730 елдан 721 елга кадәр патшалык итте һәм Раббы күзенә ятышсыз күренгән гамәлләр кылды. Исраилнең төньяк-көнчыгышында гаять зур Ашшур патшалыгы урнашкан булып, аның башкаласы Ниневә иде. Ашшурның юлбашчылары бик тә бәгырьсез һәм хакимлек итәргә яратучан бәндәләр иде. 724 елда Шалманесер патша җитәкчелегендәге куәтле Ашшур гаскәре Исраил җиренә аяк басты. Исраил патшасы Һошея, Шалманесерга буйсынырга мәҗбүр булып, аңа ясак түли башлады.

Әмма берзаман Һошея, ярдәм сорап Мисыр патшасы Со янына үзенең илчеләрен юллаганнан соң, елның-елында Ашшур патшасы Шалманесерга түли торган ясагын җибәрми башлады; Ашшур патшасы, Һошеянең хыянәте турында белеп, аны сак астына алды һәм зинданга япты. Аннары, Исраил җиренә һөҗүм итеп, Самареягә таба юнәлде һәм өч ел дәвамында аны камалышта тотты. Һошея хакимлегенең тугызынчы елында Ашшур патшасы Самареяне яулап алды да, исраилиләрне Ашшурга сөреп җибәреп, аларны Халак шәһәрендә, Хабур елгасы буендагы Гөзән төбәгендә, шулай ук мадайлылар яшәгән шәһәрләрдә урнаштырды. Шулай итеп, Төньяк патшалык таркалды.

Үз халкының гамәлгә сыймаган эшләре өчен Раббының җәзага тартуы иде бу. Шушы хәл Мәсих туганчы 721 елда булды. Бары тик ике гасырдан соң гына исраилиләрнең кайберләре Ашшурдан Исраилгә әйләнеп кайта алды. Чама белән шул ук вакытта яһүдиләр дә, ягъни Көньяк патшалыкта яшәүче гыйбриләр дә, үз илләренә әйләнеп кайтты.

*IV Патшалар 17:2–6*



## Самареялеләр

Төньяк патшалыкта яшәүче исраилиләрне әсир итеп ерак Ашшур мәмләкәтенә куып алып киткәннән соң, аларның илләре бөтенләй диярлек бушап калды. Күпмедер вакытлар үткәч, Ашшур патшасы Исраил шәһәрләренә Бабилдән һәм башка илләрдән кешеләр күчереп китерде. Күчеп килгән халык, Самареядә җирләшеп китеп, аның калаларында көн күрә башлады. Беренче мәлләрдә әлеге халык Раббыны санламады, шуның өчен Раббы, алар өстенә арысланнар җибәреп, ерткыч җанварлар кешеләргә һөҗүм итә иде. Шуннан Ашшур патшасына килеп болай дип әйттеләр: «Самарея калаларына син күчереп урнаштырган халык әлеге җирнең Алласы кануннарын белми, шул сәбәпле Ул алар өстенә арысланнар җибәрә, һәм ерткыч җанварлар аларның гомерен өзә». Моңа җавап итеп Ашшур патшасы, халык арасында яшәп шул җир Алласының кануннарына өйрәтер өчен, сөрелгән исраилиләр арасыннан берәр руханины киредән Самареягә кайтарырга боерды.

Самареядән сөрелгән руханиларның берсе, килеп, Бәйт-Элдә яши һәм халыкны Раббыдан куркырга, Аны хөрмәтләргә өйрәтә башлады. Шуның белән бергә, һәрбер халык, үз илаһларының сыннарын булдырып, кайчандыр самареялеләр төзеп калдырган мәҗүси гыйбадәтханәләрдә урнаштырды. Алар Раббыны хөрмәтләделәр, әмма бирегә күчеп килгәнче кайсы халык арасында яшәгән булсалар, шул халыкның гадәте буенча үз илаһларына да табына бирделәр.

Инҗилдә телгә алынган самареялеләрне яһүдиләр шул халыкларның токымы дип саный иде. Гәрчә Инҗил заманында самареялеләр, үзләренең мәҗүси илаһларын онытып, бары тик Раббыга гына табынсалар да, әле һаман яһүдиләрдән бик нык аерылалар һәм алар белән дошмани мөнәсәбәтләрдә яшәүләрен дәвам итәләр иде.

Самареялеләрнең үз руханилары булып, алар үз гореф-гадәтләренә тугрылык саклады. Алар хәтта Гәризим тавында үзләренә аерым гыйбадәтханә төзеделәр, әмма соңрак яһүдиләр аны җимерделәр.

*IV Патшалар 17:24–33*



# Хизәкыйя патшаның догасы

**721** елда ашшурлылар Төньяк патшалыкны яулап алып анда яшәүче исраилиләрне Ашшурга күчергәннән соң, әллә ни зур булмаган Көньяк патшалык Яһүдә, Аллаһы ярдәме белән, әле тагын 130 ел дәвамында исән-имин кала бирде.

Хизәкыйя шул Яһүдә патшаларының берсе иде; егерме тугыз ел дәвамында ул Иерусалимдә патшалык итте. Яһүдә иленең бөтен патшалары арасында ул иң яхшысы булды, чөнки Раббы юлыннан һич тайпылмады, Муса пәйгамбәргә Раббы әйтеп калдырган әмерләрне төгәл үтәде. Хизәкыйя пот-сыннарга табынучыларга каршы көрәш башлады: чит илаһларга багышланган сыннарны җимереп, халыкны бердәнбер Аллаһыга итагать итәргә өндәде. Аннары Ашшур патшасына каршы баш күтәреп, аңа хезмәт итүдән туктады.

Шуннан Ашшур патшасы Санхериб, Хизәкыйянең буйсынуын таләп итеп, аңа яный башлады һәм, Яһүдә патшасының Аллаһыга табынуыннан көлеп, Хизәкыйягә хат җибәрде. Әлеге хатта Хизәкыйянең һичбер каршылык күрсәтмичә аны, ягъни Ашшур патшасы Санхерибне тануын таләп итте. Чөнки әйләнә-тирәдәге бөтен патшалыклар инде Ашшур патшасының кул астында булып, аның кодрәтеннән аларны бернинди илаһлар да коткарып кала алмаган иде.

Әлеге хатны алганнан соң, Хизәкыйя Аллаһы йортына юнәлде һәм Раббы каршына килеп хатны ачты, аннары гыйбадәт кылды да: «И-и Раббы, керубимнәр* өстендә утыручы Исраил Аллаһысы! – диде ул. – Син бөтен җир йөзендәге патшалыкларның бердәнбер Аллаһысы, Син күкне вә җирне Бар итүче. Колагыңны куеп, Раббы, сүзләремне ишет, күзләреңне ачып, Раббы, карап бак, бар вә бер булган Аллаһыны яманлар өчен җибәрелгән Санхерибнең сүзләрен ишет! Ашшур патшаларының әйләнә-тирәдәге халыкларны вә аларның җирләрен туздырып, илаһларын утка ташлаулары хак, и Раббым; ләкин ул илаһлар алла түгел, ә бәлки кеше кулы ясаган әйбер, агач вә таш кынадыр, шуңа күрә алар юк ителгәндер дә. Әмма хәзер, Аллаһыбыз Раббы, Ашшур патшасының кулыннан коткар

---

* *Керубимнәр* – биредә сүз Аллаһы сандыгының капкачы өстенә куелган ике керубим сыны турында бара; шунда Аллаһы тәхете булган. Керубим – Аллаһы хезмәтендәге рухи зат.



безне, җир йөзендәге бөтен патшалыклар Синең, Раббы, бердәнбер Аллаһы булуыңа ышансыннар».

Хизәкыйя патшаның догасы Раббыга барып иреште һәм Ул, Үзенең изге исеменә карата кылынган дорфалыклары өчен, ашшурлыларны җәзага тартты, һәм алар тар-мар ителде.

*IV Патшалар 18:1–7; 19:9–19*

# Йошия патшаның анты

Шулай ук Йошия дә Яһүдә патшаларының берсе иде. Тәхеткә утырганда аңа сигез яшь булып, утыз бер ел дәвамында ул Иерусалимдә идарә итте. Ул, Раббы күзенә ятышлы күренгән гамәлләр кылып, уңга-сулга тайпылмыйча ерак бабасы Давыт юлыннан йөрде.

Уналты яшьлек үсмер чагыннан бөтен күңеле белән Раббыга сыгынган Йошия патшалык итүенең уникенче елында Яһүдә һәм Иерусалим җирләрен потлардан һәм аларның мәзбәхләреннән арындыра башлады. Ул бөтен Яһүдә җирендәге потларны җимерде, илаһлар хөрмәтенә куелган сыннарны көл-тузанга әйләндерде. Патшалык итүенең унсигезенче елында Йошия Раббы йортында төзекләндерү эшләрен башларга әмер бирде. Гыйбадәтханәне төзәтү-яңарту өчен бар халык күп итеп көмеш җыеп тапшырды.

Раббы йортында төзекләндерү эшләрен башкарган вакытта рухани Хилкыйя Раббының Муса аша биргән Канун китабына тап булды. Рухани әлеге китапны кәтип* Шафанга китерде, Шафан исә аны патшага илтеп тапшырды. Йошия патша китапта язылганнарны укып бирергә боерды. Табылдык китапта язылган сүзләрне укуга, Йошиянең коты алынды: чөнки бу сүзләр Аллаһы Кануны булып, халык күптән инде әлеге китапта язылган буенча гамәл кылмый иде.

Тәмам борчуга калган Йошия елый-елый Раббының гафу кылуын үтенде. Аннары патша Раббы йортына юнәлде һәм, бар халыкны җыеп, Раббы йортында табылган Килешү китабындагы сүзләрне кычкырып укып бирде. Шуннан соң ул Раббы алдында нәзерен әйтте: әлеге китапта язылганча, Аның әмерләрен, күрсәтмәләрен, кушканнарын ихлас күңелдән үтәргә ант эчте. Шулай ук ул барча халыкка Аллаһы белән төзегән әлеге Килешүгә тугры булырга нәзер әйтергә әмер бирде.

Шул рәвешле, Йошия Исраил угыллары яшәгән бөтен җирдән мәҗүсиләрнең җирәнгеч пот-сыннарын себереп түкте. Йошия исән чакта бар халык, үзенең Раббысына тугры калып, Аның юлыннан тайпылмады.

*II Елъязма 34:1–8, 14–19, 29–33*

---

* *Кәтип* – язып торучы кеше, секретарь.



## Иремия пәйгамбәр

Иремия пәйгамбәр һәрчак Аллаһы хакында сөйли килде. Бервакыт ул, чит-ят илаһларга табынган, аларга корбан китергәннәре өчен, Иерусалим халкын гаепләп чыкты. Аларны киләчәктә ни-нәрсә көткәнлеге хакында Иремия башта Тофетта бәян итте. Аннары, Иерусалим каласына килеп, Аллаһы йортының ишегалдына кереп басты да җыелган халыкка болай дип белдерде: «Күкләр Хуҗасы Раббы, Исраил Алласы менә нәрсә ди: „Алдан әйтеп куйганча, шушы каланы һәм аның әйләнә-тирәсендәге шәһәр-авылларны байтак бәла-казаларга дучар итәрмен, чөнки алар гаять үҗәтләр һәм Мин әйткәннәргә колак салмыйлар“».

Иремиянең пәйгамбәрлек сүзләрен ишеткәннән соң гыйбадәтханәдәге рухани, ачуы чыгып, Иремиягә китереп сукты, аннары аның аяк-кулларын бәйләп зинданга япты. Икенче көнне ул аны зинданнан чыгарды, һәм Иремия яңадан да Яһүдә җирендәге бөтен калаларның һәм бар халыкның, шулай ук Раббыдан йөз чөергән руханиның алдагы язмышы турында сөйләргә тотынды. Аннары Иремия мондый сүзләр белән Аллаһыга мөрәҗәгать итте: «Син мине Үзеңнең артыңнан әйдәдең, Раббым, – һәм мин Синең артыңнан киттем, Син миннән көчлерәк – һәм Син мине җиңдең; мин көн дә адәм мәсхәрәсенә калам, һәркем мине мыскыл итә. Алда көткән җәбер-золым һәм талау-туздыру хакында ачынып сөйлим мин, әмма Раббы сүзе өчен көн дә кимсетү һәм мыскыллау гына ишетәм. Шуннан мин: „Аның хакында кабат исләренә төшермәм һәм моннан ары Аның исеменнән сөйләмәм“, – дип уйладым, әмма минем йөрәгемдә ялкын иде, сөякләрем дә ут булып янды. Әлеге ут-ялкынны тыярга өметләнеп, мин тәмам хәлдән тайдым, ләкин барыбер тыя алмадым».

Тугры пәйгамбәрнең дошманнары һәрвакыт күп булды, әмма Аллаһы һәрчак аның иманын ныгытып торды. Шуңа күрә Иремия түбәндәге сүзләрне әйтте: «Раббы, пәһлевандай сугышчы сыман, һаман янәшәмдә; шуңа күрә мине эзәрлекләүчеләр, сөрлегеп калып, мине җиңә алмыйча мәсхәрә ителер, чөнки кылган гамәлләре акылсыздыр. Кодрәтле Раббым! Син тәкъва



кешене сыныйсың, анының җанын һәм йөрәген күрәсең. Раббыга дан җырлагыз, Аңа мактаулар яудырыгыз, чөнки бичара бәндәне Ул залимнәрдән коткара».

*Иремия 19:13–15; 20:1–13*

## Иремия әйткән сүзләрне Барухның яза баруы

Бервакыт Иремия пәйгамбәргә Раббы сүзе булды: «Кәгазь төргәге ал да Исраил, Яһүдә һәм барча халыклар турында әйтә килгән сүзләремнең һәммәсен – алар өстенә җибәрергә җыенган бәла-казалар турында язып куй. Мине ишетеп, Яһүдә халкы, бәлки, үзенең яман юлыннан кире борылыр, һәм Мин аларның бөтен җинаятьләрен вә гөнаһларын кичерермен».

Шуннан Иремия, Барух исемле бер адәмне чакырып алып, Раббыдан ирешкән сүзләрнең һәммәсен әйтеп яздырды. Раббыдан иңгән сүзләрне Барух кәгазь төргәгенә язып алганнан соң, Иремия аңа: «Мин әлегә сак астында, шуңа күрә Раббы йортына бара алмыйм; димәк ки, ураза көнендә син шунда бар да Раббының минем аша әйтелгән, шушы төргәккә язылган сүзләрен бөтен Иерусалим халкы һәм башка калалардан килгән барча яһүдиләр каршында кычкырып укы. Алар, бәлки, түбәнчелек белән Раббыга догаларын кылырлар, яман юлларыннан кире кайтырлар, чөнки бу халыкка Раббының ачуы үтә көчледер».

Нерия углы Барух Иремия пәйгамбәр кушканның һәммәсен үтәде. Яһүдә патшасы Йошия углы Яһоякыйм хакимлегенең бишенче елында, тугызынчы айда Иерусалимдә яшәүчеләрнең барысы, шулай ук Яһүдәнең башка калаларыннан Иерусалимгә килгән бар халык өчен Раббы хөрмәтенә ураза игълан ителде. Шул көнне Барух кәгазь төргәгенә язылган Иремия сүзләрен Раббы йортында кычкырып укып бирде.

*Иремия 36:1–10*



## Пәйгамбәрлек сүзләре язылган төргәкне Яһоякыйм патшаның утка салуы

Иремия пәйгамбәрнең сүзләре язылган төргәкне кәтип Барух Раббы йортында укып биргәннән соң, сарай түрәләренең кулы алынды, һәм алар бу хакта шундук Яһоякыйм патшага хәбәр иттеләр. Патша төргәкне алып килергә һәм укып бирергә боерды.

Патшаның үз сараенда, күмер салынган җылыткыч каршында утырган вакыты иде. Әлеге төргәкне алып килеп укырга тотындылар; патша исә, китапның укылган өлешен пычак белән кисеп алып, утка ыргыта торды. Шул рәвешле ул бөтен төргәкне яндырып бетерде. Яһоякыйм патша да, аның хезмәтчеләре дә Аллаһы сүзенә ышанмадылар, Иремия пәйгамбәрнең, Раббыга буйсыну күрсәтмәгән өчен яһүдиләрне тиздән Бабил патшасы әсир алачак, дигән кисәтүен ишетеп тә куркуга төшмәделәр. Яһоякыйм патша Барух белән Иремияне кулга алырга боерды, әмма эзәрлекли чыгучылардан Раббы аларны яшереп калды.

Кәтип Барухка Иремия әйтеп яздырган төргәкне патша яндырганнан соң, Иремиягә Раббыдан мондый сүз килеп ирешә: «Икенче бер төргәк ал да Яһүдә патшасы Яһоякыйм утка салган кәгазьдәге сүзләрнең һәммәсен яңадан язып куй. Ә Яһүдә патшасы Яһоякыймга, Раббы болай дип әйтә, диген: „Бабил патшасы һичшиксез килер, бу җирне талар, андагы кешеләрне вә терлекне кырып бетерер, дигән сүзләрне кульязма төргәгенә язган өчен Син Иремиягә янадың, шул кульязманы утка салдың. Әнә шуның өчен, әй Яһүдә патшасы Яһоякыйм, Раббы сиңа менә нәрсә ди: Давыт тәхетендә утырырдай нәсел варисларың тумас синең, мәетең көндезге эсседә һәм төнге салкында җирләнмичә ятар. Кылган явызлыкларың өчен үзеңә, нәселеңә һәм хезмәтчеләреңә Минем каһәрем төшәр. Мин аларга һәм Иерусалим халкына, шулай ук Яһүдә халкына алдан әйтеп куйган бөтен бәла-казаларны җибәрермен; бу хакта Мин алдан хәбәр иткән идем, ләкин Мине тыңлаучы табылмады“».

Шуннан Иремия икенче төргәкне алып Нерия углы Барух кәтипкә бирде, һәм ул Яһоякыйм патша утка салган төргәктә язылганнарның һәммәсен кабат яңа төргәккә теркәп куйды; анда, элек язылганнарга өстәп, тагын бик күп нәрсәләр язылган иде.

*Иремия 36:14–32*



## Бабилнең Яһүдәне яулап алуы

Барысы да Раббы Үзенең пәйгамбәре Иремия аша хәбәр итеп куйганча булды: яһүдиләр Бабил патшасы Нәбухаднессар тарафыннан әсир ителде, чөнки бөтен кисәтүләргә һәм фаш итүләргә карамастан, халык Аллаһы каршында тәүбәгә килмәде, пот-сыннарга табынуын, явыз, гөнаһлы гамәлләр кылуын дәвам итте – һәм шуның өчен Раббы аларны җәзага тартты. Көньяк патшалыкта яшәүчеләр, Раббының Төньяк патшалыкны ни рәвешле җәзага тартуын күреп торсалар да, шул хәлләрдән сабак алмыйча ятышсыз гамәлләр кылдылар, һәм Раббы, моннан йөз утыз ел элек Исраилне җимергән сыман, Бабил гаскәрләрен җибәреп бу патшалыкны да тар-мар итәргә булды.

Иерусалим тәхетенә утырганда Яһоякыйм патшаның углы Яһояхин унсигез яшендә булып, ул бар яктан да атасын кабатлады һәм Раббы күзенә ятышсыз күренгән гамәлләр кылды. Патшалык итүенең өченче аенда Бабил патшасының гаскәре Иерусалимне камап алды. Сугышчылар каланы камалышта тоткан чакта Бабил патшасы Нәбухаднессар үзе дә шәһәр янына килде. Яһүдә патшасы Яһояхин үзенең анасы, хезмәтчеләре, түрәләре һәм сарай кешеләре белән бергә Бабил патшасы янына чыгып аңа әсирлеккә бирелде. Раббы алдан әйтеп куйганча, Нәбухаднессар Раббы йортындагы һәм патша пулатларындагы бөтен хәзинәне Иерусалимнән алып китте, Раббы йорты өчен Исраил патшасы Сөләйман ясаткан барча алтын савытларны юк итте. Иерусалимнең бар халкын, бөтен түрәләрен, батыр гаскәриләрен, шулай ук барча балта осталарын һәм тимерчеләрен – барлыгы ун мең кешене – Бабилгә сөрде, шәһәрдә ярлы гади халыктан гайре беркем калмады.

Аннары Бабил патшасы, Яһояхин урынына аның абзасы Маттанияне патша итеп билгеләп, аның исемен Сәдыкыйягә алыштырды. Тәхеткә утырганда Сәдыкыйя егерме бер яшендә булып, унбер ел дәвамында ул Иерусалимдә патшалык итте. Сәдыкыйя, Яһоякыйм кебек үк, Раббы күзенә ятышсыз күренгән гамәлләр кылды. Иерусалим каласына һәм Яһүдә җиренә Раббының ачуы шул дәрәҗәдә зур иде ки, нәтиҗәдә Ул аларны Үзеннән читкә тибәрде.

*IV Патшалар 24:8–20*



## Иерусалимнең һәм Раббы йортының тар-мар ителүе

Исраил патшасы Сөләйманның Аллаһы кушуы буенча Иерусалим каласында Раббыга багышлап зиннәтле һәм күркәм гыйбадәтханә төзүе турында без укыдык инде. Әмма Иерусалимне беренче тапкыр яулап алганнан соң унбер ел үтүгә, килданиләр (Бабил гаскәрләре), кабат әлеге калага килеп, Сөләйман төзегән гыйбадәтханәне тәмам тар-мар итәләр. Изге Китапта бу хакта менә ничек бәян ителә.

Патшалык итүенең тугызынчы елында Бабил патшасы Нәбуханессар үзенең бөтен гаскәре белән Иерусалим янына килеп аны камап алды һәм кала тирәли туфрак өйдерде. Иерусалим ел ярым дәвамында камалышта булды. Бервакыт халыкның ашарына ризык тәмам бетеп, шәһәрдә ачлык башланды. Бабил гаскәрләре Иерусалимне яулап алгач, төнлә Яһүдә сугышчылары патша бакчасы янындагы ике дивар арасына куелган капкага таба йөгерде. Килданиләр шәһәрне камап алган булса да, сахрага чыга торган юлдан патша качып китә алды. Килданиләр Сәдыкыйя патшаны эзәрлекли чыктылар һәм Әрихә сахрасында аны куып җиттеләр. Яһүдә патшасының сугышчылары исә кайсы кая таралышып бетте. Шуннан бабиллеләр, патшаны тотып алып, Бабил хакиме янына Риблага китерделәр дә хөкем карары чыгардылар: Сәдыкыйянең угылларын аның күз алдында үтерделәр, Сәдыкыйянең үзен исә, күзләрен сукырайтып, бакыр богау кигезеп, Бабилгә алып киттеләр.

Шуннан Нәбухаднессарның җансакчылар башлыгы Нәбузарадан, килданиләр гаскәре белән Иерусалим каласына килеп, Раббы йортына, патша пулатларына һәм Иерусалимнең бөтен йортларына ут салды, аннары Иерусалим тирәли төзелгән диварларны җимерде; шәһәрдә калган бөтен халыкны, шулай ук Бабил патшасы ягына чыккан адәмнәрне әсирлеккә алып китте, йөзем бакчасында эшләү һәм җир сөрү өчен ярлы гади халык арасыннан күпмедер кешене генә калдырды. Килданиләр Раббы йортының ишегалдындагы бакыр баганаларны, бакырдан эшләнгән бөтен кирәк-яракны ватып-җимереп, бакырын Бабилгә алып киттеләр. Гыйбадәт кылганда кулланыла торган



барлык бакыр савыт-сабаны, көйрәтү савытларын, касәләрне, алтыннан һәм көмештән коелган барча әйберне шулай ук үзләре белән алдылар.

Бу хәл Мәсих туганга кадәр 587–586 елларда булды. Сөләйман төзеткән Аллаһы йортының гомере якынча 400 ел белән чикләнде .

*IV Патшалар 25:1–16*

## Даниил һәм аның өч дусты

Бабил патшасы Нәбухаднессар, сарайда хезмәт итәр өчен, әсир төшкән исраилиләр һәм яһүдиләр арасыннан күркәм кыяфәтле, гәүдә-сыннары төз, зирәк акыллы, төрле фәннәргә тиз төшенә торган, патша яки түрәләр нәселеннән булган үсмер егетләрне сайлап алырга боерды. Патшаның фәрманы үтәлде. Нәбухаднессар сараенда хезмәт итәр өчен сайлап алынган егетләрне патша үз табынынннан ашатып-эчертергә, шулай ук аларны төрле гыйлемнәргә һәм килданиләр язмасына өйрәтергә әмер бирде. Үсмер егетләрне шул рәвешле өч ел дәвамында тәрбия кылырга тиеш иделәр.

Әсирләр арасында Даниил, Ханания, Мишаил һәм Азария исемле яһүди үсмерләр бар иде. Бабил сараенда Даниилга – Бәлтешассар, Ханаиягә – Шадрах, Мишаилгә – Мешах, Азариягә – Әбеднәгү дигән исемнәр куштылар. Даниил биредә патша ризыгы һәм эчемлеге белән үзен нәҗесләмәскә булды, чөнки патша өстәлендәге нигъмәтләрнең Муса кануны буенча яһүдиләргә ашарга тыелган мал яки кош итеннән әзерләнгән булуы ихтимал иде. Шул сәбәпле Даниил сакчылар башлыгыннан яшелчә белән су гына биреп торуын үтенде. Егетләр ябыга калса, патшаның ачуы чыгар дип, теге башта Даниилның үтенече белән ризалашырга кыймады. Әмма Даниил, сынау өчен генә ун көн дәвамында шул рәвешле тукланыйк, дигәч, сакчылар башлыгы ризалыгын бирде. Ун көн үткәннән соң чагыштырсалар, патша нигъмәтләре белән туенып торучы башка үсмерләрнекенә караганда бу дүрт егетнең йөзгә күркәмрәк, гәүдәгә тазарак булуы ачыкланды.

Аллаһы Даниилга, Хананиягә, Мишаилгә һәм Азариягә һәртөрле белем һәм зирәк акыл биреп, болардан тыш Даниилга төш һәм илаһи күренешләрне юрау осталыгы да иңдергән иде.

Билгеләнгән өч ел үткәч, сарай хезмәте өчен сайлап алынган исраили һәм яһүди егетләрне патша үз янына китерергә боерды. Үсмерләрнең һәркайсы белән аерым-аерым әңгәмә кылганнан соң, патша алар арасында Даниил, Ханания, Мишаил һәм Азариягә тиң булырдаен тапмады. Шушы сөйләшүдән соң әлеге егетләр патша хозурында хезмәт итә башлады. Патша алардан нәрсә ха-



кында сораса да, патшалыктагы барча күрәзәче вә тылсымчылар җавабыннан аларныкы ун тапкырга акыллырак һәм зирәгрәк булып чыкты.

*Даниил 1:3–20*

# Алтын сын һәм кыю өч ир-егет

Бабил патшасы Нәбухаднессар саф алтыннан биеклеге – утыз, киңлеге өч метр булган сын ясатып Дүрә тигезлегенә куйдырды. Аннары сөрәнче көчле тавыш белән патша фәрманын белдерде: «Барча халыклар, кавемнәр һәм кабиләләр! Сезгә шундый фәрман бирелә: быргы һәм башка төр уен коралларының тавышын ишетүгә, Нәбухаднессар патша куйган алтын сын алдында җиргә капланып сәҗдә кылыгыз! Кем дә булса башын иеп җиргә капланмый икән, аны шундук ут бөркеп торган мичкә ташлаячаклар».

Шунда килданиләрдән берничә кеше килеп Нәбухаднессар патшага яһүдиләр өстеннән әләкләде: «Яһүди ирләр Шадрах, Мешах һәм Әбеднәгү синең әмереңә буйсынмыйлар, падишаһ, алар синең илаһларыңны санламыйлар һәм син куйган алтын сынга да табынмыйлар», – диде. Ачуы кузгалган Нәбухаднессар, ярсып, Шадрах, Мешах һәм Әбеднәгүне тотып китерергә боерды. «Әгәр мин ясаган алтын сынга баш имәсәгез, сезне шундук ут бөркеп торган мичкә атачаклар; шул чагында сезне минем кулдан нинди генә Алла коткара алыр икән?» – диде патша. Әмма егетләр патшага җавап итеп болай диделәр: «Табынган Аллабызның безне ут булып кызган мичтән һәм синең кулдан коткарырга кодрәте җитә. Инде Аллаһы безне коткармаган сурәттә дә, сиңа шул мәгълүм булырга тиеш, патша: без синең илаһларыңа табынмаячакбыз һәм син куйган алтын сын алдында баш ормаячакбыз». Шушы сүзләрне ишетүгә, Нәбухаднессар патшаның бик нык ачуы чыкты, һәм гаскәрендәге иң көчле сугышчыларга ул, әлеге буйсынмас яһүдиләрне бәйләп, ут бөркеп торган мичкә ыргытырга әмер бирде.

Егетләрнең һәр өчесен бәйләп утка ташладылар. Мич гадәттәгегә караганда җиде тапкыр ныграк кызганга күрә, егетләрне утка ташлаган сугышчыларны ялкын шундук көйдереп үтерде. Ялкын эченә текәлебрәк карагач, Нәбухаднессар патша гаҗәпләнеп урыныннан сикереп торды һәм янындагы түрәләреннән: «Без ут эченә өч кенә кешене бәйләп аттык түгелме? – дип сорады. – Тик ут эчендә мин аяк-куллары бәйләнмәгән дүрт кешене күрәм, һәм аларга һичнинди зыян килмәгән. Дүртенчесенең кыяфәте исә илаһи затны хәтерләтә».

Шунда Нәбухаднессар патша, мич авызына килеп: «Шадрах, Мешах һәм Әбеднәгү, Аллаһы Тәгаләнең коллары! Чыгыгыз аннан һәм



бире килегез!» – дип дәште. Тегеләр ялкын эченнән чыгып патша янына килделәр һәм әйләнә-тирәдәгеләр әлеге өч егеткә утның зыян китермәвен күрделәр: аларның чәчләре дә көймәгән, киемнәре дә әүвәлгечә калган, аларга хәтта ут-төтен исе дә сеңмәгән иде. Шулчак Нәбуходнессар патша әйтте: «Шадрах, Мешах һәм Әбеднәгүнең Алласына мактау-шөкерләр яусын! Аның галәмәтләре бөек, Ул кылган могҗизалар кодрәтле! Аның Патшалыгы – мәңгелек, Аның хакимлеге буыннан-буынга дәвам итәчәк». Шушы вакыйгадан соң Нәбуходнессар патша Шадрах, Мешах һәм Әбеднәгүне Бабил җирендә бөек дәрәҗәләргә күтәрде.

*Даниил 3*

## Даниилның аңлаешсыз сүзләрне аңлатуы

Нәбуходнессар патша хакимлегеннән соң Бабил тәхетенә Белшассар утырды. Бервакыт ул үзенең дәрәҗәле түрәләре өчен мең кешелек мәҗлес җыйды һәм табынга Иерусалимнең изге йортыннан кайчандыр атасы Нәбуходнессар талап алып кайткан алтын, көмеш савытларны куярга боерды. Белшассар патша үзе, аның түрәләре һәм аларның хатыннары шул савытлардан шәраб эчтеләр; сыйланып утырган чакта үзләренең алтын, көмеш, бакыр, тимер, агач һәм таштан ясалган илаһларына мәдхияләр яудырдылар.

Нәкъ шул мәлне патша сараеның диварында, шәмдәл каршында, нәрсәдер язучы адәм кулы пәйда булды. Моны күреп, патшаның йөзе үзгәрде, буыннары йомшарып, тезләре калтырый башлады. Патша, хезмәтчеләренә кычкырып, Бабилнең бөтен акыл ияләрен чакырырга боерды; әлеге сүзләрне укып, мәгънәсен аңлаткан кешене дәрәҗәсе буенча патшалыкта өченче кеше итеп билгеләргә вәгъдә бирде. Ләкин акыл ияләреннән беркем диварда язылган сүзләрнең мәгънәсен аңлата алмады.

Шулчак, бу хакта ишетеп, мәҗлес барган бүлмәгә патшабикә килеп керде һәм патшага Даниил турында, аның Изге Рухка ия булуы, акылы, зирәклеге, төшләрне юрый, серле күренешләрне аңлата һәм буталчык-яшерен нәрсәләрне ача белүе турында сөйләп бирде. Шуннан Даниилны китерделәр, һәм патша аңардан әлеге аңлаешсыз сүзләрнең мәгънәсен төшендереп бирүне үтенде.

«Чамасыз тәкәббер булганың һәм үз илаһларына мәдхияләр яудырып изге касәләрдән шәраб эчкәнең өчен Аллаһының сиңа, Белшассар патша, ачуы чыккан; әнә шуның өчен Ул диварга әлеге сүзләрне яздырган, – диде Даниил. – Ә бирегә МЕНЕ, МЕНЕ, ТЕКЕЛ, ПАРСИН дип язылган. Әлеге сүзләрнең мәгънәсе болайдыр: МЕНЕ – Аллаһы, синең патшалык итү көннәреңне исәпләп чыгарып, аңа чик куярга хәл кылган; ТЕКЕЛ – син, үлчәүдә үлчәнеп, артык җиңел дип табылгансың; ПАРСИН – синең патшалыгың мадайлыларга һәм фарсыларга бүлеп биреләчәк». Шуннан Белшассарның әмере буенча Даниилга җете кызыл кием кигезеп, муенына алтын муенса тактылар, үзен исә дәрәҗәсе буенча патшалыкта өченче



кеше дип игълан иттеләр. Шул ук төнне, алдан әйтелгәнчә, бу хәбәр тормышка ашты: Белшассарның гомере киселде, һәм патшалык мадайлы Дәрәвеш кулына күчте.

*Даниил 5:1–31*

# Даниилның догасы

Белшассар тәхетенә утырган Дәрәвеш патша да чамадан тыш тәкәббер бер адәм булып, ул да пот-сыннарга табынучылардан иде. Әмма җанына бөек рух иңгән, акыллы-зирәк Даниил аның күңеленә хуш килде.

Ил белән идарә итүдә үзенә һичнинди авырлык килмәсен өчен, Дәрәвеш патшалыкның бөтен төбәкләренә йөз егерме идарәче билгеләде. Алар өстеннән күз-колак булырга ул үзенең өч күзәтчесен куйды; идарәчеләр әлеге күзәтчеләргә исәп-хисап бирергә тиеш иделәр. Даниил, шул күзәтчеләрнең берсе булып, үзенең акылы һәм намуслылыгы белән башка күзәтчеләрдән һәм идарәчеләрдән шактый өстен торды, шунлыктан патша аңа бөтен патшалык белән идарә итүне йөкләргә ниятләде. Ләкин башка күзәтчеләр һәм идарәчеләр, Даниилга гаеп ташлар өчен, аның эшеннән нинди дә булса кимчелек эзләргә тотындылар. Әмма патшасына гаять тугры Даниилның эшеннән бернинди хилафлык яки канунга сыймаган гамәл таба алмадылар.

Даниилның бик еш үз Алласына сәҗдә кылуын белгән күзәтчеләр һәм идарәчеләр, Дәрәвеш патша алдында Даниилга кара ягар өчен, патшага шундый фәрман чыгарырга тәкъдим иттеләр: утыз көн дәвамында кем дә булса гозер белән синңа түгел, башка бер илаһка яисә кешегә мөрәҗәгать итсә, аны арысланнар янына чокырга ташласыннар! Патша әлеге тәкъдимнең төп сәбәбен белми иде, шуңа күрә карарга кул куярга риза булды.

Шундый фәрман бирелгән булуга карамастан, Даниил үзенең Раббысына дога кылудан туктамады. Ул көн дә, тез чүгеп, үзенең бүлмәсендә Раббысына өч тапкыр гыйбадәт кылды, туган шәһәре Иерусалимгә таба караган тәрәзәләре аның бу вакытта һаман ачык булды.

Даниилны өнәмәгән залим бәндәләр, яшертен күзәтеп торып, аның үз Алласына гыйбадәт кылганын, Аңардан рәхим-шәфкать сораганын күрделәр һәм бу хакта шундук патшага хәбәр итәргә булдылар.

*Даниил 6:1–11*



## Даниил арысланнар чокырында

Даниилны өнәмәүче сарай әһелләре, Дәрәвеш патша янына килеп: «Даниил, син раслаган фәрманга игътибар бирмичә, көнгә өч тапкыр үз Алласына дога кыла», – дип хәбәр иттеләр. Бу сүзләрне ишетеп бик нык борчуга төшкән патша Даниилны коткарырга дип күңеленә беркетеп куйды. Әмма сарай әһелләре аңа, мадайлылар һәм фарсылар кануны кушканча, патша тарафыннан игълан ителгән бер генә карар да, бер генә фәрман да үзгәртелергә тиеш түгел, дип әйттеләр. Шуннан патша Даниилны арысланнар янына чокырга ташларга мәҗбүр булды. Чокырга ташлар алдыннан Даниилга ул: «Бөтен күңелең белән табынган Аллаң коткарыр сине!» – диде. Аннары патша үзенең сараена кайтты һәм кичке ашны да китертмичә йокларга ятты, тик аның күзенә йокы кермәде. Таң атуга, патша ашыгып арысланнар чокыры янына китте һәм кызганыч тавыш белән Даниилга дәште: «Даниил, терек зат булган Аллаһының колы! Бөтен күңелең белән хезмәт иткән Аллаң сине арысланнардан коткара алдымы?» «Аллам, минем янга Үзенең фәрештәсен җибәреп, арысланнарның авызын томалады, һәм алар миңа зыян китерә алмады, чөнки Аллаһы алдында минем гөнаһым юк, шулай ук сиңа карата да мин һичнинди җинаять кылмадым», – дип җавап кайтарды Даниил.

Даниилның исән-имин булуын күреп, патша бик сөенде һәм аны чокырдан чыгарырга боерды. Чокырдан күтәреп алгач, Даниилның бер җиренә дә зыян килмәве ачыкланды. Аннары Даниилга гаеп ягучы залим бәндәләрне патша әмере буенча китертеп шул чокырга ыргыттылар, әмма алар чокыр төбенә җитә дә алмады – төшкән уңайга ук һәммәсен арысланнар өзгәләп бетерде.

Әлеге вакыйгадан соң Дәрәвеш патшалыкның һәр тарафына хатлар юллады. Үзенең мөрәҗәгатендә ул барлык халыкларга Даниил табынган Аллага ихтирам күрсәтергә әмер бирде; чөнки Даниилның Аллаһысы – мәңгелек Алла, Аның хакимлек итүе дә мәңгелек. «Ул – бәладән йолып алучы, Коткаручы, җирдә һәм күктә могҗиза-галәмәтләр күрсәтүче! Даниилны арысланнардан йолып алды Ул!» дип язылган иде әлеге хатта.

*Даниил 6:12–27*



## Яһүдиләрнең әсирлектән кайтуы

Алдагы бүлекләрдә язылганча, Ашшур гаскәрләре, Төньяк патшалык Исраилне яулап алып, халкын әсирлеккә куып алып киткәләр. Бу хәл Мәсих туганчы җиде гасыр элек була. Йөз еллар үткәч, мадайлылар белән Бабилнең берләшкән гаскәрләре, ике ел дәвамында Ниневә каласын камалышта тотканнан соң, шәһәрне тар-мар итә. Тора-бара Бабил көчле бер дәүләткә әверелә һәм әйләнә-тирәсендәге күрше илләрне, шул исәптән Көньяк патшалык Яһүдәне дә, талап көн күрә башлый, Яһүдәнең халкын исә Бабилгә әсирлеккә алып китә.

Әмма берзаман куәтле Бабил империясенең дә соңгы сәгате суга: аны мадайлылар белән фарсы гаскәрләре яулап ала, һәм шуннан соң фарсы патшасы Кир яһүдиләргә үзләренең туган ягына кайтырга рөхсәт итә. Үзенең патшалыгында ул мондый фәрман игълан итә: «Фарсы патшасы Кир белдерәдер: җирдәге бөтен патшалыкларны Күкләр Алласы Раббы минем кулга тапшырды. Ул миңа Яһүдә җирендәге Иерусалим каласында Үзенә йорт төзергә әмер бирде. Аның халкыннан булган һәммә кеше, – Аллаһы аларның юлдашы булсын, – Яһүдәдәге Иерусалимгә барып, Исраил Алласы Раббыга йорт салсын». Шул рәвешле, Исраилнең унике ыругыннан кырык меңләп кеше үз иленә әйләнеп кайтты. Аларның күпчелеген яһүдиләр, ягъни Яһүдә ыругыннан булган кешеләр тәшкил итә иде. Хәер, халыкның байтагы Фарсы җирләрендә төпләнеп калды.

Илләренә әйләнеп кайтуларының икенче елында яһүдиләр, төзелешне башларга ниятләп, Иерусалимгә җыелдылар һәм яңа гыйбадәтханәнең нигезен салырга керештеләр. Әүвәлге гыйбадәтханәне хәтерендә саклаган өлкән яшьтәге руханилар, левиләр һәм ыруг башлыклары, яңа гыйбадәтханәгә нигез салынганны күреп, шатлыктан елап җибәрделәр, икенчеләре сөенечтән шау-гөр килде. Шатлык авазлары, елаган тавышлар белән кушылып, әллә кайларга яңгырап торды.

Яңа гыйбадәтханәдә төзелеш эшләре белән Яһүдә патшасы Яһояикыймның онызы Зеруббабел җитәкчелек итте. Әмма әүвәле яһүдиләр яшәгән җиргә килеп төпләнгән халыклар, яһүдиләрне күрәлмас булып, гыйбадәтханәдәге төзелеш эшләрен тоткарладылар, яһүдиләрне куркыта һәм аларга Фарсы патшасы Артахшаста алдында төрле ялалар яга башладылар. Шул рәвешле алар төзелешне унбиш



елга – Дәрәвеш исемле икенче бер Фарсы патшасы тәхеткә килгәнчегә кадәр тоткарлый алдылар.

Дәрәвеш патша, әүвәлге патша Кирның боерыгын раслап, төзелә башлаган гыйбадәтханәдә эшләрне төгәлләү хакында Иерусалимгә хат юллады. Адар аеның өченче көнендә, Дәрәвеш патша хакимлегенең алтынчы елында яңа гыйбадәтханә төзелеп бетте.


*Эзра 1 – 6*

## Мәликә Эстер

Фарсы патшасы Ахашверош өйләнергә карар кылды һәм, бөтен чибәр кызларны башкала Шушанга җыярга әмер биреп, патшалыкның төрле тарафларына үзенең атчабарларын җибәрде. Патша хозурына керткәнче әлеге кызларны унике ай дәвамында әзерләргә тиеш иделәр. Ул заманнарда Фарсы җирендә кайчандыр Ашшур һәм Бабил гаскәрләре тарафыннан әсир ителгән гыйбриләрнең нәсел-нәсәбе яшәп, алар арасында Мәрдәкәй атлы бер яһүди бар иде. Шушы Мәрдәкәй үзенең мәрхүм абзасының чибәр йөзле, зифа буйлы Эстер исемле кызын тәрбия кыла иде. Патшалыктагы гүзәл кызларны башкала Шушанга җыя башлагач, Эстер да патша йортына чакырылды, һәм әлеге чибәрләр арасында патшага иң ошаганы Эстер булды. Ахашверош аның башына патша таҗы кидерде һәм аны мәликә итте. Аннары барлык түрәләр һәм үз хезмәтендәге кешеләр өчен Эстер хөрмәтенә зур мәҗлес җыйды, өлкәләрдә бәйрәм ясатты һәм патшаларча юмартлык белән бүләкләр өләште. Эстер исә, Мәрдәкәй кушканча, үзенең нәселе һәм кавеме турында берни әйтмәде.

Шушы хәлләрдән соң күпмедер вакыт үткәч, Ахашверош патша үзенең түрәләреннән берсен – Һәмәнне башка барлык түрәләрдән өстен итеп куйды. Патша сараенда хезмәт итүчеләрнең һәммәсе, патша боерганча, Һәмән каршында җиргә кадәр иелеп баш орырга тиеш иделәр. Бары тик Мәрдәкәй генә аның алдында тез чүкмәде, йөзе белән җиргә кадәр иелмәде. Һәмәннең аңа бик нык ачуы чыкты, һәм ул Ахашверош патшалыгындагы барлык яһүдиләрне кырып бетерергә ният корды.

«Патшалыгыңның бөтен төбәкләрендә төрле халыклар арасында таралып-сибелеп яшәүче бер кавем бар, – диде ул бервакыт Ахашверош патшага, – ул кавемнең кануннары башка барлык халыкларныкыннан үзгә – алар патша чыгарган кануннарны үтәмиләр». Шуннан патша әлеге Һәмәнгә бу халык белән ни теләсә шуны эшләргә рөхсәт бирде. Озак та үтми, «уникенче айның, ягъни Адар аеның унөченче көнендә барлык яһүдиләр – яше-карты, бала-чагасы һәм хатын-кызы – бер көн эчендә үтерелергә, кырып бетерелергә, юкка чыгарылырга, ә мөлкәтләре таланырга тиеш» дигән хатларны чапкыннар патшалыктагы



барлык төбәкләргә таратты. Патша фәрманы килеп ирешкән һәр җирдә яһүдиләр арасында моң-зар, ураза тоту, елау-сыктау хөкем сөрде.

*Эстер 1 – 3*

## Мәликә Эстер (дәвамы)

Шушы хәлләрне ишеткәч, патшаның әлеге әмере турында мәликә Эстергә Мәрдәкәй хәбәр җибәрде һәм аңа, патша янына кереп, үз халкы өчен ялварырга, аның мәрхәмәт күрсәтүен сорарга кушты. Эстер үзенең хезмәтчесе аша Мәрдәкәйгә: «Чакырылмаган килеш патша хозурына кергән һәркемне бер үк хөкем көтә, ул да булса – үлем. Патша үзенең алтын таягы белән төртеп күрсәткән кеше генә исән калырга мөмкин. Ә минем менә утыз көн инде патша хозурына чакырылганым юк», – дигән җавабын җибәрде. Моңа каршы Мәрдәкәй аңа: «Барча яһүдиләр арасыннан берүзең генә патша сараенда котылып калырмын дип өметләнмә. Кем белә, бәлки нәкъ менә шушындый вакыт өчен син мәликә дәрәҗәсенә ирешкәнсеңдер дә», – дип хәбәр итте. Мәрдәкәйгә җавабында Эстер болай диде: «Бар, Шушандагы барлык яһүдиләрне бергә җый, һәм минем хакка ураза тотыгыз, өч тәүлек буена көндезен дә, төнлә дә ашамагыз-эчмәгез. Шулай ук мин дә үземнең хезмәтче кызларым белән ураза тотачакмын. Шуннан соң, гәрчә канунга каршы булса да, патша хозурына керермен; инде һәлак булырга язган икән – димәк, һәлак булырмын». Ул арада исә явыз Һәмән, Мәрдәкәйне асарга дип, биеклеге егерме биш метр булган дар агачы ясатып куйды.

Өченче көндә Эстер, мәликәчә киенеп, патша сараеның эчке ишегалдына, патша бүлмәсенең ишеге янына килеп басты. Патша исә кулындагы алтын таягын Эстергә таба сузды. Эстер, патшага якынлашып, таякка орынды һәм патша белән Һәмәнне үзенә кунакка чакырды. Патша белән Һәмән килделәр. Шәраб эчеп утырган вакытта патша: «Нинди үтенечең бар иде, мәликә Эстер? Теләгең нинди?» – дип сорады. Аңа җавап итеп мәликә: «Теләгем шулдыр – җанымны саклачы! Һәм минем халкымны да саклап калсаң иде – үтенечем шулдыр! Чөнки безне саттылар – мине дә, халкымны да үтерергә, кырып бетерергә, юк итәргә ният кылалар», – диде. Патша, шул рәвешле, хатынының яһүди икәнен белде һәм дә Һәмәннең явыз ниятен фаш итте. Патшаның әмере буенча Һәмәнне Мәрдәкәйгә дип ясалган дар агачына астылар.

Әмма Фарсы патшалыгында яшәүче яһүдиләрне юк итү турында инде патша исеменнән язылган, патша әмерен ныгытып, йөзек белән мөһерләнгән хатны гамәлдән чыгару да, үзгәртү дә мөмкин булмастай эш иде. Шуннан, патша фәрманына буйсынып, кәтипләр



яңа күрсәтмә яздылар: анда патша яһүдиләргә бергә тупланырга һәм үз гомерләрен сакларга әзер торырга рөхсәтен бирә иде. Патшаның Һиндстаннан алып Хәбәшстан җирләренә кадәр сузылган йөз егерме җиде төбәгенә җитез атларда чапкыннар озатылды, һәм озакламый патшаның әлеге боерыгы барлык өлкәләрнең түрәләренә җиткерелде. Яһүдиләрнең шушы зур афәттән котылып калу хөрмәтенә Мәрдәкәй ел да билгеләп үтелә торган Пурим бәйрәмен игълан итте.

*Эстер 4 – 10*

## Нәхәмиянең Иерусалим диварын төзүе

Фарсыларның мәркәзе булган Шушан каласында, Артахшаста патша сараенда яһүди Нәхәмия абруйлы түрә иде.

Нәхәмиянең бер ир туганы һәм тагын берничә кеше Иерусалимнән Фарсыга килделәр. Нәхәмия үзенең кардәшеннән Иерусалим каласы, анда калган яһүдиләр хакында сораштыра башлагач, кардәше аңа менә нәрсәләр сөйләде: «Сөргеннән исән-имин әйләнеп кайта алганнар үз илләрендә бик җәфаланып, кимсетелеп көн күрә; Иерусалимнең диварлары җимерелгән, капкалары янган». Шушы сүзләрне ишеткәч, Нәхәмия ачы күз яшьләре түкте. Ничәмә көннәр дәвамында аның күңеленнән хәсрәт китмәде. Артахшаста патша аңа Иерусалимгә барырга, шәһәр диварларын төзергә рөхсәт итсен дип ул, ураза тотып, көн дә Аллаһыга ялварды.

Артахшаста патша Нәхәмиягә Иерусалимгә китәргә рөхсәт бирде, һәм Нәхәмия яһүдиләр белән бергә шәһәрнең җимерелгән диварларын күтәрергә, аның капкаларын төзекләндерергә тотынды. Яһүдиләрнең дошманнары, бу хакта ишетеп, куркытып-өркетеп аларга төрлечә аяк чалырга маташты. Әмма Нәхәмия халыкны коралландырып куйды: дивар салучыларның бер кулында таш булса, икенчесендә сугыш коралы булды; төзүчеләрнең һәммәсе кылыч белән коралланды. Төзелеш көндез дә, төнлә дә туктап тормады. Төзүчеләрне Аллаһы Үзенең канат астына алды; һәм Бабил гаскәрләре Иерусалим каласын тәмам тар-мар китереп, яндырып бетергәннән соң йөз кырык ел үткәч, шәһәр диварлары кабат төзелде.

Җиденче айга керүгә бар халык мәйданга җыелды. Рухани Эзрага исә исраилиләргә Муса аша Раббы биргән Канун китабын алып килергә куштылар. Рухани Эзра Канун китабын алып килде һәм мәйданга җыелган ир-ат белән хатын-кыз, укыганны аңлардай һәркем алдында иртә таңнан көн үзәгенә кадәр шул китапны укыды; бар халык Канун китабын игътибар биреп тыңлады. Эзра бөек Раббы Аллага мактау-шөкерләр яудырганда бар халык, кулларын югары күтәреп: «Амин, амин!»* – дип торды. Аннары бөтенесе, йөзләре белән җиргә капланып, Раббы алдында сәҗдә кылды.

*Нәхәмия 1 – 8*

* *Амин* – борынгы яһүд телендә бу сүз «дөрестән дә шулай булсын» дигән мәгънәне аңлата.



## Халыкның Аллаһыга мөрәҗәгать итүе

Тупас тукымага төренгән, уразага керү билгесе итеп башларына көл сипкән уразалы яһүдиләрнең һәммәсе шул ук айның егерме дүртенче көнендә бергә җыелдылар. Исраил угыллары, чит кавемнәрнең барчасыннан аерылып, үзләренең гөнаһларын һәм аталарының җинаятьләрен танып тәүбә китерделәр. Өч сәгать дәвамында алар аягүрә басып торып Раббы Аллаларының Канун китабын укыдылар, аннары, Раббы Аллалары алдында гөнаһларын танып, сәҗдә кылдылар. Ешуа, Бани, Кадмиел, Шебания, Бунни, Шәрәбия, Бани, Кенани, левиләр өчен ясалган баскычка менеп, Раббы Аллаларына кычкырып дога кылдылар. «Урыныгыздан торыгыз да мәңгедән-мәңгегә яшәүче Раббы Аллагызга мактау-шөкерләр яудырыгыз! – диделәр, аннары, – Синең дан-шөһрәтле исемең мактаулы, һәртөрле мактау вә данлаудан өстен! Син – бердәнбер Раббы, һәм Синнән башка бүтән алла юк. Син күкләрнең күген вә анда булган бар нәрсәне, җирне вә андагы бар әйберне, диңгезләрне вә андагы һәммә нәрсәне бар иттең һәм Син шуларның барысына тормыш өрдең, күк җисемнәренең һәммәсе Сиңа буйсына», – дип дога кылдылар.

Халык, гөнаһлы гамәлләре һәм Раббы юлыннан тайпылганы өчен ихлас күңелдән тәүбә итеп, гыйбадәт кылды: «И Аллабыз, олуг, кодрәтле вә дәһшәтле, Килешүгә тугры, мәрхәмәтле Аллаһы! Ашшур патшалары заманыннан алып, бүгенге көнгә кадәр патшаларыбыз вә башлыкларыбыз, руханиларыбыз вә пәйгамбәрләребез, аталарыбыз вә Синең бар халкың башына төшкән бәла-казалар аз булып тоелмасын иде Сиңа! Безгә җәза биреп, дөрес эшләдең Син, чөнки Син тугрылык белән эш иттең, ә без яманлык кылдык. Менә шуңа күрә без, Аллаһы кануны буенча эш итәрбез, андагы әмерләрне һәм күрсәтмәләрне бозмыйча бөтенесен төгәл үтәрбез дип, язма рәвештә килешү төзибез, һәм башлыкларыбыз, левиләребез вә руханиларыбыз аңа мөһерләрен сугалар». Түрәләр, әлеге антнамәгә кул куеп, аны үзләренең мөһерләре белән ныгыттылар. Калган барча халык, руханилар, левиләр, Аллаһы йортының сакчылары, җырчылар, Аллаһы йортында хезмәт күрсәтүчеләр, Аллаһы канунын кабул иткән чит мәмләкәт кешеләре, аларның хатыннары һәм угыл-кызлары, шулай ук башында зиһене булган



һәркем үзенең хөрмәт казанган туганнарына кушылды һәм, антлар эчеп, шушы бурычларны кабул итте.

*Нәхәмия 9:1–6; 9:32 – 10:29*

## Әюбнең башыннан үткәннәре

Утс дигән җирдә Әюб исемле бик тә диндар, искиткеч бай бер адәм яши иде. Ул саф күңелле, гадел, Аллаһыны санлаучы һәм һәртөрле явызлыктан ерак торучы бер кеше булып, аның җиде угылы һәм өч кызы бар иде.

Бервакыт Аллаһы янына шайтан килде, һәм Раббы аңардан: «Кайсы тарафлардан килешең?» – дип сорады. Шайтан Аңа: «Мин җир йөзе буйлап йөрдем һәм аны тоташтан әйләнеп чыктым», – диде. «Йөргән җиреңдә колым Әюбкә игътибар итмәдеңме? – дип сорады аңардан Раббы. – Чөнки җирдә аның кебек гөнаһсыз, гадел, Аллаһыны санлап, һәртөрле явызлыктан ерак торучы кеше бүтән юктыр». Шайтан шунда Раббыга болай дип җавап бирде: «Аллаһыны ул юкка гына санлый дип уйлыйсыңмы? Аның үзен, йорт-җирен, бар булган мал-мөлкәтен Син саклыйсың түгелме? Ул башкарган эшләргә Син Үзең фатиха биргәнгә, аның көтү-көтү маллары әнә бөтен җиргә таралган. Ләкин кулыңны сузып мал-мөлкәтенә кагыл әле – Сиңа мактау яудырыр микән ул?» Шунда Аллаһы шайтанга: «Ярар, бүгеннән аның бар мөлкәте синең кулда», – диде.

Шундый рөхсәтне алганнан соң шайтан төрле юллар белән Әюбкә зыян сала башлады. Ул аның бөтен балаларын харап итте, бар мөлкәтен юкка чыгарды, әмма Әюб сукранмады, Аллаһыны яманламады, бары тик: «Раббы Үзе бирде, Үзе алды, Раббының исеме фатихалы булсын! – дип кенә әйтеп куйды, хатынына исә, – без шулай Аллаһыдан яхшылык кына кабул итеп, начарлыкны кире кагарга тиешмени?» – диде. Раббы хакында Әюб бер генә гөнаһ сүз әйтмәде. Аннары шайтан, Әюбкә коточкыч авыру җибәреп, аның бөтен тәне башыннан аягына кадәр җәрәхәт-кутыр белән капланды. Әюбнең җәфа чигүләре чик-чамасыз булып, тора-бара аның рухы сынды.

Әюбнең зур бәлагә таруын ишеткән өч дусты, аның күңелен тынычландырмакчы булып, хәл белешергә килде. Әмма дуслары аны тынычландырасы урында, гаепләүгә күчеп, Аллаһы тәкъва адәмнәрне җәберләми, димәк синең гаебең бар, дип гәп куертырга тотындылар. Ләкин Әюб, әүвәлгечә, үзенең хаклы булуын тәкрарлады һәм, дусларының сүзләреннән канәгать булмыйча, Аллаһының Үзе белән сөйләшергә теләде. Әюб, котылуга өметен



өзмәгән хәлдә, Аңардан ни өчен шундый газапларга таруын сорады: «Йолып Алучымның барлыгы мәгълүм миңа. Ахыр сәгатем җиткәч, Ул миңа кабат җан өрер, һәм мин Аллаһыны күрәчәкмен», – диде ул.

*Әюб 1; 2; 4; 5; 19:25–26*

## Әюб үзе кичергән авыр сынаулардан соң

Әюб шулай үзенең дуслары белән әңгәмәләшеп утырган чакта кинәт кенә җил-давыл купты, аннары давыл эченнән Раббының тавышы яңгырады, һәм Аллаһы Әюбкә сораулар яудырырга тотынды. Әлеге сорауларга җавап кайтару адәм хәленнән килердәй эш түгел иде, шул сәбәпле Раббыдан хисап таләп итәргә ярамаганны Әюб аңлады – Аллаһы адәм балаларының күзаллавына караганда күпкә өстенрәк. Раббы сөйләүдән туктагач, Әюб Аңа: «Хәзер беләм: барысы да Синең иркеңдә; Син нәрсә ниятләсәң дә, башкарып чыга алмаган эшең юк», – диде.

Әюбне шул рәвешле сынаганнан соң, Аллаһы аның барлык югалткан нәрсәсен әүвәлгегә караганда икеләтә арттырып кайтарып бирде. Начар юатучы булган әлеге өч дуска исә Раббының яман нык ачуы чыкты, чөнки алар, Әюбтән аермалы буларак, Раббы турында дөреслеккә туры килмәгән сүзләр сөйләде. Шуңа күрә Аллаһы аларга үзләре өчен корбан китерергә кушты һәм әйтте: «Әюбтән үтенеп сорагыз, Минем алда сезнең хакка дога кылсын, чөнки Мин аның догасын гына кабул итәчәкмен». Әюбнең дуслары Раббы кушканча эшләделәр һәм Әюбнең догалары белән Аллаһыдан ярлыкау алдылар.

Башыннан кичкән авыр сынаулардан соң, Әюб янына ир һәм кыз туганнары, таныш-белешләре килеп күп бүләкләр китерде. Аллаһы Әюбнең соңгы көннәрен әүвәлгегә караганда күпкә бәхетлерәк итте. Күргән бәла-казалардан соң Әюб әле бик озак гомер итте, аның тагын җиде углы һәм өч кызы туды; Әюбнең кызлары белән тиңләшердәй гүзәл затлар бөтен җир йөзендә булмады.

Әюб, бу дөньяда туйганчы гомер итеп, шактый өлкән яшькә җиткәч кенә гүр иясе булды.

*Әюб 38 – 42*



# Зәбур китабы

Зәбур – Изге китапның укучылар аеруча яратып укый торган бүлеге. Әлеге китапта Аллаһыга мәдхия җырлаучы йөз илле шигъри әсәр тупланган булып, аларны көйгә салып җырлаганнар. Бу мәдхияләрдә Аллаһыга иман итүчеләрнең күңелен борчыган сораулар чагылыш тапкан: җирдә кылына торган гаделсезлеккә хәсрәтләнү, яктылыкның караңгылыкны җиңүенә ышану, кылган гөнаһларыңны танып тәүбәгә килү, Аллаһы бүләк итәчәк котылуны өметләнеп көтү. Күтәренке рухтагы кайбер мәдхияләрдә хәтта Мәсихнең килүе хакында алдан күреп хәбәр ителә.

Әлеге мәдхияләр турында сүз барганда, гадәттә, Давыт тарафыннан язылган күп санлы шигъри әсәрләрне күздә тоталар. Әмма Зәбур китабында Аллаһыдан илһам иңгән башка авторларның да җырлары урын алган. Мәсихчеләрнең күп кенә догаларында Зәбурдан өзекләр китерелә. Биредә без мисал өчен ике мәдхия тәкъдим итәбез.

### 1 нче мәдхия

Бәхетледер кеше, яманнар үгете белән йөрмәсә, гөнаһлылар юлына басмаса, мыскыллап көлүчеләр арасында утырмаса! Раббы канунында булыр аның ирке, көне-төне өйрәнер шул Канунны. Агымсу ярында үскән агач кебек ул: җимешен үз вакытында бирер, яфраклары шиңмәс-корымас, һәр эшендә уңышка ирешер ул. Яманнар андый түгелләр, җилгәреп очырган ашлык кибәге сыман алар. Шунлыктан яманнар хөкемдә акланмас, тәкъвалар арасында гөнаһлылар урын тапмас. Тәкъваларның юлын Раббы саклый, ә яманнарның юлы һәлакәткә илтә.

### 150 нче мәдхия

Раббыны данлагыз! Мөкатдәс урынында данлагыз Аллаһыны! Данлагыз Аны Үзенең кальгасында – күк гөмбәзендә! Данлагыз Аның кодрәтле гамәлләрен! Тиңсез бөеклеген данлагыз! Данлагыз Аны мөгез быргы авазлары яңгыратып, лира вә гөслә кыллары чиертеп! Данлагыз Аны барабаннар кагып, бии-бии! Данлагыз Аны хуш авазлы тәлинкәләр чыңлатып һәм яңгыравыклы тәлинкәләр чыңлатып! Әй бөтен терек җаннар, Раббыны данлагыз!



## Зәбурның кайбер юлларын хәтердә калдырыйк

Исемеңне күңелдә саклаучылар, и Раббы, Сиңа өмет баглар, чөнки нурлы йөзеңне эзләүчене Син кире какмыйсың *(9:11)*.
Күкләр Аллаһының шөһрәтен хикәяли, күк гөмбәзе Аның могҗизалы эшләрен бәян итә *(18:2)*.
Раббыдан бөтен җир йөзе курыксын, алдында бар әһле җиһан калтырап торсын! *(32:8)*.
Сынап карагыз да күрегез: никадәр игелекле Раббы! Аңа сыгынган кеше бәхетледер! *(33:9)*.
Барыр юлыңны Раббыга тапшыр! Аңа сыен, һәм Ул синең хакка барын да эшләр *(36:5)*.
Казалы көнеңдә чакыр Мине – Мин сине коткарырмын, һәм син Мине данларсың шунда! *(49:15)*.
И Аллаһы, мине саф йөрәкле кыл, какшамас яңа рух хасил ит күңелемдә *(50:12)*.
И халкым, һәрчак Аллаһыга өмет багла, күңел серләреңне бары Аңа түк! Чөнки Аллаһы – безнең сыену урыны *(61:9)*.
Җир йөзендә хак юлың мәгълүм булсын, бар халыкларга Коткаручы икәнең беленсен *(66:3)*.
Таулар туганчы ук, җир вә дөнья яратылганчы ук, Син – Аллаһы *(89:3)*.
Әмма Раббы – минем Кальгам-ныгытмам, Аллаһы – мин сыену тапкан Кыяташтыр! *(93:22)*.
Әй күңелем, Раббыга мактау-шөкерләр яудыр! Кылган игелекләрен онытма! *(102:2)*.
Чөнки күкләр җирдән никадәр югары булса, Үзеннән куркучы, Үзен хөрмәт итүчегә Раббының мәрхәмәте дә шулкадәр зурдыр *(102:11)*.
Зирәклекнең башы, Раббыдан куркып, Аны хөрмәт итүдә *(110:10)*.
Раббы – минем химаячем!* Нәрсәдән куркырга миңа? Адәм заты миңа ни кыла алсын? *(117:6)*.

* *Химаяче* – яклаучы.

**Синең сүзең –**
**аякларым өчен**
**шәм-чырагтыр,**
**сукмагымны**
**яктырткан нурдыр.**

***Зәбур 118:105***

Яшь кешегә үз юлын ничек саф тотарга? – Бары Синең сүзләреңне тыңлап! *(118:9)*.
Мин – Синеке, коткара күр мине *(118:94)*.
Яшьле күз белән җиргә орлык чәчүчеләр шулчак иген уңышын шатланып урырлар *(125:5)*.
Раббы Үзен дәшеп чакыручы, ихлас күңел белән мөрәҗәгать итүче һәркемгә якын *(144:18)*.

# Гыйбрәтле сүзләр китабы

Изге Китапның бер бүлеге «Сөләйман патшаның гыйбрәтле сүзләре» дип атала. Яшьләргә үгет-нәсыйхәт бирү йөзеннән язылган әлеге кыска-кыска гыйбрәтле киңәшләрнең шактый өлеше зирәк Сөләйман патша тарафыннан иҗат ителгән. Гыйбрәтле сүзләрнең күпчелеге зирәклек, тәкъвалык, Аллаһыдан курку һәм Аны хөрмәт итү, белем эстәү, әхлаклылык, үзеңне тыя белү, тырышлык, үз-үзеңә хуҗа булу, Аллаһыга ышаныч баглау, фәкыйрьләргә ярдәм кулы сузу, дошманнарыңа карата мәрхәмәтле булу, балалар тәрбиясе, намуслылык, гаделлек, аек акыл һ. б. шуның кебек гаять мөһим мәсьәләләргә багышлана. Гыйбрәтле сүзләр китабыннан кайбер үгет-нәсыйхәтләр китерәбез:

Гыйлемнең башы – Раббыдан курку һәм Аны хөрмәт итүдә; зирәклекне һәм киңәш-нәсыйхәтне фәкать ахмаклар гына хәкарәт итә* (*1:7*).

Углым! Атаң нәсыйхәтен тыңла, анаң үгетен кире какма (*1:8*).

Углым! Гөнаһлылар сине үз якларына аударырга тырышсалар – риза булма (*1:10*).

Бөтен йөрәгең белән Раббыга сыен, үз белдегеңә таянма. Йөрер юлларыңда һәрвакыт Аллаһыны юлдаш ит, Ул синең адымнарыңны тугры якка юнәлдерер (*3:5-6*).

Углым! Раббының сабагын кире какма, Аның шелтәсенә рәнҗемә; ата кеше үзенең сөйгән улын ничек шелтәләсә, Раббы да Үзенең яраткан бәндәсен шулай шелтәли (*3:11-12*).

Фәкыйрьне рәнҗетү – аның Яратучысын хурлау белән бер; Раббысын хөрмәт иткән кеше исә мохтаҗларга мәрхәмәт күрсәтер (*14:31*).

Тәкъвалык халыкны югары күтәрә, ә гөнаһ – халык өчен хурлык (*14:34*).

Барыр юлын кеше үзе билгели, әмма адымнарының юнәлеше – Раббы ихтыярында (*16:9*).

Атасын бөлдерүче һәм анасын өйдән куып чыгаручы угыл – оятсыз һәм хурлыклы бәндәдер (*19:26*).

Балаңа барачак юлын яшьтән үк өйрәт; шулчак ул картайгач та бу юлдан читкә тайпылмас (*22:6*).

---

* *Хәкарәт итү* – нәфрәт күрсәтү, яратмау.



Дошманың ач булса, аңа икмәгеңне бир; әгәр сусаган булса – су эчер (*25:21*).

## Вәгазьче китабы

Изге Китапта «Сөләйман патшаның гыйбрәтле сүзләре»ннән соң «Вәгазьче» дигән бүлек башлана. Әлеге бүлектә дә, Гыйбрәтле сүзләр китабындагы сыман, үгет-нәсыйхәтләр, гаҗәеп дәрәҗәдә гакыллы, зирәк фикерләр тупланган. Шушы бүлектән кайбер юлларны китерәбез.

Барысы да фани, дигән Вәгазьче, барысы да фани дөнья мәшәкате генә! (*1:2*).

Зар елау көлүдән яхшырак, чөнки йөзе кайгылы чакта кешенең күңеле йомшара (*7:3*).

Зирәклек сугыш коралыннан яхшырак; ә бер гөнаһлы бәндә күп кенә игелекләрне харап итә ала (*9:18*).

Чокыр казыган кеше үзе үк шул чокырга егылып төшәргә мөмкин; койма җимереп тишек уючыны елан чагарга мөмкин (*10:8*).

Икмәгеңне су юллары белән сатуга җибәр, чөнки күпмедер көннәрдән соң аны тагын булдырырсың (*11:1*).

И яшь егет, яшьлегеңдә күңелле итеп яшә, яшьлегең көннәреңдә йөрәгең сине шат итсен; йөрәгең һәм күзләрең теләгән юлларда йөре; әмма бел: боларның һәммәсе өчен Аллаһы сине хөкем алдына бастырачак (*11:9*).

Яшьлегеңдә, ягъни авыр көннәрең килеп җиткәнче, «алардан миңа канәгатьләнү юк!» диячәк елларың якынлашканчы, кояш һәм яктылык, ай һәм йолдызлар сүнеп караңгыланганчы, яңгырдан соң яңа болытлар җыелу вакыты җиткәнче, үзеңне Яратучыны искә ал. Килер бер көн: өй саклаучылар тетрәп калыр, көчлеләр сыгылып төшәр; болай да аз калганончылар он тартудан туктар; тәрәзәдән тамаша кылучыларның күз аллары караңгыланып, урамга чыга торган ишекләр томаланыр; тегермән шавы тынып, кош сайравыннан таң белән уянган кеше үз тавышын ишетмәс. Ул көнне биек урыннар куркыныч һәм юлда йөрү дәһшәтле тоелыр; бадәм* агачы чәчәк атар; чикерткәләр авыраер, каперс** куагы җиргә түшәлер. Ул көнне кеше мәңгелек йортына китәр, матәм кичерүче кешеләр белән урам тулыр. Көмеш чылбыр өзелгәнгә кадәр, алтын касә төшеп

* *Бадәм* – миндаль.

** *Каперс* – көньякта үсә торган куак.



ватылганга, чишмә янындагы чүлмәк ярылганга һәм кое чыгыры ашалып җимерелгәнгә кадәр үзеңне Бар итүчене искә ал! Туфрактан яратылган тән кире туфракка кайтыр; Аллаһы Тәгалә биргән рух Иясенә кире кайтыр (*12:1-7*).

# Пәйгамбәрләр

Иске Гаһеднең байтак өлешен Ишагыйя, Иремия (Барухның ярдәме белән), Яхәзкыл, Даниил һәм тагын унике пәйгамбәр язган китаплар тәшкил итә. Һошея, Йоил, Амос, Убадия, Юныс, Михә, Нахум, Хабаккук, Сефания, Хәггәй, Зәкәрия һәм Малахи язган китаплар исә әллә ни күләмле булмаганга, әлеге унике пәйгамбәрне «кече пәйгамбәрләр» дип атыйлар.

Изге Китапта тасвирланган пәйгамбәрләр алдан күреп хәбәр бирү сәләтенә ия булсалар да, алар башкарган хезмәтнең чын асылы әйләнә-тирәдәге кешеләргә электә булган, хәзерге һәм киләчәктә көткән төрле күренеш-вакыйгаларның мәгънәсенә төшенергә ярдәм итүдән гыйбарәт. Хәтере кыска Исраил халкына пәйгамбәрләр, сез җир йөзендәге башка халыклар кебек түгел, сез үзгә дип, исләренә төшереп торганнар. Аллаһы, исраилиләрне Үзенең халкы дип игълан итеп, алар белән Килешү төзегән. Халыкның киләчәге дөньядагы төрле вакыйгаларга һәм язмыш шаукымына түгел, ә бәлки халыкның ни дәрәҗәдә Раббыга бирелгән булуына бәйләнгән. Пәйгамбәрләрнең китапларында ачы фаш итү сүзләре һәм кешеләр, ахыр чиктә үз Аллаларына ялварып, Аңарда котылу табар, дигән якты өметләр чиратлашып килә.

Пәйгамбәрләр Исраил угылларына үз исеменнән мөрәҗәгать итмәгән, кешеләргә алар Аллаһыдан үзләренә иңгән сүзләрне генә җиткергән. Пәйгамбәрләрнең сөйләмендә төрле шартлы билгеләр, серле сүзләр бик күп, аларның мәгънәсен җиңел генә аңлап та булмаган. Әмма гасырлар үтү белән, алдан күреп әйтелгән әлеге сүзләрнең хаклыгына кешеләр ышанганнар һәм күп кенә вакыйгаларда пәйгамбәрләргә вәхи ителмеш сүзләрне таныганнар. Әйтик, кешелекне гөнаһ һәм үлем хакимлегеннән коткарып, мәңгегә Үз патшалыгын урнаштырачак Коткаручының дөньяга киләсен пәйгамбәрләр Мәсих туганчы бик күп алдан хәбәр иткәннәр.

Һәм бүген, пәйгамбәрләрнең шушы китапларын укып, без тарихи вакыйгаларның яки алдан күреп әйтелгән сүзләрнең тормышка ашуы белән генә түгел, ә бәлки кешенең нинди юллар белән Аллаһы каршына килүе турындагы мәңге искермәс хикәяләр белән дә танышабыз.



# Ишагыйя пәйгамбәр

Ишагыйя пәйгамбәр Мәсих туганга кадәр җиде йөз еллар элек Исраилдә яшәгән. Ул ихлас күңелдән Аллаһының данын һәм бөеклеген вәгазьләгән, Раббыдан читләшүче Исраил халкының, икейөзлеләнеп, диндар булып кылануын фаш иткән, гөнаһлы бәндәләрне тәүбәгә килергә чакырган; байтак шәһәрләрне алданиләр көткәнлеге хакында кисәтеп куйган.

Ишагыйя халыкны Аллаһыга өмет багларга чакырган. Менә аның өндәмәләреннән берсе: «Син белмисеңмени? Ишеткәнең юкмыни? Раббы – мәңгелек Аллаһы, җирнең бөтен тарафларын Бар кылучы. Ул арымый да, алҗымый да; Аның зирәклеге – акыл ирешмәслек. Арыган бәндәгә Ул – көч, хәлдән тайганга ныклык бирә. Яшьләр дә арып хәлдән тая, яшь егетләр дә абынып егыла, ә Раббыга өметләнгәннәр яңа көч ала: бөркет сыман, канатларында күтәрелә, йөгерәләр алар – алҗымыйлар, баралар – арымыйлар».

Кешелекне коткарачак Гайсә Мәсихнең туасын да Ишагыйя пәйгамбәр алдан хәбәр иткән. Мәсихнең дөньяга килүе, Аның тормышы, кичергән газаплары, вафаты һәм үледән терелүе – берничә йөз елдан соң буласы һәм Инҗил китабында тасвирланган вакыйгаларның барысы турында ул алдан әйтеп куйган.

Ишагыйя пәйгамбәр Мәсих турында болай дигән: «Ул безнең сырхауларны үз өстенә алды, авыруларыбызны күтәреп алып китте. Без аны Аллаһы тарафыннан кыйналган, җәза бирелгән һәм җәберләнгән дип уйладык, ул исә безнең җинаятьләребез аркасында тәненә җәрәхәт алды, гөнаһларыбыз аркасында кыйналды. Аның җәзалануы безгә иминлек, җәрәхәтләре сихәтлек китерде. Без барыбыз сарыклар сыман адашып йөрдек – һәркайсыбыз үз юлында булды, ә Раббы барыбызның гөнаһларын аның өстенә өйде. Аны газапларга дучар иттеләр, әмма ул күндәмлек белән аларны кабул итте, авызын ачып берни дәшмәде; чалырга алып барган сарык бәрәне сыман, йон кыркучылар алдында тавышын чыгармаган бәрән сыман, һичбер аваз салмады».

*Ишагыйя 40:28–31; 53:4–7*



## «Һәм алар кылычтан – сука төрәне, ә сөңгедән урак ясаячак»

Ишагыйя пәйгамбәр китабында ахыр заман һәм Аллаһы вәгъдә иткән Коткаручының, дөнья Хуҗасы – зарыгып көткән Мәсихнең патшалыгы турында алдан әйтеп куелган сүзләр бар:

Соңгы көннәрдә Раббы йорты урнашкан тау
башка барлык таулардан биегрәк булыр,
калкулыклар өстеннән күтәрелеп торыр,
һәм бар халыклар шунда агылыр.
Байтак халыклар, килеп:
«Әйдәгез, Раббы тавына,
Ягъкуб Алласының йортына меник, – дип әйтер. –
Ул безгә Үзенең юлларын өйрәтер,
ә без шулардан йөрербез».
Чөнки Канун – Сионнан,
Раббы Сүзе Иерусалимнән чыгачак.
Кавемнәр арасында Ул хөкем оештырачак,
күп халыкларның дәгъваларын хәл итәчәк;
һәм алар кылычтан – сука төрәне, ә сөңгедән урак ясаячак;
бер халык икенчесенә кылыч күтәрмәячәк,
һәм сугыш һөнәренә алар бүтән өйрәнмәячәк.

*Ишагыйя 2:2–4*



## «Явызлыкка вә зыян-зарарга урын калмаячак»

Аллаһы Углы Гайсә Мәсих патшалыгы урнашкачниләр буласын Ишагыйя пәйгамбәргә Раббы алдан әйтеп куя – ул вакытта инде җир йөзендә явызлык та, кайгы-хәсрәт тә булмаячак.

Юксыл-мескеннәргә ул дөреслек белән хөкем чыгарачак,
илдәге мазлумнарның* эшләрен гаделлек белән хәл итәчәк;
үзенең сүзе-таягы белән җирне кыйнаячак,
ираннәренең сулышы белән явызны үтерәчәк.
Билендә аның дөреслек вә тугрылык билбавы булачак.
Шулай, бүре белән сарык бәрәне бергә яшәячәк,
юлбарыс белән кәҗә бәтие янәшә ятачак;
бозау, яшь арыслан һәм үгез көтүен кечкенә бала көтәчәк.
Сыер белән ана аю бергә утлап йөриячәк,
аларның балалары рәттән ятачак,
арыслан да, үгез сыман, салам ашаячак.
Имчәк бала зәһәр елан өне янында уйнап йөриячәк,
һәм күкрәктән аерылган сабый үзенең кулын елан оясына сузачак.
Минем изге тавымда инде явызлыкка вә зыян-зарарга урын калмаячак,
чөнки диңгез су белән тулган кебек,
бөтен җир Раббыны танып белү белән тулачак.

*Ишагыйя 11:4–9*

* Мазлум – рәнҗетелгән, түбәнсетелгән зат.



## Һошея пәйгамбәр

Төньяк патшалыкның – Исраилнең – Раббы юлыннан тайпылуы, анда канунга сыймаган эшләр кылынуы, халыкның потсыннарга табынуы турында без сезнең белән укыган идек инде. Исраилиләрне туры юлга күндерергә өметләнеп, Раббы Үзенең пәйгамбәрләре аша халыкка мөрәҗәгать итә, аларга әледән-әле бәла-казалар җибәрә торды. Әмма барысы да файдасызга булды: халык үзе дә, патшалар да кануннарны санламады, пот-сыннарга табынуын дәвам итте. Шул сәбәпле Раббы, әлеге патшалыкны тар-мар китереп, анда яшәүче халыкны баскынчылар кулына тапшырырга карар кылды.

Төньяк патшалык тар-мар ителер алдыннан анда Һошея, Ишагыйя һәм Михә исемле пәйгамбәрләр көн күрде. Һошея пәйгамбәрнең китабында Аллаһы белән Исраил мөнәсәбәтләре, ир-ат белән хатын-кыз арасындагы никах кебек сурәтләнеп, халыкның хыянәте исә иренә тугрылык сакламаган хатын рәвешендә тасвирлана. Һошея пәйгамбәр бу хакта менә ничек яза:

> Әй Исраил угыллары, Раббы сүзенә колак салыгыз: бу җирдә яшәүчеләрне Раббы хөкемгә тарта, чөнки бирелә тугрылык та, мәрхәмәт тә, Аллаһыны танып белү дә юк. Антлар биреп тә, алдау, үтереш, угрылык, зиначылык хәттин ашты, бертуктаусыз адәм каны түгелә. Мине танып белмәгәнгә халкым юк ителер! Мине танудан баш тартканга Мин дә сездән баш тартам; руханиларым, Аллагызның канунын онытканга, Мин дә сезнең балаларыгызны онытырмын. Әй Исраил, бүтән халыклар кебек сөенмә, шатланма, чөнки син, үз Раббыңнан ваз кичеп, зина кылдың.

Әмма пәйгамбәр, шул ук вакытта, халык туры юлга төшеп Раббы алдында тәүбә китерә калса, Аллаһы Үзенең халкын фатихаларга әзер, дип тә әйтә: «Әй Исраил, Раббыга, үз Аллаңа кире кайт, чөнки син гөнаһларың аркасында түбән тәгәрәдең». Раббы болай ди: «Хыянәтләрен кичерермен, үзләрен йөрәгемә якын күреп яратырмын, чөнки аларга булган ачуым басылды инде. Исраил өчен Мин таң чыгы кебек булырмын; лалә кебек чәчәк атар ул, тамырларын Ливан эрбетедәй ныгытыр, ботак-тармаклары җәелеп китәр».



Тәүбәгә килгән халыкның ерак киләчәге турында пәйгамбәрлек кылып, Һошея мондый сүзләр әйтә: «Әмма шулай да исраилиләрнең саны диңгез комыдай үлчәп тә, исәпләп тә бетергесез булачак; һәм аларга „сез – Минем халкым түгел“ дип әйтелгән урында „сез – тере Аллаһының балалары“ диячәкләр».

*Һошея 1:10; 4:1–2, 6; 9:1; 14:2, 5–6*

# Йоил пәйгамбәр

Йоил пәйгамбәрнең кайсы елларда яшәве төгәл мәгълүм түгел, әмма ул Яһүдә җирендәге пәйгамбәрләрнең берсе дип саналган. Атап әйткәндә, ерак киләчәк турында, Раббы көненең җитүе турында пәйгамбәрлек кылып, ул болай дигән:

«Нинди дәһшәтле көн! Раббы көне җитеп килә, ул инде бик якын! Кодрәт иясе бу көнне һәлакәт яудырачак! Сионда быргы кычкыртыгыз, халык өстенә афәт ябырылуын Минем изге тавымда игълан итегез. Бу җирдә яшәгән һәркем куркудан тетрәнеп торсын – Раббы көне җитеп килә, ул инде бик якын! Аннары Мин һәр кешегә Үземнең Рухымны яудырырмын, угылларыгыз вә кызларыгыз пәйгамбәрлек кылыр, өлкәннәрегез гаиптән хәбәр* бирүче төшләр күрер, егетләрегезгә Аллаһыдан күренешләр иңәр. Ул көннәрдә хәтта кол ирләр белән кол хатыннарга да Үз Рухымны яудырырмын. Раббының бөек вә дәһшәтле көне җитәр алдыннан күктә дә, җирдә дә галәмәтле билгеләр – кан, ут вә төтен баганалары күренер, кояш каралыр, ай исә кан төсенә керер. Раббы исемен телгә алып, Аңа мөрәҗәгать иткән һәркем котылып калыр, чөнки, Раббы әйткәнчә, Сион тавына вә Иерусалимгә качып киткәннәр котылу табар».

Йөзләрчә еллар үткәннән соң рәсүл Петер, халыкка Хакимебез Гайсә Мәсих хакында сөйләгәндә, мисал итеп Йоил пәйгамбәр китабыннан әнә шул сүзләрне китерә.

Исраилнең кабат аякка басуы турында да Йоил шулай ук алдан әйтеп куя: «Менә шул көннәрдә, шул вакытта, Яһүдә белән Иерусалимне әсирлектән коткаргач, Мин, бар халыкларны җыеп, Хөкем үзәненә китерермен һәм аларны Үземнең милкем Исраилгә каршы кылган гамәлләре өчен хөкемгә тартырмын, чөнки алар Минем халкымны төрле кавемнәр арасына тараттылар, җиремне үзара бүлгәләп бетерделәр, халкымны җирәбә салып бүлгәләделәр. Раббы, Сионнан торып, Үз сүзен белдерер, Иерусалимнән Үз тавышын җиткерер – күк тә, җир дә калтырап торыр. Әмма Раббы Үз халкын сыендырыр, исраилиләрне яклап калыр. „Шул чагында сез Раббы икәнемне, Үземнең изге тавым Сионда яшәвемне белерсез; һәм Иерусалим изге урын булыр,“ – ди Раббы».

*Йоил 1:15; 2:1, 28–32; 3:1–2, 16–17*

* Гаиптән хәбәр – Аллаһыдан иңгән хәбәр.



## Юныс пәйгамбәр

Бервакыт Юныс пәйгамбәргә Раббы болай диде: «Ниневәгә юл ал! Шул бөек калага барып, халкын кисәт! Чөнки Миңа андагы явызлыклар турында хәбәр килеп иреште». Әмма Юныс, Аллаһы сүзенә колак салмыйча, Аңардан качып Таршиш шәһәренә китәргә карар кылды һәм, Яфу шәһәренә килеп җитеп, Таршишка баручы бер корабка утырды. Ләкин Раббы диңгез өстендә шундый көчле җил кузгатты ки, коточкыч давыл кубып, кораб җимерелер хәлгә килде. Котлары алынган диңгезчеләрнең һәркайсы үз илаһына ялварырга тотынды; аннары алар, корабны җиңеләйтмәкче булып, төялгән йөкләрен диңгезгә ыргытырга тотындылар. Бу вакытта Юныс корабның аскы катында тирән йокыга талган иде. Кораб хуҗасы исә Юнысны уятып: «Нишләп йоклап ятасың син? Тор! Аллаһыңа ялвар! Бәлки безне Ул коткара алыр», – диде. Диңгезчеләр дә: «Әйдәгез, жирәбә салып белик: кем аркасында бәлагә тарыдык икән?» – дип сөйләнә башладылар. Жирәбә салдылар, һәм ул Юныска чыкты. «Ташлагыз мине диңгезгә, – диде аларга Юныс, – шул чагында диңгез тынар. Мин беләмен: бу коточкыч давылга сез минем аркада эләктегез». Юнысны суга ыргытуга диңгез шундук тынып калды, һәм корабтагылар, куркуларыннан дер калтырап, Раббы хөрмәтенә корбан китерделәр, нәзерләрен әйттеләр. Аллаһы исә гаҗәп зур бер балыкка Юнысны йотарга боерды, һәм балык карынында Юныс өч көн һәм өч төн дәвамында үзенең Раббы Алласына бертуктамый дога кылды. Шуннан Раббы балыкка Юнысны коры җиргә чыгарып төкерергә әмер бирде.

Юныс пәйгамбәргә Раббы икенче мәртәбә сүзен ирештерде: «Ниневәгә юл ал! Шул бөек калага барып, Мин кушканча, халкын кисәт!» Бу юлы Юныс, Аллаһы сүзенә каршы килергә кыймыйча, Ниневәгә юл тотты. Шәһәргә килеп җиткәч ул, урамнар буйлап йөри-йөри, халыкны үгетләде. «Кырык көннән Ниневә хәрабә хәленә киләчәк!» – диде ул. Бу турыда ишеткәннән соң Ниневә патшасы, үзенең сараеннан чыгып, өстендәге патша киемнәрен салып ташлады да, тупас киндер кием киеп, бөтен халыкка тупас кием кияргә, ураза тотарга, кылган бар гөнаһлары өчен ярлыкау сорап Аллаһыга ялварырга кушты. Шәһәр халкы Аллаһыга



һәм Аның пәйгамбәренә ышанды. Раббы исә, Ниневә халкының явызлык кылудан туктавын күреп, мәрхәмәт күрсәтте, баштагы ниятеннән кайтып, алар өстенә бәла-казалар җибәрмәде.

*Юныс 1 – 3*

## Михә пәйгамбәр

Михә пәйгамбәр тумышы белән Яһүдәдәге Морешет шәһәреннән. Ул – Яһүдә патшалары Иотам, Әхәз, Хизәкыйя һәм Исраил патшалары Менахем, Пекахья, Пеках, Һошея тәхеттә утырган заманнарда, Мәсих туганга кадәр 740–700 елларда пәйгамбәрлек итә. Халыкның Аллаһы юлыннан тайпылачагы, халык юлбашчыларын көткән җәза, Самарея һәм Иерусалимнең җимереләчәге турында Михә алдан әйтеп куя. Шулай ук ул киләчәктә патшалык итәчәк Сион Патшасы Мәсих һәм Аның патшалыгы турында да алдан күреп бәян итә:

> Шундый көннәр килер: Раббы йорты урнашкан тау башка барлык таулардан биегрәк булыр, калкулыклар өстеннән күтәрелеп торыр, һәм бар халыклар шунда агылыр... «Ул көнне Мин, – дип игълан итә Раббы, – аксакларны җыеп алырмын, сөрелгәннәрне, Үзем бәла-казага дучар иткәннәрне бергә туплармын. Әнә шул аксакларны һәм сөргенчеләрне Мин көчле бер халык кылырмын һәм, шушы көннән башлап, алар өстеннән Сион тавында мәңге хакимлек итәрмен. Әй сарыкларны күзәтә торган манара, Сион-кызның ныгытмасы булган Иерусалим, хакимлек сиңа кире кайтачак; Иерусалим патшалыкны үзенә алачак».

Ягъкуб нәселеннән исән калганнар – исәпсез-хисапсыз башка халыклар арасында Раббы иңдергән чык бөртеге, һичкем көтмәгәндә, һичкем чакырмаганда килеп, басуларны сугарып киткән яңгыр кебек булыр.

*Михә 4:1, 6–8; 5:7*



## Мәсихнең килүе турында пәйгамбәрлек сүзләре

Ошбу китапның башында Аллаһының кешене Үз сурәтендә, Үзенә охшатып яратуы хакында сөйләнә. Аллаһы кешенең дә Үзе кебек үк мәрхәмәтле, гадел, гөнаһсыз булуын тели. Әмма инде беренче кешеләр – Адәм белән Һава – гөнаһка каршы тора алмыйлар. Аларның беренче углы Кабил үзенең ир туганы Һабилнең җанын кыя. Озакламый җир йөзе шул дәрәҗәдә гөнаһка бата ки, Раббы хәтта: «Һәммәсе юлдан язган, бозыклыкка бердәй баткан; игелек кылучы күренми, һичкем юк!» – дип әйтергә мәҗбүр була.

Раббы Аллаһыга тугрылык сакласын, Аның кануннары буенча яшәсен өчен Аллаһы җир йөзендәге халыклар арасыннан берсен – Исраил халкын сайлап ала. Үзенең пәйгамбәрләре аша Ул Исраил халкына Коткаручының – Аның тарафыннан май сөртелгән Затның («Мәсих» – яһүд телендә «май сөртелгән Зат» дигәнне аңлата) дөньяга киләсен алдан әйтеп куя. Ишагыйя пәйгамбәр Гайсә Мәсих туганга кадәр җиде йөз ел элек болай дип әйтә: «Менә, безнең өчен бер сабый бала туды: угыл бүләк ителде безгә; аның иңендә хакимлек булачак, һәм аңа Гаҗәеп Киңәшче, Кодрәтле Аллаһы, Мәңгелек Ата, Иминлек Хакиме дигән исем биреләчәк». Михә пәйгамбәр исә Мәсихнең кайсы төбәктә туасын да әйтеп куя: «Ләкин син, Эфратадагы Бәйт-Лехем, Яһүдә шәһәрләре арасында иң кечкенәсе булсаң да, Минем исемнән Исраил белән идарә итәсе зат синдә туачак. Аның нәсел-нәсәбе ераклардан, бик борынгыдан киләдер».

Ишагыйя пәйгамбәр китабыннан без дөньяга Мәсих килүнең төп максатын беләбез: Мәсих кешелекне гөнаһ хакимлегеннән коткару һәм адәм балаларының гөнаһлары өчен үлем кабул итеп, аларга Раббы Аллаһыга йөзләре белән борылырга ярдәм итү, коткару өчен килә. Пәйгамбәр аша Раббы болай ди: «Минем тәкъва колым күпләрне аклаячак, аларның гөнаһларын үз өстенә алачак».

Алдан күреп әйтелгән әлеге сүзләрнең һәммәсе Гайсә Мәсих җиргә килгәннән соң чынга аша. Китапның икенче өлешендә без сезгә Гайсәнең туувы, Аның тормышы һәм тәгълиматы, Аның үлеме һәм үледән терелүе турында сөйләрбез.

*Зәбур 13:3; Ишагыйя 9:6; 53:4-12; Михә 5:2*



# ЯҢА ГАҺЕД

# Аллаһы йортында Зәкәриягә фәрештәнең күренүе

Тәүратта бәян ителгән иң соңгы вакыйгалар белән Инҗилдәге вакыйгаларны йөзләгән еллар аерып тора. Гайсә Мәсих дөньяга килгәнче үк инде яһүдиләр, үзләренең сәяси бәйсезлеген тулысынча югалтып, римлылар кул астында калалар. Әмма халык өметен өзми, чөнки пәйгамбәрләрнең борынгы китапларында җиргә Коткаручының килүе турында әйтелгән була. Бик күпләр Аның, яһүдиләрне римлылар хакимлегеннән азат итеп, Исраилнең әүвәлге бөеклеген кабат кайтарасына ышанып яши. Әмма Аллаһы Үзенең халкы өчен бөтенләй башка, искиткеч нәрсә әзерләп куйган була; һәм әлеге Коткаручының – Мәсихнең* – җиргә килүе хакында беренче булып Чумдыручы Яхъя хәбәр итә.

Яхъяның дөньяга килүе бик үк гадәти булмый. Аның атасы – рухани Зәкәрия – үзенең хатыны Элисабет белән Яһүдиянең таулы өлешендә яши иде. Алар икесе дә Раббының әмер-боерыкларын төгәл үтәүче тәкъва кешеләр иде. Аларның хәсрәтенә, олы яшькә җиткән бу икәүнең балалары юк иде.

Көннәрдән беркөнне Зәкәрия Иерусалимдәге Аллаһы йортында рухани хезмәтен башкара, Аллаһы йортының ишегалдына җыелган күп санлы халык исә дога кылып тора иде. Зәкәрия хуш исле сумала-майлар көйрәткән мәлне аның янына Раббы фәрештәсе инде. Аны күреп Зәкәрия бик нык курыкты. Фәрештә исә аңа: «Курыкма, Зәкәрия, синең догаң кабул булды, – диде. – Хатының Элисабет сиңа ир бала тудырыр, син аңа Яхъя дип исем кушарсың. Синең күңелең шатлык-сөенеч белән тулыр, баланың тууына күпләр куаныр, чөнки Раббы каршында ул бөек булыр. Углың авызына шәраб капмас, анасының карынында чакта ук Изге Рух белән сугарылыр. Исраилиләрнең күбесен ул Раббыга, аларның үз Алласына кире кайтарыр». Әмма фәрештәнең сүзләренә Зәкәрия шикләнә калды һәм аңарга: «Моның шулай буласын мин ничек белермен? Мин инде карт, хатыным да олы яшьтә», – диде. Фәрештә исә аңа җавап итеп: «Мин – Аллаһы хозурындагы Җәбраилмен,

* *Мәсих* – дөньяны коткару өчен Аллаһы тарафыннан сайланып, май сөртелгән Зат (Исраил патшасын билгеләгәндә Аллаһы кушуы буенча сайланган кешенең башына руханилар зәйтүн мае сөртә торган булганнар).



һәм Ул мине шушы куанычлы хәбәрне сиңа белдерү өчен җибәрде. Минем сүзләремә ышанмаган өчен, әйткәннәрем тормышка ашканчы, син телдән язарсың һәм сөйләшә алмассың», – диде.

*Лук 1:5–21*

## Чумдыручы Яхъяның дөньяга килүе

Барысы да нәкъ фәрештә әйткәнчә булды: вакыты җиткәч, Зәкәрия белән Элисабетның угылы туды. Аларның шатлыгы чиксез иде; алар белән бергә туган-тумача һәм күрше-күлән дә куанды. Чөнки ул заманнарда ир белән хатынның – Зәкәрия белән Элисабетныкы сыман – балалары булмаса, бу зур бәхетсезлек һәм хурлык саналган.

Сабый дөньяга килеп сигез көн үткәннән соң, Муса кануны кушканча, баланы сөннәткә утырту йоласы башкарылырга тиеш иде; һәм шушы йоланы гамәлгә ашырырга килүчеләрнең һәммәсе балага, атасыныкы кебек үк, Зәкәрия дип исем кушарга теләде, чөнки ул вакытларда балага ата-анасының яисә туган-тумачасының исемен бирү гадәткә кергән була. Әмма аларның бу теләкләренә каршы, баланың анасы: «Юк, аның исеме Зәкәрия түгел, Яхъя булырга тиеш», – диде. Аңа җавап итеп: «Синең кардәшләрең арасында андый исем бирәүдә дә юк бит», – диделәр. Аннары, балага нинди исем кушарга телисең дип, төрле ишарәләр белән атасына мөрәҗәгать иттеләр. Зәкәрия, язу тактасы сорап алып, «аның исеме Яхъя булыр» дип язды. Бу хәлгә бөтенесенең исе китте. Шул мизгелдә Зәкәриянең теле ачылды, һәм ул Аллаһыны данлап сөйли башлады. Күрше-тирәдә яшәүчеләр барысы шомланып калды; таулы Яһүдиянең барлык төбәкләрендә әлеге вакыйга кеше теленнән төшмәде. Бу хакта ишеткән һәркем «бу бала кем булыр икән?» дип баш ватты, чөнки Раббының аңа ярдәм итүе күренеп тора иде. Баланың атасы Зәкәрия исә, Изге Рух белән сугарылып, Аллаһыдан бирелгән сүзләрне әйтте: «Раббыны, Исраилнең Алласын данлыйк, чөнки Ул ярдәмгә килде һәм Үз халкын азат итте, күп еллар элек изге пәйгамбәрләре аша вәгъдә иткәнчә, Үзенең колы Давыт* нәселеннән куәтле Коткаручы җибәрде. Ә син, сабый, Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәре дип аталырсың, чөнки Раббыга юл әзерләп, Аның алдыннан барырсың, Аның халкына «гөнаһларыгыз кичерелгәч, сезне котылу көтә» дип белдерерсең. Караңгыда һәм үлем дөньясында утырганнарга яктылык бирер, аякларыбызны тынычлык юлына юнәлтер өчен, шәфкате ташып торган Аллаһы безгә югарыдан таң кояшы иңдерер».

* *Давыт* – Мәсих туганга кадәр якынча 1000 елда идарә итә башлаган бөек Исраил патшасы.



Яхъя исемле сабый үсә, рухи яктан ныгый бирде һәм Исраил халкына күренер вакыты җиткәнче чүл якларында яшәде.

*Лук 1:22–25, 57–80*

## Гайсәнең тууы хакында Яхшы хәбәр

Адәм балаларын гөнаһ һәм үлем коллыгыннан коткарыр өчен Аллаһы Тәгалә дөньяга Үзенең Углы Гайсә Мәсихне җибәрә. Ул туганнан соң җирдә яңа дәвер башлана. Без еллар исәбен дә Гайсә Мәсих туган көннән саныйбыз.

Гайсәнең дөньяга килүе искитәрлек. Ул, Аллаһы Углы булуына карамастан, мал абзарында туа. Гайсә дөньяга килеп күпмедер вакыт үтүгә, Һируд* патша аны үтерергә карар кыла.

Әмма барысын да тәртип буенча сөйлик. Исраил иленең төньягында урнашкан кечерәк кенә Насара шәһәрендә саф йөрәкле, ихлас күңелдән Аллаһы Тәгаләгә бирелгән Мәрьям исемле бер кыз яши иде. Беркөн Аллаһы аның янына Үзенең фәрештәсе Җәбраилне җибәрде. Мәрьям янына килеп, Җәбраил: «Иминлек сиңа, и Аллаһының мәрхәмәтенә ирешкән бәндә! Раббы синең белән!» – диде. Мәрьям аптырап калды, бу сүзләрнең мәгънәсен аңларга тырышты. Җәбраил аңа: «Курыкма, Мәрьям! Аллаһы сиңа мәрхәмәт кылды. Син буйга узарсың һәм Ир Бала табарсың, Аңа Гайсә дип исем кушарсың. Ул бөек булыр. Аны Аллаһы Углы дип йөртерләр. Раббы Алла Аңа ерак бабасы Давытның тәхетен бирер, һәм Ул Ягъкуб халкы өстеннән мәңге патшалык итәр, һәм патшалык итүенең азагы булмас», – диде.

Йосыф атлы бик диндар кешегә ярәшелгән Мәрьям исә фәрештәдән: «Ничек шулай булыр икән, мин бит әле кияүдә түгелмен?» – дип сорады. Җәбраил аңа җавап итеп: «Изге Рух иңеп, сине Аллаһы Тәгаләнең кодрәте чолгап алыр, шуңа күрә синнән туган Бала изге булыр һәм Аллаһы Углы дип аталыр», – диде. Мәрьям аңа: «Мин – Раббы бәндәсемен, син ничек әйтсәң, шулай булсын», – дип җаваплады. Шуннан фәрештә аның яныннан китеп барды.

Мәрьямнең балага узганын белгәннән соң Йосыф ярәшүне өзәргә ниятләде, әмма төшендә аның янына Раббы фәрештәсе килеп: «Давытның нәсел варисы Йосыф! Мәрьямне хатынлыкка алырга курыкма. Карынында йөрткән баласы аның Изге Рухтан. Мәрьям Угыл тудырачак, һәм син Аңа Гайсә дип исем кушарсың, чөнки Ул Үз халкын гөнаһлардан коткарачак!» – диде.

*Маттай 1:19–21; Лук 1:26–35*

* *Һируд* – биредә яһүд патшасы Бөек Һируд күздә тотыла.



## Гайсә Мәсихнең тууы

Шул көннәрдә кайсар* Август бөтен Рим империясендә халык санын алырга фәрман биргәнлектән, Мәрьям белән Йосыфка ерак юлга кузгалырга туры килде. Исемлеккә теркәлү өчен һәркем үз токымының шәһәренә кайтырга тиеш иде. Йосыф белән Мәрьям исә Гайсә туганга кадәр мең еллар элек Исраилдә идарә иткән Давыт патша нәселеннән иделәр.

Шул рәвешле, Йосыф белән Мәрьям дә Давыт патшаның шәһәре саналган Бәйт-Лехемгә юл алды. Насара шәһәре белән Бәйт-Лехем арасы йөз чакрымнан артык иде. Ул заманнарда әле поездлар да, автомобильләр дә булмаганга, аларның сәфәре берничә көнгә сузылды. Насара шәһәре Исраилнең төньягындагы Гәлиләядә, Бәйт-Лехем исә көньяк тарафта – Яһүдия җирендә урнашкан иде. Гәлиләядән Яһүдиягә бару өчен алар Самарея төбәген узарга тиеш булдылар; өстәвенә Самарея белән Яһүдия таулы өлкәләр иде.

Йосыф белән Мәрьям, озын юл үтеп, Бәйт-Лехемгә аяк басканда кунакханәләрдә буш урын калмаган, ә Мәрьямнең инде бала табар вакыты җиткән иде. Бу хакта без Инҗилдән: «Мәрьям үзенең беренче Баласын – Ир Бала тапты, Аны биләп утлыкка салды», – дип укыйбыз. Димәк ки, төн кунарга алар терлек абзарында тукталалар, ә Сабыйны исә маллар өчен куелган утлыкка салалар. Борынгы риваятьләрдә язылганча, әлеге абзар тау куышында урнашып, ул якларда көтүчеләр андый куышларга төнгелеккә мал-туарны куып кертә торган булалар.

*Лүк 2:1–7*

* *Кайсар* – Рим императорының рәсми исемнәреннән берсе.



## Гайсә Мәсихнең тууы хакында фәрештәләрнең көтүчеләргә хәбәр итүе

Шул төнне Бәйт-Лехем тирәсендәге кырда берничә көтүче үзләренең сарыкларын саклый иде. Бермәлне алар каршында Раббы фәрештәсе пәйда булып, әйләнә-тирә Раббы шөһрәтеннән балкып китте. Көтүчеләр бик нык курыктылар. Әмма фәрештә аларга: «Курыкмагыз! Мин сезгә куанычлы хәбәр – бөтен халык өчен зур шатлык алып килдем, – диде. – Бүген Давыт шәһәрендә* сезнең Коткаручыгыз – Мәсих, Хаким туды! Сез аны менә шушы билге аша танырсыз: мал утлыгында биләүле Бала ятар». Кинәт фәрештә янында күк гаскәре – күп санлы башка фәрештәләр пәйда булып: «Күкләрдәге Аллаһыга дан! Аллаһы илтифат күрсәткән кешеләргә җирдә иминлек булсын!» – дип Аллаһыны данларга тотындылар.

*Лук 2:8–14*

* *Давыт шәһәре* – ягъни Бәйт-Лехем.



## Көтүчеләр Гайсә янында

Фәрештәләрне күрүгә көтүчеләрнең куркуга төшүләре дә, Коткаручының – Хаким Гайсә Мәсихнең тууы хакында ишетеп гаҗәпкә калулары да бик аңлашыла. Шуңа күрә алар сарыкларын ташладылар да Бәйт-Лехемгә таба юл алдылар. Бу хакта Инҗилдә болай дип язылган: «Фәрештәләр күккә ашканнан соң, көтүчеләр бер-берсенә: „Әйдәгез, Бәйт-Лехемгә барыйк, анда ниләр булганны, Раббы хәбәр иткәнне күрик“, – диделәр. Алар ашыгып Бәйт-Лехемгә килделәр, анда Мәрьям белән Йосыфны һәм мал утлыгында яткан Баланы эзләп таптылар. Баланы күргәннән соң, Аның хакында үзләренә әйтелгән сүзләрне башкаларга да сөйләделәр. Көтүчеләрне ишеткән кешеләрнең барысы хәйран калды. Мәрьям исә боларның һәммәсен күңеленә салып куйды. Ишетергә һәм күрергә насыйп булган бар нәрсә өчен Аллаһыны данлап һәм мактап, көтүчеләр үзләренең маллары янына кайттылар. Барысы да фәрештә әйткәнчә булды».

*Лук 2:15–20*



## Тәкъва Шимун

Илаһи Бала туып сигез көн үткәннән соң, рухани Аны сөннәткә утыртты, аннары Сабыйга Гайсә дип исем куштылар. Бу исемне Аңа, әнкәсе Мәрьям авырга узганчы ук, фәрештә биргән иде, һәм әлеге исем «Раббы коткара» дигәнне аңлата.

Раббы кануны буенча гаиләдәге беренче ир бала Аллаһыга багышланырга тиеш булганлыктан, Гайсәгә алты атна тулгач, Аны Раббыга багышлау өчен һәм ике урман күгәрченен яки ике бала күгәрченне корбанга китерү өчен Иерусалимдәге Аллаһы Йортына алып килделәр.

Ул заманнарда Иерусалимдә Шимун исемле бер кеше бар иде. Исраилгә юаныч килүен көтеп яшәүче тәкъва һәм диндар бу адәм Изге Рух белән сугарылган иде. Изге Рух аңа: «Раббы Мәсихен күрмичә үлмәссең», – дип әйткән була. Канунда язылган йоланы башкару өчен Мәрьям белән Йосыф нарасый Гайсәне Аллаһы йортына алып килгәч, Изге Рух кушуы буенча Шимун да шунда килде, Баланы кулларына алды һәм Аллаһыны данлап: «И Хөкемдар, вәгъдәңне үтәп, Син мине, Үз колыңны, тынычландырып дөньядан озатасың, чөнки барча халыклар каршында Син әзерләгән коткаруны, мәҗүсиләрнең күзен ачасы яктылыкны, халкың Исраилгә киләчәк данны күрдем», – диде. Гайсәнең атасы һәм анасы Шимунның Бала хакында әйткән сүзләрен гаҗәпләнеп тыңлап тордылар.

Шимун аларны фатихалады һәм Баланың анасы Мәрьямгә: «Бу Бала Исраилдә күпләрнең егылуына, икенче берәүләрнең күтәрелүенә сәбәпче, Аллаһыдан килгән кисәтүче бер билге кебек булыр; күпләр бу билгене кире кагар һәм шул рәвешле аларның уй-ниятләре фаш ителер. Үзеңнең дә йөрәгеңә кылыч кадалгандай булыр», – диде.

*Лүк 2:21–35*



## Йолдызчыларның сәҗдә кылырга килүе

Яһүдия җирендәге Бәйт-Лехем шәһәрендә Гайсә туганнан соң, Иерусалимгә көнчыгыштан йолдызчылар килде. Ул заманда Яһүдиядә Һируд патша идарә итә иде. «Яһүдиләрнең яңа туган Патшасы кайда? – дип сораштылар алар кешеләрдән. – Көнчыгышта Аның йолдызын күреп, Аңа баш иярга дип килдек без».

Бу хакта ишеткәч, Һируд патша һәм аның белән бергә бөтен Иерусалим хафага төште. Һируд, барлык баш руханиларны һәм Канун белгечләрен җыеп, алардан Мәсихнең кайда туарга тиешлеген сорады. «Яһүдия җирендәге Бәйт-Лехем шәһәрендә, – диде алар, – чөнки пәйгамбәр аша Аллаһы болай дип әйткән: „Ә син, Яһүдә җирендәге Бәйт-Лехем, Яһүдәнең бөек шәһәрләреннән һич тә ким түгелсең, чөнки синдә Юлбашчы туачак һәм Ул халкым Исраилнең Көтүчесе булачак“». Шуннан Һируд, йолдызчыларны яшертен генә чакыртып алып, алардан йолдызның төгәл калыккан вакытын белеште һәм аларны Бәйт-Лехемгә җибәреп: «Барыгыз, Бала хакында барын да җентекләп белешегез. Аны тапкач, миңа хәбәр итегез, мин дә барып Аңа баш иярмен», – диде. Чынлыкта исә Һируд патша Баланы үтерергә карар кылды, чөнки тора-бара Ул аның тәхетен алыр дип курыкты.

Патшаны тыңлап бетергәннән соң йолдызчылар юлга чыктылар, ә көнчыгышта алар күргән йолдыз алларыннан барды һәм, Бала яткан урынга барып җиткәч, туктап калды. Йолдызны күрүләренә алар бик шат иде.

*Маттай 2:1–10*



## Йолдызчыларның бүләкләре. Һирудның гаепсез сабыйларны үтерергә боеруы

Йолдызчылар, Бәйт-Лехемгә килеп җитеп, йолдыз туктап калган урында бер йортка керделәр һәм Бала белән анасы Мәрьямне күреп Бала каршында тезләнеп баш иделәр, аннары, хәзинәләрен чыгарып, Аңа алтын, ладан һәм мирра бүләк иттеләр.

Төшләрендә, Һируд янына кире кайтмаска дип, Аллаһыдан кисәтү алгач, алар башка юл белән үз илләренә кайтып киттеләр. Йолдызчылар тарафыннан алданганын күреп, Һируд бик ярсыды. Шуннан ул, йолдызчылар сүзе буенча Баланың яшен чамалап, Бәйт-Лехемдәге һәм аның тирәсендәге ике яшькә җитмәгән барлык ир балаларны үтерергә боерды. Бәйт-Лехемгә гаскәриләр килделәр дә бер гаепсез сабыйларның җаннарын кыйдылар.

*Маттай 2:10–12, 16*



## Мисырга качу

Йолдызчылар: «Киләчәктә Ул Исраил тәхетенә утырачак», – дигән теге Бала да җаннары кыелган сабыйлар арасында булыр, дип уйлады Һируд патша. Әмма аның өмете акланмады. Акыл ияләре китүгә, Раббы фәрештәсе Йосыфның төшенә кереп: «Бала белән анасын ал да Мисырга кач; Мин сиңа әйткәнгә кадәр шунда кал, чөнки Һируд Баланы табып үтерергә ниятли», – диде. Төнлә Йосыф торды да, анасы белән Баланы алып, Мисырга китеп барды һәм Һируд үлгәнчегә кадәр шунда яшәде. Раббының пәйгамбәр аша: «Үземнең Углымны Мин Мисырдан чакырып алдым», – дигән сүзе әнә шулай гамәлгә ашты.

Бәйт-Лехемнән Мисырга барып җитәр өчен йөзләрчә чакрым җир үтәргә кирәк иде. Сабый бала күтәргән Йосыф белән Мәрьямгә андый озын юлны узу җиңел булмады.

*Маттай 2:13–15*



## Гайсәнең Насарада үткәргән балалык еллары

Һируд патша исән чакта Йосыф, Мәрьям һәм сабый бала Гайсә Мисырда кала бирделәр. Һируд дөнья куйганнан соң, Раббы фәрештәсе кабат Йосыфның төшенә кереп: «Тор, Бала белән Аның анасын алып, Исраил җиренә әйләнеп кайт. Баланы юк итәргә теләүчеләр инде үлде», – диде.

Йосыф, фәрештә сүзенә буйсынып, Исраил җиренә юл алды. Әмма Яһүдиядә атасы Һируд урынына Архелай патша идарә итүен ишетеп, Йосыф анда барырга курыкты. Төшендә кисәтү алгач, Гәлиләя өлкәсенә юнәлде һәм әүвәле Мәрьям яшәгән Насара шәһәренә килеп урнашты.

Гайсәнең Насарадагы тормышы хакында без бик аз беләбез. Аның атасы Йосыф балта остасы була; аңардан күреп, булышкалап Гайсә дә әлеге һөнәргә өйрәнә. Гайсәнең балалык еллары, үсмер чагы турында Инҗилдә аз язылган. Әмма түбәндәге юллар бик күпне сөйли: «Бала үсә, ныгый, гакыл туплый бирде, һәм Аллаһының шәфкате һәрчак Аның юлдашы булды»; «Гайсә үсте, акыл җыйды; һәм үскән саен Аллаһының вә бәндәләрнең илтифатын ныграк казана барды».

Биредә Гайсәнең ата-ана сүзеннән чыкмавын да әйтеп үтәргә кирәк. Бу хакта без Инҗилдә болай дип укыйбыз: «...һәм ата-анасына итагатьле булды». Аллаһы бит балаларның ата-ананы яратуын һәм алар сүзеннән чыкмавын тели. Аллаһының ун боерыгының берсе: «Ата-анаңны хөрмәт ит. Шулай эшләсәң, Раббы Аллаң сиңа бирәсе җирдә гомерең озын булыр», – дип өйрәтә.

*Маттай 2:19–23; Лук 2:40, 50–52; Чыгыш 20:12*



## Яшүсмер Гайсә Аллаһы йортында

Гайсә, Насара шәһәрендә яшәп, тәрбия алуында булды. Ул үсә бирде, рухи яктан ныгып, акыл-зиһен җыйды, һәм Аллаһының шәфкате һәрчак Аның юлдашы булды.

Гайсәнең ата-анасы һәр елны Иерусалимгә Котылу бәйрәменә бара торган иде. Гайсәгә унике яшь тулгач, алар аны да үзләре белән Иерусалимгә бәйрәмгә алып килделәр.

Бәйрәм көннәре тәмам булгач, бөтенесе дә кайтыр юлга чыктылар, үсмер Гайсә исә Иерусалимдә калган булып чыкты. Мәрьям белән Йосыф моны абайламады, кардәшләре һәм таныш-белешләре белән кайта торгандыр, дип уйлады. Күпмедер вакыттан соң алар Гайсәне эзләргә тотындылар һәм таба алмыйча кабат Иерусалимгә килделәр. Өч көннән соң алар Аны Аллаһы йортында эзләп таптылар. Гайсә сораулар биреп, остазларның сөйләгәнен тыңлап алар арасында утыра иде. Гайсәнең сүзләрен ишеткән һәркем Аның тирән акылына, биргән җавапларына хәйран калды.

Гайсәнең анасы Аны күрүгә: «Балам! Ник шулай борчыйсың безне? Күрәсеңме, атаң белән икебез тәмам хәсрәткә калып сине эзләп йөрибез», – диде. Аларга җавап итеп Ул: «Ни өчен сез Мине эзлисез? Атам Йортында булырга тиешлегемне белмисезме әллә?» – диде. Ләкин алар Аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңламадылар. Әнисе Мәрьям исә әлеге сүзләрне күңеленә салып куйды.

Гайсә ата-анасы белән бергә Насарага әйләнеп кайтты; ата-анасы сүзеннән Ул бер дә чыкмады. Гайсә үсте, акыл җыйды; һәм үскән саен Аллаһының вә бәндәләрнең илтифатын ныграк казана барды.

*Лук 2:40–52*



## Чумдыручы Яхъяның вәгазьләве

Рухани Зәкәриянең углы Яхъя чүлдә яшәп көн күрде. Раббы аны махсус хезмәт өчен әзерли иде: озакламый Мәсихнең, ягъни Гайсәнең килүе турында халыкка хәбәр итеп, Яхъя адәм балаларын тәүбәгә килергә өндәргә тиеш иде. Мәсих килүгә Яхъяның халыкны әзерләргә тиешлеге турында әле Яхъя туганчы ук йөзәр ел алдан пәйгамбәрләр болай дип язып калдырган була: «Менә, синең алдыңнан Мин хәбәрчемне җибәрәм, ул Синең барыр юлыңны әзерли торыр. Чүлдә әнә бер аваз яңгырый: „Раббыга юл әзерләгез, Ул үтәсе сукмакларны турайтыгыз!“».

Яхъяның киеме дөя йонынннан булып, билендә күн каеш иде, ә ашаган ризыгы аның саранча һәм кыр балы булды. Яхъяга Аллаһы сүзе килеп ирешкәннән соң, Яхъя, Үрдүн елгасы буендагы барлык төбәкләрне әйләнеп чыгып, тәүбәгә килүегезнең билгесе итеп суга чуму йоласын үтәгез, һәм Аллаһы сезнең гөнаһларыгызны кичерер, дип халыкны вәгазьләп йөрде. Тәүбә итәр, суга чуму йоласын үтәр өчен Яхъя янына бөтен Яһүдия җиреннән һәм Иерусалимнән күпләп халык килә, Яхъя исә аларны Үрдүн елгасында чумдыра иде.

«Безгә нәрсә эшләргә соң?» – дип сораучыларга Яхъя: «Ике күлмәге булган кеше аның берсен күлмәге булмаган кешегә бирсен. Ризыгы булганнар да башкалар белән бүлешсен», – дип җавап кайтара иде. Суга чуму йоласын үтәр өчен салым җыючылар да килеп Яхъядан: «Остаз! Ә безгә нәрсә эшләргә?» – дип сорый иде. Ул аларга: «Тиешеннән артыгын таләп итмәгез», – дип җавап бирә иде. Шулай ук гаскәриләр дә: «Ә безгә нәрсә эшләргә?» – дип сорый иде. Аларга исә ул: «Талап, янап беркемнән әйбер алмагыз. Хезмәт хакыгыздан канәгать булыгыз», – дип әйтә иде.

*Марк 1:1–6; Лук 3:2–14*



## Гайсә Мәсихнең суга чумдырылуы

Халык Мәсихнең килүен көтеп яшәде, шуңа күрә күбесе: «Вәгъдә ителгән Мәсих, Коткаручы шушы Яхъя микән инде?» – дип бер-берсеннән сораша иде. Әмма Яхъя аларга: «Тәүбә итүегезнең билгесе итеп мин сезне суга чумдырам, ләкин миннән кодрәтлерәк Берәү килә; мин Аның аяк киемен күтәреп йөрергә дә лаек түгелмен. Ул башкарган чумдыру Изге Рух һәм ут белән булыр», – дип җавап бирә иде. Шулай дип аның Гайсә Мәсих турында әйтүе иде.

Бервакыт Яхъя тарафыннан суга чумдырылыр өчен аның янына Гайсә килде. Яхъя Аны туктатырга тырышып: «Син мине чумдырырга тиешсең, ә Син миңа килгәнсең!» – диде. Әмма аңа җавап итеп Гайсә: «Хәзергә шулай булсын, чөнки Аллаһы ихтыярын без шул рәвешле үтәргә тиеш», – диде, һәм Яхъя Аның белән килеште. Йоланы үтәгәннән соң Гайсә судан чыкты. Ул шунда күк капусы ачылуын һәм Аллаһы Рухының күгәрчен рәвешендә Үзенә иңүен күрде. Аннары күкләр киңлегеннән: «Бу – Минем сөекле Углым, Ул – Минем куанычым!» – дигән өн килеп иреште.

*Маттай 3:11–17*



## Гайсәнең чүлдә сыналуы

Гайсә суга чуму йоласын үтәгәннән соң, Изге Рух Аны иблис тарафыннан сынар өчен чүлгә алып китте. Ризык капмыйча кырык көн һәм кырык төн уздырып, Гайсә бик нык ачыкты. Сынаучы иблис, Аның янына килеп: «Әгәр Син Аллаһы Углы икәнсең, бу ташларга боер – икмәккә әйләнсеннәр!» – диде. Гайсә аңа болай дип җавап бирде: «Изге Язмада „кеше икмәк белән генә яшәмәс, Аллаһының һәр сүзе белән яшәр” дип әйтелгән».

Шуннан иблис Аны Иерусалимгә алып килде дә Аллаһы йортының иң биек урынына китереп бастырды һәм: «Әгәр Син Аллаһы Углы булсаң, түбән ташлан! Изге Язмада „Аллаһы Синең турыда фәрештәләренә әмер бирер. Алар Сине кулларына күтәреп алырлар, аякларың ташка абынмас“ дип әйтелгән бит», – диде. «Анда „Раббы Аллаһыңны сынама“ дигән сүзләр дә бар», – дип җавап кайтарды Гайсә.

Аннары иблис Аны биек тау башына алып менеп дөньяның барлык патшалыкларын, аларның бар шөһрәтен күрсәтте һәм: «Әгәр йөзтүбән капланып миңа табынсаң, боларның һәммәсен Сиңа бирәм!» – диде. «Кит, иблис! – дип җавап кайтарды Гайсә. – Изге Язмада „Раббы Аллаңа табын, Аңа гына хезмәт ит“ дип әйтелгән». Шуннан соң иблис Гайсәне калдырып китеп барды, ә Аның янына фәрештәләр килеп хезмәт күрсәтә башлады.

*Маттай 4:1–11*



## Гайсә Мәсихнең унике шәкерте

Җиткән егет булганнан соң Гайсә, Насарадан китеп, Гәлиләя җиренә – Геннисарет күле буенда урнашкан Кәпәрнаум шәһәренә килеп төпләнде. Ул заманда әлеге күлне Гәлиләя диңгезе дип тә атыйлар иде. Шул рәвешле, Ишагыйя пәйгамбәрнең: «И Зәбулун җире, Нәптали җире, диңгезгә алып баручы юл һәм Үрдүн аръягы – мәҗүсиләр иле Гәлиләя! Караңгылыкта яшәүче халык бөек яктылыкны күрде. Үлем караңгылыгында яшәүчеләр өчен нур балкыды», – дип әйткән сүзләре гамәлгә ашты.

Шул вакыттан Гайсә: «Тәүбәгә килегез! Күкләр Патшалыгы инде бик якын!» – дип вәгазьли башлады. Аңа төрле төбәкләрдән килгән халык төркемнәре ияреп йөрде, Ул аларны өйрәтә, авыручыларны исә савыктыра иде.

Беркөнне Гәлиләя күле буеннан үтеп барганда Гайсә ятьмә салып йөрүче агалы-энеле ике балыкчыны – Петер дип аталган Шимун белән Әндрине күреп, аларга: «Миңа иярегез! Мин сезне кеше аулаучы* итәрмен!» – диде. Хакыйкатьне танып белсеннәр өчен Мин сезне кешеләр янына Яхшы хәбәрне сөйләргә җибәрермен, дигәнне аңлата иде бу. Әндри белән Петер, шунда ук ятьмәләрен калдырып, Аңа иярделәр. Арырак киткәч, Гайсә бертуган кардәшләрне – Ягъкуб һәм Яхъяны күрде. Алар аталары Зебедәй белән бергә көймәдә ятьмә сипләп утыра иде. Гайсә аларны Үзе белән чакырды; алар шунда ук, көймәне һәм аталарын калдырып, Аңа иярделәр. Шулай ук башка шәкертләр дә Гайсә чакыруга шунда ук Аның артыннан иярде. Гайсә аларга авыруларны савыктыру һәм җеннәрне куып чыгару кодрәте бирде.

Шулай итеп Гайсә, һәрчак Аның янында булсыннар өчен унике шәкертне сайлап алып, аларны махсус өйрәтте. Әлеге шәкертләрнең исемнәре түбәндәгечә: Гайсә «Петер» дип исем кушкан Шимун, Әндри, Яхъя, Ягъкуб, Филип, Бартулумай, Маттай, Томас, Һалфай углы Ягъкуб, Таддай, Көрәшче Шимун һәм соңыннан Гайсәгә хыянәт итәчәк Яһүдә Искариот. Гайсәнең бөтен шәкертләре гаптади кешеләр иде, әмма Аллаһы аларга Гайсә Мәсихнең – Аллаһы Улының – дуслары һәм шәкертләре булу бәхетен бирде.

*Маттай 4:12–22; Марк 3:14–19*

* ...кеше аулаучы... – кешеләрне Аллаһы юлына алып килүне Гайсә биредә балык тоту белән чагыштыра.



## Гайсә кылган беренче могҗиза

Бервакыт Гайсәне һәм Аның шәкертләрен Гәлиләя өлкәсендәге Кәна шәһәренә туй мәҗлесенә чакырдылар. Мәҗлес барышында кунакларга дигән шәраб беткән булып чыкты. Туйга Гайсәнең анасы да килгән иде, углы Гайсәгә ул: «Аларның шәраблары беткән», – диде. Әмма анасына Гайсә: «Минем әлегә вакытым җитмәгән», – дип җавап бирде. Шунда Мәрьям, углы Гайсәгә күрсәтеп, хезмәтчеләргә: «Ул нәрсә әйтсә, шуны эшләгез», – диде.

Янәшәдә генә зур-зур алты таш чүлмәк тора иде. Хезмәтчеләргә Гайсә: «Чүлмәкләргә су тутырыгыз», – дип әйткәч, алар чүлмәкләрне мөлдерәмә итеп тутырдылар. Шуннан Гайсә аларга: «Инде чумырып алыгыз да туй башлыгына илтеп бирегез», – диде. Эчемлектән авыз иткәч, туй башлыгы үз янына кияүне чакырып алып: «Кешеләр башта табынга яхшы шәрабны куя, ә инде җитәрлек эчелгәч, начаррагын китерә; ә син яхшы шәрабны азакка калдыргансың», – диде. Туй башлыгы шәрабның кайдан икәнен белми иде, бу хакта суны чумырып алган хезмәтчеләргә генә мәгълүм иде.

Шул рәвешле, Гәлиләянең Кәна шәһәрендә могҗизалы гамәлләрен башлап җибәреп, Гайсә Үзенең данын күрсәтте, һәм шәкертләре Аңа ышаныч белдерделәр.

*Яхъя 2:1–11*



## Гайсәнең Аллаһы йортыннан сатучыларны куып чыгаруы

Котылу бәйрәме алдыннан Гайсә Иерусалимгә килде. Аллаһы йортының ихатасында үгез, сарык, күгәрчен сатучыларны, өстәл янында акча алмаштырып утыручыларны күргәч, Ул, баудан чыбыркы үреп, сарыклары, үгезләре белән бергә һәммәсен Аллаһы йортыннан куып чыгарды; акча алмаштыручыларның акчаларын чәчеп җибәрде, өстәлләрен аударып ташлады; күгәрчен сатучыларга: «Алып китегез боларны! Атамның йортын базарга әйләндермәгез!» – диде. Шунда Гайсәнең шәкертләре Изге Язмадагы «Йортың өчен җан атып көям Мин» дигән сүзләрне исләренә төшерде.

Гайсәнең Аллаһы йортындагы шушы гамәленнән соң яһүдиләр Аңардан: «Болай эшләргә хокукың барлыгын безгә нинди билге-ишарә белән исбатлый аласың?» – дип сорадылар. «Шушы Аллаһы йортын җимереп ташлагыз, Мин аны өч көндә яңадан төзиячәкмен», – диде аларга Гайсә. Моңа җавап итеп яһүдиләр: «Бу Йорт кырык алты ел төзелде, ә Син аны өч көндә торгызмакчы буласыңмы?» – дип әйттеләр. Әмма Гайсә, Аллаһы йорты дип, Үзенең тәне хакында әйткән иде. Гайсә үледән терелеп торганнан соң шәкертләре, Аның шушы хакта әйткәннәрен искә төшереп, Изге Язмага да, Гайсәнең сүзләренә дә ышандылар.

Котылу бәйрәме көннәрендә Гайсәнең Иерусалимдә күрсәткән могҗизалы гамәлләрен күреп, күпләр Аңа иман китерде.

*Яхъя 2:13–23*



## Гайсәнең Никәдим белән әңгәмә коруы

Яһүдиләрнең башлыкларыннан Никәдим атлы бер фарисей* төнлә яшертен генә Гайсә янына килеп: «Остаз! Синең Аллаһыдан килүең безгә мәгълүм: чөнки Син күрсәткән могҗизалы гамәлләрне Аллаһы ярдәменнән башка беркем дә эшли алмас иде», – диде. Аңа җавап итеп Гайсә: «Хак сүз әйтәм сиңа: яңадан тумаса, беркем дә Аллаһы Патшалыгын күрә алмас», – диде. «Картаеп беткәч кеше ничек яңадан туа алсын инде? – диде Никәдим. – Анасы карынына кереп кабат туа алмый бит ул!» Гайсә аңа болай дип җаваплады: «Хак сүз әйтәм сиңа: әгәр кеше судан һәм Рухтан тумаса, Аллаһы Патшалыгына керә алмас. Тәннән туган – тән, Рухтан туган – рух була. Сез яңадан туарга тиешсез, дип әйтүемә гаҗәпләнмә». Никәдим Аның әйткәннәрен аңламады, шуңа күрә: «Ничек алай була алсын?» – дип сорады. Гайсә аңа җавап биреп әйтте: «Исраилиләр чүлдә йөргәндә Муса колга башында еланны югары күтәргән сыман**, Адәм Углы*** да шулай югары күтәрелергә тиеш. Аллаһы дөньяны шулкадәр яратты ки, Углына ышанган беркем һәлак булмасын, ә бәлки мәңгелек тормыш алсын өчен, Ул Үзенең бердәнбер Углын бирде. Аллаһы Үз Углын дөньяны хөкем итү өчен түгел, ә бәлки дөнья Аның аша котылсын өчен дөньяга җибәрде. Аның Углына ышанучы хөкемгә тартылмый, ә ышанмаучы хөкем ителде инде, чөнки Аллаһының бердәнбер Углына ышанмады. Хөкем исә шуннан гыйбарәт: дөньяга яктылык килде, әмма кешеләр, яман эшләр башкарганга, яктылык урынына караңгылыкны яратты. Явызлык эшләүче һәркем яктылыкка нәфрәт белән карый һәм үзенең яман эшләре ачылмасын өчен яктылыкка килми. Ә дөреслек буенча эш итүче, гамәлләренең Аллаһы аша башкарылуы күренеп торсын өчен, яктылыкка килә».

*Яхъя 3:1–21*

---

* *Фарисейлар* – борынгы Яһүдиядәге дини төркемнәрнең берсе. Фарисейлар Муса канунын һәм кешеләр тарафыннан гасырлар буена Канунга өстәлеп килгән кагыйдәләрне төгәл үтәүне алга сөреп яшәгәннәр.

** Бу урында Мусаның, Аллаһы кушуы буенча бакырдан ясалган еланны колга башына беркетеп куеп, югары күтәрүе турында сүз бара.

*** *Адәм Углы* – Мәсихнең Даниил пәйгамбәр китабында телгә алынган исемнәренең берсе.



## Гайсә һәм Самарея хатыны

Бервакыт Гайсә Исраилнең көньягындагы Яһүдиядән Гәлиләягә барырга чыкты. Яһүдия белән Гәлиләя арасында Самарея җирләре урнашкан булып, самареялеләр, яһүдиләр кебек үк, күк вә җирне бар иткән бердәнбер Аллаһыга табыналар, әмма аларның йолалары да, руханилары да, кайчандыр яһүдиләр җимереп киткән гыйбадәтханәләре дә башка иде. Әлеге самареялеләр белән яһүдиләрнең үзара мөнәсәбәтләре һәрчак дошмани булды.

Гайсә Үзенең шәкертләре белән Самареянең Сухар дигән шәһәренә килеп җиткәч, ерак юлдан арып, кое янына килеп утырды, ә шәкертләре ризык юнәтергә дип китеп барды. Көн урталары иде. Шунда су алырга дип бер Самарея хатыны килде. Гайсә аңа: «Миңа эчәргә су бир әле», – диде. Хатын гаҗәпләнеп: «Ничек итеп Син, яһүди була торып, миннән, Самарея хатыныннан эчәргә сорыйсың?» – диде. Гайсә аңа болай җавап бирде: «Әгәр дә син Аллаһының бүләге турында һәм „Миңа эчәргә бирче“ дип сораучының Кем икәнен белсәң, син үзең Аңардан эчәргә сорар идең, һәм Ул сиңа тереклек суы бирер иде». Шуннан хатын Аңа: «Әфәндем! Синең бит чумырып алырга савытың юк, ә кое тирән. Син ул тереклек суын кайдан алырсың икән?» – диде. Гайсә аңа: «Бу суны эчкән һәркем янә сусар, ә Мин биргән суны эчкән кеше һичкайчан сусамас. Мин биргән су аңарда мәңгелек тормышка ага торган чишмәгә әвереләчәк», – дип җавап кайтарды. Әлеге хатын Аңардан: «Аллаһыга кайда табынырга кирәк – самареялеләрнең ата-бабалары табынган калку җирдәме, әллә Иерусалимдәме?» – дип сорады. Гайсә аңа: «Аллаһы ул – Рух, һәм Аңа табынучылар рух вә хакыйкать кушканча табынырга тиеш», – дип җавап бирде. Хатын исә Аңа болай диде: «Мәсихнең киләсен беләм. Ул, килгәч, безгә бөтенесен аңлатып бирер». «Мин Ул, менә хәзер синең белән сөйләшеп торучы», – дип җаваплады Гайсә.

Шуннан хатын, су чүлмәген калдырып, шәһәргә китте һәм андагы кешеләргә: «Бәлки Ул Мәсихтер» – дип, кое янында очраткан Кеше турында сөйләде. Хатынның сүзләрен ишеткәч, әлеге шәһәрдә яшәүче самареялеләрнең күбесе Гайсәгә ышанды. Шуңа күрә самареялеләр, Мәсих янына килеп, үзләрендә калуын



үтенгәч, Ул анда янә ике көнгә тоткарланды. Аның сөйләгәннә-
рен тыңлаганнан соң тагын да күбрәк кеше Аңа инану белдерде.

*Яхъя 4:1–42*

## Мул табыш

Бервакыт Геннисарет күле буенда җыелган халык, Аллаһы сүзләрен тыңларга теләп, Гайсәне төрле яклап кысрыклый башлады. Шуннан Ул су читендә торган ике буш көймәнең берсенә – Шимуннныкы дигәненә керде дә ярдан бераз арырак китеп күл буендагы халыкны өйрәтә башлады.

Сүзен тәмамлагач, Ул: «Шимун, ятьмәләрегезне тирәнрәк урынга китеп салыгыз», – диде. Шимун Аңа: «Остаз! Без төнозын тырыштык, тик һичнәрсә тота алмадык. Әмма Син кушкач, ятьмәне салам», – дип җавап бирде. Тирән урынга җитеп ятьмәләрен салгач, бик күп балык эләкте, хәтта ятьмәләре ертыла башлады. Шуннан балыкчылар, икенче көймәдәге дуслары Ягъкуб белән Яхъяны чакырып, көймәләрнең икесен дә балык белән тутырдылар – йөкләре авыр булу сәбәпле көймәләре аздан гына батмый калды. Шимун-Петер, шушы хәлне күреп, Гайсә алдында тезләренә егылды да: «Хакимем, якын килмә миңа, мин гөнаһлы кешемен!» – диде. Гайсә белән янәшә торырга да үзен лаексыз санаганга, аның тәмам коты алынган иде. Гайсә исә Шимунга: «Курыкма, бүгеннән башлап син инде балык түгел, кеше аулый башларсың», – дип җавап бирде.

Вакытлар узу белән Шимун-Петер, дөрестән дә, вәгазь сөйли һәм адәм балаларын Хакимебез Гайсәгә иман китерергә күндерә башлап, аларны котылу юлына әйдәүче булды.

*Лүк 5:1–10*



## Паралич суккан кешенең савыгуы

Гайсә Кәпәрнаум шәһәренә килгәч, гади халыктан да, югары катлаудан да төрле төбәкләрдән бик күп кеше җыелды. Ул һәрвакыттагыча халыкны өйрәтте, Аллаһының кодрәте исә, Аның юлдашы булып, Аңа авыруларны савыктырырга ярдәм итте. Бервакыт Гайсә вәгазь сөйләгән йорт янына, ятагы-ние белән күтәреп, Гайсә савыктырсын өчен паралич суккан бер кешене алып килделәр. Әмма халык арасыннан үтә алмаганга, йортның түбәсен сүтеп, авыруны ятагы белән бергә бүлмә уртасына, Гайсәнең алдына төшерделәр. Гайсә, аларның ышануларын күреп, авыру адәмгә: «Дустым, синең гөнаһларың кичерелде», – диде.

Канун белгечләре* һәм фарисейлар әлеге сүзләрне ишетеп: «Көфер сүз сөйләүче бу Кеше кем соң? Гөнаһларны Аллаһыдан башка кем кичерә алсын?» – дип үзара гәп куерта башлады. Гайсә аларның уйларын белеп: «Ни өчен күңелегездә шундый уйлар йөртәсез? – диде. – Нәрсә дип әйтү җиңелрәк: „гөнаһларың кичерелде“ дипме, әллә „тор да йөреп кит“ дипме? Адәм Углының җир йөзендә гөнаһларны кичерергә кодрәте барлыгын белеп торыгыз, – дип әйтте, аннары паралич суккан кешегә мөрәҗәгать итеп, – сиңа әйтәм, урыныңнан тор да ятагыңны алып өеңә кайт!» – диде.

Теге шундук барысының күз алдында торды да ятагын алып, Аллаһыны данлый-данлый өенә кайтып китте. Шушы хәлне күрүчеләр дә: «Без бүген искитәрлек нәрсәләр күрдек», – дип Аллаһы хөрмәтенә дан-шәрәфләр яудырды.

*Лүк 5:17–26*

---

* *Канун белгечләре* – Муса кануны белгечләре. Алар кешеләргә Канун таләпләрен өйрәткәннәр.



## Таудагы вәгазь: чын бәхет кануннары

Бервакыт Гайсә, җыелып торган халык төркемен күреп, тауга күтәрелде. Аның шушы таудан торып халыкка биргән вәгазе таудагы вәгазь дип атала. Тәүратта бәян ителгән вакыйгалар заманында Аллаһы Үзенең халкына ирештергән ун канундагы сыман, таудагы вәгазьдә дә кеше яшәешенең әхлакый нигезләре һәм Аллаһы Патшалыгына илтүче туры юл хакында сүз бара. Шәкертләре һәм башка кешеләр Гайсә тирәсенә килеп урнашканнан соң, Ул аларны өйрәтеп сөйли башлады:

Аллаһыга мохтаҗ булганнар бәхетле, чөнки Күкләр Патшалыгы – аларныкы.
Хәсрәт чигүчеләр бәхетле, чөнки алар юаныч табарлар.
Юашлар бәхетле, чөнки алар җирне мирас итеп алырлар.
Тәкъвалыкка ачыккан-сусаган кешеләр бәхетле, чөнки Аллаһы аларны тукландырыр.
Шәфкатьлеләр бәхетле, чөнки аларга да шәфкать күрсәтелер.
Саф күңеллеләр бәхетле, чөнки алар Аллаһыны күрерләр.
Татулык урнаштыручылар бәхетле, чөнки алар Аллаһы балалары дип аталыр.
Тәкъва булган өчен эзәрлекләнүчеләр бәхетле, чөнки Күкләр Патшалыгы – аларныкы.
Кешеләр сезне Минем аркада хурлаганда, эзәрлекләгәндә һәм сезгә каршы төрле явызлык эшләгәндә – сез бәхетле. Шатланыгыз һәм куаныгыз, чөнки күкләрдә әҗерегез зур. Сезгә кадәр яшәгән пәйгамбәрләрне дә шулай эзәрлекләгәннәр.
Сез – җирнең тозы. Әгәр тоз үзенең тәмен җуйса, аңа ничек тәм кайтарасың? Аяк астына чыгарып ташлаудан башкага ярамас ул.
Сез – дөнья өчен яктылык. Тау башына салынган шәһәр күренми калмас. Шәмгә ут алгач, аны савыт астына куймыйлар, киресенчә, шәмдәлгә утырталар, һәм ул өйдәгеләрнең бөтенесе өчен дә яктырта. Яхшы эшләрегезне күреп Күктәге Атагызны данласыннар өчен, сезнең яктылык та кешеләр алдында шулай балкысын.

*Маттай 5:1–16*



## Таудагы вәгазь: Муса кануны турында

Минем хакта, Муса канунын яки пәйгамбәрләр язганны юкка чыгарыр өчен килгән, дип уйламагыз. Мин юкка чыгарыр өчен түгел, бәлки аларны үтәр өчен килдем. Хак сүз әйтәм сезгә: җир һәм күк юкка чыкканчы, Канунның бер генә сызыгы да юкка чыкмаячак. Анда язылганның барысы да тормышка ашачак! Шулай итеп, кем дә булса андагы иң кечкенә әмерләрнең берәрсен бозып кешеләрне дә шуңа өйрәтсә, Күкләр Патшалыгында ул иң кечесе дип саналыр. Ә инде кем дә булса, әмерләрне үтәп, башкаларны да шуңа өйрәтсә, ул кеше Күкләр Патшалыгында бөек дип аталыр. Сезгә әйтәм: тәкъвалыгыгыз фарисейларныкыннан һәм Канун белгечләренекеннән өстен булмаса, Күкләр Патшалыгына кермәячәксез.

Ата-бабаларыгызга: «Үтермә! Кеше үтерүче хөкемгә лаек», – дип әйтелгәнне сез ишеттегез. Ә Мин исә болай дим: туганына юкка-барга ачу тотучы хөкемгә лаек; туганына «яраксыз» дип әйтүче исә Югары киңәшмә алдында җавапка тартылуга, ә инде «ахмак» дип әйтүче җәһәннәм утына лаек. Шуңа күрә корбан китерү урынына Аллаһыга багышлап бүләк алып барганда туганыңның сиңа булган рәнҗеше мәзбәх алдында исеңә төшсә, бүләгеңне шунда калдырып торып башта туганың белән татулаш, аннан соң гына кире килеп бүләгеңне тапшыр.

Сез: «Зина кылма», – дип әйтелгәнне ишеттегез. Ә Мин исә болай дим: хатын-кызга җенси теләк белән караучы күңеленнән инде зина кылган була. «Берәрсе хатынын аерып җибәрсә, аңа аерылышу кәгазе бирсен» дигән сүзләр дә бар. Ә Мин исә болай дим: хатыны тарафыннан зина кылу булмыйча, ире башка сәбәп аркасында аерылышса, ул аны зина кылуга этәрә, дип әйтәм. Иреннән аерылган хатынга өйләнүче дә зина кыла.

Ата-бабаларга: «Биргән антыңны бозма! Раббы алдында биргән антыңны үтә!» – дип әйтелгәнне дә сез ишеттегез. Ә Мин исә болай дим: бөтенләй дә ант итмә! Күк белән дә ант итмә, чөнки ул – Аллаһының тәхете; җир белән дә ант итмә, чөнки ул – Аллаһының аяк баскан урыны; Иерусалим белән



дә ант итмә, чөнки ул – бөек Патшаның каласы; башың белән дә ант итмә, чөнки чәчеңнең бер генә бөртеген дә ак яки кара итә алмыйсың. Сезнең «әйе» дигән сүзегез – «әйе», «юк» дигәнегез – «юк» булсын, чөнки шуннан артыгы – иблистән.

*Маттай 5:17–37*

## Таудагы вәгазь: мәхәббәт һәм дога турында

Сез: «Күз өчен – күз, теш өчен – теш», – дип әйтелгәнне ишеттегез. Ә Мин исә болай дим: явызлыкка каршы явызлык белән кайтарма. Уң яңагыңа суккан кешегә сул яңагыңны да куй. Берәрсе сине, хөкемгә тартып, күлмәгеңне алырга теләсә, аңа өске киемеңне дә биреп калдыр; берәрсе сине бер чакрым җир үтәргә мәҗбүр итсә, аның белән бергә ике чакрым үт. Синнән сораучыга бир һәм бурычка алырга теләүчене буш итмә.

Сез: «Якыныңны ярат, дошманыңа нәфрәт белән кара!» – дип әйтелгәнне ишеттегез. Ә Мин исә болай дим: дошманнарыгызны яратыгыз һәм сезне эзәрлекләүчеләр өчен догада булыгыз. Шулай эшләп, Күктәге Атагызның балалары булуыгызны күрсәтерсез. Аллаһы кояшны явызлар өчен дә, рәхимлеләр өчен дә чыгара һәм яңгырны тәкъваларга да, тәкъва булмаганнарга да яудыра бит. Әгәр сезне яраткан кешеләрне генә яратсагыз, Аллаһы сезгә нәрсә өчен әҗер бирер? Салым җыючылар да шулай эшли түгелме соң? Дусларыгызны гына сәламләсәгез, искитәрлек нәрсәсе бар моның? Мәҗүсиләр дә шулай эшли түгелме соң? Димәк ки, Күктәге Атагыз кебек сез дә камил булыгыз. Карагыз аны, тәкъва эшләрегезне кешеләр күрсен дип башкармагыз. Югыйсә Күктәге Атагыздан әҗер алмассыз. Шулай итеп, сәдака бирәсең икән, ул хакта сөйләп йөрмә; гыйбадәтханәләрдә, урамнарда макталыр өчен икейөзле кешеләр генә шулай эшли. Хак сүз әйтәм сезгә: алар инде үзләренең әҗерен алды. Әгәр хәер бирәсең икән, уң кулың ни кылганны сулы белмәсен, ярдәмең яшертен эшләнсен. Яшерен эшләрнең һәммәсен күреп торучы Атаң сиңа һичшиксез әҗерен бирер.

Дога кылганда да икейөзле кешеләр сыман булмагыз. Алар, барысы да күрсен дип, гыйбадәтханәләрдә яисә урам чатларында тукталып дога кылырга ярataлар. Хак сүз әйтәм сезгә: алар үзләренең әҗерен алды инде. Ә син, дога кылганда, бүлмәңә кереп артыңнан ишегеңне яп та күзгә күренмәс Атаңа дога кыл. Яшерен эшләрнең һәммәсен күреп торучы Атаң сиңа һичшиксез әҗерен бирер.

«Күбрәк сөйләсәк, яхшырак ишетелер» дип уйлаган мәҗүсиләр сыман, дога кылганда буш сүз сөйләмәгез. Алар сыман булмагыз, чөнки нәрсәгә мохтаҗ булуыгызны сез сораганчы ук Атагыз белеп тора. Сез менә болай дип дога кылыгыз:

**КҮКТӘГЕ АТАБЫЗ!**
**Исемең изге дип танылсын,**
**Синең Патшалыгың килсен,**
**Күктәге кебек, җирдә дә**
**Синең ихтыярың гамәлгә ашсын.**
**Кирәкле икмәгебезне безгә бүген бир.**
**Безгә явызлык кылучыларны**
**без кичергән кебек,**
**Син дә безнең явыз эшләребезне кичер.**
**Безне сынауларга дучар итмә,**
**ә явыз заттан сакла.**
**Чөнки Патшалык,**
**кодрәт вә дан мәңге Синекедер.**
**Амин.**

*Маттай 5:38 – 6:13*

## Таудагы вәгазь: Аллаһыга мөнәсәбәт турында

Ураза тотканда икейөзле адәмнәр сыман караңгы чырайлы булмагыз; ураза тотуларын кешеләр күрсен дип алар шулай боегып йөри. Хак сүз әйтәм сезгә: алар үзләренең әҗерен алды инде. Син исә ураза тотканда чәчләреңне майлап, битләреңне юып йөр; синең ураза тотуыңны башкалар түгел, ә бәлки күзгә күренмәс Атаң гына белсен. Яшерен эшләрнең һәммәсен күреп торучы Атаң сиңа шул чагында әҗерен бирер. Дөньялыкта мал-мөлкәт җыймагыз: аны көя кисә, тутык баса, караклар урлап чыга. Хәзинәне сез күкләрдә туплагыз: анда аны көя дә кисми, тутык та басмый, караклар да кереп урлап чыкмый, чөнки хәзинәгез кайда, күңелегез дә шунда булыр. Тәннең яктырткычы – күзләрдер. Күзләрең якты булса, синнән яктылык бөркелеп торыр; әгәр күзләрең нурсыз икән, бөтен тәнең караңгылыкка уралган кебек булыр. Әгәр инде эчеңдәге яктылык тоташ караңгылык икән, ул вакытта караңгылык үзе нинди булырга тиеш соң?

Берәү дә ике хуҗага хезмәт итә алмас: чөнки берсен ул яратмас, ә икенчесе күңеленә якын булыр; берсенә тугрылык саклар, икенчесен санга сукмас. Аллаһыга да, байлыкка да берьюлы хезмәт итә алмассыз.

Шуңа күрә Мин сезгә болай дим: җан асрар өчен нәрсә белән туклаыйм һәм тәнемне каплар өчен нәрсә киим дип борчылмагыз. Җан – ризыктан, тән киемнән мөһимрәк түгелме соң? Әнә кошларга карагыз: алар чәчми дә, урмый да, амбарларга ашлык та салмый, шулай да Күктәге Атагыз аларны туендыра. Ә сез кошлардан кадерлерәк түгелме соң? Сезнең кайсыгыз, кайгырганга карап, үз гомерен бер сәгатькә булса да озайта ала? Кием өчен ник борчыласыз? Кырда үсеп утырган чәчәкләргә карагыз: алар эшләми дә, эрләми дә; әмма мин сезгә болай дим: Сөләйман патша никадәр мәһабәт булмасын, аларның берсе кадәр дә киенә алмаган. Бүген кырда үсеп утырган, ә иртәгә учакка ташланасы үләнне Аллаһы шулай киендерә икән, сезне ничек киендермәсен инде, и сай иманлылар! Шулай булгач, «ни ашарбыз, ни эчәрбез, ни киярбез?» дип борчылмагыз. Мәҗүсиләрнең генә төп кайгылары шулдыр. Ә боларның һәммәсенә мохтаҗ



булуыгызны Күктәге Атагыз болай да белеп тора. Барыннан да бигрәк Аллаһы Патшалыгын һәм Аның гадел ихтыярын эзләгез, һәм боларның барысы сезгә насыйп ителер. Шулай итеп, иртәгәге көн турында кайгырмагыз, чөнки туачак көн үзе хакында үзе кайгыртыр; һәр көннең үз мәшәкате үзенә җитәрлек.

*Маттай 6:16–34*

# Таудагы вәгазь: кешеләргә мөнәсәбәт турында

Беркемне дә хөкем итмәгез, шул чагында үзегез дә Аллаһы хөкеменә дучар булмассыз, чөнки башкаларны ничек хөкем итсәгез, үзегезгә карата да шундый ук хөкем кылыныр; нинди үлчәм белән үлчәп бирсәгез, үзегезгә дә шундый ук үлчәм белән кайтарырлар. Нигә син туганың күзендәге чүп бөртеген күрәсең, ә үз күзеңдәге бүрәнәне сизмисең? Үз күзеңдә бүрәнә була торып, ничек син туганыңа: «Кая, күзеңдәге чүпне алыйм әле», – дип әйтә аласың. Икейөзле бәндә! Элек үз күзеңдәге бүрәнәне чыгар, шул чакта туганың күзендәге чүпне ничек алырга икәнен ачыграк күрерсең.

Изге дип саналган әйберләрне этләргә бирмәгез, юкса алар борылып үзегезне ботарлар. Энҗегезне дуңгызлар алдына сипмәгез, юкса алар аны таптап изәр.

Сорагыз – һәм Аллаһы сезгә бирер; эзләгез – һәм табарсыз; шакыгыз – һәм Ул сезгә ачар; чөнки һәр сораучы – ала, эзләүче – таба, һәм шакучыга ачалар. Арагыздан кайсыгыз, углы икмәк сораса, аңа таш тоттырыр; балык сораса, елан бирер икән? Әгәр сез, начар кеше булып та, балаларыгызга игелекле гамәлләр кыла аласыз икән, сезнең Күктәге Атагыз Үзеннән сораганнарга игелекне һичшиксез бирер.

Шулай итеп, кешеләрнең сезгә нәрсә эшләвен теләсәгез, үзегез дә аларга һәрчак шуны эшләгез; чөнки Муса канунының һәм пәйгамбәрләр язмаларының асылы шулдыр.

Тар капкадан керегез,  
чөнки һәлакәткә илтүче юл киң булыр,  
аның капкасы да иркен,  
һәм күпләр шул капкадан керә;  
ә тормыш капкасы тар,  
аның юлы да тар,  
һәм аны бик азлар гына таба.

*Маттай 7:1–14*

## АЛТЫН КАГЫЙДӘ

**Шулай итеп,**
**кешеләрнең сезгә**
**нәрсә эшләвен теләсәгез,**
**үзегез дә аларга һәрчак**
**шуны эшләгез.**

***Маттай 7:12***

## Таудагы вәгазь: хакыйкать һәм ялган

Яныгызга сарык тиресе ябынып килүче ялган пәйгамбәрләрдән сакланыгыз – асылда ерткыч бүре алар. Кылган гамәлләренең җимешенә карап танырсыз сез аларны. Күгән куагыннан – йөзем, тигәнәк сабагыннан инҗир җыялармыни? Һәрбер яхшы агач – яхшы җимеш, начар агач исә начар җимеш бирә. Яхшы агачның җимеше начар була алмаган сыман, начар агачның да җимеше яхшы була алмый. Яхшы җимеш бирми торган һәр агачны кисеп утка ташлыйлар. Шулай итеп, ялган пәйгамбәрләрне кылган гамәлләренең җимешенә карап танырсыз.

Миңа «Хакимем! Хакимем!» дип әйтүчеләрнең һәммәсе дә Күк Патшалыгына керә алмас; Күктәге Атамның ихтыярын үтәүче генә анда аяк басар.

Шул көнне күпләр Миңа: «Хакимем! Хакимем! Без Синең исемеңнән пәйгамбәрлек итмәдекмени? Синең исемне телгә алып җеннәрне куып чыгармадыкмыни? Синең исемне телгә алып байтак могҗизалар башкармадыкмыни?» – дип әйтерләр. Шулвакыт Мин аларга: «Мин сезне белмим; китегез янымнан, явызлык кылучылар!» – дип җавап кайтарырмын.

Шулай итеп, сүзләремә колак салган һәм аларны үтәгән һәркем үзенең йортын таш нигез өстенә төзегән гакыллы кешегә охшаган: яңгыр явып, елгалар ташып, җилләр ябырылса да, йорты җимерелмәгән, чөнки аның нигезе таштан булган. Ә инде Минем сүзләремне ишетеп тә, аларны үтәмәгән кем дә үзенең йортын ком өстенә төзегән гакылсыз кешегә охшаган: яңгыр явып, елгалар ташып, көчле җилләр ябырылуга, йорты җимерелеп төшкән – аңардан хәрабә генә калган.

Шунда Гайсә сөйләүдән туктады. Халык Аның тәгълиматын шаккатып тыңлады; чөнки Ул аларны Канун белгечләре сыман түгел, ә бәлки Аллаһы тарафыннан зур хакимлек бирелгән кеше кебек өйрәтте.

*Маттай 7:15–29*



## Тол хатынның үлгән углын терелтү

Көннәрнең берендә Гайсә Наин дип аталган шәһәргә китте. Аның артыннан шәкертләре һәм бик күп халык ияреп барды. Гайсә шәһәр капкасына якынлашып килгәндә, шәһәрдән мәет күтәреп чыгып баралар иде – бер тол хатынның бердәнбер углы үлгән икән. Үксеп елаган ананы күреп, Гайсә аны бик кызганды. «Елама!» – диде Ул аңа; аннары, якынрак килеп, кулы белән табутка орынды. Мәетне күтәреп баручылар туктадылар, һәм Гайсә: «Егет! Сиңа әйтәм, тор!» – диде. Мәет торып утырды һәм сөйләшә башлады. Гайсә, шул рәвешле, егетне анасына кайтарды. Бу хәлне күреп торган кешеләрнең күңеленә курку керде: «Арабызда бөек Пәйгамбәр барлыкка килде! Аллаһы Үз халкына ярдәмен җибәрде!» – дип, алар Аллаһыны данладылар.

*Лук 7:11–16*



## Орлык чәчүче турында гыйбрәтле хикәя

Бервакыт Гайсә Үзен тыңлап торучы халыкка орлык чәчүче турында гыйбрәтле хикәя сөйләде:

Менә бер кеше чәчүгә чыккан ди. Чәчкән вакытта орлыкның бер өлеше юл буена төшкән, һәм кошлар, очып килеп, аны чүпләп бетергән. Икенче бер өлеше аз туфраклы ташлы урынга төшкән. Тирән ятмаганга күрә орлык бик тиз тишелеп чыккан. Ә инде кояш чыгып кыздыра башлагач, тамырланып өлгермәгән үсентеләр шиңеп төшкән. Орлыкның кайберсе күгән куагы арасына төшкән. Куак, үсеп, орлыкны басып киткән. Уңдырышлы җиргә төшкән башка орлыклар исә йөз, алтмыш, утыз тапкыр артыграк уңыш биргән. Колагы булганнар – ишетсен!

Аннары Гайсә Үзенең шәкертләренә әлеге гыйбрәтле хикәянең асылын аңлатты:

Күкләр Патшалыгы турындагы сүзне ишетүчеләр, әмма аны аңламаучылар янына иблис килә дә алар күңеленә салынганны урлап китә – юл буена чәчелгән орлык әнә шундый кешеләрне хәтерләтә.

Ташлы җиргә чәчелгән орлыклар – ишеткән сүзне шундук шатланып кабул итүчеләр, әмма тамыры булмаганга, сүзне алар вакытлыча гына тота. Шул сүз өчен авырлыклар яки эзәрлекләүләр башланса, алар бик тиз кире чигенә.

Күгән куагы арасына төшкән орлыклар исә – сүзне ишетүчеләр, әмма тормыш мәшәкатьләре һәм байлыкка хирыслык аркасында аларның ишеткән сүзләре басылып кала һәм уңыш бирми.

Ә уңдырышлы туфракка чәчелгәне – сүзне ишетеп, аның асылына төшенүчеләр. Андыйлар йөз, алтмыш, утыз тапкыр артыграк уңыш бирә.

*Маттай 13:3–9, 18–23*



# Күкләр Патшалыгы турында гыйбрәтле алты хикәя

Беркөн Гайсә, өйдән чыгып, диңгез ярына барып утырды. Аны күрүгә янына бик күп халык җыелды. Шуннан Ул көймә эченә керде дә яр буендагы халыкны өйрәтә башлады. Гыйбрәтле хикәяләр ярдәмендә Гайсә аларга күп нәрсәләрне аңлатты:

Күкләр Патшалыгын нәрсә белән чагыштырып булыр иде? Әйтик, бер кеше үзенең басуына яхшы орлык чәчкән ди. Әмма төн җитеп һәммәсе йокыга талгач, дошманы килеп иген арасына тиле бодай орлыгы чәчеп киткән. Бодай үсентеләре күтәрелеп башак җибәрә башлауга, тиле бодай да күренгән. Хезмәтчеләре, йорт хуҗасына килеп: «Әфәнде, син бит басуыңа орлыкның яхшысын чәчкән идең, тиле бодай каян килеп чыккан соң?» – дип сораганнар. «Дошман эше бу», – дип җавап биргән хуҗалары. Хезмәтчеләр аңа: «Теләсәң, барып утыйк аны», – дигән. Әмма ул аларга: «Кирәкми, югыйсә утаганда тиле бодай белән бергә бодайны да йолкып атуыгыз ихтимал, – дип җаваплаган. – Иген өлгергәнче тегесе дә, монысы да үссен, уракка төшкәч уракчыларыма мин: „Башта тиле бодайны җыеп алып көлтәләргә бәйләгез дә яндырыгыз, ә ашлыкны урып келәткә илтеп салыгыз“, – диярмен».

Гайсә аларга тагын бер гыйбрәтле хикәя сөйләде:

Күкләр Патшалыгын кырга чәчкән горчица орлыгы белән чагыштырып булыр иде. Ул барча орлыклардан варак, ә инде үсеп җиткәч, бакчадагы һәммә үсемлектән биегрәк, агач кебек була; кошлар очып килеп аның сабакларында оя кора.

Аннары янә бер хикәя сөйләде:

Күкләр Патшалыгын ачыткы белән чагыштырып булыр иде. Әйтик, бер хатын өч үлчәм* онга ачыткы сала да, күпмедер вакыттан ачыткы камырны бик нык кабарта.

Күкләр Патшалыгын нәрсә белән чагыштырып булыр иде? Әйтик, берәү кырда күмеп куелган хәзинә тапкан ди. Ул аны яңадан күмеп куйган һәм шатлыгыннан бар мөлкәтен саткан да шул кырны сатып алган.

---

* *Өч үлчәм* – якынча 23 килограмм.



Күкләр Патшалыгы тагын нәрсә белән чагыштырып булыр иде? Әйтик, сәүдәгәр яхшы энҗеләр эзләгән ди. Менә ул искиткеч матур энҗе тапкан һәм, кайтып, бар мөлкәтен саткан да шул энҗене сатып алган.
Күкләр Патшалыгы тагын нәрсәгә охшаганмы? Әйтик, балыкчылар диңгезгә ятьмә салган, һәм аңа төрледән-төрле балык эләккән ди. Ятьмә балык белән тулгач, алар ятьмәне ярга тартып чыгарганнар да утырып балык сайлый башлаганнар: яхшысын кәрзингә салганнар, яраксызын читкә ташлаганнар. Дөнья беткәндә дә нәкъ шулай булыр: фәрештәләр килеп яман кешеләрне тәкъвалардан аерып алыр да дөрләп янган мичкә ташлар – анда елау һәм теш шыкырдату булыр.

*Маттай 13:24–33, 44–50*

## Гайсәнең давылны тынычландыруы

Шулай беркөнне Гайсә белән шәкертләре көймәгә утырдылар да Геннисарет күленең аръягына чыгарга булдылар. Көймәдә барганда Ул йоклап китте. Кинәт күл өстендә көчле давыл күтәрелеп, дулкыннар көймәгә бәрә башлады. Шәкертләре: «Хакимебез, коткар! Батабыз!» – дип Гайсәне уяттылар. «Әй сай иманлылар, нигә шулай курыктыгыз?» – диде Гайсә аларга һәм, аягүрә басып, җилне дә тыйды, диңгезгә дә: «Шаулама, тынычлан!» – дип боерды. Җил шундук басылды, күл өсте дә тынычланды, әйләнә-тирә тып-тын булып калды.

Котлары алынган шәкертләр гаҗәпләнеп бер-берсенә: «Кем соң Ул? Җилгә дә, дулкыннарга да әмер бирә, һәм алар Аңа буйсына», – диештеләр.

*Маттай 8:23–27; Марк 4:37–41; Лүк 8:22–25*



# Яһир кызының үледән терелүе

Бервакыт Гайсә төрле төбәкләрдән килгән халыкны Гәлиләя диңгезе буенда өйрәтеп торганда, гыйбадәтханә башлыкларыннан Яһир исемле берәү, Гайсә янына килеп, Аның аягына егылды да: «Кызым үлем хәлендә ята. Килеп, кулларың белән аңа орынсаң, ул савыгыр һәм яшәр иде», – дип ялварырга тотынды. Гайсә аның белән китеп барды. Алар артыннан, Гайсәне һәр яктан кысрыклап, бик күп кеше иярде.

Халык арасында унике ел дәвамында кан китүдән газапланган бер хатын бар иде. Күп кенә табибларда дәваланып та савыга алмаган бу хатын, Гайсә хакында ишеткәннең соңында «аның киеменә генә кагылсам да савыгыр идем» дигән ният белән арттан килде дә сиздермичә генә Гайсәнең киеменә кагылды һәм шундук үзенең савыгуын тойды.

Гайсә исә, Үзеннән көч киткәнне сизеп, артына борылды да халыктан: «Кайсыгыз киемемә кагылды?» – дип сорады. Шәкертләре, Аның ни өчен шулай сораганын аңламыйча: «Төрле яктан халык кысрыклый бит», – диделәр. Әмма Ул Үзенә орынган кешене күзләре белән эзли бирде. Куркуыннан калтырап төшкән хатын, үзенең сихәтләнүен аңлап, халык арасыннан чыкты һәм, Гайсә алдына егылып, дөресен сөйләп бирде. «Сине ышануың савыктырды, имин йөр һәм сәламәт бул», – диде аңа Гайсә.

Ул шулай дип сөйләшеп торганда, гыйбадәтханә башлыгының өеннән кешеләр килде һәм Яһирга: «Кызың вафат. Остазны ник борчып торырга», – дип әйтте. Әмма Гайсә, аларның сүзләрен ишетеп, Яһирга: «Курыкма, тик ышан гына», – диде. Яһирның өе янына җиткәч, Гайсә анда такмаклап елаган, каушап калган туган-тумачаны күрде. «Нигә хәсрәтләнәсез, нигә елыйсыз? Бала үлмәгән, йоклый гына!» – диде Ул. Аңардан көлә башладылар, әмма Ул Үзе белән Петерне, Ягъкубны, Яхъяны һәм кызның атаанасын ияртеп кыз яткан бүлмәгә керде. Кызның кулыннан тотып, Гайсә аңа: «Кыз бала, сиңа әйтәм, тор!» – диде. Кыз шундук торып басты һәм йөреп китте. Әлеге могҗизаны күргән һәммәсе тәмам хәйран калды.

*Марк 5:21–42*



## Гайсәнең биш мең кешене ашатуы

Бервакыт Гайсә Үзенең шәкертләре белән Гәлиләя диңгезенең аръягына, Тибериас тарафына китте. Гайсәнең авыруларны савыктыруын, могҗизалы гамәлләрен күргән халык Аның артыннан иярде.

Гайсә Үзенең шәкертләре белән тау битләвенә килеп утырды. Яһүдиләрнең Котылу бәйрәме якынлашып килгән көннәр иде бу. Гайсә, Үзенә таба килүче халыкның күплеген күреп, Филипкә: «Аларны ашатырга икмәкне кайдан сатып алырбыз икән?» – диде. Бу сүзләрне Ул Филипне сынар өчен әйтте, чөнки Үзенең ни кылачагын белә иде.

«Аларның һәрберсенә аз-аз гына бирү өчен дә ике йөз динарлык* икмәк җитмәс», – дип җавап бирде Филип.

Шәкертләренең берсе, Шимун-Петернең бертуган кардәше Әндри: «Монда бер малайның биш арпа икмәге белән ике балыгы бар, әмма моның кадәр халык өчен нәрсә инде ул?» – диде. «Халыкка утырырга кушыгыз», – дип әйтте Гайсә. Ул урында куе булып чирәм үскән иде – бар халык шунда утырды. Алар арасында ир-атлар гына биш меңгә якын иде.

Гайсә икмәкне алды да, шөкрана кылып, халыкка өләште, шулай ук балыкны да таратты – һәркем теләгәнчә алды. Кешеләр ашап туйгач, шәкертләренә Гайсә: «Калган сыныкларны җыеп алыгыз, бернәрсә әрәм булмасын», – диде. Ашап туклангannan соң да әле биш арпа икмәгеннән калган сыныклар белән унике кәрзин тулды.

Гайсә кылган могҗизаны күреп, кешеләр: «Дөньяга килергә тиеш булган Пәйгамбәр чынлап та шушыдыр», – диештеләр.

*Яхъя 6:3–14*

* *Динар* – шул чорда Исраилдә кулланышта йөргән Рим тәңкәсе.



# Гайсәнең су өстеннән атлап килүе

Икмәк һәм балык белән булган могҗизадан соң Гайсә Үзенең шәкертләренә көймәдә каршы ярга чыга торырга кушты, Үзе исә халыкны озата калды. Халыкны кайтарып җибәргәч, аулакта дога кылыр өчен Гайсә тауга күтәрелде һәм кич җиткәнче ялгызы гына шунда булды. Ул арада инде шәкертләр утырган көймә диңгез уртасына җиткән булып, каршы искән көчле җил дулкыннарны көймә читенә кага башлаган иде. Таң сызылып килгәндә, шәкертләр су өстеннән атлап үзләренә таба килүче Гайсәне күреп алдылар. Аның су өстеннән атлап килүен күреп, шәкертләре курка калдылар һәм: «Өрәк!» – дип кычкырырга тотындылар. Әмма Гайсә шундук аларга дәшеп: «Тынычланыгыз! Мин бу, курыкмагыз!» – диде. «Хакимем, әгәр Син икәнсең, – диде шунда Петер, – су өстеннән атлап яныңа килергә әмер бирче миңа». «Кил!» – диде аңа Гайсә, һәм Петер, көймәдән чыгып, су өстеннән Гайсәгә таба атлап китте, әмма җилнең көчле булуын күргәч, курка калды да бата башлады. «Коткар мине, Хакимем!» – дип кычкырып җибәрде ул. Гайсә шундук кулын сузып аны эләктереп алды һәм: «И сай иманлы! – диде. – Нигә икеләнеп калдың?» Алар көймәгә кереп урнаштылар. Шунда җил тынды.

Көймәдәге шәкертләре Гайсә каршында баш иеп: «Син дөрестән дә Аллаһы Углы икәнсең!» – диделәр.

*Маттай 14:22–33*



## Гайсәнең кыяфәте үзгәрү

Бервакыт Гайсә, Үзе белән Петерне, Ягъкубны һәм Яхъяны ияртеп, биек тауга күтәрелде. Дога кылган вакытта кинәт кенә Аның кыяфәте үзгәреп китте: йөзе кояштай балкып, өстендәге киеме көн яктысыдай ап-ак булды. Менә алар каршында Муса һәм Ильяс пәйгамбәр күренде дә Гайсә белән сөйләшә башлады. Шушы хәлгә тәмам исе киткән Петер Гайсәгә: «Хакимебез! Ничек рәхәт биредә! Телисеңме, агач ботакларыннан өч чатыр корабыз: берсе – Сиңа, берсе – Мусага, берсе Ильяска булыр», – диде. Петер шулай дип сөйләп торган арада, аларны яп-якты болыт чорнап алды, һәм болыт арасыннан: «Бу – Минем сөекле Углым, Ул – Минем куанычым, Аның сүзеннән чыкмагыз!» – дигән тавыш килеп иреште.

Әлеге тавышны ишетеп котлары алынган шәкертләр җиргә капландылар. Гайсә, яннарына килеп, аларга орынды да: «Торыгыз, курыкмагыз!» – диде. Күтәрелеп карагач, шәкертләре Гайсәдән башка һичкемне күрмәделәр.

Таудан төшкән чакта Гайсә аларны: «Адәм Углы үледән терелгәнгә кадәр биредә күргәннәрегезне һичкемгә әйтәсе булмагыз», – дип кисәтте.

*Маттай 17:1–9; Лук 9:28–36*



## Барысын да кичерә торган мәхәббәт

Бервакыт Гайсә янына Петер килеп: «Хакимем, әгәр туганым миңа каршы гөнаһ эш кылса, мин аны ничә тапкыр кичерергә тиешмен? Җиде тапкырмы?» – дип сорады. «Юк, җиде тапкыр түгел, җитмеш тапкыр җидегә кадәр», – дип җавап кайтарды аңа Гайсә һәм гыйбрәт итеп бер хикәя сөйләде:

Күкләр Патшалыгын менә нәрсә белән чагыштырып булыр иде: бер патша үзенең хезмәтчеләреннән исәп-хисап эшләрен таләп иткән. Акча хисабын ачыклый башлагач, аның янына ун мең талант* бурычы булган бер кешене китергәннәр. Әлеге кешенең түләрлек акчасы булмагач, бурычын түләтер өчен патша аның үзен дә, хатынын да, балаларын да, бар милкен дә сатарга әмер биргән. Хезмәтче, патшаның аягына егылып: «Бераз гына көтче, барын да кайтарып бирермен!» – дигән. Хуҗасы, аны кызганып, кайтарып җибәргән һәм бурычын да бәхилләгән. Патша хозурыннан чыгуга, әлеге хезмәтче үзенә йөз динар бурычы булган иптәшен очраткан да: «Бурычыңны түлә!» – дип аның бугазына ябышкан. Иптәше, аның аягына егылып: «Аз гына көт инде, тиененәчә түләрмен!» – дип ялварырга тотынган. Әмма хезмәтче, риза булмыйча, бурычын кайтарганчыга кадәр аны төрмәгә утырткан. Дус-ишләре, шушы хәлне күреп, бик борчылганнар һәм бу хакта патшага сөйләп биргәннәр. Шуннан патша әлеге хезмәтчене чакырып китереп: «Явыз бәндә! Ялынып-ялварып сорагач, мин синең бурычыңны бәхилләдем; мин сиңа мәрхәмәт кылган кебек, син дә иптәшеңә мәрхәмәтле булырга тиеш идең түгелме?» – дип әйткән. Ачуы чыккан патша, хезмәтчесе бөтен бурычын түләп бетергәнче, аны җәза бирүчеләр кулына тапшырган. Әгәр туганыгызны ихлас күңелдән кичермәсәгез, Күктәге Атам да сезгә шундый ук мөгамәлә кылачак.

«Күктәге Атабыз» дигән догада Раббы безне гафу кылырга өйрәтеп: «Без үзебезгә бурычлы адәмнәрнең әҗәтләрен кичергән кебек, Син дә безнең бурычларны кичер», – ди.

*Маттай 18:21–35*

---

* *Талант* – борынгы римлыларның иң зур акча берәмлеге, 30 килограмм чамасы көмешкә тәңгәл булган.



# Шәфкатьле самареяле хакында гыйбрәтле хикәя

Канун белгечләреннән берәү, Гайсәне сынамакчы булып: «Остаз, мәңгелек тормышка ирешер өчен миңа нәрсә эшләргә кирәк?» – дип сорау бирде. Гайсә аңа: «Бу хакта Канунда нәрсә язылган соң?» – диде. «Раббы Алланы бөтен йөрәгең, бөтен жаның, бөтен көчең вә акылың белән ярат» һәм «якыныңны үзеңне яраткан кебек ярат», – дип җавап бирде Канун белгече. «Җавабың дөрес синең. Шулай эшләсәң – яшәрсең», – диде аңа Гайсә. Әмма теге, үзен акларга теләп, Гайсәдән: «Ә минем якыным кем соң?» – дип сорады. Аның бу сүзләренә Гайсә болай дип җавап кайтарды:

Бер кеше Иерусалимнән Әрихә каласына барганда юлбасарлар кулына эләккән. Алар әлеге юлчыны талаганнар һәм, кыйнап, үлем хәлендә калдырып киткәннәр. Бер руханига, юлы төшеп, шул турыдан үтәргә кирәк булган; әмма теге кешене күргәч ул, юлның икенче ягына чыгып, ары киткән. Шулай ук левиләрдән берәү узып барышлый бу кешене күргән дә, аны урап үтеп, юлын дәвам иткән. Бер самареяле* исә, үтеп барганда бу кешегә тап булып, аны бик кызганган, янына килеп, яраларын шәраб белән юган һәм зәйтүн мае сөртеп бәйләгән, аннары үзенең ишәгенә атландырып кунак йортына алып килгән һәм анда да әлеге юлчыны ярдәменнән ташламаган. Ә икенче көнне юлга чыгарга җыенганда кунак йорты хуҗасына акча калдырып: «Аның хакында кайгыртчы, – дигән, – әгәр күбрәк сарыф итсәң, кире кайтканда түләрмен».

Сүзен йомгаклап, Гайсә: «Ничек уйлыйсың, шушы өч кешенең кайсысы юлбасарлар кулына эләккән теге бичараның якыны булыр икән?» – дип сорады. «Аңа шәфкать күрсәткәне», – дип җавап бирде Канун белгече. Гайсә аңа: «Бар, син дә шулай эшлә», – диде.

*Лук 10:25–37*

* Яһүдиләр белән самареялеләр бер-берсен өнәмәгәннәр.



## Гайсә – яхшы Көтүче

Гайсәне Аллаһы Үз халкы өчен Көтүче итеп җибәрә. Көтүче үзенең сарыкларын кайгырткан кебек, дөньяны Коткаручы Гайсә дә Үзен ихлас күңелдән кабул иткән һәм дә Аның өйрәтүләре буенча яшәгән адәмнәрне шулай кайгырта. Бу хакта Гайсә менә ничек ди:

Хак сүз әйтәм сезгә: сарык утарына капкадан түгел, башка юл белән кергән кеше – карак һәм юлбасар. Ә капкадан керүче – сарыкларның көтүчесе: сакчы аңа капканы ача, сарыклар аның тавышын таный, һәм ул аларны исемнәре белән чакырып утардан алып чыга. Сарыкларның бөтенесен алып чыккач, алар алдыннан атлый, ә сарыклар аның тавышын таныганга артыннан ияреп бара. Чит кешегә исә алар иярми, тавышы таныш булмаганга аңардан качып китә.

Хак сүз әйтәм сезгә: Мин – сарыклар өчен капка. Миннән алда килгәннәрнең барысы да карак, юлбасар иде, һәм сарыклар аларны тыңламады. Мин – капка. Минем аша керүче котылачак һәм көтүлек җир дә табачак. Карак бит урлау, үтерү, һәлак итү өчен генә килә. Мин исә тормыш бирергә, мул тормыш бирергә дип килдем.

Мин – яхшы көтүче: яхшы көтүче үзенең сарыклары өчен җанын да кызганмый. Ә ялланган көтүче – чын көтүче түгел ул; сарыклар үзенеке булмаганга аларны кайгыртмый: бүре килгәнне күрсә, сарыкларны ташлап кача; бүре һөҗүм иткәч, сарыклар таралып бетә. Ялланган көтүче кача, чөнки ул ялланып эшли, сарыкларны чынлап кайгыртмый.

Мин – яхшы көтүче. Атам – Мине, ә Мин Атамны таныган кебек, Мин Үземнең сарыкларымны таныйм, алар Мине таный; сарыкларым өчен Мин җанымны бирәм. Минем бу утардан тыш башка сарыкларым да бар, Мин аларны да алып килергә тиешмен, алар Минем тавышыма буйсыначак, шулай итеп, бер генә көтү һәм бер генә Көтүче булачак.



Җанымны яңадан кабул итү өчен бирәм Мин аны, Атам Мине әнә шуның өчен ярата. Җанымны Мин Үз ихтыярым белән бирәм, Аны Миннән беркем тартып ала алмый, аны бирергә дә, кире алырга да хокукым бар, чөнки Атамның ихтыяры шундый.

*Яхъя 10:1–5, 7–18*

## Марта һәм Мәрьям исемле кыз туганнар

Иерусалим тирәсендә урнашкан Бәйт-Әния дигән авылда үзләренең Элгазар исемле ир туганы белән Марта һәм Мәрьям исемле апалы-сеңелле ике кыз яши иде. Аларның һәр өчесе Гайсәне ихластан яратканга, Аны еш кына үзләренә кунакка дәшә иде.

Бервакыт шулай Гайсә аларның өенә килгәч, Мәрьям, Гайсәнең аяк очына утырып, Аның сөйләгәнен тыңлады. Марта исә мул итеп табын әзерләү белән мәшгуль булды. Мәрьямнең ярдәм итмәве аңа бер дә ошамады, шул сәбәпле Гайсәгә ул: «Хакимем! Сеңлемнең бөтен эшне миңа калдыруын күрмисеңме? Әйт әле, булышсын миңа», – диде. Аңа җавап итеп Гайсә: «Марта, Марта! Син күп нәрсәне кайгыртып ыгы-зыгы килеп йөрисең, ә бит бары бер нәрсә генә кирәк. Мәрьям әнә үзе өчен яхшырак нәрсәне сайлады, һәм бу аңардан тартып алынмас», – диде.

*Лук 10:38–42*



## Акылсыз бай турында гыйбрәтле хикәя

Бервакыт шулай халыкка үгет-нәсыйхәт биргән чакта Гайсә: «Карагыз аны, һәртөрле комсызлыктан сакланыгыз, чөнки кешенең гомере мал-мөлкәтенең муллыгына бәйләнмәгән», – диде һәм гыйбрәт өчен аларга бер хикәя сөйләде:

Бер бай үзенең кырларыннан бик зур уңыш җыеп алган һәм күңеленнән болай дип уйлаган: «Инде миңа нәрсә эшләргә? Җыйган уңышымны саклар урын юк». Шуннан ул мондый карарга килгән: «Болай итим әле мин: амбарларымны сүтим дә зуррак амбарлар салыйм һәм бөтен ашлыгымны, бар мөлкәтемне шунда җыйыйм. Шуннан соң үземә: „Синең күп елларга җитәрлек малың бар; ял ит, аша-эч, тормышның рәхәтен күр!“ – диярмен». Әмма Аллаһы аңа әйткән: «Әй акылсыз! Шушы төндә җаның синнән алыныр; җыйган малың кемгә калыр соң?» Үзе өчен хәзинә туплап, Аллаһы хуплаган байлыкны туплау турында уйламаган һәркем белән менә шулай булыр.

Аннары Гайсә Үзенең шәкертләренә болай диде: «Әнә шуның өчен Мин сезгә: „Җан асрар өчен нәрсә белән тукланыйм, нәрсә эчим дип борчылмагыз һәм хафаланмагыз. Дөньяда халыкларның төп кайгысы шулдыр, ә Атагыз шушы нәрсәләргә мохтаҗ булуыгызны белә. Сез исә Аллаһы Патшалыгын эзләгез, һәм сезгә шушы нәрсәләрнең барысы да өстәп бирелер. Әй кечкенә көтү, курыкма! Атагыз Патшалыкны сезгә тапшыруны хуш күрде. Милкегезне сатыгыз да ярлыларга сәдака өләшегез. Үзегезгә тузмый торган янчыклар әзерләгез, һич тә кимеми торган хәзинәне күктә туплагыз – анда карак та тия алмас, көя дә төшмәс. Хәзинәгез кайда, күңелегез дә шунда булыр».

*Лук 12:15–21, 29–34*



## Бай һәм Элгазар турында гыйбрәтле хикәя

Аннары Гайсә Үз янына җыелган халыкка тагын шундый бер гыйбрәтле хикәя сөйләде:

Кайчандыр бер бай яшәгән. Ул нәфис җитеннән һәм куе кызыл төстәге тукымадан тегелгән затлы киемнәр генә кия, көн дә зур-зур мәҗлесләр җыя торган булган. Ә аның капка төбендә, бай табынынннан өстәл астына төшкән сынык-саныкларга өметләнеп, бөтен тәнен җәрәхәт баскан Элгазар исемле бер фәкыйрь ята, һәм этләр, килеп, аның яраларын ялап китә икән. Көннәрдән беркөнне әлеге фәкыйрь үлеп киткән, һәм фәрештәләр аны Ибраһим пәйгамбәр янына илткәннәр; шуннан соң бай да дөнья куйган, аны да җир куенына тапшырганнар. Бай кеше, үлеләр дөньясында газап чиккән вакытта, башын күтәреп караган да еракта Ибраһимны һәм аның янында Элгазарны күреп алып: «Ибраһим атам! Шәфкать күрсәтеп, минем янга Элгазарны җибәрче, бармак очын суга чылатып телемне суытсын иде, чөнки ялкын эчендә бик нык газап чигәм», – дип кычкырган. Әмма Ибраһим аңа: «Углым! Исеңә төшер, син тормышыңда бар рәхәтне татыдың инде, ә Элгазар михнәт чикте; хәзер исә ул монда юаныч тапты, ә син газап чигәсең. Моннан тыш, безнең белән сезнең арада тирән упкын, шул сәбәпле сезнең якка биредән беркем чыга алмас, сезнең яктан да беркем монда аяк баса алмас», – дип җавап кайтарган. Бай исә: «Атам, алайса, зинһар өчен, Элгазарны әткәм йортына җибәр: анда минем биш ир туганым бар; Элгазар барып кисәтсен – алар да бу газапларга тарымасын иде», – дигән. Ибраһим аңа болай дип җавап кайтарган: «Аларда Муса һәм башка пәйгамбәрләрнең язмалары бар; шуларга колак салсыннар». Бай исә: «Юк, Ибраһим атам! Минә үлгәннәрдән берәрсе, терелеп, алар янына барса, бәлки тәүбәгә килерләр иде», – дигән. Шушы сүзләрдән соң Ибраһим аңа: «Әгәр алар Мусаны һәм пәйгамбәрләрне тыңламыйлар икән, берәрсе үледән терелсә дә, ышанмаячаклар», – дип җаваплаган.

*Лук 16:19–31*



## Югалган сарык турында гыйбрәтле хикәя

Салым җыючылар һәм гөнаһлы башка кешеләр, Гайсәне тыңлар өчен, Аның янына җыелдылар. Фарисейлар һәм Канун белгечләре исә: «Бу Кеше гөнаһлыларны кабул итә һәм алар белән бергә ашый», – дип сукрандылар. Шуннан Гайсә аларга әлеге гыйбрәтле хикәяне сөйләде:

> Әйтик, берегезнең йөз сарыгы булып, шуларның берсен ул югалтса, туксан тугызын кырда калдырып, шул югалганын тапканчы эзләмәсме әллә? Ә инде аны тапкач, шатланып, җилкәсенә салып алып кайтыр. Өенә кайткач исә, дусларын һәм күршеләрен чакырып: «Минем белән бергә шатланыгыз: чөнки югалган сарыгымны таптым», – дияр. Хак сүз әйтәм сезгә: күкләрдә дә шулай – тәүбәне кирәксенмәгән туксан тугыз тәкъвага караганда, гөнаһлы бер кешенең тәүбәгә килүенә анда күбрәк шатланырлар.

*Лук 15:3–7*



## Юлдан язган угыл турында гыйбрәтле хикәя

Янына җыелган халыкка Гайсә тагын бер гыйбрәтле хикәя сөйләде:

Бер кешенең ике углы булган ди. Шуларның кечерәге атасына: «Әти, милекнең миңа тиешле өлешен бүлеп бир», – дип әйткән. Атасы үзенең милкен угылларына бүлеп биргән.

Берничә көн үткәч, кече углы үз өлешен саткан да, булган акчаны үзе белән алып, ерак илгә чыгып киткән һәм анда, азгынлыкка бирелеп, байлыгын туздырып бетергән. Ул шулай бөтен байлыгын туздырып бетергәннән соң, бу илдә бик каты ачлык башланып, егет мохтаҗлыкта калган. Шуннан ул җирле бер кешегә эшкә ялланган, һәм теге аны үзенең басуына дуңгыз көтәргә җибәргән. Егет шулкадәр ачка интеккән, хәтта дуңгызлар ашый торган азыкка да шат буласы икән, тик аңа беркем бернәрсә бирмәгән.

Шуннан ул, акылына килеп: «Атам йортында күпме ялчы туйганчы ризык ашый, ә мин биредә ачка тилмерәм. Хәзер үк атам янына кайтыйм да: „Әти, мин Күктәге Алла каршында һәм синең алдыңда гөнаһ кылдым, инде синең углың дип аталырга лаек та түгелмен; ялчыларыңның берсе булырга рөхсәт ит миңа“, – дип әйтим», – дигән дә атасы янына кайтып киткән.

Атасы аны ерактан ук күреп алып бик нык кызганган, каршына йөгереп барып кочаклап үпкән. Угылы исә аңа: «Әти, мин Күктәге Аллаһы каршында һәм синең алдыңда гөнаһ кылдым, инде синең угылың дип аталырга да лаек түгелмен», – дигән. Әмма атасы үзенең хезмәтчеләренә: «Тиз генә аңа затлы киемнәр алып килегез, бармагына – йөзек, аягына сандал бирегез. Аннары симертелгән берәр бозауны чалыгыз. Сыйланыйк, күңел ачыйк! Минем бу углым үлгән иде – хәзер терелде, югалган иде – инде табылды», – дигән.

Аның өлкән углы исә бу вакытта кырда булган. Өенә кайтып җитәрәк, ул җыр-бию тавышлары ишеткән һәм хезмәтчеләрнең берсен чакырып, бу ни хәл, дип сораган. Хезмәтче аңа: «Синең энең кайтты, аның сау-сәламәт әйләнеп кайтуына куанып, әтиең симертелгән бозау чалдырды», – дигән. Өлкән угылның бу хәлгә ачуы килгән, һәм ул өйгә керергә теләмәгән. Атасы,



чыгып, аның өйгә керүен үтенгән. Әмма атасына җавап итеп ул: «Менә, мин сиңа күпме еллар кол сыман хезмәт итәм, кушканыңны һич карусыз башкарам, алай да дусларым белән күңел ачарга синең миңа беркайчан кәҗә бәтие дә биргәнең булмады. Ә инде милкеңне фахишәләр белән туздырып бетергән бу углың кайткач, аның өчен симертелгән бозау чалдыргансың», – дигән.

Аңа җавап итеп атасы: «Углым! Син һәрвакыт минем янда, минем бөтен нәрсәм – синеке. Шатланырга, күңел ачарга безнең сәбәп бар, чөнки энең үлгән иде – хәзер терелде, югалган иде – инде табылды», – дип әйткән.

*Лук 15:11–32*

## Махау зәхмәте кагылган ун кешенең савыгуы

Иерусалимгә барышлый Гайсәгә Самарея белән Гәлиләя арасындагы чик буйлап үтәргә туры килде. Бер авылга кереп килгәндә Аңа махау авырулы ун кеше очрады. Алар еракта ук туктап калып: «Гайсә! Остаз! Кызган безне!» – дип кычкырдылар. Гайсә аларны күрүгә: «Барыгыз, руханиларга күренегез!» – диде. Тегеләр китеп бардылар һәм юлда чакта ук инде чирләреннән арындылар.

Махау зәхмәтеннән арынган ун кешенең берсе Гайсә янына әйләнеп килде һәм, Аның аягына егылып, рәхмәт укыды, кычкырып-кычкырып Аллаһыга дан-шөһрәтләр яудырды. Әлеге кеше самареяле булып, калган тугызы яһүдиләрдән иде.

«Унысыз да савыкмадымыни? Калган тугызыгыз кайда соң? – дип сорады Гайсә аңардан. – Аллаһыга рәхмәтен белдерү өчен, читтән килгән шушы кешедән башка берсе дә кире әйләнеп килмәдемени?» Шуннан Гайсә аңа: «Тор һәм юлыңда бул; сине ышануың савыктырды», – диде.

*Лүк 17:11–19*



## Фарисей һәм салым җыючы турында гыйбрәтле хикәя

Үзләрен тәкъвалардан санап, башкаларны түбәнсетүче кайберәүләргә ишарәләп Гайсә шушы гыйбрәтле хикәяне сөйләде:
Ике кеше дога кылу өчен Аллаһы йортына кергән ди: аларның берсе – фарисей, бөтен кануннарны төгәл үтәүче, кешеләр арасында хөрмәт казанган, бик тә мөхтәрәм кеше икән. Ә икенчесе – гади халыкны җәберләп-кыерсытып, Рим баскынчылары файдасына салым җыючы икән. Фарисей, алгарак чыгып, болай дип дога кылган: «Йа Аллаһы! Башкалар кебек талаучы да, алдакчы да, зина кылучы да яисә менә бу салым җыючы кебек тә түгелмен. Шуның өчен Сиңа шөкер әйтәм. Атнага ике тапкыр ураза тотам, табышымның уннан бер өлешен сәдака итеп бирәм».
Читтәрәк басып торган һәм күзләрен күтәреп күккә карарга да батырчылык итмәгән салым җыючы исә күкрәгенә суга-суга: «Йа Аллаһы! Мин гөнаһлыны мәрхәмәтеңнән аерма!» – ди икән.
Хак сүз әйтәм сезгә: фарисей түгел, нәкъ менә салым җыючы Аллаһы тарафыннан акланып өенә кайтып киткән; чөнки үзен башкалардан өстен куючы түбәнсетелер, ә үзен түбәнсетүче – күтәрелер.

*Лук 18:10–14*



## Гайсәнең балаларга фатиха бирүе

Шулай бервакыт шәкертләре Гайсәдән: «Күкләр Патшалыгында кем бөегрәк?» – дип сорады. Гайсә бер баланы чакырып алып аларның уртасына бастырды да: «Әгәр сез, үзгәреп, балалар кебек булмасагыз, Күкләр Патшалыгына керә алмассыз, – диде. – Кем шушы бала кебек үзен кече итеп тота, Күкләр Патшалыгында шул иң бөеге булыр. Шушындый балаларның берсен Минем хакка күңеле белән кабул иткән кеше Мине кабул итә дигән сүз».

Бервакыт Гайсә янына, башларына кулын куеп дога кылсын өчен, кешеләр балаларын алып килделәр, әмма шәкертләре аларны Гайсә янына якын җибәрмәде. «Балаларга Минем яныма килергә ирек бирегез, комачауламагыз аларга, чөнки Күкләр Патшалыгы әнә шундый сабыйларныкы», – диде Гайсә, аннары, балаларга кулларын куеп, фатихасын бирде.

*Маттай 18:1–5; 19:13–15*



## Гайсәнең сукыр Бартимәйне савыктыруы

Беркөн Гайсә Әрихә шәһәренә килде. Һәрвакыттагыча, Аның артыннан бик күп халык ияргән иде. Соңрак, әлеге шәһәрдән чыгып барганда, юл читендә сукыр Бартимәй хәер сорап утыра иде. Байтак могҗизалар кылган Гайсәнең яныннан гына узып баруын ишетеп, әлеге сукыр: «Давыт Углы Гайсә! Кызган мине!» – дип кычкырып җибәрде. Кешеләр аны тыймакчы булды, әмма Бартимәй тагын да катырак кычкырырга тотынды: «Давыт Углы! Кызган мине!»

Гайсә, барган җиреннән туктап, аны чакырырга кушты. Берничә кеше, сукыр адәм янына килеп: «Тор әйдә, сине чакыра», – диде. Бартимәй сикереп торды да, өс киемен салып ташлап, Гайсә янына килде. Гайсә аңардан: «Син Миннән нәрсә көтәсең?» – дип сорады. «Остаз! Күзләрем күрсә иде!» – дип җавап кайтарды сукыр адәм. Гайсә исә аңа: «Бар, сине ышануың савыктырды!» – диде. Бартимәй шундук күрә башлады һәм, Аллаһыга дан-шөһрәтләр яудырып, Гайсә артыннан ияреп китте.

*Марк 10:46–52; Лук 18:35–43*



## Зәкәйнең котылуы

Үле диңгез буендагы Әрихә шәһәренә Гайсә кабат әйләнеп килде. Шәһәрнең салым җыючылар башлыгы – Зәкәй исемле бер бай адәм – Гайсәнең ниндирәк кеше икәнен бик тә күрергә тели иде; әмма буе кыска булу сәбәпле халык арасыннан Аны күрә алмаганга, алгарак йөгереп узды да Гайсә үтәсе юл буенда үскән кыргый инҗир агачына менеп утырды. Шул турыга җиткәч, Гайсә югарыга күз салды һәм: «Зәкәй! Төш тизрәк, бүген Мин синең өеңдә тукталырга тиешмен», – диде. Теге ашыгып агачтан төште һәм шатланып Аны өендә кабул итте.

Бу хәлне күрүчеләрнең ачуы кабарды, Гайсә шул гөнаһлы адәмнең өенә керде, дип шаулашты алар. Зәкәй исә Хаким Гайсәгә: «Милкемнең яртысын фәкыйрьләргә өләшәм, инде кемне дә булса алдаганмын икән, аңа дүртләтә кайтарып бирәм», – диде. «Бүген шушы йортка котылу килде, – дип әйтте Гайсә, – чөнки бу кеше дә Ибраһим нәселеннән бит. Адәм Углы югалганны эзләп табар һәм коткарыр өчен килде».

*Лук 19:1–10*



## Гайсәнең үле Элгазарны терелтүе

Иерусалим янындагы Бәйт-Әния дигән авылда Марта һәм Мәрьям исемле кыз кардәшләре белән Элгазар исемле бер кеше яши иде. Алар Гайсәнең дуслары иде. Бервакыт Гайсә үзенең шәкертләре белән аулак урында калгач, Элгазарның кыз туганнарыннан: «Хакимебез! Син яраткан абыебыз авырып китте», – дигән күңелсез хәбәр килеп ирешге. Бу турыда ишеткәч Гайсә: «Бу чир үлемгә китермәс, ә бәлки Аллаһыга һәм Аның Углына дан өстәр», – диде. Барган җирендә тагын ике көнгә тоткарланганнан соң, Элгазарның дөнья куйганын тәгаен белеп, Гайсә үзенең шәкертләре белән Бәйт-Әниягә юл алды.

Абыйлары өчен зар елаучы Марта белән Мәрьямне юатырга бик күп яһүдиләр җыелган иде. Гайсәне күргәч, Марта Аңа: «Хакимем! Син монда булсаң, абыем үлмәс иде. Әмма хәзер дә беләм: Аллаһыдан нәрсә генә сорасаң да, Ул сиңа бирәчәк», – диде. «Абыең тереләчәк», – диде аңа Гайсә, аннары болай дип өстәде: «Мин – терелү һәм тормыш. Миңа ышанган кеше үлсә дә тереләчәк. Миңа ышанып яшәүче һәркем беркайчан үлмәячәк. Син шуңа ышанасыңмы?» «Әйе, Хакимем! – диде Марта. – Дөньяга килергә тиеш булган Мәсих, Аллаһы Углы икәнеңә ышанам».

Аннары Марта, Аның яныннан китеп, сеңлесе Мәрьямне чакырып китерде. Мәрьямнең һәм аңа ияреп килгән яһүдиләрнең елавын күреп, Гайсә Үзе дә бик борчылды һәм көенеп: «Кайда күмдегез аны?» – дип сорады. Аңарга: «Әйдә барыйк, Әфәнде! Үзең күрерсең», – диделәр. Гайсә, Элгазар яткан тау куышы янына килеп, мәгарә авызын томалаган ташны читкә тәгәрәтергә кушты. Мәрхүмнең сеңлесе Марта исә Элгазарның инде дүртенче көн төрбәдә ятуын искәртте. Аңа җавап итеп Гайсә: «Әгәр дә ышансаң, Аллаһының данын күрерсең, дип әйтмәгән идеммени сиңа?» – диде. Таш читкә алынгач, Гайсә, күзләрен күккә төбәп: «Атам! Мине ишеткәнең өчен рәхмәт Сиңа. Мине һәрвакыт ишетүеңне беләм, ләкин бу сүзләремне янәшәмдә басып торган кешеләр өчен, Синең тарафтан җибәрелүемә ышансыннар өчен әйтәм», – диде. Әлеге сүзләрдән соң Ул көчле тавыш белән: «Элгазар, чык!» – дип кычкырды. Шулвакыт тау куышыннан аяк-куллары кәфенгә уралган Элгазар килеп чыкты.



Әлеге могҗизалы хәлләрне күргән яһүдиләрнең күбесе Гайсәгә иман китерде. Фарисейлар белән руханилар исә шушы вакыйгадан соң Гайсәнең җанын кыярга ният кылдылар.

*Яхъя 11:1–50, 53*

## Кичерелгән гөнаһың зур булса, ныграк яратасың

Фарисейлардан Шимун исемле бер кеше Гайсәне ашка чакырды. Гайсә, аның тәкъдимен кабул итеп, Шимунның өенә килде.

Әлеге шәһәрдә яшәүче гөнаһлы бер хатын, Гайсәнең фарисей өенә ашка килүен белеп, хуш исле май салынган алебастр савытын алды да шул йортка килде. Ул елый-елый Гайсә артында басып торды, хатынның күз яшьләре Аның аякларын чылатты. Хатын, Гайсәнең аякларына тамган күз яшьләрен үзенең чәчләре белән сөртеп, Аның аякларын үбә-үбә хуш исле май белән майлады.

Гайсәне ашка чакырган фарисей моны күреп: «Әгәр Ул пәйгамбәр булса, Үзенә орынган хатынның кем икәнен белер иде. Гөнаһлы хатын бит бу», – дип уйлады. Шулчак Гайсә, фарисейга мөрәҗәгать итеп, болай диде: «Шимун! Мин сиңа бер сүз әйтергә телим». «Әйт, Остаз», – диде теге. «Бер адәм ике кешегә бурычка акча биреп торган ди: берсенә – биш йөз динар, икенчесенә – илле динар, – дип сүзен башлады Гайсә. – Ләкин бурычларын кайтарырга акчалары булмаганга, ул һәр икесен бәхилләгән. Ничек уйлыйсың, аларның кайсысы аны ныграк яратыр икән?» «Бурычы күбрәк булганы, дип фараз кылам», – диде Шимун. «Дөрес уйлыйсың, – диде аңа Гайсә; аннары хатынга таба борыла биреп сүзен дәвам итте, – бу хатынны күрәсеңме? Мин өеңә килдем, әмма син аяк юарга су бирмәдең. Ә бу хатын аякларымны күз яшьләре белән чылатты, чәчләре белән сөртте. Син сәлам биреп Мине үпмәдең, ә ул, Мин бирегә килгәннән бирле, аякларымны үбүдән туктамый. Син Минем башыма май сөртмәдең, ә ул аякларымны хуш исле май белән майлады. Шуңа күрә Мин сиңа болай дип әйтәм: аның гөнаһлары күп иде, һәм алар кичерелде, шуның өчен аның Миңа мәхәббәте зур. Ә аз гөнаһлары кичерелгән кешенең мәхәббәте дә аз була».

Ә теге хатынга Гайсә: «Гөнаһларың кичерелде», – диде. Табын янында утыручылар үзара: «Гөнаһларны кичерергә кем Ул?» – дип гәпләште. Гайсә шунда хатынга: «Сине ышануың коткарды, имин йөр», – диде.

*Лүк 7:37–50*



## Гайсәнең Иерусалимгә керүе

Иерусалимгә якынлашып, Зәйтүн-тау итәгендәге Бәйт-Фәги авылына җиткәндә, Гайсә ике шәкертен чакырып алды да: «Каршыгыздагы авылга барыгыз, – диде. – Анда керүгә бәйдәге яшь бер ишәкне күрерсез; аны бәйдән ычкындырыгыз да Минем янга алып килегез. Кем дә булса бер-бер сүз әйтә калса, аңа „безнең Хуҗага кирәк ул“ диярсез, һәм ишәкне алып китәргә шундук рөхсәт итәрләр». Шәкертләре китеп бардылар, һәм барысын да Гайсә кушканча эшләделәр.

Яшь ишәкне алып килеп, малның сыртына өс киемнәрен салгач, Гайсә ишәккә атланды. Халыкның күбесе юлга өс киемен җәйде, башкалар исә агач ботакларын кисеп түшәде. Алдан баручы халык та, арттагылар да: «Давыт Углына һошанна*! Раббы исеме белән Килүче мөбарәктер! Күкләрдә һошанна!» – дип кычкырды.

Гайсә Иерусалимгә аяк басуга, бөтен шәһәр хәрәкәткә килде, кешеләр бер-берсеннән: «Кем соң Ул?» – дип сорашты. Гайсәгә дан җырлаучылар аларга: «Гәлиләядәге Насарадан килгән Гайсә пәйгамбәр бу», – дип җавап кайтарды. Алар Гайсәнең Элгазарны үледән терелтүе, шулай ук башка могҗизалары турында да бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр. Шушы хәлләрне күреп торган фарисейлар үзара: «Күрәсезме, безгә бернәрсә ярдәм итми. Бөтен дөнья Аның артыннан бара!» – дип сөйләштеләр. Халык арасындагы кайбер фарисейлар Гайсәгә: «Шәкертләреңне тый, Сине данлаудан тuктасыннар», – диде. Әмма аларга җавап итеп Ул: «Сезгә шуны әйтәм: әгәр алар тынып калсалар, ташлар кычкыра башлаячак», – диде.

*Маттай 21:6–11; Марк 11:1–10; Лүк 19:39–40; Яхъя 12:14–19*

---

* Һошанна – яһүдчә сүзгә-сүз: «коткар безне!» Гайсә заманында әлеге сүз Аллаһыны мактау өчен кулланылган.



## Гайсәнең Иерусалим хакында зар елавы

Үзен кабул итмәгән Иерусалимне кызганып Гайсә зур хәсрәт кичерде. Кайчандыр шушы калада гомер иткән акыл ияләре һәм пәйгамбәрләр турында, булып узган сугышлар һәм бәла-казалар турында, ихлас күңелдән укылган догалар һәм өметләр турында мондагы һәр таш күпме нәрсә сөйли алыр иде! Әлеге кала үзенең Коткаручысын бик озак көтте, көтеп алгач исә – Аны танымады:

> И Иерусалим, Иерусалим, пәйгамбәрләр җанын кыючы, сиңа килүчеләрне ташлар атып кыйнаучы шәһәр! Кош үзенең балаларын канат астына җыйган сыман, Мин дә ничәмә тапкырлар синең халкыңны бергә җыярга омтылдым, әмма сез, Иерусалим кешеләре, каршы килдегез! Инде менә Изге йортыгыз ташландык хәлдә калыр. Сезгә әйтәм: «Раббы исеме белән Килүче мөбарәктер!» дип әйтми торып, Мине кабат күрмәссез!

Иерусалимгә якынлашып шәһәргә карашын ташлагач, аның язмышы өчен көенеп Гайсәнең күзләренә яшь килде:

> Син дә шушы көндә үз иминлегең өчен нәрсә кирәклеген белсәң икән! – диде Ул. – Тик хәзергә синең күзләрең өчен бу яшерендер. Синең өчен шундый көннәр килер, дошманнарың әйләнә-тирәңә чокырлар казып, туфрак өемнәре күтәртеп сине камап алыр һәм һәр тарафтан кысрыклый башлар; сине җимереп, халкыңны кырып бетерерләр, таш өстендә таш калдырмаслар, чөнки яныңа Аллаһы килеп шәфкать күрсәткән вакытны син абайламый калдың.

*Лук 13:34–35; 19:41–44*



# «Чакырылганнар күп булыр, тик сайлап алынганнар аз»

Бервакыт Гайсә бер фарисейның өенә килде һәм, анда бик күп кунак җыелганны күреп, хуҗага болай диде: «Аш мәҗлесе уздыра-нитә калсаң, дусларыңны да, абый-энеләреңне дә, туган-тумачаңны да, бай күршеләреңне дә чакырма, чөнки чакыруыңа каршы алар да бервакыт сине ашка дәшәр, һәм шуның белән исәп-хисап беткән булыр. Мәҗлес үткәрә калсаң, фәкыйрьләрне, гарипләрне, аксак-сукырларны чакыр. Әнә шул чакта бәхетле булырсың, чөнки алар синең яхшылыгыңа каршы яхшылык белән җавап кайтара алмыйлар; ә тәкъвалар үледән терелгән көндә сиңа әҗере булыр».

Гайсә белән табын янында утыручыларның берсе моны ишетеп Аңа: «Аллаһы Патшалыгындагы мәҗлестә сыйланачак кеше бәхетледер!» – диде. Гайсә исә аңа болай дип җавап бирде:

> Бер кеше, зур аш мәҗлесе уздырырга ниятләп, күп итеп кунак дәшкән. Табын янына утырыр вакыт җиткәч, чакырылган кешеләргә: «Килегез, инде бар нәрсә әзер», – дип әйтергә үзенең хезмәтчесен җибәргән. Ләкин чакырылган кешеләр, сүз куешкан сыман, килә алмыйбыз, дип гафу үтенергә керешкән. Беренчесе: «Җир сатып алган идем, шуны барып карарга кирәк, зинһар, гафу ит», – дигән. Икенчесе: «Биш пар үгез сатып алган идем, хәзер шуларны эштә сынап карамакчы булам, зинһар, гафу ит», – дип әйткән. Өченчесе: «Мин күптән түгел генә өйләндем, шуңа күрә килә алмыйм», – дигән.
>
> Хезмәтчесе, кайтып, бу турыда хуҗасына җиткергән. Хуҗасының ачуы чыгып, хезмәтчесенә ул: «Бар, тиз генә шәһәр урамнарыннан һәм тыкрыклардан фәкыйрь, гарип, аксак һәм сукырларны җыеп алып кайт», – дигән. Берникадәр вакыт үткәч, хезмәтчесе аңа: «Хуҗам, әмерең үтәлде, әле тагын да буш урыннар бар», – дигән. Хуҗа исә хезмәтчесенә: «Бар, шәһәр читенә чыгып юлларны, койма буйларын карап уз һәм кешеләрне монда килергә кыста, өем тулы кунак булсын.



Сезгә әйтәм: элек чакырылганнарның берсе дә минем сыйнигъмәтемне татымас; чөнки чакырылганнар күп булыр, тик сайлап алынганнар аз,»– дигән.

*Лук 14:12–24; Маттай 22:14*

## «Кайсарныкын – кайсарга, Аллаһыныкын – Аллаһыга»

Фарисейлар һәм канунчылар, Гайсәне гаепләрдәй сәбәп тапмакчы булып, төрле юллар белән Аны үзләренең бәхәсләренә тартырга тырышалар иде. Бервакыт алар Аның янына үзләренең шәкертләрен җибәрделәр, һәм тегеләр килеп: «Остаз! Синең гадел булуыңны һәм Аллаһы юлына хакыйкать кушканча өйрәтүеңне без беләбез. Син берәүгә дә ярарга тырышмыйсың, чөнки кемнең кем булуы Сиңа мөһим түгел. Шуңа күрә әйт әле безгә: Синеңчә, кайсарга салым түләргә рөхсәт ителәме, әллә юкмы?» – дип сорадылар.

Фарисейларның соравы четерекле иде: әгәр Гайсә «кайсарга салым түләргә кирәк» дип җавап бирсә, Аны Исраил мәнфәгатьләренә хыянәттә һәм римлылар хакимиятенә сатылуда гаепләрләр иде; әгәр инде Ул «салым түләргә кирәкми» дисә, Аңа «Римга каршы фетнә оештыручы» дип гаеп ташларлар иде.

Әмма Гайсә аларның хәйләсен аңлап: «Нәрсәгә дип сынийсыз Мине, икейөзле бәндәләр? Кая, күрсәтегез әле, салымны нинди тәңкәләр белән түлисез?» – диде. Аңарга бер динарлык тәңкә бирделәр. «Монда кемнең сурәте төшерелгән, кемнең исеме сугылган?» – дип сорады Гайсә алардан. «Кайсарныкы», – дип җавап кайтарды фарисейлар. «Шулай булгач, – диде Гайсә, – кайсарныкын – кайсарга, Аллаһыныкын – Аллаһыга бирегез». Бу сүзләрне ишетеп, алар хәйран калдылар һәм Гайсә яныннан китеп бардылар.

Аннары Гайсә халыкка һәм Үзенең шәкертләренә мөрәҗәгать итеп болай диде: «Муса урынына хәзер Канун белгечләре һәм фарисейлар утырды. Шуңа күрә сез алар әйткәнне тыңлагыз һәм алар кушканны үтәгез, ләкин аларның гамәлләрен кабатламагыз, чөнки алар үзләре өйрәткән буенча гамәл кылмыйлар. Алар кеше җилкәсенә чамасыз авыр, уңайсыз йөк салалар, әмма аны кузгатыр өчен бармак та кыймылдатырга теләмиләр. Нәрсә генә эшләсәләр дә, кеше күрсен дип эшлиләр».

*Маттай 22:15–22; 23:1–5*



## «Беренче һәм иң мөһим әмер»

Бервакыт шулай Канун белгечләреннән берәү, Гайсә янына килеп, Аңардан: «Остаз! Канундагы әмерләрнең иң мөһиме кайсы?» – дип сорады. Аңа җавап итеп Гайсә: «Раббы Алланы бөтен йөрәгең, бөтен җаның һәм бөтен акылың белән ярат», – диде. – Бу – беренче һәм иң мөһим әмер. Икенчесе дә шундый ук: «Якыныңны үзеңне яраткан кебек ярат». Бөтен Канун һәм пәйгамбәрләрнең язмалары да шушы ике әмергә нигезләнгән.

*Маттай 22:36–40*



## Фәкыйрь тол хатын салган ике данә вак акча

Бервакыт Аллаһы йортында халыкны өйрәтеп, Гайсә болай дип сөйләде: «Халыкның ихтирам белән сәламләвен, гыйбадәтханәләрдә иң алгы рәтләрдә утыруны һәм мәҗлесләрдә түр башында кырын ятып сыйлануны ярата торган Канун белгечләреннән сакланыгыз. Алдап-йолдап тол хатыннарның мал-мөлкәтен талаучы һәм кеше күрсен дип озаклап дога кылучы әлеге адәмнәрне каты хөкем көтә».

Соңрак Гайсә халыкның сәдака сандыгына акча салуын күзәтеп утырды. Алар арасында шактый мул итеп акча салучы бай адәмнәр байтак иде. Шулай ук бер фәкыйрь тол хатын да сәдака сандыгы янына килеп ике данә вак акча* салды.

Гайсә, шәкертләрен чакырып алып, аларга: «Хак сүз әйтәм сезгә: менә бу фәкыйрь тол хатын акчаны һәммәсенә караганда күбрәк салды, чөнки тегеләрнең барысы да үзеннән артканны бүләк итте, ә бу ярлы хатын бар акчасын – яшәү өчен кирәк булганның бөтенесен бирде», – дип әйтте.

*Марк 12:38–44*

* *...ике данә вак акча...* – грекча сүзгә-сүз «ике лепта»; *лепта* – иң вак акча.



## Гайсәнең киләчәк турындагы сүзләре

Изге Китапның бик күп урыннарында Мәсихнең килүе һәм бөтен дөньяда Аллаһы Патшалыгының урнашуы турында сөйләнә. Мәсих дан-шөһрәткә күмелеп килергә тиеш, әмма бу дөньяның явыз көчләре көрәшсез генә Аңа юл бирмәячәк. Шуңа күрә, явыз көчләр тулысынча тар-мар ителгәнчегә кадәр, шактый күп бәла-казалар булачак. Бу турыда Гайсә Үзенең шәкертләрен кат-кат кисәтә:

Карагыз аны, алдамасыннар үзегезне,– дип әйтә Ул, – чөнки күпләр, килеп, үзләрен Минем исем белән атарлар һәм «Мин – Мәсих» дип әйтеп байтак кешене алдарлар. Якындагы сугыш авазын һәм ерактагы сугышлар хакында ишетерсез – карагыз аны, куркып калмагыз. Шулай булырга тиеш ул. Әмма моның белән генә бетмәс әле: халык – халыкка, патшалык патшалыкка каршы чыгар, төрле урыннарда ачлык, җир тетрәүләр булыр; әмма боларның һәммәсе – газап чигүләрнең башы гына әле. Әнә шул вакытта сезне газапларга дучар итәрләр, җаныгызны кыярлар; һәм бар халыклар Минем аркада сезгә нәфрәт белән карар; күпләр иманнан ваз кичәр, бер-берсенә хыянәт итәр һәм бер-берсен күрәлмас булыр; бик күп ялган пәйгамбәрләр барлыкка килеп байтак кешене туры юлдан яздырыр; явызлык артканнан-арта барганга күпләрнең мәхәббәте сүрелер. Әмма шушыларның һәммәсенә ахыргача түзә алган кеше – котылыр. Барча халыклар ишетсен өчен, Аллаһы Патшалыгы хакындагы Яхшы хәбәр бөтен җир йөзендә игълан ителер, – әнә шунда инде ахыр заман җитәр.

Ул көннәрдә ялган мәсихләр белән ялган пәйгамбәрләр килер һәм, Аллаһы тарафыннан сайлап алынганнарны да юлдан яздырмакчы булып, искиткеч галәмәтләр һәм могҗизалар күрсәтер. Һәм шул фаҗигале көннәрдән соң кинәт «кояш тоныкланып, ай яктыртмас булыр, күктән йолдызлар коелып, күк җисемнәре тетрәнеп куяр». Шулвакыт күктә Адәм Углының кайтуын белгертүче билге пәйда булыр. Аның күктәге болытлар өстендә кодрәт һәм дан белән килүен күреп, җирдәге бөтен кавем-ыруглар кайгырып елашыр. Күк һәм җир юкка чыгар, әмма Минем сүзләрем һичкайчан юкка чыкмас. Ул көннең һәм сәгатьнең кайчан киләсен һичкем – хәтта күктәге фәрештәләр



дә белми, бу турыда бары тик Атама гына мәгълүм. Шулай итеп, уяу булыгыз, чөнки Хакимегез кайсы сәгатьтә киләсен сез белмисез.

*Маттай 24:3–14, 24, 29–30, 35–36, 42*

## Ун кыз турында гыйбрәтле хикәя

Һәрчак уяу булырга һәм Адәм Углы каршына килеп басарга әзер торырга кирәклеген Гайсә гыйбрәтле хикәя итеп сөйләде. Әлеге хикәяне Ул ахыр заман турындагы пәйгамбәрлек сүзләреннән соң бәян итте. Гел көтмәгәндә киләчәк Күкләр Патшалыгын Гайсә Үзенең бер хикәясендә менә болай тасвирлый:


Күкләр Патшалыгын нәрсә белән чагыштырып булыр иде? Әйтик, ун кыз, кулларына яктырткычлар тотып, кияү каршыларга чыккан ди. Аларның бишесе – акылсыз, ә бишесе акыллы булган. Акылсызлары яктырткычларын алганнар, ә өстәр өчен лампа мае алмаганнар. Акыллылары исә яктырткычлары белән бергә савытта май да алып килгәннәр. Кияү тоткарланып, кызлар йокымсырый башлаган да йоклап киткән.

Төн уртасында «кияү килә, каршыларга чыгыгыз!» дигән тавыш ишетелгән, һәм кызлар, уянып, яхшырак янсын өчен яктырткычларын рәтләргә керешкән. Акылсызлары «яктырткычларыбыз сүнә бит, бераз май бирегезче» дип, акыллы кызларга ялына башлаган. Ә тегеләр «сезнең белән бүлешсәк, май бөтенебезгә дә җитмәс – сатучылардан барып алыгыз» дигәннәр. Әмма тегеләр майга киткән арада, кияү килеп тә җиткән. Кияүне каршыларга әзер булып торган кызлар аның белән бергә туй мәҗлесенә кереп киткәннәр, һәм алар артыннан ишек ябылган.

Бераздан теге кызлар кайтып җитеп: «Әфәнде, ишекне ач әле!» – дигәннәр. Ләкин ул: «Хак сүз әйтәм сезгә, мин сезне белмим», – дип җавап кайтарган.

Димәк ки, уяу булыгыз, чөнки Адәм Углының кайтыр көнен дә, сәгатен дә сез белмисез.

*Маттай 25:1–13*



## Гайсә – йөзем куагы

Үзенең шәкертләренә Гайсә болай дип сөйләде:
Мин – чын йөзем куагы, ә Минем Атам – йөзем үстерүче. Җимеш бирми торган Миндәге һәр ботакны Ул кисеп ташлый, җимеш бирердәен исә уңыш мулрак булсын дип чистарта. Сезгә сөйләгән сүзләрем ярдәмендә сез инде чистартылдыгыз. Мин – сездә булган кебек, сез дә Миндә булыгыз. Йөзем ботагы үзеннән-үзе җимеш бирә алмаган кебек, Миндә булмасагыз, сез дә җимеш бирә алмассыз. Мин – йөзем куагы, ә сез – ботаклар; Миндә булган, Мин дә аңарда булган кеше генә мул җимеш бирер; чөнки Миннән башка берни дә эшли алмассыз. Кем Миндә яшәми – аны агач ботагы сыман кисеп ыргыталар, һәм ул корып бетә; ә корыган ботакларны җыеп утка ташлыйлар да яндыралар. Миндә яшәсәгез һәм Минем сүзләрем күңелегездә сакланса, теләгәнегезне сорагыз, һәм сезгә бөтенесе дә бирелер.
Атам Мине яраткан кебек, Мин дә сезне яраттым; Минем мәхәббәтемдә яшәгез. Атамның әмерләрен үтәп, мин Аның мәхәббәтендә яшим, һәм сез дә әмерләремне үтәгәндә Минем мәхәббәтемдә яшәрсез. Минем сезгә әмерем шулдыр: бер-берегезне яратыгыз.
Әгәр дөнья сезгә нәфрәтләнә икән, исегездә тотыгыз: сездән элек ул Миңа нәфрәтләнгән иде. Сез шушы фани дөньяныкы булсагыз, дөнья сезне үзенеке кебек итеп яратыр иде. Ләкин сез бу дөньяныкы түгел, Мин, сезне сайлап алып, бу дөньядан аердым, шунлыктан дөнья сезгә нәфрәтләнә. Мине эзәрлекләгәннәр икән, сезне дә эзәрлекләрләр. Минем сүземне тотканнар икән, сезнекен дә тотарлар. Мине җибәргән Затны белмәгәнгә күрә, дөнья халкы боларның барысын сез Минеке булган өчен эшләр. Мин килеп аларга сөйләмәсәм, гаепләре булмас иде, ә хәзер аларның акланыр чаралары юк. Миңа нәфрәтләнгән кеше Атама да нәфрәтләнә.

*Яхъя 15:1–7, 9–10, 17–23*



## Гайсәнең шәкертләр белән уздырган соңгы аш мәҗлесе

Котылу бәйрәме җиткәч, Гайсә: «Барыгыз, Котылу бәйрәме хөрмәтенә безгә табын әзерләгез», – дип Петер белән Яхъяны Иерусалимгә җибәрде. Тегеләр исә Аңардан: «Кайда әзерләргә кушасың?» – дип сорады. «Шәһәргә аяк басуга, сулы чүлмәк күтәреп кайтучы бер кешене очратырсыз, – дип җавап бирде Гайсә. – Аның артыннан барыгыз да, ул кергән йортка кереп, йорт хуҗасына болай дип әйтегез: „Остазыбыз синнән, бәйрәм ризыгын шәкертләрем белән кайсы бүлмәдә ашыйк, дип сорый“. Ул сезгә өске каттагы җыештырылган зур бүлмәне күрсәтер, шунда әзерләгез», – диде. Шәкертләр киттеләр, һәм барысы да Гайсә әйткәнчә булып чыкты; шуннан алар бәйрәм табыны әзерләделәр.

Аш вакыты җиткәч, Гайсә рәсүлләр белән бергә табын яныннан урын алды. «Газапларга дучар ителгәнче шушы Котылу бәйрәме табынында сезнең белән утырып ашарга бик тә теләгән идем! – диде аларга Гайсә. – Сезгә әйтәм: Аллаһы Патшалыгы килмичә, Мин инде Котылу бәйрәме ашын ашамаячакмын». Гайсә касәне алды да шөкрана кылганнан соң аларга сузып: «Алыгыз, үзара бүлешеп эчегез, – диде. – Сезгә әйтәм: Аллаһы Патшалыгы килмичә, Мин инде йөзем шәрабы эчмәячәкмен».

Аннары Гайсә икмәк алып шөкрана кылды да сындыргалап: «Бу – сезнең хакка бирелә торган тәнем. Мине искә алып шулай эшләгез», – дигән сүзләр белән шәкертләренә бирде. Аштан соң Гайсә янә касәне алып: «Менә бу касә – сезнең хакка түгелә торган каным белән расланган яңа Килешү», – диде.

*Лук 22:8–20*



## Соңгы аш мәҗлесендәге әңгәмә

Кичке аш вакыты иде. Гайсә табын яныннан торып биленә сөлге урады, аннары ләгәнгә су салды һәм шәкертләренең аякларын юып билендәге сөлге белән сөртә башлады. Чират Шимун-Петергә җиткәч, теге, тәмам исе китеп: «Хакимем! Минем аякны юмакчы буласыңмы?» – диде. «Минем нәрсә эшләгәнемне син әлегә аңламыйсың, әмма соңыннан аңларсың», – дип җавап кайтарды аңа Гайсә.

Шәкертләренең аякларын юып бетергәч, Ул аларга мондый сүзләр белән мөрәҗәгать итте: «Минем нәрсә эшләгәнемне аңлыйсызмы? Сез Мине Остаз, Хаким дип атыйсыз. Сез хаклы: Мин нәкъ шулмын. Әгәр дә Мин, сезнең Хакимегез һәм Остазыгыз, аягыгызны юганмын икән, сез дә бер-берегезнең аягын юарга тиеш. Минем кебек эшләгез дип, сезгә үрнәк күрсәтүем. Хак сүз әйтәм сезгә: хезмәтче үзенең хуҗасыннан бөегрәк түгел, илче дә үзен җибәрүчедән бөек түгел. Сез хәзер моны беләсез. Белгәнегезне үтисез икән, бәхетле булырсыз. Мин барыгыз турында да әйтмим. Кемнәрне сайлап алганымны беләм, ләкин Язмада „Минем белән бергә икмәк ашаучы Миңа каршы баш күтәрде“ дип әйтелгән сүзләр тормышка ашырга тиеш».

Шул сүзләрдән соң Гайсә бик нык көенеп шәкертләренә: «Хак сүз әйтәм: сезнең берегез Миңа хыянәт итәчәк», – диде. Шәкертләре исә, Аның кем турында сөйләвен аңламыйча, бер-берсенә караштылар. Аларның берсе, Гайсәнең күкрәгенә терәлеп диярлек утырганы, Аңардан: «Хакимем! Кем ул?» – дип сорады. «Икмәк сыныгын манып кемгә бирсәм – шул булыр», – дип җавап кайтарды Гайсә һәм, икмәкне манып алып, Искариот углы Яһүдәгә бирде. Шул сыныкны кулына алуга Яһүдә шундук чыгып китте. Урамда инде төн иде.

Яһүдә чыгып киткәч, Гайсә болай диде: «Балаларым! Мин сезгә яңа әмер бирәм: бер-берегезне яратыгыз. Мин сезне ничек яратсам, сез дә шулай бер-берегезне яратыгыз. Бер-берегезне яратсагыз, Минем шәкертләрем булуыгызны барысы да белер».

Аннары Гайсә аларга: «Бу төндә сез барыгыз да Миннән баш тартырсыз», – диде. Петер исә Аңа җавап итеп: «Синнән һәммәсе



баш тартканда да, мин һичкайчан баш тартмам», – диде. Гайсә аңа болай дип әйтте: «Хак сүз әйтәм сиңа: бүген төнлә әтәч кычкырганчы, син Миннән өч тапкыр ваз кичәрсең».

*Маттай 26:33–34; Яхъя 13:4–35*

## Гетсимәни бакчасында кылынган дога

Шул ук төнне, ашап-эчкәннән соң, Гайсә Үзенең унбер шәкерте белән Иерусалимнән чыгып Гетсимәни дип аталган урынга килде. Шәкертләре белән бергә бакчага кергәч, Гайсә аларга: «Мин читтәрәк дога кылып килгәнче, шушында утырып торыгыз», – дип әйтте дә, Үзе белән Петер, Ягъкуб һәм Яхъяны ияртеп, арырак атлады. Аның күңелен әрнү, шом биләп алды. «Йөрәгемне үлем сагышы басты, шушында көтеп торыгыз һәм Минем белән бергә уяу булыгыз!» – диде Ул аларга һәм читкәрәк китте дә җиргә йөзтүбән капланып дога кыла башлады: «И Атам! Әгәр мөмкин икән, бу газаплар касәсе Мине читләтеп үтсен! Хәер, Мин теләгәнчә түгел, Син теләгәнчә булсын». Шулвакыт Аның янына күктән бер фәрештә иңеп Аңа ныклык бирде. Күңеле газапланганга, Гайсә аеруча тырышып дога кылды; Аңардан, җиргә тамган кан тамчылары кебек, тир акты.

Догасын тәмамлаганнан соң, Ул шәкертләре янына әйләнеп килде һәм аларның йоклап ятуын күрде. «Нигә йоклап ятасыз сез? – диде Ул. – Йокламагыз, вәсвәсәгә бирелмәс өчен дога кылыгыз. Рух гайрәтле, тән зәгыйфьтер!»

Гайсә, яңадан читкәрәк китеп, янә дога кылды: «Атам! Миңа бу касәдән эчми калырга ярамый икән, Синең ихтыярыңча булсын». Гайсәнең гөнаһларыбыз өчен кичерәсе газаплары хакында сүз алып баруы иде.

*Маттай 26:36–44; Лук 22:39–46*



## Гайсәнең сак астына алынуы

Шәкертләре янына Гайсә өч тапкыр әйләнеп килде; Ул кайчан гына килсә дә, алар һаман йокыда булды. Өченче кат килүендә Ул: «Һаман йоклыйсызмы? – диде. – Менә, сәгате сукты: Адәм Углын гөнаһлылар кулына тапшыралар. Торыгыз, киттек! Миңа хыянәт итүче килә инде».

Гайсә әле әйтеп тә бетермәде, унике шәкертнең берсе – утыз көмеш тәңкә бәрабәренә Аны баш руханиларга тотып бирергә ризалашкан Яһүдә Искариот килеп чыкты. Аның белән бергә, кулларына факел, кылыч һәм чукмарлар тотып, фарисейлар белән баш руханилар җибәргән гаскәриләр һәм бер төркем кешеләр күренде. «Мин кемне үпсәм, шул Гайсә булыр, Аны кулга алыгыз», – дип хыянәтче Яһүдә алар белән алдан сүз беркеткән була. Яһүдә туп-туры Гайсә янына килде дә: «Исәнме, Остаз!» – дип Аны үбеп алды. Ә Гайсә аңа: «Нәрсә өчен килгән булсаң, шуны эшлә, дустым! – диде, аннары, Яһүдә белән килгән хәрбиләргә мөрәҗәгать итеп, – кемне эзлисез сез?» – дип сорады. «Насаралы Гайсәне», – дип җавап бирде тегеләр. «Мин Ул», – диде Гайсә. Әлеге сүзләрне ишетүгә барчасы, артка чигенеп, җиргә егылды. «Юлбасар тотарга чыккандай, Минем янга кылыч һәм чукмарлар күтәреп килгәнсез, – диде Гайсә. – Мин һәр көнне Аллаһы йортында сезнең алда халыкны өйрәттем, һәм сез Мине кулга алмадыгыз. Әмма хәзер – сезнең заман, караңгылык чоры!»

Гаскәриләр, Гайсәне сак астына алып, баш рухани йортына юнәлделәр, ә шәкертләрнең барысы Аны ташлап китте.

*Маттай 26:45–49, 56–57; Лук 22:45–54;*
*Яхъя 18:1–12*



## Гайсәне хөкем итү.
## Петернең Гайсәдән ваз кичүе

Петер һәм тагын бер шәкерт, бу хәлнең ничек тәмамлануын күрергә теләп, баш руханиның ишегалдына килеп җиткәнче читтән генә күзәтеп Гайсә артыннан ияреп барды. Баш руханилар, халык өлкәннәре һәм Югары киңәшмә әгъзалары, Гайсәне үлем җәзасына хөкем итәр өчен, Аңа каршы ялган дәлилләр табарга тырышты. Бик күп ялган шаһитлар килеп Гайсәгә каршы нахак сүз сөйләсә дә, Аны гаепләрдәй нәрсә табылмады.

Ниһаять, тагын ике шаһит килеп болай диде: «Бу кеше „Мин, Аллаһы Йортын җимереп, өч көндә аны яңадан төзи алам“ дип әйтте». Шуннан олуг рухани торып Гайсәдән: «Боларның гаепләүләренә каршы ник бернинди җавап кайтармыйсың?» – дип сорады. Гайсә дәшмәвендә булды. Шуннан олуг рухани Аңардан: «Мәңге тере Аллаһы алдында ант итеп әйтүеңне таләп итәм: Син Мәсихме, Аллаһы Углымы?» – дип сорады. «Моны син үзең әйттең, – диде аңа Гайсә. – Ә Мин сезгә болай дим: шушы мәлдән башлап Кодрәт Иясенең уң ягында Адәм Углының утыруын һәм күктәге болытлар өстендә килүен күрерсез».

Шунда олуг рухани, өстендәге киемен ертып җибәреп: «Көфер сүз бу! Тагын нинди шаһитлар кирәк безгә? Көфер сүз сөйләвен хәзер генә үзегез ишеттегез бит! Бу хакта сез нәрсә уйлыйсыз?» – диде. «Ул гаепле һәм үләргә тиеш», – дип җавап бирделәр аңа. Шуннан алар Гайсәнең йөзенә төкерергә, Аны кыйнарга тотындылар; кайберләре исә, яңагына китереп сугып: «Әй, Мәсих, пәйгамбәрлегеңне күрсәт әле – кем сукты Сиңа?» – диделәр.

Петер исә бу вакытта олуг рухани йортының ишегалдында хезмәтчеләр белән бергә учак янында җылынып утыра иде. Шулчак аның янына бер хезмәтче кыз килеп: «Син дә бит гәлиләяле Гайсә белән идең», – диде. Әмма Петер, җыелган халык алдында ваз кичеп: «Синең нәрсә сөйләгәнеңне мин аңламыйм», – диде. Петер капкага якынлашканда, икенче бер хезмәтче кыз, аны танып, янәшәдәгеләргә: «Менә бу кеше дә насаралы Гайсә белән иде», – диде. Петер, ант итеп, Гайсәдән кабат ваз кичте: «Мин ул Кешене белмим!» – диде. Бераздан шул тирәдә басып торган кешеләр килеп аңа: «Син чыннан да аларның берсе бит, чөнки



сөйләшүеңнән күренеп тора», – диделәр. Петер, ант итеп, тагын: «Мин ул Кешене белмим!» – дип әйтте. Нәкъ шул вакытта әтәч кычкырды.

Шунда Петер Гайсәнең «әтәч кычкырганчы, син Миннән өч тапкыр ваз кичәрсең» дип әйткән сүзләрен исенә төшерде һәм, урам якка чыгып, ачынып елап җибәрде.

*Маттай 26:58–75; Яхъя 18:15*

# Гайсә Пилат янында

Иртән иртүк барлык баш руханилар һәм халык өлкәннәре җыелып Гайсәне үлем җәзасына хөкем итәргә булдылар. Алар Аны бәйләп Яһүдиядәге Рим идарәчесе Понтий Пилат янына алып килделәр. Гайсәгә хыянәт иткән Яһүдә, Аның үлем җәзасына хөкем ителүен белгәч, кылган гамәленә үкенеп утыз көмеш тәңкәне баш руханиларга һәм халык өлкәннәренә кайтарып бирде. «Гөнаһ эш кылдым мин, бер гаепсез Кешегә хыянәт иттем», – диде ул аларга. Яһүдә шул көмеш тәңкәләрне гыйбадәтханәдә ташлап калдырды да аннан чыгып китте; шуннан соң барып асылынды.

Гайсәне алып килгән яһүдиләр, пакьләнүләре бозылыр дип, мәҗүси Пилатның сараена кермәделәр. Пилат аларның каршысына үзе чыгып: «Сез бу Кешене нәрсәдә гаеплисез?» – дип сорады. Аңа җавап итеп тегеләр: «Әгәр җинаятьче булмаса, Аны сиңа тотып китермәгән булыр идек», – диделәр. Аннары алар: «Без бу Кешене халкыбызны station аздыручы дип таптык. Ул Үзен Мәсих, Патша дип атый һәм кайсарга салым түләүне тыя», – дип Гайсәне гаепләргә тотындылар.

Шунда Пилат яңадан сараена керде һәм, Гайсәне чакыртып, Аңардан: «Син – яһүдиләр Патшасымы?» – дип сорады. «Минем Патшалыгым бу дөньяныкы түгел, – дип җавап кайтарды аңа Гайсә. – Әгәр Патшалыгым бу дөньяныкы булса, Мине яһүдиләр кулына бирмәс өчен хезмәтчеләрем көрәшкән булыр иде». Пилат Аңардан: «Шулай да Син Патшамы?» – дип сорады. «Мин хакыйкать турында шаһитлык бирү өчен тудым, дөньяга шуның өчен килдем. Хакыйкать яклы һәркем Мине тыңлый», – дип җавап бирде Гайсә. «Нәрсә соң ул – хакыйкать?» – дип сорады Пилат.

Гайсәнең Һируд* патша идарә иткән Гәлиләядән булуын белгәч, Пилат Аны Һируд янына җибәрде. Ул көннәрдә Һируд үзе дә Иерусалимдә иде. Һируд патша Гайсәгә шактый күп сораулар бирсә дә, Ул аларның берсенә-бер җавап кайтармады. Янәшәдә басып торган баш руханилар һәм Канун белгечләре исә тырышып-тырышып Аны гаепләделәр. Һируд һәм аның гаскәриләре, Гайсәдән мыскыллап көлгәннән соң, Аны купшы киемнәргә киендерделәр дә кабат Пилат янына җибәрделәр. Моңа хәтле дошманлашып йөргән Пилат белән Һируд шул көннән дуслашып киттеләр.

---

* *Һируд* – биредә Бөек Һирудның угылы Һируд Антипас турында сүз бара.



Баш руханиларны, түрәләрне һәм халыкны җыеп, Пилат аларга: «Әлеге Кешене сез минем янга „халыкны котырта“ дип алып килдегез. Менә мин сезнең алда Аңардан сорау алдым, ләкин бу Кешедә сез әйткән гаепләрнең берсен дә тапмадым», – диде. Кабул ителгән гадәт буенча, бәйрәм хөрмәтенә Пилат бер тоткынны азат итәргә тиеш булып, ул нәкъ менә Гайсәне иреккә җибәрергә җыена иде. Әмма шулчак бар халык бертавыштан: «Үлем Аңа! Ә безгә Барабны азат ит!» – дип кычкыра башлады. Әлеге Бараб, шәһәрдә чуалыш чыгарган һәм кеше үтергән өчен зинданда утыра иде. Гайсәне азат итәргә омтылып, Пилат тагын халыкка мөрәҗәгать итте, әмма халык: «Хачка кадакла Аны, хачка!» – дип кычкыра бирде; һәм аларның кычкыруы Пилатның тавышыннан көчлерәк булып чыкты.

*Маттай 27:1–4; Лук 23:2, 7–23; Яхъя 18:28–30, 33–38*

## «Үзенең хачын күтәреп»

Шуннан соң Пилат Гайсәне камчы белән суктырырга кушты. Гаскәриләр Аның башына күгән ботакларыннан үрелгән таҗ, өстенә куе кызыл төстәге япанча кидерделәр һәм Аның янына килеп: «Яшәсен яһүдиләр патшасы!» – дип мыскылладылар, яңакларына суктылар. Пилат янә халык янына чыгып: «Карагыз, Аңарда бернинди гаеп тапмавымны белдерү өчен Аны сезнең алдыгызга чыгарам», – диде.

Башына чәнечкеле таҗ, өстенә куе кызыл төстәге япанча кигән Гайсә чыгып басты. «Менә ул Кеше!» – диде Пилат. Гайсәне күрүгә баш руханилар һәм сакчылар: «Хачка кадакла Аны, хачка!» – дип кычкырдылар. «Мин Аңарда бернинди гаеп тапмыйм», – дип кабатлады Пилат. «Безнең Канун буенча Ул үләргә тиеш, чөнки Үзен Аллаһы Углы дип атады», – дип җавап кайтарды яһүдиләр. Әлеге сүзләрне ишетеп Пилат бигрәк тә куркуга калды һәм яңадан сарайга кереп Гайсәдән: «Син кайдан буласың?» – дип сорады. Әмма Гайсә дәшмәде. «Миңа җавап бирәсең килмиме? Сине хачка кадаклатырга да, азат итәргә дә хокукым барлыгын белмисеңме әллә?» – диде Аңа Пилат. «Сиңа югарыдан бирелмәсә, Минем өстән һичнинди хакимлегең булмас иде. Шуңа күрә Мине сиңа тапшырган кешенең гөнаһы синекеннән зуррак», – дип җавап кайтарды Гайсә. Шул сүзләрдән соң Пилат Аны азат итү чарасын эзли башлады.

Пилат, Гайсәне сарайдан чыгарып, хөкемче урынына барып утырды. «Менә сезнең Патшагыз!» – диде Пилат яһүдиләргә. Әмма алар: «Олактыр Аны! Хачка кадакла!» – дип кычкырырга тотындылар. «Мәсих дип аталган Гайсә белән нишләргә соң миңа?» – диде Пилат. «Хачка кадакларга Аны!» – дип җаваплады бөтенесе бер булып. «Нинди явызлык кылды соң Ул?» – дип сорады идарәче. Әмма халык: «Хачка кадакларга Аны!» – дип тагын да ныграк кычкыруында булды. Үзенең бернәрсә дә эшли алмавын һәм дә халык арасында ризасызлык арта баруын күреп, Пилат су китерергә кушты; аннары халык алдында кулларын юды да: «Бу Кешенең үлемендә гаебем юк. Үзегез карагыз», – диде. Аның сүзләренә каршы: «Гаебе безгә һәм безнең балаларга төшсен!» – дип дәррәү җавап кайтарды халык. Шуннан Пилат Барабны азат итте, ә Гайсәне камчы белән суктырганнан соң хачка кадакларга боерды.



Гаскәриләр Гайсәне җәза буласы урынга алып киттеләр. Гайсә, Үзенең хачын күтәреп, «Баш сөяге»* дип аталган җәза мәйданына юнәлде. Аларга бик күп халык иярде, араларында Гайсәне кызганып елаган хатын-кызлар да байтак иде. Гайсә аларга таба борылып: «Әй Иерусалим хатын-кызлары! Минем өчен күз яшьләре түкмәгез, бәлки үзегез һәм балаларыгыз өчен елагыз, – диде. – Чөнки „бала таба алмаган һәм бала тудырмаган, күкрәк сөте имезмәгән хатыннар бәхетле“ дип әйтер көннәр җитә».

*Маттай 27:20–26; Лук 23:27–29; Яхъя 19:1–17*


* *Баш сөяге* – русчасы «Голгофа».

## Гайсәне хачка кадаклау

Җәза урынына Гайсә белән бергә ике җинаятьчене дә алып бардылар. «Баш сөяге» дип аталган урынга килеп җиткәч, Аны да, теге җинаятьчеләрне дә – берсен Аның уң ягындагы, икенчесен сул ягындагы хачка кадакладылар. Гайсә шунда: «И Атам! Кичер бу кешеләрне, чөнки нәрсә эшләгәннәрен белмиләр», – диде. Пилат кушканча язу язып, хач өстенә беркеттеләр. Анда яһүдчә, грекча һәм латинча «Насаралы Гайсә, яһүдиләр Патшасы» дип язылган иде.

Гайсәне хачка кадаклагач, гаскәриләр, жирәбә салып, Аның киемнәрен, япанчасын бүлештеләр. Халык карап торды. Башлыклар исә, Гайсәне мыскыллап: «Башкаларны коткарып йөрде бит; әгәр Аллаһы тарафыннан сайланган Мәсих булса, Үзен коткарсын!» – дип көлделәр. Гаскәриләр дә Аңа әче шәраб тәкъдим итеп: «Әгәр яһүдиләр Патшасы булсаң, Үзеңне коткар», – дип мыскылладылар. Хачка кадакланган җинаятьчеләрнең берсе, Аны хурлап: «Мәсих булгач, Үзеңне дә, безне дә коткар», – диде. Икенчесе исә тегене тыеп: «Аллаһыдан курык! Син үзең дә, Аның кебек үк, хөкемгә дучар ителгән кеше бит. Безне гадел хөкем иттеләр, кылган эшебез өчен тиешлесен алдык, ә Ул һичбер начарлык эшләмәгән, – диде, аннары Гайсәгә мөрәҗәгать итеп, – Гайсә, Үз Патшалыгыңа килгәч мине искә ал», – дип өстәде. «Хак сүз әйтәм: син бүген үк Минем белән бергә оҗмахта булырсың», – дип җавап кайтарды аңа Гайсә. Көн үзәгендә бөтен җир йөзен караңгылык каплап алды, һәм шушы хәл көндезге өчкә кадәр дәвам итте. Сәгать өчләр тирәсендә Гайсә: «Эли, Эли! Лама савахфани?» («И Аллам, Аллам! Ник ташладың Мине?») – дип ачыргаланып кычкырып җибәрде. Янәшәдә басып торган хәрбиләрнең берсе шунда, йөгереп килеп, әче шәрабка манчыган губка кисәген таякка элде дә Аңа эчәргә бирде. Әче шәрабны йотканнан соң Гайсә: «Гамәлгә ашты! – диде, аннары, – Атам! Рухымны Синең кулыңа тапшырам!» – дип кычкырды да җан бирде.

Шулвакыт Аллаһы Йортындагы пәрдә өстән аска кадәр урталай ертылып төште. Җир тетрәде, таш кыялар ярылды, каберләр ачылып китеп, гүр иясе булган бик күп изгеләргә җан керде, һәм алар каберләреннән торып чыкты; соңыннан, Гайсә үледән терелгәч, алар изге шәһәр Иерусалимгә килделәр, һәм күпләр аларны күрде. Йөзбашы һәм аның белән бергә Гайсәне саклаучы гаскәриләр, җир тетрәвен һәм башка вакыйгаларны күреп, бик нык курыктылар.



«Ул чынлап та Аллаһы Углы булган икән», – диеште алар. Җәзаны карарга җыелган халык шушы вакыйганы күргәннән соң кайгыдан күкрәген төя-төя өенә таралды.

*Маттай 27:45–49, 51–54; Лүк 23:32–43, 46– 48;*
*Яхъя 19:19–24, 30*

## Гайсәне кабергә салу

Әлеге хәлләр иртәгә шимбә дигән көнне булды. Шимбә бөек бәйрәм көне булганлыктан, җәзалап үтерелгән кешеләрнең гәүдәләрен яһүдиләр хачта калдырырга теләмәделәр. Шунлыктан, хачка кадакланган кешеләрнең үлемнәрен тизләтү өчен, аларның балтырларын сындырып, гәүдәләрен хачтан төшерергә Пилаттан рөхсәт сорадылар. Шуннан гаскәриләр килеп теге ике юлбасарның балтыр сөякләрен сындырдылар. Әмма Гайсә янына килгәч, Аның инде үле булуын күреп, аякларына тимәделәр. Алай да гаскәриләрнең берсе Аның кабыргасына сөңге белән чәнчеде – ярадан шундук кан катыш су агып чыкты. Шулай итеп, Язмадагы «Аның һичбер сөяге сындырылмас» дигән сүзләр гамәлгә ашты *(Чыгыш 12:46)*. Язманың башка бер урынында «алар үзләре чәнчегән Затка карарлар» дип тә әйтелгән *(Зәкәрия 12:10)*.

Югары киңәшмә әгъзасы, күренекле һәм бай кеше, ариматайлы Йосыф шуннан соң Пилат янына килде. Яһүдиләрдән курыкканга, Гайсәнең шәкерте булуын ул яшереп йөри иде. Әлеге Йосыф идарәче Пилаттан Гайсәнең гәүдәсен хачтан төшерергә рөхсәт сорады, һәм Пилат аңа ризалык бирде.

Алдагы төннәрнең берсендә яшертен генә Гайсә белән очрашкан Никәдим атлы кеше дә килде (ул синедрион әгъзаларының берсе иде) һәм зур-зур савытларда хуш исле майлар китерде. Яһүдиләрнең йоласы буенча алар Гайсәнең гәүдәсен хуш исле май сеңдерелгән кәфенгә төрделәр. Гайсә хачка кадакланган урыннан ерак түгел бер бакча булып, анда тауны чокып ясаган, һичкемнең мәете салынмаган яңа кабер-мәгарә бар иде. Йосыф белән Никәдим, Гайсәнең гәүдәсен шунда урнаштырып, мәгарә авызын зур таш белән томалап куйдылар.

Иртәгесе көнне – ул шимбә көн иде – Пилат янына баш руханилар белән фарисейлар килде. «Әфәнде, исән чагында теге ялганчының „өченче көндә Мин үледән тереләчәкмен“ дигән сүзләре искә төште, – диде алар. – Шуңа күрә өченче көнгә кадәр каберне сакларга әмер бир, югыйсә төнлә шәкертләре килеп гәүдәсен урлап китәрләр дә соңыннан халыкка „Ул үледән терелде“ дип әйтерләр; һәм бу ялган беренчесеннән яманрак булыр».

Тегеләр киттеләр һәм, мәгарә авызын томалаган ташка мөһер сугып, гаскәриләрне каравылга куйдылар.

*Маттай 27:57–66; Яхъя 19:31–42*



## Гайсәнең үледән терелүе

Шимбә үткәннән соң, икенче көннең таңында, җирләрне тетрәтеп күктән Раббы фәрештәсе иңде дә кабер янына килеп ташны читкә тәгәрәтте. Аның йөзеннән яшен утыдай нур бөркелә, ә киемнәре кар сыман ап-ак иде. Мәгарә янына сакка куелган гаскәриләр, котлары алынып, җиргә егылдылар. Һушларына килгәч алар шәһәргә кайттылар һәм күргәннәре турында баш руханиларга сөйләп бирделәр. Халык өлкәннәре белән җыелып киңәшкәннән соң баш руханилар, гаскәриләргә күп итеп акча биреп, аларны: «Сораган кешегә, төнлә без йоклаган чакта шәкертләре килеп Гайсәнең гәүдәсен урлап киткәннәр, дип әйтегез. Бу хәбәр идарәчегә барып ирешер дип борчылмагыз, сезнең гаепсез булуыгызга аны ышандыра алырбыз», – дип кисәтеп куйдылар. Сакчылар акчаны алдылар һәм ничек кушсалар, шулай эшләделәр.

Шул ук көнне магдалалы Мәрьям, Ягъкуб белән Иосиянең анасы Мәрьям һәм Салуми, Гайсәнең гәүдәсенә хуш исле майлар сөртергә дип, иртә таңнан бакча эчендәге төрбә янына киттеләр. «Мәгарә авызындагы ташны аударырга кем булышыр икән безгә?» – диеште алар бер-берсенә. Килеп җитеп карасалар – әлеге шактый зур таш читтә ята. Мәгарә эченә кергәч, ап-ак киемле фәрештәне күреп куркып киттеләр. «Курыкмагыз! – диде аларга фәрештә. – Хачка кадакланган Гайсәне эзлисездер сез. Биредә юк Ул, алдан ук сезгә Үзе әйтеп куйганча, Гайсә үледән терелде. Менә Ул яткан урын. Ә хәзер сез тизрәк Аның шәкертләренә барып хәбәр итегез: Гайсә үледән терелде, Ул аларны Гәлиләядә көтеп тора, дип әйтегез».

Хатыннар куркып, шул ук вакытта бик нык шатланып тиз генә мәгарәдән чыктылар да Гайсәнең шәкертләренә сөйләргә йөгерделәр.

*Маттай 28:1–8, 11–15; Марк 16:1–7, 9*



## Гайсә исән!

Гайсәнең үледән терелүе хакында Аның шәкертләренә хәбәр итәргә барган чакта хатыннарның каршында Гайсә Үзе пәйда булды. «Иминлек телим сезгә!» – диде Ул. Аны күреп хатыннар бик сөенделәр, янына килеп, баш иеп сәламнәрен күндерделәр. «Курыкмагыз! – диде аларга Гайсә. – Шәкертләремә кайтып әйтегез: Гәлиләягә бара торсыннар. Мине шунда күрерләр».

Унбер шәкерт янына килеп җиткәч, хатыннар аларга үледән терелгән Гайсәне күрүләре хакында сөйләп бирделәр, ләкин шәкертләр хатыннарның сүзенә ышанмадылар.

Тик шулай да Петер белән Яхъя төрбә янына йөгерделәр. Петергә караганда Яхъя җитезрәк аяклы иде, шуңа күрә мәгарә янына алданрак барып җитте; иелеп эчкә карагач, анда яткан кәфенне күрде, әмма мәгарәгә кермәде. Аның артыннан Шимун-Петер дә йөгереп килеп җитте һәм, мәгарә эченә кереп, анда яткан кәфенлекне һәм Гайсәнең башында булган яулыкны күрде. Шуннан Яхъя да мәгарә эченә керде һәм андагы әйберләрне үз күзләре белән күргәннән соң Гайсәнең үледән терелүенә ышанды.

*Маттай 28:8–10; Лук 24:9–12; Яхъя 20:3–8*



## Гайсәнең Эммаус юлында шәкертләренә күренүе

Шул ук көнне Гайсәнең ике шәкерте Иерусалим янындагы Эммаус авылына барырга чыкты. Юлда алар соңгы көннәрдә булып узган вакыйгалар турында сөйләшеп бардылар. Алар шулай фикер алышып атлаган чакта, Гайсә Үзе аларга якынлашып яннарыннан бара башлады. Әмма шәкертләренең күзе томаланган кебек иде, шуңа алар Аны танымады.

«Нәрсә хакында гәпләшеп барасыз сез һәм ни өчен йөзләрегез борчулы?» – дип сорады Гайсә Үзенең шәкертләреннән. Клеопас исемлесе Аңа җавап итеп: «Шушы көннәрдә Иерусалимдә ниләр булганын шәһәргә килүчеләрдән бары Син генә белмисеңдер», – диде. «Нәрсә булганын?» – дип сорады Ул. «Насаралы Гайсә белән булган хәлне, – дип җавап кайтарды тегеләр. – Ул Аллаһы алдында һәм бөтен халык алдында сүздә дә, гамәлдә дә кодрәтле Пәйгамбәр иде. Әмма баш руханилар белән башлыкларыбыз Аны үлемгә хөкем итәр өчен Пилат кулына тапшырдылар һәм хачка кадакладылар. Ә без, Исраилне азат итәргә тиешле Кеше шулдыр, дип өметләнгән идек! Шуның өстенә менә тагын ниләр булды: ул вакыйгадан соң инде өченче көн китте, һәм арабыздан берничә хатын безне гаҗәпкә калдырды. Алар таңнан торып кабер янына барганнар, ләкин Аның гәүдәсен тапмаганнар. Кайткач, шунда фәрештәләрнең пәйда булуын һәм „Гайсә исән“ дип әйтүен сөйләделәр. Аннары арабыздан кайберәүләр кабер янына барганнар һәм хәлнең хатыннар сөйләгәнчә булуын күргәннәр – Гайсә кабердә булмаган». Шунда Гайсә аларга: «И аңсызлар, пәйгамбәрләрнең барлык сүзләренә сез шундый авырдан ышанасыз! Үзенең шөһрәтенә ирешкәнче, Мәсих шулай газап чигәргә тиеш түгел идемени?» – диде. Аннары Ул, Мусаның һәм барлык пәйгамбәрләрнең язмаларыннан башлап, Үзе турында анда әйтелгән сүзләрне аңлатып бирде.

Авылга якынлашкач, тегеләр Аңа: «Инде кич җитеп килә, безнең белән кал», – дип, Аны күндерделәр, һәм Ул алар белән йорт эченә узды. Бөтенесе бергә өстәл янына ашарга утыргач, Гайсә икмәк алып шөкрана кылды да сындырып шәкертләренә бирде. Шулчак шәкертләрнең күзләре ачылып киткәндәй булды, һәм алар Гайсәне танып алдылар; әмма Ул күренмәс булды. Алар



бер-берсенә: «Ул безнең белән юлда сөйләшеп барганда һәм язмаларның мәгънәсен аңлатканда күңелләребез күтәрелеп китте түгелме соң?» – диештеләр.

*Лук 24:13–32*

## Гайсәнең башка шәкертләргә дә күренүе

Эммаус юлында Гайсәгә тап булган шәкертләр шундук Иерусалимгә әйләнеп кайттылар һәм, җыелып торган унбер рәсүл белән башка шәкертләрне күреп, аларга юлдагы вакыйга турында, икмәк сындырган чакта ничек итеп Гайсәне танып алулары турында сөйләп бирделәр.

Алар шулай сөйләшеп торганда, Гайсә Үзе яннарында пәйда булып: «Иминлек сезгә!» – диде. Шәкертләре, өрәктер бу дип уйлап, куркудан катып калдылар. Ләкин Гайсә аларга: «Нигә каушап калдыгыз һәм ни өчен күңелегезгә шундый шик керә? – диде. – Кулларыма һәм аякларыма карагыз – Мин бу. Орынып карагыз Миңа; өрәкнең тән-бәдәне һәм сөяге булмый, ә Миндә, күргәнегезчә, бар». Шулай дип әйтеп, Ул аларга кул-аякларындагы җәрәхәт эзләрен күрсәтте. Тегеләр шатлыктан һәм гаҗәпләнүдән һаман ышанмый торганда, Ул: «Сезнең берәр нинди ризыгыгыз бармы?» – дип сорады. Аңа бер кисәк пешкән балык белән кәрәзле бал бирделәр, һәм Ул аларның күз алдында алып ашады.

Шуннан шәкертләренә Гайсә болай диде: «Сезнең янда чакта Мин нәкъ менә шушы хакта сөйләгән идем. Муса канунында, пәйгамбәрләрнең язмаларында һәм Зәбурда Минем турыда әйтелгәннәрнең барысы да гамәлгә ашырга тиеш, дигән идем. Язмаларда әйтелгәнчә, Мәсихнең газап чигүе, өченче көндә үледән терелүе, кешеләрнең Аның исеме хакына тәүбәгә килүе һәм гөнаһларының кичерелүе турындагы хәбәр Иерусалимнән башлап барча халыкларга таратылырга тиеш. Сез – шушы хәлләрнең шаһиты. Мин сезгә Атам вәгъдә иткәнне җибәрермен, әмма сез югарыдан кодрәт алганчы шәһәрдә калыгыз».

*Лүк 24:33–49*



## «Син Мине яратасыңмы?»

Үледән терелгән Хаким Гайсә шушы хәлләрдән соң Гәлиләядә, Тибериас диңгезе буенда, Үзенең шәкертләренә янә күренде. Аның күренүе болай булды: Шимун-Петер, Игезәк кушаматлы Томас, Гәлиләянең Кәна шәһәреннән Натанаил, Зебедәй угыллары һәм Гайсәнең тагын ике шәкерте бергә җыелган иде. Шимун-Петер: «Балык тотарга барам», – дигәч, башка шәкертләр дә аның белән барырга булды. Алар көймәгә утырдылар да ярдан эчкәрәк кереп киттеләр, әмма ул төнне һичнәрсә тота алмадылар.

Таң атканда яр буенда Гайсә басып тора иде, әмма шәкертләре Аны танымады. «Дусларым, ашардай берәр нәрсә тота алдыгызмы?» – дип сорады Гайсә. «Юк», – дип җавап бирде тегеләр. Шуннан Ул аларга: «Ятьмәне көймәнең уң ягына салыгыз – тотарсыз», – диде. Алар ятьмәне салдылар һәм эләккән балыкның күплегеннән аны тартып чыгара алмадылар. Гайсәнең яраткан шәкерте шунда Петергә: «Бу – Хакимебез!» – диде, һәм Петер шушы сүзләрне ишетүгә суга сикерде дә ярга йөзеп чыкты. Башка шәкертләр исә, балык тулган ятьмәне сөйрәп, ярга таба көймәдә киттеләр – алар балыкны ярдан бик ерак китмичә тоталар иде. Ярга чыккач, учактагы күмер өстендә яткан балыкны күрделәр; учак янында икмәк тә бар иде.

Бу инде Гайсәнең үлеп терелгәннән соң шәкертләренә өченче тапкыр күренүе иде.

Ашап утырган вакытта Шимун-Петердән Гайсә: «Яхъя углы Шимун, син Мине башка шәкертләремнән ныграк яратасыңмы?» – дип сорады. «Әйе, Хакимем! Минем ратуымны Син беләсең», – дип җавап бирде Петер. «Минем бәрәннәрне кайгырт», – диде аңа Гайсә. Аннары Ул кабат: «Яхъя углы Шимун, син Мине яратасыңмы?» – дип сорады. «Әйе, Хакимем! Минем яратуымны Син беләсең», – дип җавап бирде Петер. «Минем сарыкларны көт», – диде аңа Гайсә. «Яхъя углы Шимун, син Мине яратасыңмы?» – дип сорады Гайсә өченче тапкыр. Аның шулай өченче тапкыр: «Син Мине яратасыңмы?» – дип соравына Петернең кәефе кырылды, һәм ул Аңа: «Хакимем! Син бөтенесен беләсең. Минем яратуымны Син беләсең», – диде. Шуннан Гайсә аңа: «Минем сарыкларны кайгырт», – диде.



Теге вакытны Гайсәдән өч тапкыр ваз кичкән кебек, бу юлы Петер Аңа булган мәхәббәте турында өч тапкыр ихлас күңелдән әйтте. Гайсә Мәсихнең, «Минем сарыкларыма көтүче бул» дип әйтеп, Үзенә иман итүчеләрне кайгыртуны Петергә һәм шәкертләренә тапшыруы иде.

*Яхъя 21:1–17*

## Гайсәнең күккә ашуы

Үледән терелгән Мәсих, әле яңадан кырык көн дәвамында Үзенең шәкертләренә күренеп, аларга Аллаһы Патшалыгы турында сөйләде. Ахырда, барысын бергә җыеп, Гайсә мондый боерык бирде:

> Иерусалимнән китмәгез, Атам вәгъдә иткән бүләкне көтегез – ул турыда Мин сезгә сөйләгән идем. Яхъя суга чумдырды, сез исә берничә көннән Изге Рухка чумдырылырсыз.
>
> Сезгә Изге Рух иңгәннән соң кодрәткә ия булырсыз һәм Иерусалим җирендә, шулай ук бөтен Яһүдиядә, Самареядә, хәтта дөньяның читендә дә Минем хакта шаһитлык кылырсыз.

Шушы сүзләрдән соң Гайсә Мәсих аларның күз алдында күккә күтәрелә башлады һәм болыт эчендә юкка чыкты. Алар шулай Гайсәнең күтәрелүен күзәтеп күккә текәлеп торганда, кинәт яннарында актан киенгән ике ир заты пәйда булып: «Гәлиләя ирләре! Ник сез күккә текәлеп торасыз? Яныгыздан күккә ашкан Гайсә күз алдыгызда ничек күтәрелгән булса, шул рәвешчә яңадан киләчәк», – диде.

*Рәсүлләрнең эшләре 1:3–11*



## «Юл, хакыйкать һәм тормыш»

Хакимебез Гайсә Мәсих чама белән өч ел дәвамында, хачта җәза кабул иткәнче, җирдә адәм балаларына хезмәт күрсәтте. Ул котылу һәм Аллаһы Патшалыгы турындагы Яхшы хәбәрне, ягъни Инҗилне вәгазьләп йөрде. Гайсә Мәсих әйткән иң мөһим фикерләр менә мондый:

> Мин – юл, хакыйкать һәм тормыш; Атам янына һәркем бары Минем аша гына килә ала *(Яхъя 14:6)*.
>
> Мин – терелү һәм тормыш. Миңа ышанган кеше үлсә дә, терeләчәк *(Яхъя 11:25)*.
>
> Дөньяда чагымда Мин – дөньяга яктылык *(Яхъя 9:5)*.
>
> Мин – тормыш икмәге. Яныма килүче һичкайчан ачыкмас, Миңа инанучы һичкайчан сусамас *(Яхъя 6:35)*.
>
> Адәм Улы югалганны эзләп табар һәм коткарыр өчен килде *(Лүк 19:10)*.
>
> Барыннан да бигрәк Аллаһы Патшалыгын һәм Аның гадел ихтыярын эзләгез *(Маттай 6:33)*.
>
> Мин сезгә тынычлык калдырам, Үз тынычлыгымны сезгә бирәм, әмма Мин биргән тынычлык кешеләр биргәненә охшамаган. Күңелегез борчылмасын һәм курыкмасын *(Яхъя 14:27)*.
>
> Хәлдән тайганнар, авыр йөктән җәфа чигүчеләр, һәммәгез Миңа килегез. Мин сезгә тынычлык бирермен. Минем камытымны киегез һәм Миннән өйрәнегез: чөнки Мин юаш, йомшак күңеллемен; һәм сез җаннарыгызга тынычлык табарсыз – Минем камытым уңайлы, йөгем дә җиңел *(Маттай 11:28–30)*.
>
> Сүземне тыңлаучы һәм Мине җибәргән Затка ышанучы кеше мәңгелек тормышка ия. Ул кеше хөкемгә дучар булмаячак, чөнки инде үлемнән тормышка күчкән санала *(Яхъя 5:24)*.
>
> Аллаһы Улына ышанган кеше мәңгелек тормышка ия, ә Аңа буйсынмаганы тормыш күрмәячәк – аның өстендә Аллаһының ачуы тора *(Яхъя 3:36)*.
>
> Минем арттан барырга теләгән кеше үз мәнфәгатьләреннән баш тартсын һәм, үзенең хачын күтәреп, Миңа иярсен *(Лүк 9:23)*.



Бөтен дөньяны яулап, әгәр үзен харап итә яки үзенә зыян китерә икән, кешегә моннан ни файда? *(Лук 9:25)*.

Кешеләр алдында Мине таныган һәркемне Мин дә Күктәге Атам алдында танырмын. Ә инде берәрсе кешеләр алдында Миннән ваз кичсә, Мин дә Күктәге Атам хозурында аңардан ваз кичәрмен *(Маттай 10:32–33)*.

Күк белән җир юкка чыгар, әмма Минем сүзләрем һичкайчан юкка чыкмас *(Лук 21:33)*.

## Рәсүлләрнең эшләре

Моңарчы без Хакимебез Гайсә Мәсих күккә ашканчы булып узган вакыйгалар турында сүз алып бардык. Әлеге вакыйгалар Маттай, Марк, Лүк һәм Яхъя тарафыннан язылган дүрт Инҗилдә бәян ителә.

Яңа Гаһеднең бишенче китабы Рәсүлләрнең эшләре дип атала. Әлеге китапта шул заманнарда Рим империясенең төрле төбәкләрендә мәсихчелекнең ни рәвешле таралуы турында сөйләнә. Рәсүлләр Петер белән Паулның эшчәнлеге, бигрәк тә рәсүл Паулның мәҗүсиләр дөньясында Яхшы хәбәрне таратуга куйган хезмәтләре үзәк урынны алып тора.

Гайсә Мәсихнең Гөлгетә хачында җан бирүе, соңыннан үледән терелүе бәрабәренә Аллаһы кешеләргә котылу (Аллаһы белән татулашу) бүләк итә, һәм без Рәсүлләрнең эшләре дигән китапта котылу турындагы хәбәрнең мәҗүсиләр арасында да тарала башлавын күрәбез.

Лүк язган Инҗил дә, Рәсүлләрнең эшләре дигән китап та инҗилче Лүк тарафыннан иҗат ителгән дип санала. Аларның язылу вакыты Гайсә Мәсих туганнан соң 60 нчы елларга туры килә. Рәсүлләрнең эшләре дигән китап, Инҗилдә бәян ителгән вакыйгаларның дәвамы булып, үз эченә Гайсәнең үледән терелүеннән алып 60 нчы еллар башына кадәр булган вакыт аралыгын ала. Бу – мәсихчелекнең тарала башлау тарихы.



## Изге Рухның иңүе

Шуннан соң шәкертләр, Гайсә күккә ашкан Зәйтүн тавыннан төшеп, Иерусалимгә әйләнеп кайттылар да үзләре тукталган йортның түр ягына үттеләр. Алар һәрвакыт барысы бергә дога кылалар иде. Анда берничә хатын-кыз да булып, араларында Гайсә Мәсихнең анасы Мәрьям дә бар иде. Шунда Яһүдә урынына уникенче рәсүл итеп Маттиас исемле кеше сайланды.

Котылу бәйрәменнән соң илле көн узгач үткәрелә торган Илленче көн бәйрәмендә рәсүлләрнең уникесе дә бергә җыелды. Бермәлне, көчле җил искәндәге кебек, күктән тавыш ишетелде һәм алар җыелган йортны тутырды. Аннары ялкын телләре пәйда булды да һәр рәсүлнең өстенә берәр ялкын теле кунды. Шул рәвешле, рәсүлләргә Изге Рух иңеп, алар моңарчы үзләренә мәгълүм булмаган ниндидер ят телләрдә сөйләшә башладылар.

Бу вакытны Иерусалимгә бәйрәмгә дип төрле тарафлардан, төрле илләрдән диндар яһүдиләр җыелган иде. Кинәттән купкан әлеге тавышны ишетеп, алар шул якка юнәлделәр һәм үзләренең туган телләрендә сөйләшүче рәсүлләрне күреп хәйран калдылар. «Бу адәмнәр барысы да Гәлиләядән бит! – диеште алар гаҗәпләнеп. – Нишләп соң без, алайса, үзебез яшәгән илдәге телне ишетәбез? Аллаһының бөек эшләре турында алар безнең туган телебездә сөйли бит!»

Барысы да, тәмам исләре китеп, бер-берсеннән: «Нәрсә аңлата икән бу?» – дип сорашты. Кайберәүләр исә: «Шәраб эчеп исергән алар», – дип көлде.

*Рәсүлләрнең эшләре 1:12–26; 2:1–13*



## Петер сөйләгән вәгазь

Шулчак Петер унбер рәсүл белән бергә торып басты да бар кеше ишетерлек итеп кычкырып сөйли башлады: «Яһүди кардәшләрем һәм Иерусалимнең бар халкы! Мин сезгә моның нәрсә икәнен хәзер аңлатып бирәм! Сүзләремне игътибар белән тыңлагыз, – диде ул. – Сез уйлаганча исерек түгел алар, чөнки әле көн туып кына килә. Аллаһының Йоил пәйгамбәр аша әйткәннәре тормышка аша дигән сүз бу: „Ахыргы көннәрдә, – ди Аллаһы, – һәр кешегә Үз Рухымны яудырырмын: угыл-кызларыгыз пәйгамбәрлек кылыр, егетләрегезгә күренешләр иңәр, өлкәннәрегез гаиптән хәбәр* бирүче төшләр күрер. Ул көннәрдә кол ирләремә дә, кол хатыннарыма да Үз Рухымны яудырырмын, һәм алар пәйгамбәрлек кылыр. Раббы исемен телгә алып, Аңа мөрәҗәгать иткән һәркем котылыр“.

Исраилиләр! Бу сүзләрне тыңлагыз: белгәнегезчә, Аллаһы сезнең күз алдыгызда Гайсә аша кодрәтле эшләр, могҗизалар, галәмәтләр кылды һәм шул эшләре белән насаралы Гайсәнең сезнең өчен билгеләнгән Зат икәнен исбат итте. Аллаһының максаты һәм ихтыяры белән сезнең кулга тапшырылган шушы Кешене сез канунсызлар кулы белән хачка кадаклап үтердегез. Әмма Аллаһы, үлем богауларын өзеп, Гайсәне үледән терелтте – үлем Аның алдында көчсез булып чыкты.

Аллаһы менә шул Гайсәне үледән терелтте, һәм без һәммәбез – моның шаһитлары. Шулай итеп, Аллаһы Аны Үзенең уң ягына утырткач, Ул, Атасыннан вәгъдә ителгән Изге Рухны кабул итеп, өстебезгә сез хәзер күреп-ишетеп торган бүләкне яудырды. Шуңа күрә бөтен Исраил халкы белеп торсын: Аллаһы сез хачка кадаклаган шушы Гайсәне Хаким һәм Мәсих итте».

Бу сүзләр тыңлаучыларның йөрәгенә барып кадалды: «Туганнар, нишләргә инде безгә хәзер?» – дип сорады алар Петердән һәм башка рәсүлләрдән. «Гөнаһларыгыз кичерелсен өчен һәркайсыгыз, тәүбә итеп, Гайсә Мәсих исеме белән суга чуму йоласын үтәгез, шул чагында сез Аллаһы бүләген – Изге Рухны кабул итәрсез. Бу вәгъдә Раббы Аллабыз Үзенә чакырган һәркемгә – сезгә, балаларыгызга һәм еракта яшәүче барлык кешеләргә дә бирелгән, – дип җаваплады Петер».

* *Гаиптән хәбәр* – киләчәк турында Аллаһыдан иңгән хәбәр.



Җыелганнарның күбесе Петернең сүзләрен чын күңелдән кабул итте, һәм шул көнне өч меңгә якын кеше суга чуму йоласын үтәде. Шул вакыттан Раббы котылучыларның санын – Үзенең Бердәмлеген* – көн дә арттыра торды.

*Рәсүлләрнең эшләре 2:14–47*

* *Бердәмлек (Мәсих Бердәмлеге)* – Гайсә Мәсихкә иман итүчеләр җәмгыяте.

## Аксак кешенең савыгуы

Шулай беркөнне Петер белән Яхъя дога кылу вакытында Аллаһы Йортына килделәр. Аяклары тумыштан гарип бер кешене һәркөн, Аллаһы Йортының Матур дип аталган капкасы янына алып килеп, керүчеләрдән хәер сорарга утыртып китәләр иде. Шул кеше, Аллаһы Йортына керүче Петер белән Яхъяны күреп, алардан хәер сорады.

Петер белән Яхъя әлеге кешегә игътибар белән караганнан соң, Петер аңа: «Кара әле безгә!» – диде. Теге кеше, нәрсә дә булса алырга өметләнеп, сораулы карашын рәсүлләргә төбәде. Әмма Петер: «Алтын-көмеш юк миндә, ә булган нәрсәмне исә сиңа бирәм: Гайсә Мәсих исеменнән боерам – тор да йөреп кит!» – дип, аны уң кулыннан тотып торгызды. Гарип кешенең табаннарына, тез буыннарына шундук көч керде, һәм ул, җәһәт кенә торып, йөри башлады, Аллаһыга мактауларын яудыра-яудыра, сикерә-сикерә рәсүлләр белән бергә Аллаһы Йортына керде. Кешеләр, Матур капка янында хәер сорашып утырган адәмне танып, бу хәлгә хәйран калдылар.

Әлеге савыккан адәмнең бер тотам калмыйча Петер белән Яхъяга ияреп йөрүенә гаҗәпләнгән халык, Сөләйман әйваны дип аталган залга йөгереп кереп, алар янына җыелды. Петер, моны күреп, халыкка: «Исраил ирләре! Нигә моңа гаҗәпләнәсез? – диде. – Ник шулай безгә текәлеп карап торасыз? Әллә аны үзебезнең кодрәтебез яисә диндарлыгыбыз белән аякка бастырган дип уйлыйсызмы? Ата-бабаларыбызның Алласы Үзенең Углы Гайсәне шөһрәтле итте, сез исә, Пилат Аны азат итәргә теләгән чакта, Аңарга хыянәт иттегез һәм Аңардан ваз кичтегез. Сез чын тормыш Бирүчене үтердегез, әмма Аллаһы Аны үледән терелтте. Без – моның шаһитлары, – диде Петер. – Гайсәнең исеме сез күреп белгән шушы кешегә куәт бирде, чөнки ул Аңа ышанды. Гайсә аша килгән иман һәммәгезнең күз алдында аны тулысынча савыктырды. Хәер, туганнар, мин беләм: сез, башлыкларыгыз кебек үк, аңышмыйча эш иттегез. Аллаһы Үз Мәсихенең газап чигәсен барлык пәйгамбәрләр аша алдан әйткән иде, һәм бу хәбәре әнә шулай тормышка ашты. Ә сез гөнаһларыгыз кичерелсен өчен тәүбә итегез һәм Аллаһыга йөзегез белән борылыгыз. Шулай эшләсәгез, Раббыдан сөенечле заманнар килер, Ул сезгә алдан билгеләнгән Мәсихне – Гайсәне



җибәрер. Аллаһы Үзенең изге пәйгамбәрләре аша күптән үк белдереп куйган барлык сүзләр гамәлгә ашканчы, Гайсә күктә калырга тиеш. Аллаһы, сезнең һәркайсыгызны яман эшләрдән аралап фатихасын күндерү өчен, Үзенең Углы Гайсәне үледән терелтте һәм Аны иң әүвәл сезгә җибәрде».

*Рәсүлләрнең эшләре 3:1–26*

## Петер белән Яхъяның кулга алынуы

Петер сөйләгән вәгазьдән һәм гарип аяклы кеше савыкканнан соң биш меңгә якын кеше Гайсә Мәсихкә иман китерде. Әмма Петернең сүзләре руханиларның, башлыкларның ачуын кузгатты, шул сәбәпле алар Петер белән Яхъяны кулга алып сак астына тапшырдылар. Икенче көнне Иерусалимдә яһүдиләрнең башлыклары, халык өлкәннәре һәм Канун белгечләре җыелды. Алар рәсүлләрне алып килергә куштылар һәм, тоткыннарны уртага бастырып, теге гарип аяклы адәмне ни рәвешле савыктырулары турында сорадылар: «Нинди кодрәт белән һәм кем исеменнән эшләдегез моны?» – диде алар. Шулвакыт Петер, Изге Рух белән сугарылып, аларга болай диде: «Халык башлыклары, Исраил өлкәннәре! Хаста кешегә кылынган яхшылык һәм аның ни рәвешле савыгуы турында бүген бездән җавап таләп ителә икән, сезнең һәммәгезгә, шулай ук бөтен Исраил халкына мәгълүм булсын: сез хачка кадаклаткан, әмма Аллаһы үледән терелткән Гайсә Мәсих исеме ярдәмендә савыккан адәм хәзер сау-сәламәт килеш каршыгызда басып тора. Ә Гайсә – „сез, төзүчеләр, кире каккан иң мөһим почмак ташы” ул. Башка һичкемнән котылу килмәс. Җир йөзендә кешеләргә бирелгән исемнәр арасында безне коткарырдай бүтән исем юк».

Укымаган, гап-гади бу ике кешенең – Петер белән Яхъяның кыюлыгын күреп, Югары киңәшмәдә утыручылар бик гаҗәпләнделәр, аларның Гайсә белән бергә йөргән кешеләр икәнен аңладылар. Савыккан кешене дә Петер белән Яхъя янында күргәч, каршы сүз әйтә алмадылар һәм аларга Югары киңәшмәдән чыгып торырга боердылар. «Бу кешеләр белән нәрсә эшләргә? Алар кылган гаҗәеп могҗиза Иерусалим халкының һәммәсенә мәгълүм, һәм без моны инкяр итә алмыйбыз; әмма халык арасында артык сүз таралмасын өчен, аларны катгый рәвештә кисәтик: бу исем турында беркайчан да кешеләргә сөйләмәсеннәр», – дип үзара киңәшләштеләр.

Петер белән Яхъяны яңадан чакырып керттеләр, Гайсә исемен телгә алып һичнәрсә сөйләмәскә һәм һичкемне өйрәтмәскә әмер бирделәр. Әмма тегеләр: «Үзегез уйлап карагыз: Аллаһы сүзен тыңлауга караганда сезнең сүзне күбрәк тыңлау Аллаһы каршында дөрес булырмы икән? Күргән-ишеткәннәребез турында без сөйләми



булдыра алмыйбыз», – дип җавап бирделәр. Киңәшмәдәгеләр исә җәза бирерлек сәбәп таба алмыйча, кат-кат янап рәсүлләрне чыгарып җибәрделәр. Алар халыктан курка иделәр, чөнки гарип кешенең савыгуын күргән-ишеткән һәркем Аллаһыны данлый иде.

*Рәсүлләрнең эшләре 4:1–21*

# Иман хакына иң беренчеләрдән Эстефәннең корбан булуы

Рәсүлләрнең тәкъдиме буенча мәсихчеләр бердәмлеге, җиде хезмәтчене сайлап алып, имандашлар арасындагы фәкыйрьләрне һәм мохтаҗлыкка төшкәннәрне кайгыртуны шулар өстенә йөкләде. Әлеге вазифаны Изге Рух белән сугарылган, иман һәм кодрәт тулы Эстефәнгә йөкләделәр. Халык арасында ул бөек могҗизалар һәм галәмәтләр кылуы белән танылды. Мәсихчеләрнең дошманнары шушы эш-гамәлләре өчен Эстефәнне күрәлмадылар һәм җае чыккан саен аның белән бәхәскә керү ягын карадылар. Әмма дошманнары аның сүзләрендәге зирәклеккә каршы тора алмады, чөнки ни-нәрсә әйтергә аны Изге Рух Үзе өйрәтә иде. Шуннан алар, Эстефәннең Аллаһыга һәм Мусага каршы көфер сүз сөйләгәнен ишеттек, дип аңа яла ягар өчен кайбер адәмнәрне котыртып куйдылар. Халык арасында шул рәвешле коткы тараткannнан соң, алар, Эстефәнне тотып алып, Югары киңәшмә каршына китерделәр. Гаепләүчеләр аңа нахак бәлаләр тага башлагач, Киңәшмәдә утыручыларның һәммәсе Эстефәннең йөзе фәрештәнекенә тиң булуын абайлап алды.

Гаепләүчеләрне тыңлап бетергәннән соң баш рухани Эстефәннән: «Бу сүзләр дөресме?» – дип сорады. Аңа җавап итеп Эстефән Изге Язмадагы сүзләрне китерде. Эстефәннең фаш итеп сөйләгән сүзләрен тыңлаган чакта Киңәшмәдә утыручылар, ачудан тешләрен шыкырдатып, үзләрен кая куярга белмәделәр.

Изге Рух белән сугарылган Эстефән исә, күзләрен күккә текәп, Аллаһының шөһрәтен һәм Аның уң ягында торган Гайсәне күрде. «Менә, мин ачылып киткән күкләрне һәм Аллаһының уң ягында басып торучы Адәм Углын күрәм», – диде ул. Әлеге сүзләрне ишетүгә киңәшмәдәгеләр Эстефәннең әйткәннәрен тыңламас өчен колакларын томаладылар да кычкыра-кычкыра дәррәү аңа ташландылар һәм, аны шәһәр читенә өстерәп алып чыгып, таш ата башладылар. Тегеләр таш аткан вакытта Эстефән: «Хакимем Гайсә, рухымны кабул ит! – дип дога кылуында булды, аннары тезләренә егылды һәм, – Хакимем! Бу гөнаһны алар өстенә салма!» – дип кычкырды да җан бирде.

*Рәсүлләрнең эшләре 6:2–15; 7:1–60*



## Филип һәм Хәбәшстан түрәсе

Эстефәннең газаплы үлеменнән соң Иерусалимдәге иман итүчеләр бердәмлеген эзәрлекләү башлангач, рәсүлләрдән гайре барысы да Яһүдиянең һәм Самареянең төрле урыннарына таралып бетте. Рәсүлләр исә халыкка Аллаһы сүзен сөйләүләрен дәвам иттеләр.

Бервакыт шулай Раббы фәрештәсе иман итүчеләр бердәмлеге башлыгының ярдәмчесе Филипкә: «Җыенып чык та көн үзәгендә Иерусалимнән Газага илтә торган юлда бул», – диде. Филип, җыенып, юлга чыкты. Нәкъ шул вакытта юл буйлап бер хәбәши – Аллаһыга табыну өчен Иерусалимгә килгән дәрәҗәле бер түрә, Хәбәшстан патшабикәсенең хәзинә сакчысы үз арбасында Ишагыйя пәйгамбәр китабын укып үз иленә кайтып бара иде.

«Арба янына кил дә рәттән атла», – диде шулчак Филипкә Изге Рух. Филип якынрак килде һәм, хәбәшинең Ишагыйя пәйгамбәр китабын укып баруын ишетеп, аңардан: «Укыганыңны аңлыйсыңмы соң?» – дип сорады. «Берәрсе төшендермәсә, ничек аңлыйм инде?» – дип җавап кайтарды теге һәм Филипкә үз янына утырырга тәкъдим итте. Хәбәши адәм Язманың шушы урынын укый иде: «Аны, сарык сыман, чалырга алып бардылар; йон кыркучы алдында ул, бәрән сыман, авызын да ачмады. Аны кимсеттеләр, гадел хөкемнән мәхрүм иттеләр. Аның нәселе турында кем сөйли алыр? – Җир йөзендәге гомере өзелде бит!»

«Зинһар, әйт әле, пәйгамбәр монда кем турында сөйли? Үзе турындамы, әллә башка берәү турындамы?» – дип сорады Филиптән түрә. Шуннан Филип, Язманың шушы урыныннан аңлата башлап, хәбәшигә Гайсә турындагы Яхшы хәбәрне сөйләп бирде.

Бара торгач, алар су буена килеп җиттеләр. «Менә бит, су да бар – чуму йоласын үтәргә миңа нәрсә комачаулый?» – диде хәбәши. «Чын күңелдән ышансаң, мөмкин», – дип җавап бирде Филип. «Гайсә Мәсихнең Аллаһы Углы икәненә ышанам», – диде теге һәм арбаны туктатырга боерды. Алар икесе дә суга керделәр, һәм Филип аны суга чумдырып алды. Судан чыккач, Раббы фәрештәсе Филипне алып китте, һәм хәбәши аны бүтән күрмәде, шатлана-шатлана юлын дәвам итте.

*Рәсүлләрнең эшләре 8:26–39*



## Шаулның иман итүчеләр бердәмлеген эзәрлекләве

Иерусалимдәге иман итүчеләр бердәмлеген эзәрлекләүчеләр арасында Шаул исемле яшь бер фарисей бар иде. Бик яхшы дини белем алган, Изге Язманы әйбәт белгән әлеге Шаул ата-бабалардан килгән йолаларны, бөтен гореф-гадәтләрне һәм Канун кушканнарны һәрчак төгәл үтәве белән аерылып тора һәм башкалардан да шуны таләп итә иде. Әмма чын дөреслекне белмәгәнгә күрә, Гайсәнең Мәсих икәнлегенә ул ышанмый һәм Аның тарафдарларын динне бозучылар дип саный иде. Ул, Гайсә Мәсих шәкертләренең өйләренә бәреп кереп, аларны бәйләп зинданнарга ташлады, әллә күпме кешене газапка, үлемгә дучар итте.

Бердәмлек башлыгы ярдәмчесе Эстефәнне таш атып кыйнаган чакта Шаул, әлеге җәзага үзенең мөнәсәбәтен белдергән сыман, залимнәрнең киемнәрен саклап торды. Шаул бәгырьсез бәндә түгел иде, әмма «гадел хөкем кылына» дигән фикер аңа какшамас ышаныч бирә иде.

«Динне бозучы» әлеге тәгълиматның инде таралып өлгерүен һәм Дәмәшкънең үзенә күрә бер үзәккә әйләнүен белгәннән соң, Шаул шунда барырга карар кылды. Раббы шәкертләренә карата йөрәгендә нәфрәт кайнаган Шаул, олуг руханига барып, Дәмәшкъ яһүдиләренең гыйбадәтханәләренә тәгаенләнгән хат яздырып алды. Әлеге хат мәсихчеләрне кулга алу һәм җәзага тарту өчен богаулап Иерусалимгә алып кайту хокукы бирергә тиеш иде.

*Рәсүлләрнең эшләре 7:58; 8:1, 3; 9:1–2*



## Раббының Шаулга күренүе

Юлда барганда, инде Дәмәшкъ каласына якынлашып килгәндә, кинәт Шаулның тирә-ягы күктән төшкән яктылыктан балкып китте, һәм ул куркудан җиргә егылды. Шулвакыт аңа: «Шаул, Шаул! Нигә син Мине эзәрлеклисең?» – дигән тавыш килеп ирешә. «Әфәндем, Син кем?» – дип сорады Шаул. «Син эзәрлекләгән Гайсә Мин, – дип җавап бирде тавыш. – Тор да шәһәргә бар. Анда сиңа нәрсә эшләргә кирәклеген әйтерләр».

Шаулның юлдашлары барган уңайга катып калдылар – алар әлеге тавышны ишеттеләр, ләкин һичкемне күрмәделәр. Шаул аягына торып басты; күзләре ачык булса да, бернәрсә күрә алмады, чөнки күктән иңгән яктылык аны сукырайткан иде. Шуңа күрә Дәмәшкъкә юлдашлары аны җитәкләп алып килделәр.

Дәмәшкъ каласында Гайсәнең Һанани исемле бик тә тугрылыклы тарафдары бар иде. Илаһи күренештә Хуҗа-Хаким аңа болай дип әйтте: «Һанани! Тор да, «Туры» дип аталган урамга барып, Яһүдә яшәгән йортка кер һәм тумышы белән Тарстан булган Шаул исемле адәмне сора. Хәзерге мәлдә ул дога кылып утыра. Аңа илаһи күренеш булды: әлеге күренештә Һанани исемле берәү, Шаулның күзләре янә күрә башласын өчен, аның янына килде дә куллары белән орынды». «Хакимем! Мин ул адәмнең Иерусалимдә Синең изгеләреңә күрсәткән явызлыклары турында күп кешедән ишеттем; бирегә дә ул, баш руханилардан вәкаләтнамә алып, Синең исемне телгә алучыларның һәммәсен кулга алыр өчен килгән», – диде Һанани. Әмма Хуҗа-Хаким аңа: «Бар, кузгал, чит халыкларга һәм патшаларга, шулай ук Исраил халкына исемемне танытыр өчен Мин аны Үземә корал итеп сайладым. Мин аңа исемем хакына күпме газаплар кичерергә тиешлеген күрсәтермен», – диде.

Шуннан Һанани Раббы кушкан урынга юнәлде. Йорт эченә аяк басуга ул, Шаулның башына кулларын куеп: «Шаул туган! Күзләрең күрә башласын һәм син Изге Рух белән сугарылсын өчен, юлыңда очраган Хакимебез Гайсә мине синең янга җибәрде», – диде. Шулчак Шаулның күзләрен томалап торган пәрдә сыман нәрсә төшкән кебек булды да, ул янә күрә башлады. Шул көнне үк Шаул суга чуму йоласын үтәп: «Гайсә – Аллаһы Углы», – дип яһүдиләрнең гыйбадәтханәләрендә сөйләп йөри башлады.

*Рәсүлләрнең эшләре 9:3–20*



## Шаулның Дәмәшкътән качуы

Шаулның сүзләрен ишеткән бар кеше хәйран калып: «Иерусалимдә Гайсә Мәсих исемен телгә алучыларны эзәрлекләп йөргән Шаул түгелме соң бу? Бирегә ул аларны кулга алыр һәм баш руханиларга тапшырыр өчен килгән иде кебек», – диде. Шаулның иманы исә көннән-көн ныгый барды; үзенең вәгазьләрендә ул, Гайсәнең Коткаручы Мәсих икәнлеген исбатлап йөреп, Дәмәшкътә яшәүче яһүдиләрне аптырашка салды.

Күпмедер вакытлар үткәннән соң яһүдиләр Шаулны үтерергә сүз куештылар. Шуңа күрә алар, Шаул Дәмәшкътән китәргә уйласа эләктереп алырга дип, шәһәр капкаларының бөтенесенә сакчылар куйдылар. Әмма Шаул аларның ниятен белеп алды да шәһәрдә калды. Төн җиткәч исә Гайсәнең шәкертләре аны, зур бер кәрзингә утыртып, шәһәр диварының тышкы ягына төшерделәр.

Дәмәшкътән китеп Иерусалимгә килгәч, Шаул шәкертләргә кушылырга тырышты. Әмма аның дөрестән дә Мәсих шәкерте булуына ышанмаганга, Шаул белән аралашырга барысы да курка иде. Шуннан рәсүлләрнең Барнаб исемлесе, Шаулны ияртеп, шәкертләр янына килде һәм юлда аның Хакимне күрүен, Хакимнең нәрсәләр әйтүен, Дәмәшкътә Шаулның Гайсә турында кыюлык белән вәгазьләвен сөйләп бирде. Шуннан соң рәсүлләр һәм Мәсихнең Бердәмлеге Шаулны туганыдай үз арасына кабул итте. Соңрак аны рәсүл Паул дип йөртә башладылар, һәм мәҗүси халыкларга Гайсә Мәсих хакында вәгазь сөйләү аның төп максатына әйләнде.

Рәсүл Паул төрле шәһәрләрдәге бердәмлекләргә бик күп хатлар язып җибәрде. Аларның берсендә рәсүл Паул болай диде: «Элек үзем өчен табыш дип санаган нәрсәләрнең Мәсих ярдәмендә хәзер файдасыз булуын аңладым. Алай гына да түгел, Хакимем Гайсә Мәсихне танып белүне бердәнбер кыйммәтле табыш дип, мин бар нәрсәдән баш тарттым, калган бар нәрсәне чүп-чар дип исәпли башладым. Минем хаклыгым Канунны үтәүгә түгел, ә бәлки Мәсихкә булган иманыма, Аллаһыдан килгән хаклыгыма нигезләнә».

*Рәсүлләрнең эшләре 9:21–28; Филиппуйлыларга хат 3:7–9*



## Яфу шәһәрендә яшәүче Табита исемле хатынның үледән терелүе

Урта диңгез буенда урнашкан, зур порты булган Яфу (Иоппия) шәһәрендә Гайсәнең шәкерте – яхшы эшләр кылучы, фәкыйрьләргә ярдәм итүче Табита исемле бер хатын яши иде. Әмма көннәрдән беркөнне ул авырып китте дә вафат булды. Аны юыпҗыеп түр бүлмәгә урнаштырдылар.

Лүддә шәһәре Яфуга якын булганлыктан, Петернең анда икәнен ишеткән шәкертләр, аның тизрәк килүен үтенеп, янына ике кеше җибәрделәр.

Петер алар белән Яфуга килгәч, аны түр бүлмәгә алып керделәр. Шунда җыелган тол хатыннар кайчандыр аларга Табита тегеп биргән күлмәкләрне, киемнәрне елый-елый Петергә күрсәтә башладылар. Бүлмәдәге кешеләрнең барысын чыгарып җибәргәч, Петер тезләнеп дога кылды да мәеткә таба борылып: «Табита, тор!» – диде. Хатын күзләрен ачты һәм, Петерне күреп, торып утырды. Кулын биреп, Петер аңа аякка басарга ярдәм итте, аннары иман итүчеләрне һәм тол хатыннарны чакырып кертеп аларга үледән терелгән Табитаны күрсәтте.

Бу хәл бөтен Яфу халкына билгеле булды, һәм күпләр Хаким Гайсәгә иман китерде. Петер исә Яфу каласындагы күнче Шимун йортында әле аннан соң да байтак көннәр яшәде.

*Рәсүлләрнең эшләре 9:36–43*



# Йөзбашы Көрнили

Гайсә Мәсих һәм Аның рәсүлләре яшәгән заманда Исраил җире генә түгел, ә бәлки Урта диңгез буендагы бөтен илләр Рим империясенә буйсынып, римлылар әлеге илләрдә үзләренең гаскәриләрен тота иде. Мәсәлән, Италия полкы дип аталган гаскәр Урта диңгез буендагы Кайсария портында урнашкан булып, шул полкта йөзбашы булып хезмәт итүче Көрнили исемле кеше бар иде. Ул үзе дә, аның бөтен гаиләсе дә бик диндар иде, алар Аллаһыны олылап һәм Аңардан куркып яшәүчеләрдән иде. Көрнили фәкыйрьләргә мул итеп хәер тарата һәм Аллаһыга ялварып өзлексез дога кыла иде. Бервакыт илаһи күренештә Көрнилигә Аллаһы фәрештәсе күренде. Фәрештә аның янына килеп: «Көрнили! Догаларыңны һәм биргән хәерләреңне корбанга санап, Аллаһы сине искә алды. Петер исемле Шимунны алып килергә Яфуга кешеләр җибәр. Ул синең үзеңне һәм гаиләңне коткарырга тиешле сүзләрне әйтер», – диде. Фәрештә киткәч, Көрнили, үзенең ике хезмәтчесен һәм шәхси йомышларын үтәүче диндар бер гаскәриен чакырып алды да, һәммәсен аңлатып, аларны Кайсариядән көньякта урнашкан Яфуга җибәрде.

Гаскәриләр, Яфуга килеп җитеп, Петерне юллап таптылар. Петер аларны өйгә чакырып кунак итте һәм үзендә төн кунарга калдырды, ә иртәгесен алар белән бергә Кайсариягә китеп барды. Көрнили исә, үзенең туган-тумачасын һәм якын дусларын җыеп, аларны көтеп тора иде. Җыелган кешеләргә мөрәҗәгать итеп Петер болай дип сүз башлады: «Хәзер мин чынлап та аңлыйм: Аллаһы кешеләрне тигез күрә. Аллаһыны олылаучыны һәм гадел эшләр кылучыны, кайсы гына халыктан булса да, Ул хуп күрә. Аллаһы, Гайсә Мәсих аша килүче тынычлык хакындагы Яхшы хәбәрне сөйләп, Исраил угылларына Үзенең сүзен ирештерде: Гайсә – һәммәбезнең Раббысы. Аның Яһүдиядә һәм Иерусалимдә кылган барлык эшләренә без шаһит. Аны хачка асып үтерделәр, ә өченче көндә Аллаһы Аны үледән терелтте. Гайсә ул – терeләрне һәм үлеләрне хөкем итәр өчен Аллаһы тарафыннан билгеләп куелган Зат. Ул безгә шул хакта халыкка сөйләргә һәм шаһитлык кылырга боерык бирде. Барча пәйгамбәрләр әйткәнчә, Аңа иман китергән һәрбер адәмнең гөнаһлары Аның исеме белән кичереләчәк».



Петер сөйләгән вәгазьдән соң Көрнили үзе дә, аның бөтен гаиләсе һәм барча дуслары да Аллаһы Углы Гайсә Мәсихкә иман китереп, Аның исеме белән суга чуму йоласын үтәделәр.

*Рәсүлләрнең эшләре 10*

## Фәрештәнең Петерне зинданнан азат итүе

Шул вакытларда Һируд патша иман итүчеләр бердәмлегендәге кайбер кешеләрне эзәрлекли башлады; Яхъяның бертуган кардәше Ягъкубны кылыч белән чабып үтертте. Бу эшнең яһүдиләргә ошавын күреп, Котылу бәйрәме узуга халык алдында җәзалау нияте белән рәсүл Петерне дә зинданга утыртты. Зинданда Петерне уналты гаскәри саклады. Ул сак астында ятканда, иман итүчеләр бердәмлеге аның өчен бик тырышып Аллаһыга дога кылды.

Һируд патша Петерне халык каршына чыгарыр алдыннан, ике богау белән богауланган рәсүл Петер төнлә ике гаскәри уртасында йоклап ята иде. Ә ишек янында сакта каравылчылар тора иде. Төн уртасында кинәт Петер янында Раббы фәрештәсе пәйда булып, бүлмә эче нурга тулды. Фәрештә: «Тор тизрәк!» – дип Петерне төртеп уятуга, богаулар үзеннән-үзе аның кулыннан шуып төште. «Өстеңә ки дә минем арттан атла», – диде аңа фәрештә. Петер, фәрештә кылган бу эшләрнең чынбарлыкта икәнен дә аңламыйча, аның артыннан китте. Илаһи күренештер бу, дип уйлады ул. Сакчыларның икесе яныннан да үтеп, шәһәргә чыга торган тимер капка төбенә килеп җиткәч, капка үзеннән-үзе ачылды да алар урамга чыктылар, һәм бер урам узуга, фәрештә кинәт юк булды.

Шунда Петер, исенә килеп: «Хәзер мин төгәл беләм: Раббы үзенең фәрештәсен җибәреп мине Һируд кулыннан һәм яһүдиләр күрергә теләгән җәзадан коткарды», – диде. Петер як-ягына каранып алды да Яхъяның әнисе Мәрьям яшәгән йортка таба юнәлде. Дога кылырга дип анда байтак халык җыелган иде. Алар янына кергәч Петер Раббының ничек итеп аны зинданнан чыгаруын сөйләп бирде.

*Рәсүлләрнең эшләре 12:1–17*



## Яхшы хәбәрне тарату максатыннан Паулның беренче сәфәре

Рәсүл Паул, үзенең вазифасына тугрылык саклап, мәҗүсиләр арасында Яхшы хәбәрне таратуын дәвам итте. Хаким Гайсә Мәсих әмер иткән, иман итүчеләр өчен бүгенге көндә дә әһәмиятен югалтмаган, «шулай итеп, барыгыз, Ата белән Угыл һәм Изге Рух хакына барча халыкларны суга чумдырып, Мин сезгә кушканнарны аларга да өйрәтегез» дигән боерыгын ул ихлас күңелдән башкаруында булды. Шул замандагы Рим империясенең кала һәм төбәкләре буйлап озак вакытларга сузылган сәфәренең өчесен дә Паул Антиухия шәһәреннән башлады.

Беренче сәфәргә Паул белән бергә рәсүл Барнаб та барды. Антиухиядән кораб аларны Кипр утравына алып килде. «Рәсүлләрнең эшләре» дигән китаптан белгәнебезчә, биредә, Кипрда, Аллаһының бөек хезмәтчесенә әйләнгән Шаулга Паул дигән латин исеме куштылар. Кипрдан соң алар яңадан Кече Асиягә әйләнеп кайттылар, аннары әле җәяүләп, әле ишәккә атланып Гәләтия төбәгенә килеп җиттеләр; шунда, Икүниунда, алар үзләренең вәгазьләрен башладылар, һәм җирле халыкның байтагы Раббыга иман китерде. Икүниуннан алар Лустра каласына юнәлделәр. Биредә Аллаһы, рәсүл Паул аша, аяклары гарип бер аксакны савыктырды. Бу хикмәтне күргәч анда яшәүче халык Паул белән Барнабны илаһлар дип уйлады, ә грек алласы Зевс гыйбадәтханәсенең каһине* алар хөрмәтенә корбан китерергә теләк белдерде. Әмма бу хакта ишеткәч рәсүлләр, өсләрендәге киемнәрен ертып: «Җәмәгать! Нәрсә эшлисез сез? – дип кычкыра-кычкыра халык арасына омтылдылар. – Без дә сезнең кебек үк кешеләр бит. Бу файдасыз илаһларыгыздан арынып, күкне һәм җирне, диңгезне һәм шундагы бар нәрсәне яраткан мәңге Тере Аллаһыга йөзегез белән борылсын өчен, без сезгә Яхшы хәбәр алып килдек. Әүвәлге заманнарда Аллаһы һәр халыкка үз юлыннан йөрергә ирек бирсә дә, яхшылыклар кылып, Үзен һаман күрсәтеп тора иде: вакытында күкләрдән яңгырын яудыра һәм мул уңыш өлгертә, безне ризык белән тәэмин итә һәм йөрәкләребезне куандыра иде».

Лустрада рәсүлләр үзләренең кыю вәгазьләрен дәвам иттеләр. Әмма Лустра каласына килгән кайбер яһүдиләр: «Аларның бер

* *Каһин* – мәҗүсиләрдә дин башлыгы.



генә хак сүзләре дә юк, һәммәсе ялган», – дип халыкны котырттылар. Паулны таш атып кыйнадылар, әмма Аллаһы аны саклап калды, һәм ул исән-имин юлын дәвам итте. Лустрадан соң ул Дерби шәһәренә юл тотты. Анда да Яхшы хәбәрне вәгазьләде, һәм байтак кеше Раббыга иман китерде. Дербидән соң Паул белән Барнаб, язмышларын Аллаһы мәрхәмәтенә тапшырып, Антиухия каласына – кайчандыр юлга кузгалган урыннарына әйләнеп кайттылар. Үзләренә йөкләнгән эшне башкарып кайтканнан соң рәсүлләр, иман итүчеләр бердәмлеген җыеп, Аллаһының үзләре ашаниләр эшләвен, Аның мәҗүси халыкларга иман ишекләрен ачуын – һәммәсен бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр.

Рәсүл Паулның Яхшы хәбәрне тарату максатыннан кылынган беренче сәфәре өч елга якын дәвам итте.

*Маттай 28:19–20; Рәсүлләрнең эшләре 13; 14*

## Яхшы хәбәрне тарату максатыннан Паулның икенче сәфәре

Икенче сәфәрендә рәсүл Паулны Гайсәгә иман итүче яһүди Силас озата йөрде. Антиухиядән чыгып китеп, алар яңадан Дерби һәм Лустра калаларына (берничә ел элек Паулны Лустрада ташлар атып кыйнап аздан гына үтерми калганнар иде) юл тоттылар. Лустрада Паул соңрак үзенең тугрылыклы ярдәмчесенә әйләнгән Тимутәй атлы егетне очратты.

Күпмедер вакыттан соң алар Эгей диңгезенең яр буенда, Асия өлкәсендә урнашкан Троас шәһәренә килеп җиттеләр. Биредә Паулга төнлә шундый бер илаһи күренеш булды: македунияле берәү аның каршына килеп басты да: «Македуниягә килеп безгә ярдәм ит», – дип ялварып сорады. «Рәсүлләрнең эшләре» дигән китапны язган инҗилче Лүк бу хакта болай дип бәян итә: «Әлеге илаһи күренештән соң без, Яхшы хәбәрне сөйләргә Раббы безне шунда чакыра дигән нәтиҗәгә килеп, шундук Македуниягә китәргә булдык». Лүк үзе, күрәсең, Паулга Троас каласында килеп кушылган. Македуния исә, Грециянең төньяк-көнчыгышында урнашкан булып, Рим хакимлегенә буйсынучы бер төбәк иде. Корабка утырып Эгей диңгезен кичеп чykканнан соң, алар Филиппуй шәһәренә килеп җиттеләр. Ихтимал, нәкъ менә Филиппуй шәһәрендә, Аурупада беренчеләрдән булып, Гайсәгә иман итүчеләр бердәмлеге оешкан булса кирәк. Филиппуйда Паул белән Силасны зинданга ябалар, әмма бу хакта сез икенче хикәядә укырсыз. Филиппуй шәһәреннән соң Паул Эгей диңгезе буена, зур порты булган Тессалуникә каласына килде. Биредә шактый күп греклар, шулай ук яһүдиләрнең кайберләре Гайсәгә иман китерде. Әмма яһүдиләр арасында Паул белән Силасны дошман күрүчеләр дә байтак иде; алар, халыкны котыртып, шәһәрдә чуалыш китереп чыгардылар, һәм Паул белән Силас Беруяга китәргә мәҗбүр булды. Беруядан соң Паул Грециянең башкаласы Афинага юл тотты. Ул заманнарда Греция Рим хакимиятенә буйсынып, аның исемен Ахая дип үзгәрткәннәр иде. Афинада Паул фәлсәфәчеләргә һәм гади халыкка Аллаһы сүзе турындагы вәгазьләрен дәвам итте (бу турыда без алдагы хикәяләрнең берсендә укырбыз). Афинадан соң ул Рим империясендәге иң зур һәм иң мәртәбәле шәһәрләрдән саналган Көринт каласына юнәлде. Биредә Паул ел ярым яшәде; шул вакыт эчендә калада Гайсәгә иман



итүчеләрнең зур бердәмлеге оешып китте. Көринттән соң Паул диңгез юлы буйлап Кече Асиягә әйләнеп кайтты, аннары шактый зур Эфес каласына юнәлде. Шуннан соң, кабат юлын дәвам итеп, Иерусалимгә килде, аннан Антиухиягә әйләнеп кайтты.

Паулның икенче сәфәре дә өч ел чамасы дәвам итте. Шул вакыт эчендә Паул меңнәрчә чакрым юл үтте.

*Рәсүлләрнең эшләре 15:36 – 18:22*

## Паул белән Силас тоткынлыкта

Бервакыт рәсүл Паул үзенең юлдашы Силас белән римлыларның шәһәр-колониясе Филиппуйга килде. Анда алар, Гайсә Мәсих исеменнән боерып, җен кагылган, күрәзәчелек рухына ия булган бер хезмәтче кызны савыктырдылар. Әлеге кыз, күрәзәчелек итеп, үзенең хуҗаларына зур табыш китерә икән. Кызның хуҗалары, табыш чыганагы юкка чыкканны аңлап, Паул белән Силасны тотып алдылар да мәйданга – шәһәр башлыклары янына алып килделәр. «Бу кешеләр – яһүдиләр, – диде алар. – Алар безгә, римлыларга, кабул итәргә дә, башкарырга да ярамаган йолаларны вәгазьләп, шәһәрдә тынычсызлык тудыра». Халык та Паул белән Силаска каршы чыккан кешеләргә кушылды. Шуннан гаскәр башлыклары, рәсүлләрнең киемнәрен йолкып төшерергә һәм аларны таяк белән суктырырга боерды. Кыйнаганнан соң, аларны зинданга ташлап, каравылчыга тоткыннарны бик нык-лап сакларга боердылар. Шушындый әмер алгач, каравылчы, рәсүлләрне зинданның иң эчке бүлмәсенә ябып, аякларына агач богаулар салды. Әмма Паул белән Силас әллә ни кайгырмадылар: төн урталарында дога кылдылар, Аллаһыны мактап мәдхияләр җырладылар, ә башка тоткыннар аларны тыңлап утырды.

Кинәт бик нык итеп җир тетрәде, зинданның хәтта нигезе селкенеп куйды. Шундук барлык ишекләр ачылып китте, һәркайсының богаулары ишелеп төште. Зиндан каравылчысы йокысыннан уянды да, ишекләрнең ачык булуын күреп, тоткыннар качкандыр, дип уйлады һәм үзенә кул салмакчы булды. Әмма Паул аңа: «Харап итмә үзеңне, без барыбыз да монда!» – дип кычкырды. Каравылчы, куркуыннан дер калтырап, Паул белән Силасның аягына егылды. «Әфәнделәрем! Котылу өчен миңа нәрсә эшләргә кирәк?» – дип сорады ул алардан. «Хаким Гайсә Мәсихкә иман китер, шул чагында үзең дә котылырсың, өйдәгеләрең дә котылыр», – дип җавап бирде аңа Паул белән Силас. Шуннан каравылчы, аларны зинданнан алып чыгып, җәрәхәтләрен юды, аннары үзе дә, өендәге якыннары да суга чуму йоласын үтәде.

Паул белән Силасны зинданга япкан шәһәр идарәчеләре, икенче көнне төрмә каравылчысы янына үзләренең ярдәмчеләрен җибәреп, әлеге ике тоткынны азат итәргә куштылар. Әмма Паул аларга: «Безне, Рим гражданнарын, халык алдында хөкемсез-нисез кыйнадылар,



зинданга яптылар, ә хәзер яшерен рәвештә чыгарырга телиләрме? Юк! Килсеннәр дә безне үзләре чыгарсыннар», – диде. Ярдәмчеләр әлеге сүзләрне шәһәр идарәчеләренә җиткерделәр; тегеләр исә, рәсүлләрнең Рим гражданнары икәнен ишеткәч, курка калдылар һәм яннарына килеп алардан гафу үтенделәр, аннары, зинданнан чыгарып, Паул белән Силасның шәһәрдән китүен сорадылар.

*Рәсүлләрнең эшләре 16:16–39*

## Паул Афинада

Үзенең икенче сәфәренә чыккач Паул, инде әйткәнебезчә, Афинага килде. Афина каласы, үз вакытында дөнья мәдәниятенең үзәге саналып, Сократ, Платон кебек мәшһүр фәлсәфәчеләрнең һәм башка акыл ияләренең туган җире иде. Биредә пот-сыннарның күплеген күреп Паулның җаны әрнеде. Гыйбадәтханәдә ул яһүдиләр һәм Аллаһыны олылаучы башка кешеләр белән әңгәмә корып утырды, шулай ук һәр көн базар мәйданында үтеп-сүтеп йөрүчеләр белән сөйләште. Шулай бер көнне кайбер фәлсәфәчеләр – эпикурчылар һәм стоиклар – аның белән бәхәскә керделәр. Паул аларга Гайсә һәм Аның үледән терелүе турындагы Яхшы хәбәрне җиткергәч, фәлсәфәчеләрнең кайберләре: «Бу тел бистәсе нәрсә әйтергә тели соң?» – дисә, икенчеләре: «Чит илаһлар турында вәгазь сөйли ахры», – диде.

Алар Паулны үзләре белән Арейпәг* киңәшмәсенә алып килеп: «Син вәгазьли торган яңа тәгълимат турында күбрәк белергә телибез. Безгә сөйләгән сәер сүзләреңнең мәгънәсенә төшендер», – диделәр. Паул Арейпәг киңәшмәсе алдына чыгып басты. «Афиналылар! Сез, күрәсең, кайсы яктан карасаң да бик диндар халык, – диде ул. – Сезнең изге урыннарны игътибар белән карап йөргәндә мин „Билгесез илаһка“ дип язылган мәзбәх күрдем. Мин сезгә үзегез табына торган әнә шул билгесез Аллаһы турында вәгазь сөйләмәкчемен. Дөньяны һәм андагы һәммә нәрсәне бар иткән Аллаһы, күкнең һәм җирнең Хакиме, кеше кулы төзегән гыйбадәтханәләрдә яшәми һәм кешеләрнең Аңа хезмәт итүенә мохтаҗ түгел. Ул Үзе һәркемгә тормыш, сулыш һәм бар нәрсәне бирә. Бер кешедән барлык халыкларны яратып, Ул аларга бөтен җир йөзенә таралып яшәргә мөмкинлек бирде, аларның яшәү вакытын һәм гомер итәсе җирләренең чикләрен алдан билгеләп куйды. Ул моны кешеләр Аллаһыны эзләсеннәр һәм, Аны тоемлап, Аңа юл тапмаслармы икән дип эшләде; ә бит Ул безнең беребездән дә ерак түгел. Сезнең кайбер шагыйрьләрегез „без дә Аның нәселеннән“ дип әйткән кебек, „без Аның ярдәме белән яшибез, хәрәкәт итәбез, көн күрәбез“. Әгәр без Аллаһы нәселеннән икән, Аллаһы – осталар кулы һәм хыялы белән иҗат ителгән алтын, көмеш яки таш сынга

* *Арейпәг* – Афина каласы урнашкан калкулыкларның берсе. Арейпәгтә җыела торган хөкем итү шурасын шулай дип атаганнар.



охшаган, дип уйларга тиеш түгелбез. Шул рәвешле, хакыйкатьне белмичә яшәгән заманнарны Аллаһы гаеп итмәсә дә, хәзер Ул бөтен җирдәге бар кешегә тәүбәгә килергә боера. Галәм өчен гадел хөкем көнен Аллаһы билгеләде инде, хөкемне Ул Үзе билгеләгән Зат аша башкарыр. Шул Затны үледән терелтеп, Аллаһы моны һәркемгә исбат итте».

*Рәсүлләрнең эшләре 17:16–31*

## Яхшы хәбәрне тарату максатыннан Паулның өченче сәфәре

Күпмедер вакытлар үтүгә Паул, үзенең өченче сәфәренә кузгалып, Антиухиядән төньяк тарафка юл алды. Фрүгия төбәген үткәннән соң, Эгей диңгезенең Асия ярлары буенда урнашкан Эфес каласына килеп җитте. Порты булган, чирек миллион халык яшәгән зур шәһәр иде бу. Паул биредә ике елга якын яшәде. Шул рәвешле, Асиянең* бөтен төбәкләрендә яһүдиләр дә, яһүди булмаганнар да Гайсә Мәсих турындагы вәгазьне ишеттеләр. Аллаһы исә Паулның куллары белән искитәрлек кодрәтле эшләр кылды.

Эфес каласында алиһә Артемида хөрмәтенә мәрмәрдән салынган мәһабәт гыйбадәтханә җир йөзендәге җиде могҗизаның берсе саналып, әлеге бина 220 ел дәвамында төзелә. Эфес шәһәрендәге көмешчеләр һәм һөнәрчеләр көмештән шушы Артемида гыйбадәтханәсенең кечерәйтелгән өлгесен ясап кәсеп итәләр иде. Алиһә Артемидага табынучыларның күбесе мәңге тере Аллаһыга иман китерә башлау сәбәпле, әлеге осталар Паул вә аның юлдашларына каршы шәһәрдә зур чуалыш кузгаттылар, һәм Паул Эфес каласыннан китәргә мәҗбүр була. Шуннан ул, корабта Эгей диңгезен кичеп, әүвәле үзе вәгазьләп йөргән Македуния һәм Грециянең кайбер төбәкләрендә, шул исәптән Филиппуй белән Көринттә туктала. Шуннан Асиягә әйләнеп кайта һәм Троаста кабат үзенең вәгазьләрен дәвам итә. Троастан соң ул, яңадан сәфәргә кузгалып, Ассуска килеп җитә, аннары корабта Митулини шәһәренә, Сам утравына һәм Милит каласына сугыла. Милиттә Паул, Эфескә кешеләр җибәреп, хушлашыр өчен бердәмлектәге өлкәннәрне чакырта, чөнки ул алар белән башкача күрешмәячәген белә иде. Аннары ул, Көс һәм Родос утравындагы, шулай ук Кече Асиядәге Патара һәм Сур портлары аша узып, Пытулемаис шәһәренә килеп туктала. Әлеге каладан соң Паул юлын җәяүләп дәвам итә һәм, Кайсарияне үтеп, Иерусалим тарафына юнәлә. Иерусалимгә килеп җиткәч исә Паулны кулга алалар. Паулның өченче сәфәре өч ел – Гайсә туган вакыттан санап 54 нче елдан 57 нче елга кадәр – дәвам итә.

Рәсүл Паулның әлеге сәяхәтләре гади бер сәфәр кылу түгел иде. Гайсә Мәсих турында Яхшы хәбәр таратып йөргәндә Паулга

---

* *Асия* – ул заманнарда бүгенге Кече Асиянең бер өлешен генә Асия дип атаганнар.



байтак кыенлыклар кичерергә туры килә. Бу хакта соңыннан Паул үзе болай дип яза: «…мин һаман хезмәттә булдым, зинданнардан башым чыкмады, күп тапкырлар кыйналдым һәм күп мәртәбәләр үлем хәлендә булдым; яһүдиләр мине биш тапкыр – һәрберсендә утыз тугызар мәртәбә камчы белән суктырдылар; мине өч мәртәбә таяк белән кыйнадылар, бер тапкыр таш атып үтерергә теләделәр; өч мәртәбә кораб һәлакәтенә очрадым, бер төн һәм бер көн ачык диңгездә үткәрдем; күп мәртәбәләр ерак җирләргә сәфәр кылдым; елгалар кичкәндә хәтәр хәлләргә юлыктым; юлбасарлар һөҗүменә дучар булдым; ыругдашларымнан һәм мәҗүсиләрдән миңа куркыныч янады; шәһәрләрдә, чүл сахраларында, диңгезләрдә, ялган имандашлар арасында мине хәвеф сагалады…»

*Рәсүлләрнең эшләре 18:23–21:34; II Көринтлеләргә 11:23–26*

## Сихерчелек – зур гөнаһ

Аллаһы Үз халкын сихерчелек, багучылык, күз буу яки әфсен белән шөгыльләнүдән катгый рәвештә тыйганны, «күрәзәлек итмәгез, сихер белән шөгыльләнмәгез» *(Левиләр 19:26)* дигән әмерне бозган очракта үлем җәзасына тартырга боерганны без инде Тәүрат китабыннан укып беләбез. «Сезнең арада улын яисә кызын корбан итеп уттан үткәрүче, күрәзәче, фалчы, багучы, сихерче, әфсен укучы, әрвахларның рухын чакыручы, тылсымчы һәм үләләрнең рухы белән сөйләшүче булырга тиеш түгел. Раббы каршында мондый эшләрне эшләүче һәркем җирәнгеч, һәм шул җирәнгеч эшләр өчен Раббы Аллагыз аларны сезнең күз алдыгыздан сөрер» *(Канун 18:10–12)*. «Әрвахларның рухын чакыручы, сихерче ир-ат яки хатын-кыз үлем җәзасына тартылырга тиеш – аларны таш атып үтерегез; үлемнәрендә алар үзләре гаепле» *(Левиләр 20:27)*.

Рәсүл Паулның өченче сәфәрендә, Эфес каласында, аның куллары белән Аллаһы искитәрлек кодрәтле эшләр кылды: Паул орынган кулъяулыкларны, аның эш алъяпкычын авыру адәмнәр өстенә салганда, хасталар чирдән савыга, алардан явыз рухлар чыгып китә иде. Кайбер ырымчы илгизәр яһүдиләр дә, кешеләрдән явыз рухларны куып чыгармакчы булып: «Мин сезгә Паул вәгазьләгән Гайсә исеменнән боерам», – дип, Хаким Гайсәнең исемен кулланырга тырышалар иде. Мәсәлән, яһүдиләрдән булган Эскевә исемле баш руханиның җиде углы да шулай эшләде. Әмма бервакыт явыз рух алардан: «Гайсәне беләм, Паул да миңа таныш, ә сез кемнәр?» – дип сорады. Шулчак явыз рух иялләнгән кеше, агай-энеләргә ташланып, аларны шундый итеп кыйнады ки, тегеләр ул йорттан киемнәре ертылган, яраланган хәлдә чыгып качтылар. Бу турыда Эфестә яшәүче яһүдиләргә һәм грекларга мәгълүм булгач, бар кеше куркуга төште, һәм Хаким Гайсәнең исеме тагын да ныграк ихтирам ителә башлады. Иманга килгәннәрнең күпчелеге үзләре кылган начар эшләрне танып сөйләде, ә сихерчелек белән шөгыльләнүчеләрнең күбесе бар халык алдында үзләренең сихер китапларын җыеп утка салды.



Санап карагач, яндырылган китапларның бәясе илле мең көмеш тәңкә* булды. Шулай итеп, Раббы сүзенең кодрәте һәм тәэсире һаман арта барды.

*Рәсүлләрнең эшләре 19:11–20*

* *Көмеш тәңкә* – ялланып эшләүче кешенең бер көнлек хезмәт хакы.

## Паулның Эфес бердәмлегендәге өлкәннәр белән хушлашуы

Эфес бердәмлегенең җитәкчеләре Паул белән хушлашырга Милит шәһәренә килгәч, ул аларга болай диде: «Асия өлкәсенә килгән беренче көнемнән бирле мин һаман сезнең белән булдым. Яһүдиләрнең явыз ниятләре аркасында килеп туган сынауларга карамастан зур күндәмлек күрсәтеп, күз яшьләремне түгә-түгә Хуҗа-Хакимебезгә хезмәт иттем. Сезгә файдалы булырдай бер нәрсәне дә әйтми калдырмадым, сезне халык алдында да, өйдән-өйгә йөреп тә өйрәттем. Тәүбә итеп Аллаһыга таба борылуның һәм Хакимебез Гайсәгә инануның кирәклеге турында яһүдиләргә дә, грекларга да үтемле итеп аңлаттым. Ә хәзер, Изге Рухның ихтыярына буйсынып, Иерусалимгә барам, Анда мине нәрсә көтәдер – белмим. Фәкать шуны беләм: һәр шәһәрдә мине богаулар һәм хәсрәт көтә. Изге Рух шуны раслый. Ләкин минем өчен үз тормышымның кадере юк, тик алган юлымны ахырга кадәр үтәргә һәм Хакимебез Гайсәдән кабул иткән хезмәтне – Аллаһының мәрхәмәте турындагы Яхшы хәбәрне тарату вазифасын төгәлләргә телим. Миңа хәзер шул билгеле: арагызда йөреп, Аллаһы Патшалыгын вәгазьләвемне ишеткән сезләр башкача мине күрмәссез. Мин киткәннән соң сезнең янга көтүне аямаган ерткыч бүреләр киләсен беләм. Иман тотучыларны үзләренә ияртү өчен сезнең арада да хакыйкатьне бозып сөйләүчеләр табылыр. Хәзер сезне Аллаһы кулына һәм Аның мәрхәмәт тулы сүзенә тапшырам. Аның сүзе сезне тагын да ныгыта һәм изге халыкка вәгъдә ителгәнне бирә ала. Мин һичкемнән көмеш тә, алтын да, кием-салым да көтмәдем. Үзегез беләсез, менә шушы кулларым белән эшләп тапканым үземнең һәм янымдагыларның ихтыяҗын канәгатьләндерде. Хакимебез Гайсәнең „алуга караганда бирүдә бәхет күбрәк“ дигән сүзләрен истә тотып, тырышлык куеп мохтаҗларга ярдәм итәргә кирәклеген мин сезгә һәр эштә күрсәттем». Сөйләп бетергәннән соң, ул аларның барысы белән бергә тезләнеп дога кылды. Һәммәсе күз яшьләре агызып Паулны кочаклап үбә башлады. Паулның «мине бүтән күрмәссез инде» дигән сүзләре аларны аеруча кайгыга салган иде. Шуннан аны корабка кадәр озата киттеләр.

*Рәсүлләрнең эшләре 20:17–38*



## Паул идарәче Фисте алдында

Иерусалимдә кулга алганнан соң, Паулны икенче көнне Югары киңәшмә алдына кертеп бастырдылар. Хөкем барышында рәсүлнең сүзләреннән соң яһүдиләр ызгышып киттеләр дә, Паулны өзгәләп ташларлар дип курка калган гаскәриләр башлыгы, аны кешеләр арасыннан алып, кирмәнгә* илтергә гаскәриләргә әмер бирде.

Шул ук төнне Паул каршында Хуҗа-Хаким пәйда булып: «Нык бул, Паул! Иерусалимдә Минем турыда ничек шаһитлык биргән булсаң, Римда да шулай шаһитлык бирергә тиешсең», – диде. Көн тууга, кайбер яһүдиләр бергә җыелып явыз ният кордылар – Паулны үтергәнчегә кадәр ашамаска-эчмәскә сүз бирделәр. Ант итүчеләрнең саны кырыктан артык иде. Югары киңәшмә утырышында Паулны коткарып калган гаскәриләр башлыгы бу хакта белгәннән соң ике йөз җәяүледән, җитмеш атлыдан һәм ике йөз укчыдан торган сак астында Паулны Кайсариягә озатты. Ул заманнарда Яһүдиядәге Рим идарәчеләре Кайсариядә яши иде. Кайсариядә Паул Рим идарәчесе Филикес каршында җавап тотты. Паулга каршы булган бөтен дәлилләрне тыңлап бетергәннән соң, Филикес аның һичнинди гаеп эшен тапмады, ләкин шулай да аны ике ел сак астында тотарга әмер бирде.

Ике ел вакыт узды, идарәче Филикес урынына Порки-Фисте билгеләнде. Берничә көн үтүгә, Фистене тәбрикләргә дип яһүдиләр патшасы Әгрип үзенең хатыны Берники белән Кайсариягә килде. Фисте исә Паулның нотыгын алар да ишетерлек итеп җайлады. Әгрип һәм Берники үзләре белән хәрби җитәкчеләрне, күренекле шәхесләрне ияртеп тантаналы рәвештә утырышлар бүлмәсенә кергәч, Паулны алып килделәр. Ул үзенең тормыш юлы, Гайсәнең хезмәте, ничек итеп Аңа иман китерүе турында сөйләде: «Аллаһыдан ярдәм алып, мин бүген дә һәммәсенә – олыларга да, кечеләргә дә шаһитлык бирәм: Мәсихнең газап чигәргә тиешлеген һәм беренче булып үледән терeләчәген, яһүдиләргә дә, мәҗүсиләргә дә яктылык турындагы хәбәрне игълан итәчәген сөйлим».

Паул үзен шулай дип яклаганда, Фисте аңа: «Паул, син акылдан шашкансың! Зур гыйлемлек сине акылдан яздыра», – дип кычкырып җибәрде. «Юк, мөхтәрәм Фисте, – дип җавап бирде

---

* Кирмән – русчасы: крепость.



Паул, – мин үз акылымда һәм хак дөресен сөйлим. Бүген мине тыңлаган һәркемнең минем кебек, тик богаусыз булуын сорап Аллаһыга дога кылам».

*Рәсүлләрнең эшләре 21, 23 – 26*

## Паулны Римга озату

Бар вә бер булган Аллаһы һәм Коткаручы Гайсә Мәсих турында шаһитлык биргән өчен рәсүл Паулны зинданга яптылар. Үзенең яман эш кылмавын белгәнгә күрә, Паул кайсарның хөкем итүен таләп итте: Рим гражданы буларак мондый таләп куярга аның хакы бар иде. Шул сәбәпле, Паулны каравыллауны йөзбашы Юлигә тапшырып, аны башка тоткыннар белән бергә корабка утыртып Римга озаттылар.

Диңгездә барганда бик көчле җил кузгалып, дулкыннар корабны үз уңаена агызып алып китте. Өченче көн дигәндә кешеләр корабтагы бөтен йөкне диңгезгә ыргытып бетерделәр. Давыл озакка сузылды, һәм кешеләрдә котылуга булган соңгы өмет юкка чыкты. Корабтагы кешеләр байтактан бирле берни ашамаганга, Паул аларга мөрәҗәгать итеп болай диде: «Җәмәгать! Күңелегезне төшермәгез, чөнки сезнең берегез дә һәлак булмаячак, кораб кына җимереләчәк. Мин – Аллаһы кешесе һәм Аңа хезмәт итәм. Үткән төндә миңа Аллаһы фәрештәсе күренеп: „Курыкма, Паул! Син кайсар каршына барып басарга тиешсең, һәм Аллаһы юлдашларыңның барысына да тормыш бүләк итә“, – диде. Шулай булгач, җәмәгать, күңелегезне төшермәгез! Мин Аллаһыга ианнам – бөтенесе дә Ул әйткәнчә булыр. Без, шәт, берәр утрауга килеп чыгарбыз».

Ундүртенче көнне диңгезчеләр сөзәк яры булган бер култыкны күреп алганнан соң корабны шунда юнәлтергә карар кылдылар. Якорьларны һәм кече җилкәнне күтәреп, ярга таба юл алуга, һич көтмәгәндә корабның борыны комга утырды да хәрәкәтсез калды, ә койрыгы килеп-килеп бәрелгән дулкыннардан җимерелә башлады. Йөзбашы Юли йөзә белгәннәргә суга сикерергә һәм ярга чыгарга боерды, башкаларга исә такта кисәкләренә тотынып йөзәргә кушты. Шулай итеп, корабтагы ике йөз җитмеш алты кешенең барысы да исән-имин ярга чыгып җитте. Утрау халкы аларга гадәттән тыш кунакчыллык күрсәтте. Раббы анда рәсүл Паул аша бик күп могҗизалы эшләр кылды. Өч айдан соң алар Искәндәрия корабына утырып Рим тарафына юлларын дәвам иттеләр. Утрауда яшәгән чакта җирле халык рәсүл Паул хакына аларга зур хөрмәт күрсәтте, китәргә җыена башлагач исә аларны кирәк булган бар нәрсә белән тәэмин итте, чөнки Паул утраудагы халыкның күбесен төрле авырулардан савыктырган иде.



Рәсүл Паул, Хуҗа-Хакимгә хезмәт күрсәтүен дәвам итеп, шактый күп сынауларга дучар булды. Тормышта аның һәр адымы белән кодрәт һәм мәрхәмәт иясе булган Аллаһының идарә итүенә Паулның иманы камил иде. Рим шәһәрендәге имандашларына тәгаенләнгән хатында ул болай дип яза: «Аллаһыны яратучыларга, ягъни Аның нияте буенча чакырып алынган кешеләргә бар нәрсә файдага гына».

*Рәсүлләрнең эшләре 25:1–12; 27:14–44; 28:1–11;*
*Римлыларга хат 8:28*

## Паул Рим каласында

«Рәсүлләрнең эшләре» дигән китапны язган инҗилче Лүк менә нәрсә ди:

Рим каласына килеп җиткәч, йөзбашы тоткыннарны гаскәр башлыгына тапшырды, Паулга исә сак астында аерым яшәргә рөхсәт ителде. Римга килеп өч көн торганнан соң, Паул анда яшәүче күренекле яһүдиләрне җыеп алды. Билгеләнгән көнне тегеләр Паул яшәгән йортка килгәч, ул аларга иртәдән кичкә кадәр Аллаһы патшалыгының асылын аңлатты, Гайсә турында Муса кануныннан һәм пәйгамбәрләрнең язмаларыннан ышанычлы дәлилләр китерде. Берәүләр аның сүзләренә ышанды, икенчеләре исә ышанмады. Шулай бер-берсе белән килешә алмыйча таралыша башлагач, Паул аларга болай диде: «Изге Рух сезнең ата-бабаларыбызга Ишагыйя пәйгамбәр аша дөрес әйткән: „Бу халык янына бар да әйт: Ничек кенә тыңласагыз да – аңламассыз, ничек кенә карасагыз да – күрмәссез. Чөнки бу халыкның йөрәген май баскан. Көчкә генә ишетә колаклары, күзләрен дә йомган алар. Әгәр шулай булмаса, күзләре белән күрерләр, колаклары белән ишетерләр, йөрәкләре белән аңларлар, Миңа таба борылырлар иде, һәм Мин аларны савыктырыр идем“. Шуңа күрә сезгә мәгълүм булсын: Аллаһының коткару турындагы хәбәре мәҗүсиләргә юлланган, һәм алар аны ишетәчәк!» – диде Паул. Ул шулай дигәннән соң, яһүдиләр бәхәсләшә-бәхәсләшә таралыштылар. Ә Паул Римда үзе түләп торган йортта ике ел яшәде һәм янына килүчеләрнең барысын да кабул итте. Ул кыю рәвештә һәм каршылыкларга очрамыйча Аллаһы патшалыгын вәгазьләде, Хакимебез Гайсә Мәсих турындагы тәгълиматны өйрәтте.

Шушы сүзләр белән «Рәсүлләрнең эшләре» дигән китап тәмамлана.

Укучыларны, мөгаен, рәсүл Паулның моннан соңгы язмышы да кызыксындыра торгандыр. Әмма Инҗил китабында бу хакта берни дә әйтелми. Рәсүл Паулның мәсихчеләр бердәмлекләренә һәм аерым кешеләргә язган хатларыннан, шулай ук башка чыганаклардан күренгәнчә, Паул, сак астында үткәргән әлеге ике



елдан соң азат ителеп, Италия, Греция һәм Кече Асия җирләрендә Яхшы хәбәрне таратуын дәвам итә. Риваятьләрдә әйтелгәнчә, рәсүл Паул рәхимсез Рим кайсары Нерон идарә иткән көннәрдә мәсихчеләрне эзәрлекләүчеләр кулыннан газаплы үлем кабул итә.

*Рәсүлләрнең эшләре 28:16–31*

# Рәсүлләрнең хатлары

Хаким Гайсә Мәсих үлеп терелгәннән соң Аның тәгълиматы, ягъни Яхшы хәбәр, Фәләстин җирләрендә, бөтен Рим империясендә, Якын Көнчыгыш илләрендә, аннары инде бөтен дөньяда бик тиз тарала башлады. Рәсүлләр, ягъни Гайсә Мәсих Үзе сайлап алган шәкертләр, шулай ук башка шәкертләр, төрле шәһәрләргә, илләргә таралып, Аллаһы сүзен вәгазьли башладылар. Раббы исә рәсүлләрнең сүзләрен төрле могҗизалар белән раслап торды: алар Гайсә Мәсих исеме белән Аллаһыга дога кылганда, хаста булганнар сихәтләнде, гариплләр савыкты, хәтта үлеләр дә терелде. Шушы хәлләргә шаһит булган кешеләр исә, Аллаһы сүзләрен йөрәкләренә салып, гөнаһларыннан тәүбә итте һәм туры юлга күнде. Мәсихкә иман китерүчеләрне һаман эзәрлекли тордылар, әмма Аллаһы Улы Гайсә Мәсихкә булган инану аларга җәбер-золым каршында ныклык бирде.

Мәсих юлына аяк басучыларның иманнарын ныгыту максатыннан рәсүлләр төрле шәһәрләрдәге мәсихчеләр бердәмлекләренә хатлар юллаганнар. Әлеге хатларның кайберләре кыска, нибары бер бит булып, икенчеләре, мәсәлән, Римлыларга язылган хат, шактый озын. Ягъкуб, Петер, Яхъя һәм Яһүдә язган хатлар Мәсихкә иман итүчеләрнең барысына да тәгаенләнгән, шуңа күрә алар җәмгыятькә язылган хатлар дип атала. Рәсүл Паул исә үзенең хатлары белән аерым шәхесләргә яисә бердәмлекләргә мөрәҗәгать итә.

Рәсүл Паулның кайбер хатлары зинданда утырган вакытта язылган. «Шул хезмәтем өчен мин, җинаятьче кебек богауланып, газап чигәм. Әмма Аллаһы сүзен богаулау мөмкин түгел», – дип яза Паул үзенең дусты Тимутәйгә *(II Тимутәйгә 2:9)*.

Рәсүлләрнең барлык хатлары Изге Рух белән сугарылган кешеләр тарафыннан язылу сәбәпле, Изге Язманың башка китаплары кебек үк, Аллаһының адәм балаларына мөрәҗәгате дип кабул ителә. Мәсихкә беренче булып иман китерүчеләр әлеге хатларны зур тырышлык белән күчереп язалар, бердәмлекләрдә һәм өйләрдә укыйлар, дусларына күрсәтәләр, бер-берсенә бүләк итәләр. Шул рәвешле алар Аллаһы сүзен кешеләргә җиткерүдә катнашалар.

Ул заманнарда кәгазь урынына үсемлектән эшләнгән папируска яисә махсус ысул белән эшкәртелгән юка тире кисәкләренә (пергаментка) язганнар.



## Хаким Гайсә истәлегенә Кичке аш

Рәсүл Паул әле оешып кына килүче Көринт бердәмлегенә төгәенләнгән Беренче хатын шундагы мәсихчеләр арасында туган төрле низагларга чик кую һәм кайбер бәхәсле сорауларга җавап бирү максатыннан яза. Әлеге сорауларның берсе мәҗүсиләр уздыра торган мәҗлесләрдә мәсихчеләрнең катнашу-катнашмавына бәйле. Бу хакта рәсүл Паул болай дип кисәтә:

> Аллаһыга рәхмәт белдереп шөкрана касәсеннән эчүебез Мәсих канында катнашыбыз барлыгын аңлата түгелме? Сындырып алган икмәбегез Мәсих тәнендә катнашыбыз барлыгын аңлатмыймы? Бер икмәкне уртаклашканга, без бер тәнне тәшкил итәбез, гәрчә күп булсак та. Исраил халкына карагыз: корбан итен ашаучылар мәзбәх өстендә корбан китерүдә катнашучылар түгелме? ...мәҗүсиләр корбанны Аллаһыга түгел, җеннәргә китерәләр, мин исә җеннәр белән аралашуыгызны теләмим. Сез бер үк вакытта Хакимебез Гайсә касәсеннән дә, җеннәр касәсеннән дә эчә алмыйсыз, бер үк вакытта Хакимнең дә, җеннәрнең дә табынында катнаша алмыйсыз.

Рәсүл Паул шул ук хатында, Гайсә Мәсих истәлегенә багышланган Кичке аш мәҗлесен ничек уздыру турында киңәшләрен биреп, көринтлеләргә болай дип әйтә:

> Хакимнең Үзеннән кабул итеп, сезгә җиткергән хәбәрем мондый иде бит: Хакимебез Гайсә хыянәткә дучар ителгән төнне кулына икмәк ала да шөкрана кылып сындырганнан соң: «Бу – сезнең өчен бирелә торган тәнем. Мине искә алып шулай эшләгез», – ди. Кичке аштан соң шулай ук кулына касә ала да: «Менә бу касә – Минем каным белән расланган Яңа Килешү. Аңардан эчкән саен Мине искә алыгыз», – ди. Шулай итеп, бу икмәкне ашаган һәм бу касәдән эчкән саен сез Хакимебезнең үлеме турында шаһитлык кыласыз. Ул кайтканчыга кадәр шулай эшләгез. Димәк, кем дә булса әлеге йолага хөрмәт күрсәтмичә бу икмәкне ашаса һәм Хакимнең касәсеннән эчсә, Аның тәне һәм каны алдында гаепле булыр.
>
> *I Көринтлеләргә 10:16-21; 11:23-27*



## Ягъкубның хаты

Ягъкубның хатында без кыска гына итеп әйтелгән, әмма тирән мәгънәле, гыйбрәт булырдай фикерләр белән еш очрашабыз. Мәсәлән, **дөнья малы турында**: «Кояш, калкып, үзенең көйдергеч эссесе белән үсемлекне корыта – аның чәчәге коела һәм матурлыгы югала. Байлар да шулай эш ыгы-зыгысында юкка чыгачак»; күңелгә кергән **вәсвәсә хакында**: «Сынауларга түзгән кеше бәхетле, чөнки ул, сынауларны кичкәннән соң, Аллаһы Үзен яратканнарга вәгъдә иткән тормыш таҗын алачак»; **ачулану хакында**: «Газиз имандашларым, хәтерегездә тотыгыз: һәркем тыңларга әзер булсын, сөйләргә һәм ачуланырга ашыкмасын, чөнки кеше ачулы чагында Аллаһы теләгән яхшы эшләрне башкармый»; **Аллаһы кушканнарны үтәү хакында**: «Сүзне тыңлап кына калмагыз, аны үтәгез дә, юкса үз-үзегезне алдаган булып чыгасыз»; **иман турында**: «Кеше иман белән генә түгел, бәлки кылган гамәлләре белән Аллаһы тарафыннан аклана. Чөнки җансыз тән үле булган кебек, яхшы гамәлләрдән башка иман да үледер»; **телнең гөнаһлары хакында**: «Тел дә шулай ук – гәүдәнең кечкенә генә әгъзасы булса да, чамасыз мактана. Урмандагы зур янгын да кечкенә генә очкыннан башланып китә. Бер үк чишмәдән төче һәм тозлы су чыгамыни?»; **ант эчү турында**: «Бөтенесеннән бигрәк, имандашларым, күк белән дә, җир белән дә, бүтән нәрсә белән дә ант итмәгез; Аллаһы хөкеменә юлыкмас өчен, сезнең „әйе“ дигән сүзегез – „әйе“, „юк“ дигәнегез – „юк“ булсын»; **хасталар турында**: «Арагызда кемдер авырый икән, иман итүчеләр бердәмлегенең өлкәннәрен чакырсын, һәм алар, Хуҗа-Хаким исеме белән аңа зәйтүн мае сөртеп, аның өчен дога кылсыннар. Иман белән кылынган дога авыру адәмне сәламәтләндерер, һәм Хуҗа-Хакимебез аны аякка бастырыр. Әгәр авыру адәм гөнаһ кылган булса, Аллаһы аны кичерер»; **тәүбә итү һәм дога кылу турында**: «Савыгыр өчен бер-берегез алдында гөнаһларыгызны таныгыз һәм бер-берегез өчен дога кылыгыз: тәкъва кешенең ихлас догасы зур кодрәткә ия»; **юлдан язганнарга мәхәббәт турында**: «Имандашларым, әгәр сезнең берәрегез хакыйкатьтән читләшеп, икенчегез аны хакыйкать кочагына кире кайтарса, белегез: гөнаһлыны ялган юлдан кайтаручы



кеше бу гөнаһлының җанын үлемнән коткарыр һәм күп гөнаһларны юкка чыгарыр».

*Ягъкуб 1:11-12, 19-20, 22; 2:17, 26; 3:5, 11-12; 5:12, 14-16, 19-20*

## Рәсүл Петернең ике хаты

Гайсә Мәсихнең унике рәсүленнән берсе булган Петер Кече Асиядәге мәсихчеләр бердәмлекләренә атап ике хат язган. Үзенең беренче хатын Петер, тәхеткә Нерон кайсар килеп, Рим империясендә мәсихчелекне юк итәргә омтылган, Мәсихкә иман итүчеләрне эзәрлекли һәм җәзалап үтерә башлаган заманда язган булырга тиеш дип уйланыла. Рәсүл Петер, имандашларының күңелен күтәрергә теләп, болай дип яза:

Ата-бабаларыгыздан сезгә мирас булып күчкән мәгънәсез яшәү рәвешеннән алтын-көмеш ише фани нәрсәләр белән түгел, ә гаепсез һәм кимчелексез бәрән кебек булган Мәсихнең каны белән йолып алындыгыз сез... Чөнки «һәр җан иясе үлән кебек, аның бөтен күркәмлеге кыр чәчәге кебек; үлән кибә, чәчәк тә шиңә; әмма Раббы сүзе мәңге яши». Бу Сүз – сезгә бирелгән Яхшы хәбәр!

Газиз дусларым! Җанга каршы көрәшүче гөнаһлы теләкләрдән качыгыз. Мәҗүсиләр сезне явызлык кылучылар дип нахак сүз сөйләсә дә, алар арасындагы эшләрегез тел тидермәслек булсын... Гөнаһлардан котылып хаклык өчен яшәсеннәр дип, безнең гөнаһларны Ул Үз өстенә алып хачка күтәрде: сезне Аның яралары савыктырды. Адашып йөргән сарыклар сыман идегез сез, инде хәзер Көтүчегез, җаннарыгызны Саклаучы янына әйләнеп кайттыгыз.

Яманлыкка – яманлык белән яки ачулы сүзләргә ачуланып җавап кайтармагыз; киресенчә, кешеләрне фатихалагыз, чөнки Аллаһы сезне шулай эшләргә чакырды; бары шул чакта гына сез Аллаһы фатихасын мирас итеп алырсыз... Йөрәкләрегездә Мәсихне Хаким буларак изге дип олылагыз.

Мәсих тә бит безне Аллаһыга якынайту максатыннан безнең гөнаһлар өчен бер тапкыр, Тәкъва кеше буларак гөнаһлылар хакына газап чикте. Аның тәне үлемгә тапшырылды, әмма Аллаһы Аны Үзенең Рухы белән терелтте... Әгәр сезне Мәсих исеме өчен мыскыл итәләр икән – сез бәхетле, чөнки Аллаһының шөһрәтле Рухы, Аллаһы Рухы – сезнең юлдашыгыздыр... Адәм җаны кыйган, урлашкан, җинаять кылган яки башкалар эшенә тыкшынган өчен җәфа чигәргә язмасын сезгә. Әгәр инде



мәсихче буларак газап чигәсез икән, оялмагыз, мәсихче исемен йөртүегез өчен Аллаһыны данлагыз.
Риваятьләргә караганда, Петер үлем җәзасына хөкем ителә, һәм аның үтенече буенча аны башы белән аска каратып хачка кадаклыйлар. Чөнки ул үзен Хаким Гайсә Мәсих сыман итеп хачка кадакланырга лаек түгел дип саный.

*I Петер 1:18–19, 24–25; 2:11–12, 24–25;*
*3:9, 15, 18; 4:14–16*

## Рәсүл Яхъяның өч хаты

Борынгыларның раславынча һәм дин белгечләренең фикеренчә, әлеге өч хат рәсүл һәм инҗилче Яхъя тарафыннан язылган. Яхъя иҗат иткән Инҗилдә дә, шулай ук ул язган хатларның өчесендә дә иң төп һәм мөһим сүзләрнең берсе – **мәхәббәт**.

Яхъя язган Беренче хатның төп эчтәлеге – мәхәббәт, Аллаһыга иман итеп яшәү, шатлык, иманның көче һәм яшәү мәгънәсе. Әлеге хаттан кайбер нәсыйхәтләрне тәкъдим итәбез. **Яктылыкта яшәү турында**: «Аллаһы яктылыкта булган кебек, без дә яктылыкта йөрсәк, бер-беребез белән аралашып яшибез һәм Аның Углы Гайсәнең каны безне һәртөрле гөнаһтан пакьләндерә дигән сүз. Кемдер „мин яктылыкта“ дип әйтеп, үзе имандашына нәфрәтләнсә, димәк, ул һаман караңгылыкта әле»; **фани дөньяга мөнәсәбәт турында**: «Фани дөньяны һәм андагы нәрсәләрне яратмагыз: дөньяны яратучыда Атабызны ярату юк. Бу дөньядагы һәммә нәрсә – тән нәфесе, күз нәфесе һәм тәкәбберлеккә китерүче нәрсәләр – Атабыздан түгел, бәлки дөньялыктан килә. Дөнья да, дөньяның нәфесләре дә үтеп китә, Аллаһы ихтыярын үтәүче исә мәңге яши»; **Мәсихнең дошманы турында**: «Алайса, кем ялганчы соң? Гайсәнең Мәсих икәнен инкяр итүче түгелме?! Менә ул – Мәсихнең дошманы: ул Атаны да, Аның Углын да инкяр итә. Аллаһы Углын инкяр итүченең күктәге Атасы да юк, Аллаһы Углын танучының исә күктәге Атасы бар»; **Коткаручы Гайсә турында**: «Мәсихнең кеше гөнаһларын Үз өстенә алыр өчен килгәнен сез беләсез. Ә Аның Үзендә гөнаһ юк. Аның белән бердәм булган адәм дә гөнаһ кылмый»; **мәхәббәт турында**: «Аллаһы безгә булган мәхәббәтен менә ничек күрсәтте: Үзенең Углы аша безгә тормыш бирер өчен бердәнбер Углын дөньяга җибәрде. Аллаһы – мәхәббәт ул. Мәхәббәттә яшәүче – Аллаһыда, һәм Аллаһы аңарда яши. Без яратабыз, чөнки беренче булып безне Аллаһы яратты. Гайсәнең Мәсих булуына инанган һәр адәм – Аллаһыдан туган. Аллаһының әмерләрен үтәп, без Аны яратуыбызны күрсәтәбез; Аның әмерләре авыр түгел»; **ялган пәйгамбәрләр турында**: «Аллаһы Рухын сез шуннан танып белерсез: кеше буларак килгән Гайсә Мәсихне таныган рух – Аллаһыдандыр. Ә Гайсәне танымаган рух Аллаһыдан түгел, ул – Мәсих дошманының



рухы»; **мәңгелек тормыш турында**: «Мин моны сезгә, Аллаһы Углына ышанучыларга, үзегезнең мәңгелек тормышыгыз барлыгын белегез, дип яздым».

*1 Яхъя 1:7; 2:9, 15-17, 22-23; 3:5-6; 4:2-3, 9, 16, 19; 5:1-3, 13*

# Яһүдәнең хаты

Әлеге хатның Маттай бәян иткән Инҗилдә *(13:55)* телгә алынган рәсүл Яһүдә, Гайсә Мәсих энеләренең берсе тарафыннан язылуы һичкемдә бәхәс тудырмый.

Яһүдә, мәсихчеләргә үгет-нәсыйхәт биреп, «Аллаһының изге халкына бер тапкыр һәм гомерлеккә бирелгән иманны яклауның кирәклеген» искә төшерә. Ул, Тәураттан мисаллар китереп, гөнаһлы бәндәләрнең хилаф эшләрен кабатламагыз дип, иман итүчеләрне алдан кисәтеп куя: «Боларның барысын белсәгез дә, хәтерегезгә төшерергә телим: Раббы халыкны Мисырдан алып чыгып коткарса да, ышанмаучыларны соңыннан һәлак итә. Үзенә бирелгән хакимлекне сакламаган һәм торакларын ташлап киткән фәрештәләрне дә Раббы, мәңгелек богаулар белән бәйләп, бөек хөкем көненә кадәр тирән караңгылыкта тота. Аларга охшап фәхешлеккә, җенси азгынлыкка бирелгән Сәдүм белән Гамура һәм шул тирәдәге калаларның халкы да, гыйбрәтле мисал буларак, мәңгелек ут җәзасына дучар ителә. Бу кешеләр дә, күргән төшләренә таянып, шулай ук тәннәрен нәҗесли, Раббы хакимлеген инкяр итә, күктәге көчләргә яла яга. Бу адәмнәр исә үзләре аңламаган һәммә нәрсәне яманлый; аңсыз хайваннар кебек, табигый теләкләренә бирелеп яши, һәм нәкъ шул аларны харап итә дә».

Менә шушы инсафсыз дәһриләр* юлына капма-каршы буларак, рәсүл Яһүдә иман белән яшәргә үгетли: «Сез исә, газиз дусларым, иң изге иманыгыз нигезендә бер-берегезне ныгытыгыз һәм Изге Рух белән илһамланып һәрчак догада булыгыз. Хакимебез Гайсә Мәсихнең мәрхәмәтенә, Ул бирәчәк мәңгелек тормышка өметләнеп, Аллаһының мәхәббәте белән яшәгез. Икеләнгән кешеләргә карата мәрхәмәтле булыгыз; башка берәүләрне, ялкын эченнән тартып алгандай, коткарыгыз; кемгәдер шәфкать күрсәтегез, әмма сак булыгыз: хәтта аларның гөнаһлы эшләр белән пычранган киемнәреннән дә җирәнегез».

Әлеге хат Аллаһыга яудырган мәдхияләр белән тәмамлана: «Сезне гөнаһка төшүдән саклый алучы, Үзенең шөһрәте алдына шатлыкка күмеп, пакь килеш китерә алучы бердәнбер Аллаһыга, Хакимебез Гайсә Мәсих аша безне Коткаручыга дөнья яратылганчы, хәзер һәм киләчәктә дан, мәһабәтлек, кодрәт һәм хакимлек булсын! Амин».

* Дәһри – Аллаһыга ышанмаучы.



# Рәсүл Паулның хатлары

Инжил китабына рәсүл Паулның Рим, Көринт, Эфес, Филиппуй, Көллесәй, Тессалуникә шәһәрләрендә һәм Гәләтия төбәгендә яшәүче мәсихчеләргә, шулай ук үзенең шәкертләре Тимутәйгә, Титуска, Филимунга атап язылган унөч хаты кергән (Гыйбриләргә хат та Паул тарафыннан язылган дип санала).

Паулның хатлары Инжил китабының дүрттән бер өлешен тәшкил итә. Бу хатларның бай эчтәлеген берничә биттә генә сөйләп бетерү мөмкин түгел. Әлеге китапта без рәсүл Паулның кайбер хатларына гына тукталып үтәбез.

Мәхәббәт

«Аллаһы – мәхәббәт ул», – дип өйрәтә безне Изге Китап.
Көринтлеләргә юллаган Беренче хатында *(13:1-8)* рәсүл Паул мәхәббәт турында болай яза:
Әгәр кешеләр телендә, хәтта фәрештәләр телендә сөйләшә белеп тә, күңелемдә мәхәббәт яшәми икән, мин бакыр яңгыравы яки тәлинкә чыңы кебек булыр идем.
Пәйгамбәрлек сәләтем булса да, барлык серләрне һәм һәртөрле гыйлемнәрне белсәм дә, таулар күчерерлек иманым булса да, әгәр күңелемдә мәхәббәт яшәмәсә, мин бер буш нәрсә булыр идем.
Бөтен мөлкәтемне өләшеп, тәнемне яндырырга тапшырсам да, әгәр күңелемдә мәхәббәт яшәмәсә, миңа берни ярдәм итә алмас.
Мәхәббәт ул – Гайсә Мәсих өйрәтүләренең төп нигезе: «„Раббы Алланңны бөтен йөрәгең, бөтен җаның һәм бөтен акылың белән ярат“, – диде Гайсә. – Бу – беренче һәм иң мөһим әмер. Икенчесе дә нәкъ шундый ук: „Якыныңны үзеңне яраткан сыман ярат“. Бөтен Канун һәм пәйгамбәрләрнең язмалары шушы ике әмергә нигезләнгән» *(Маттай 22:37–40)*.
Аллаһы мәхәббәте турында Гайсә болай ди: «Аллаһы дөньяны шулкадәр яратты ки, Углына ышанган беркем һәлак булмасын, ә бәлки мәңгелек тормыш алсын өчен, Ул Үзенең бердәнбер Углын бирде» *(Яхъя 3:16)*.

## МӘХӘББӘТ

**Мәхәббәт түземле, шәфкатьле,**
**көнләшми,**
**мактанмый, тәкәбберләнми,**
**дорфа түгел,**
**үз файдасын эзләми, ярсымый,**
**яман эшләрне истә тотмый.**
**Мәхәббәт гаделсезлеккә сөенми,**
**киресенчә, хакыйкатькә шатлана.**
**Ул бөтенесенә түзә,**
**бар нәрсәгә ышана,**
**һәрчак өметләнә,**
**барысына сабыр итә.**
**Ә менә бу өч нәрсә –**
**иман, өмет, мәхәббәт –**
**мәңге булачак.**
**Алар арасында иң бөеге исә –**
**мәхәббәт.**

***I Көринтлеләргә 13:4-13***

## «Кешенең гөнаһлы табигатенә хас булган эшләр» һәм «Рух үстергән җимешләр»

Хаким Гайсә Мәсих Үзенең шәкертләренә: «Мин – йөзем куагы, ә сез – ботаклар. Миндә булган, Мин дә аңарда булган кеше генә күп итеп җимеш бирер, чөнки Миннән башка бернәрсә дә эшли алмассыз», – дип әйтә. Үзенең Таудагы вәгазендә Гайсә болай дип сөйли: «Яныгызга сарык тиресе ябынып килүче ялган пәйгамбәрләрдән сакланыгыз – асылда ерткыч бүре алар. Кылган гамәлләренең җимешенә карап танырсыз сез аларны. Күгән куагыннан – йөзем, тигәнәк сабагыннан инҗир җыялармыни? Һәрбер яхшы агач – яхшы җимеш, начар агач исә начар җимеш бирә».

Гәләтиялеләргә юллаган хатында рәсүл Паул «гөнаһлы табигатьнең эшләре» һәм «Рух үстергән җимешләр» турында яза: «Кешенең гөнаһлы табигатенә хас булган эшләр билгеледер: болар – фәхешлек, бозыклык, азгынлык, потка табыну, сихерчелек, дошманлык, ызгыш-талаш, хөсетлек, ярсучан булу, үз файдаңны кайгырту, низаглар, төркемнәргә бүлгәләнү, көнчелек, эчкечелек, котырынкы мәҗлесләр һәм шуңа охшаш гамәлләр. Инде, элек әйткәнемчә, сезне кабат кисәтәм: шундый юлга басучылар Аллаһы Патшалыгын мирас итеп алмас. Изге Рух исә Үз җимешен үстерә: болар – мәхәббәт, шатлык, иминлек, сабырлык, игелеклелек, изгелек, тугрылык, басынкылык, тотнаклылык».

*Гәләтиялеләргә 5:19–23; Маттай 7:15–17; Яхъя 15:5–6*



# Яшь егет Тимутәй

Үзенең икенче сәфәрендә Паул, Раббы сүзен вәгазьләп йөри-йөри, Дерби һәм Лустра шәһәрләренә килеп җитте һәм анда Тимутәй исемле яшь бер мәсихче егетне очратты. Аның анасы Әүникә, углы кебек үк Гайсәгә иман итүче булып, яһүдиләрдән, атасы исә грек иде. Әбисе Лоис шулай ук мәсихче иде. Тимутәй, инҗилче Лүк сыман, рәсүл Паулның тугры юлдашына әйләнеп, аның белән Македуниядә, Грециядә, Рече Асиядә, хәтта Рим каласында да була. Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, Паул Римда җәзалап үтерелгәннән соң, Тимутәй Эфес каласындагы зур бердәмлек белән җитәкчелек итүне үз өстенә ала, һәм, Рим кайсарларының берсе идарә иткән заманда мәсихчеләрне эзәрлекләү башлангач, аны газаплап үтерәләр.

Рәсүл Паул үзенең яшь дусты Тимутәйгә ике хат яза. Әлеге хатларда бәян ителгән гаять мөһим фикерләрнең кайберләре түбәндәгедән гыйбарәт: **бөтен кешеләр өчен дога кылу турында:** «Иң элек шуны үтенәм: Аллаһыга хөрмәт күрсәтеп һәм сафлыкта тыныч-имин тормыш итәргә мөмкинлегебез булсын өчен барлык кешеләр хакына, шулай ук патшалар, хакимият җитәкчеләре хакына гозер-үтенечләрегезне, рәхмәт сүзләрегезне әйтеп дога кылыгыз. Бу гамәл Коткаручыбыз Аллаһы каршында яхшы һәм мәгъкуль»; **шайтан коткысы турында:** «Изге Рух ачык әйтә: заман соңында кайберәүләр, ялган рухларга һәм җен өйрәтүләренә колак салып, иманнан кире чигенерләр»; **байлык турында:** «Бар явызлыкның башы – акчага хирыслык. Акча артыннан куып, иман юлыннан язган һәм үзләрен күп кайгыларга дучар иткән кешеләр аз түгел. Ә син, Аллаһы кешесе, болардан кач һәм тәкъвалыкка, Аллаһы күңеленә хуш килгән гамәлләр кылуга, иманга, мәхәббәткә, түземлелеккә һәм басынкылыкка омтыл; **иман батырлыгы турында:** «Иман юлында үз-үзеңне кызганмыйча көрәшеп, мәңгелек тормышка ия бул. Аллаһы сине шуңа чакырды, һәм син күп шаһитлар алдында иманыңны ачыктан-ачык белдердең»; **ихлас күңелдән Аллаһыга хезмәт итү турында:** «Үзеңне ихлас күңелдән Аллаһыга табынырга күнектер. Сүздә, үз-үзеңне тотышыңда, мәхәббәттә, иманда, сафлыкта иман итүчеләр өчен үрнәк бул. Изге Язманы кычкырып укы, үгет-нәсыйхәт бир, өйрәт».

Тимутәйгә дигән Икенче хатны Паул үлем җәзасы көтеп зинданда утырган чакта язган дип фаразлана: «Бу дөньядан китәр вакытым



җитте; мин яхшы көрәштем, ахырга тикле йөгердем, иманымны саклап калдым, Минем өчен тәкъвалык таҗы инде әзерләп куелган. Көне җиткәч, аны миңа гадел Хөкемче, Раббы тапшырачак; миңа гына түгел, Хакимебезнең килүен сагынып көткәннәрнең барысына да бирәчәк».

*I Тимутәйгә 2:1-3; 4:1, 7, 12-13; 6:10-12; II Тимутәйгә 4:7-8*

## «Хакимебез – бер, иман – бер, суга чуму йоласы – бер». Хатлардан юллар

Бөтенесе дә гөнаһ кылып Аллаһы данынннан мәхрүм калды бит *(Римлыларга 3:23)*.

Кылынган гөнаһ өчен үлем белән түлибез, ә Аллаһының бүләге – Хакимебез Гайсә Мәсихтәге мәңгелек тормыш *(Римлыларга 6:23)*.

Аллаһы бер, Аллаһы белән кешеләр арасындагы арадашчы да бер, ул Кеше – Гайсә Мәсих *(I Тимутәйгә 2:5)*.

Мәсих безнең гөнаһларыбыз өчен үлде *(I Көринтлеләргә 15:3)*.

Гайсәне Хаким дип танысаң һәм Аллаһының Аны үледән терелтүенә йөрәгең белән инансаң – котылачаксың *(Римлыларга 10:9)*.

Һәлакәт юлыннан баручылар өчен хач турындагы сүз – акылсызлык, ә безгә, котылу юлындагыларга, – Аллаһы кодрәте *(I Көринтлеләргә 1:18)*.

Иманда нык торыгыз! Кыю һәм көчле булыгыз! *(I Көринтлеләргә 16:13)*.

Яхшы хәбәрне вәгазьләргә мин оялмыйм, чөнки аңарда иман тотучыларның һәрберсенә котылу алып килүче Аллаһы кодрәте бар *(Римлыларга 1:16)*.

Ялгышмагыз: Аллаһыны алдау мөмкин түгел! Кеше ни чәчсә, шуны урыр *(Гәләтиялеләргә 6:7)*.

Чөнки тәндә вакытта яхшылык эшләсәк тә, яманлык эшләсәк тә, кылганына карап һәркем үзенә тиешлене алсын өчен, безнең барыбызга да Мәсих хөкеме каршына басарга туры киләчәк *(II Көринтлеләргә 5:10)*.

Безнең һәркайсыбыз Аллаһыга үзе хакында хисап бирәчәк *(Римлыларга 14:12)*.

Бүген Аллаһының тавышын ишетәсез икән, Аллаһыга каршы чыккан вакыттагы сыман, йөрәгегездә үҗәтлек булмасын *(Гыйбриләргә 3:15)*.

Хакимебез – бер, иман – бер, суга чуму йоласы – бер *(Эфеслеләргә 4:5)*.



## Рәсүл Яхъяга булган вәхи

Без яшәгән җир йөзе мәңгелек түгел. Изге Китапның бик күп урыннарында ахыр заман турында алдан күреп әйтелгән сүзләрне укырга мөмкин. Әмма Изге Китапның азагында, рәсүл Яхъя язган Ачылыш китабында, бу хакта аеруча басым ясап әйтелә.

Яхъя – Гайсә Мәсихнең унике шәкертеннән берсе. Риваятьләргә караганда, Яхъядан гайре бөтен рәсүлләр дә газаплы үлемгә дучар булалар. Әмма Мәсих хакына Яхъя да байтак кыенлыклар күрә – аны грекларның Патмос утравына сөрәләр. Шунда аңа Хуҗа-Хаким күренеп: «Мин – Альфа һәм Омега*, Беренче һәм Соңгы; күргәннәреңнең барысы турында кәгазь төргәгенә яз да бердәмлекләргә җибәр», – дип әйтә *(Ачылыш 1:8–17)*.

Соңгы көннәрдә булачак вакыйгалар хакында Ачылыш китабында төрле символлар ярдәмендә, шартлы рәвештә бәян ителә. Болар: җирле җиде бердәмлеккә атап язылган хатлар, җиде мөһер, дүрт җайдак, җиде быргы, Аллаһы ачуының җиде касәсе, Һармагедун, Тормыш китабы, җанвар саны – 666, фәхешлеккә баткан Бабил, җиде башлы һәм ун мөгезле җанвар, ун патша, меңъеллык патшалык, Яңа Иерусалим, асылташлар, Тормыш агачы...

Ачылыш китабында тел белән аңлата алмаслык серләр гаять күп. Әмма бер нәрсә ап-ачык: Хаким Гайсә Мәсих, кабат җир йөзенә кайтып, дөньяны хөкемгә тартачак. Аның Икенче тапкыр җиргә кайтуын беренче гасырдагы мәсихчеләр дә көткән, аны без дә көтәбез.

Җиде бердәмлеккә атап язылган хатларның берсенә тукталып үтик. Әлеге җиде бердәмлек Ачылыш китабы иҗат ителгән заманнарда булган, әмма бу хатлар Мәсих Бердәмлегенең киләчәгенә дә турыдан-туры кагыла. Ә бәлки шушы хаттагы кайсыдыр сүзләрнең сезнең белән безгә дә мөнәсәбәте бардыр.

* *Альфа һәм Омега* – грек әлифбасының беренче һәм соңгы хәрефләре.



## «Ишек төбендә шакып торам»

Ачылыш китабында рәсүл Яхъя болай дип яза:
Амин дип аталган Зат, тугры һәм хакыйкый Шаһит, Аллаһы булдырган нәрсәләрнең Чыганагы болай дип әйтә: «Мин синең эшләреңне беләм: син салкын да, кайнар да түгелсең. Их, әгәр салкын яисә кайнар булсаңчы! Әмма син салкын да, кайнар да түгелсең, җылымса гына булганга күрә, сине төкереп ташлыйм! Син: „Мин бай, күп байлык тупладым, бер нәрсәгә дә мохтаҗлыгым юк“, – дисең. Әмма син үзеңнең бәхетсез, мескен, фәкыйрь, сукыр һәм ялангач булуыңны аңламыйсың. Баер өчен – Миннән утта чистартылган алтын, шәрәлегеңнең мәсхәрәсе ачылмасын өчен – өстеңә ак кием, күзләрең күрсен өчен – сөртергә күз мае сатып алырга киңәш итәм. Үзем яраткан һәркемгә Мин гаебен күрсәтәм һәм җәза да бирәм; шуңа күрә тырышлык куй һәм тәүбә ит.
Менә Мин ишек төбендә шакып торам. Берәрсе тавышымны ишетеп ишеген ачса, аның янына керермен һәм аның белән бергә кичке ашны ашармын, ул да Минем белән ашар.
Мин, җиңеп, Атам белән бергә Аның тәхетенә утырган кебек, җиңүчене Үзем белән рәттән тәхетемә утыртырмын. Рухның мәсихчеләр бердәмлекләренә әйткән сүзләрен колагы булганнар ишетсен».

*Ачылыш 3:14–22*



## Яңа күк һәм яңа җир

Яхъя иҗат иткән Ачылыш китабының соңгы берничә бүлегендә соңгы хөкем көне, яңа күк һәм яңа җир турында бәян ителә: Аннан соң мин ак тәхет һәм анда Утыручыны күрдем. Аның карашыннан җир белән күк качты, һәм аларга урын табылмады. Мин Аллаһы тәхете алдында торган үлеләрнең кечеләрен дә, бөекләрен дә күрдем – каршыларында ачык китаплар иде. Аннары Тормыш китабы дип аталган тагын бер китапны ачтылар. Үлеләрнең һәрберсе, китапларда язылганча, кылган гамәлләренә карап хөкем ителде. Диңгез үзендә булган үлеләрне бирде, үлем һәм үлеләр дөньясы да үзендәге үлеләрне кайтарды; үлеләрнең һәркайсы кылган гамәлләренә карап хөкем ителде. Шуннан мин яңа күкне һәм яңа җирне күрдем. Әүвәлге күк һәм әүвәлге җир юкка чыгып, инде диңгез дә юк иде. Һәм мин, Яхъя, Аллаһы яныннан, күктән төшүче изге шәһәрне, ягъни яңа Иерусалимне күрдем – кияве өчен бизәнгән кәләшкә охшаган иде ул. Шулчак мин тәхет ягыннан килгән көчле тавыш ишеттем: «Менә, Аллаһының торагы кешеләр арасында булачак – Аллаһы кешеләр белән бергә яшәячәк; алар – Аллаһының халкы, Аллаһы Үзе дә аларның Алласы булачак. Ул аларның һәрбер күз яшен сөртер. Үлем дә, кайгы-хәсрәт тә, елау да, авырулар да башкача булмаячак, чөнки элеккеләр үтте инде».

Тәхеттә утыручы: «Менә, Мин һәммә нәрсәне яңадан бар кылам, – диде, аннары миңа эндәште, – язып куй, чөнки бу сүзләр ышанычлы һәм хак», – диде. Ул миңа тагын болай диде: «Гамәлгә ашты! Мин – Альфа һәм Омега, Башы һәм Азагы. Сусаучыга Мин тереклек чишмәсеннән бушлай су эчертермен. Җиңүче боларның барысын мирас итеп алыр, һәм Мин аның Алласы булырмын, ә ул Минем балам булыр. Әмма куркакларны, иманнан ваз кичкәннәрне, әшәке бәндәләрне, кеше үтерүчеләрне, фәхешлек кылучыларны, сихерчеләрне, потка табынучыларны, барлык ялганчыларны ялкынланып торган күкертле күл көтә. Бу – икенче үлем».



Шәһәр кояшның һәм айның яктыртуына мохтаҗ түгел – аны Аллаһының шөһрәте яктыртып, Бәрән* шәһәрнең яктырткычы иде. Пычраклык, әшәкелек кылган һәм ялган сөйләгән һичбер адәм шәһәргә керә алмаячак. Исемнәре Бәрәннең Тормыш китабына язылганнар гына керә алачак анда.

*Ачылыш 20:11–13; 21:1–8; 23, 27*


* Бәрән – биредә сүз Гайсә турында бара.

## Изге Китапның соңгы бите

Изге Язма Аллаһы Углы Гайсә Мәсихнең җиргә яңадан килүе турындагы пәйгамбәрлек сүзләре белән тәмамлана. Рәсүл Яхъя язган Ачылыш китабының йомгаклау өлешен – Изге Китапның соңгы битен укыйк:

> Шуннан фәрештә миңа: «Бу китапның пәйгамбәрлек сүзләрен мөһер астына яшермә, чөнки вакыты инде җитте. Яман бәндә яманлык кылуда булсын, бозык бәндә тагын да бозыклыкка батсын, тәкъва кеше исә – тәкъвалыкта һәм изге кеше изгелектә яшәвен дәвам итсен.
>
> Менә, Мин тиздән киләчәкмен! Кылган гамәлләренә карап һәркемгә бирәсе әҗерне Үзем белән алып киләчәкмен. Мин – Альфа һәм Омега, Башы һәм Азагы, Беренче һәм Соңгы.
>
> Киемнәрен юганнар бәхетле – аларның тормыш агачыннан тукланырга һәм шәһәргә капка аша керергә хокукы булачак. Ә этләр*, сихерчеләр, фәхешлек кылучылар, кеше үтерүчеләр, потка табынучылар, ялган яратучылар һәм ялган сүз сөйләүчеләр тышкы якта калачак.
>
> Мин, Гайсә, болар турында бердәмлекләрдә шаһитлык итәр өчен сезгә Үземнең фәрештәмне җибәрдем. Мин – Давыт тамырыннан үсеп чыккан Сабак, аның Токымы, якты таң йолдызы».
>
> Рух та, кәләш тә: «Кил!» – ди. Боларны ишетүче дә: «Кил!» – дип әйтсен. Сусаучы килсен, теләгән кеше тереклек суын бушлай алсын.
>
> Бу пәйгамбәрлек китабының сүзләрен ишетүчене кисәтәм: әгәр кем дә булса шушында язылганнарга берәр нәрсә өстәсә, Аллаһы ул кешегә бу китапта әйтелгән бәла-казаларны өстәр. Әгәр кем дә булса бу пәйгамбәрлек китабындагы сүзләрнең берәрсен төшереп калдырса, Аллаһы әлеге китапта тасвирланган тереклек агачыннан һәм изге каладан ул кешенең өлешен төшереп калдырыр. Боларның һәммәсе турында шаһитлык Бирүче: «Әйе, тиздән киләчәкмен!» – ди.

* *Этләр* – ихтимал, биредә ялган укытучылар һәм тоткан юлыннан читкә тайпылучылар хакында сүз барадыр.


Καὶ λέγει μοι. Μὴ σφραγίσῃς τοὺς λόγους τῆς
προφητείας τοῦ βιβλίου τούτου, ὁ καιρὸς γὰρ
ἐγγύς ἐστιν. ὁ ἀδικῶν ἀδικησάτω ἔτι καὶ ὁ ῥυπαρὸς
ῥυπανθήτω ἔτι καὶ ὁ δίκαιος δικαιοσύνην ποιησάτω
ἔτι, καὶ ὁ ἅγιος ἁγιασθήτω ἔτι.
Ἰδοὺ ἔρχομαι ταχύ, καὶ ὁ μισθός μου μετ᾽ ἐμοῦ
ἀποδοῦναι ἑκάστῳ ὡς τὸ ἔργον ἐστὶν αὐτοῦ. ἐγὼ τὸ
Ἄλφα καὶ τὸ Ὦ, ὁ πρῶτος καὶ ὁ ἔσχατος, ἡ ἀρχὴ
καὶ τὸ τέλος.
Μακάριοι οἱ πλύνοντες τὰς στολὰς αὐτῶν, ἵνα
ἔσται ἡ ἐξουσία αὐτῶν ἐπὶ τὸ ξύλον τῆς ζωῆς καὶ τοῖς
πυλῶσιν εἰσέλθωσιν εἰς τὴν πόλιν. ἔξω οἱ κύνες καὶ οἱ
φάρμακοι καὶ οἱ πόρνοι καὶ οἱ φονεῖς καὶ οἱ
εἰδωλολάτραι καὶ πᾶς φιλῶν καὶ ποιῶν ψεῦδος.
Ἐγὼ Ἰησοῦς ἔπεμψα τὸν ἄγγελόν μου μαρτυρῆσαι
ὑμῖν ταῦτα ἐπὶ ταῖς ἐκκλησίαις. ἐγώ εἰμι ἡ ῥίζα καὶ τὸ
γένος Δαυίδ, ὁ ἀστὴρ ὁ λαμπρὸς ὁ πρωϊνός.
Καὶ τὸ πνεῦμα καὶ ἡ νύμφη λέγουσιν, Ἔρχου. καὶ ὁ
ἀκούων εἰπάτω, Ἔρχου. καὶ ὁ διψῶν ἐρχέσθω, ὁ
θέλων λαβέτω ὕδωρ ζωῆς δωρεάν.
Μαρτυρῶ ἐγὼ παντὶ τῷ ἀκούοντι τοὺς λόγους τῆς
προφητείας τοῦ βιβλίου τούτου· ἐάν τις ἐπιθῇ ἐπ᾽
αὐτά, ἐπιθήσει ὁ θεὸς ἐπ᾽ αὐτὸν τὰς πληγὰς τὰς
γεγραμμένας ἐν τῷ βιβλίῳ τούτῳ,
καὶ ἐάν τις ἀφέλῃ ἀπὸ τῶν λόγων τοῦ βιβλίου τῆς
προφητείας ταύτης, ἀφελεῖ ὁ θεὸς τὸ μέρος αὐτοῦ
ἀπὸ τοῦ ξύλου τῆς ζωῆς καὶ ἐκ τῆς πόλεως τῆς ἁγίας
τῶν γεγραμμένων ἐν τῷ βιβλίῳ τούτῳ.
Λέγει ὁ μαρτυρῶν ταῦτα, Ναί, ἔρχομαι ταχύ. Ἀμήν,
ἔρχου κύριε Ἰησοῦ.
Ἡ χάρις τοῦ κυρίου Ἰησοῦ μετὰ πάντων.

Амин, Хаким Гайсә, кил! Хаким Гайсәнең мәрхәмәте барыгызның юлдашы булсын!


*Ачылыш 22:10–21*

# КУШЫМТА



Борынгы Шәрык
Кара диңгез
Каспий диңгезе
Эгей диңгезе
ХИТТИЛӘР
ХУРИЛӘР
АШШУР
Харан
Алеппо
Угарит
Хамат
Кипр
Ниневә
Тигр елгасы
Фырат елгасы
МЕСОПОТАМИЯ (АРАМ-НАҺАРАИМ)
Әкбатана
Ашшур
Мари
БАБИЛ
Бабил
ШУМЕР
Ур
Шушан
Фарсы култыгы
Бөек (Урта) диңгез
Библ
АРАМ (СУРИЯ)
Сидун
Сур
Дәмәшкъ
Хатсор
Дор
КӘНГАН
Шәкем
Газа
Иерусалим
Хебрун
Беер-Шеба
Үле (Тозлы) диңгез
ГАРӘП ЧҮЛЕ
МИДЬЯН
МИСЫР
ЛУБ (ЛИВИЯ)
Нил елгасы
Кызыл диңгез
Ибраһимнең сәяхәте
Борынгы бөек дәүләтләр кул астындагы җирләр (б. э. к. 1350 ел)
Мисыр
Хиттиләр
Бабил
0
125
250
500
км
© UBS,1999



Гайсә Мәсих
заманында
Фәләстин җире
Сидун
Сарепат
ФОЙНИКӘ
Сур
Хәрмун тавы
Дәмәшкъ
Филип Кайсариясе
ГӘҮЛӘНИТИС
ТРАХУНИТИС
ГӘЛИЛӘЯ
Пытулемаис
Хоразин
Кәпәрнаум
Бәйт-Сайда
Бөек (Урта) диңгез
Кәна
Гәлиләя
диңгезе
Кәрмил тавы
Тибериас
Насара
Гәдара
Скифополис
САМАРЕЯ
Кайсария
УН КАЛА
Самарея
Герәсә
Гәризим
тавы
Сухар
Урдун елгасы
Ариматай
Филаделфея
Эммаус
Әрихә
Явне
ПЕРЕЯ
Ашдод
Иерусалим
Мәдебә
Бәйт-Лехем
Кумран
Ашкылун
ЯҺҮДИЯ
Махер
Хебрун
Газа
Яһүдия чүле
Үле диңгез
ИДУМАЯ
Сыйн чүле
Масада
Рафия
Беер-Шеба
НӘБАТИЯ
Ун кала
Филип идарәсендәге өлкә
Һируд Антипас идарәсендәге өлкә
Понти Пилат идарәсендәге өлкә
0
20
40
60
80
100
км
© UBS,1999




Horace Knowles © The British & Foreign Bible Society 1954,1967,1972




Horace Knowles © The British & Foreign Bible Society 1954, 1967, 1972


Гайсә Мәсих
заманында
Рим империясе
ГАЛЛИЯ
ИТАЛИЯ
ИСПАНИЯ
Рим
Бөек (Урта) диңгез
СИЦИЛИЯ
Карфаген
МАВРИТАНИЯ
АФРИКА
Рим империясенең чикл


Каспий диңгезе
Кара диңгез
ТРАКИЯ
Византия
МАКЕДУНИЯ
ГӘЛӘТИЯ
АСИЯ
Тарс
ГРЕЦИЯ
Эфес
Антиухия
КИПР
Сур
Дәмәшкъ
ЯҺҮДИЯ
КРИТ
Иерусалим
Күрини
Искәндәрия
Нил елгасы
ре
0
200
400
800
км
© UBS,1994


Рәсүл Паулның
беренче сәяхәте
ГӘЛӘТИЯ
Писидия
Антиухиясе
Икүниун
Лустра
Перги
Дерби
Тарс
КРИТ
Антиухия
КИПР
Саламин
Паф
Бөек (Урта) диңгез
0
125
250
500
км
Иерусалим
© UBS, 1994


МАКЕДУНИЯ
Филиппуй
Беруя
Тессалуникә
Апуллуния
Рәсүл Паулның
икенче сәяхәте
Троас
Көринт
Афина
Эфес
Писидия
Антиухиясе
Икүниун
Лустра
Перги
Дерби
Тарс
КРИТ
Антиухия
КИПР
Саламин
Паф
Бөек (Урта) диңгез
0
125
250
500
км
Самарея
Кайсария
Иерусалим
© UBS, 1994


Рәсүл Паулның
өченче сәяхәте
МАКЕДУНИЯ
Амфиполис
Филиппуй
Беруя
Неаполис
Тессалуникә
Апуллуния
Троас
Ассус
АХАЯ
АСИЯ ӨЛКӘСЕ
Митулини
Пергәм
Көринт
Смурна
Писидия
Антиухиясе
Эфес
Икүниун
Милит
Лустра
Дерби
Родос
Патара
Тарс
СҮРИЯ
Антиухия
Бөек (Урта) диңгез
Сур
0
125
250
500
км
Пытулемаис
Кайсария
Иерусалим
© UBS, 1994


Рәсүл Паулның
Рим шәһәренә
сәяхәте
Рим
Өч кунакханә
Потиулуй
ИТАЛИЯ
ЛУКИЯ
Мура
СҮРИЯ
Ригиун
Книд
СИЦИЛИЯ
РОДОС
КИПР
Суракүсәй
Сидун
КРИТ
МАЛЬТА
Кайсария
Яхшы гаваньнар
Иерусалим
Бөек (Урта) диңгез
0
125
250
500
км
© UBS, 1994



Иерусалим: Зәйтүн тавыннан күренеш (көнчыгыштан)
*Сөләйман патша салдырган Аллаһы йортының урыны. Бу урында хәзер Омар мәчете урнашкан.*



Иерусалим һәм Зәйтүн тавы (көнбатыштан)
*«Иерусалимгә якынлашып шәһәргә карашын ташлагач, аның язмышы өчен көенеп Гайсәнең күзләренә яшь килде»* (Лүк 19:41).



Синай тавы
*«Раббы Синай тау башына иңде һәм Мусаны чакырды. Муса тауга менде» (Тәүрат, Чыгыш китабы 19:20).*



Тозлы (Үле) диңгез
*«Биш патша бүгенге көндә дә Тоз күле урнашкан Сиддим үзәнлегендә үзләренең сугышчан көчләрен берләштерделәр» (Тәүрат, Яратылыш китабы 14:3).*



Табор тавы
*«Төньякны вә көньякны бар иттең Син; Табор вә Хәрмун таулары сөенеч белән исемеңне тәкрарлый» (Зәбур 88:13).*



Насара
*«Элисабет балага узып алтынчы ай киткәч, Аллаһы Җәбраил фәрештәне Гәлиләя өлкәсендәге Насара шәһәренә, Мәрьям исемле гыйффәтле кыз янына җибәрде. Давыт нәселеннән булган Йосыф атлы кешегә ярәшелгән әлеге Мәрьям...» (Лүк 1:26–27).*



Бәйт-Лехем
*«Ә син, Яһүдә җирендәге Бәйт-Лехем, Яһүдәнең бөек шәһәрләреннән һич тә ким түгелсең, чөнки синдә Юлбашчы туачак һәм Ул халкым Исраилнең Көтүчесе булачак» (Мат. 2:6).*



Үрдүн елгасы
*«Шулай бервакыт Яхъя тарафыннан суга чумдырылыр өчен Үрдүн буена Гәлиләядән Гайсә килде» (Мат. 3:13).*



Кәпәрнаум
*«Гайсә... Гәлиләя күле янындагы Зәбулун һәм Нәптали җирендә урнашкан Кәпәрнаум шәһәренә күчендe» (Мат. 4:13).*



Кәна
*«Ике көннән соң Гәлиләя өлкәсенең Кәна шәһәрендә туй булды, анда Гайсәнең анасы да катнашты» (Яхъя 2:1).*



Яһүдиядән Самареягә бара торган юл
*«Бу турыда белгәннән соң Гайсә, Яһүдияне калдырып, тагын Гәлиләягә китте. Аңа Самарея өлкәсе аша үтәргә туры килде» (Яхъя 4:3–4).*



Геннисарет күле
*«Беркөнне Геннисарет күле буена җыелган халык, Аллаһы сүзен тыңларга теләп, Гайсәне төрле яклап кысрыклый башлады» (Лүк 5:1).*



Бәйт-Әния

*«Котылу бәйрәменә алты көн кала Гайсә Бәйт-Әния авылына килде. Ул авылда Гайсә үледән терелткән Элгазар яши иде» (Яхъя 12:1).*



Рим Колизее: мәсихчеләр газаплап үтерелгән урын

*«Аннары мин... Гайсә хакында шаһитлык иткән һәм Аллаһы сүзе өчен башлары киселгән, җанварга һәм аның сынына табынмаган, маңгаена һәм кулына җанварның тамгасын салдырмаган кешеләрнең җаннарын да күрдем. Алар үледән терелеп тордылар да Мәсих белән бергә мең ел буе патшалык иттеләр» (Ачылыш 20:4).*

## Китапларның тулы һәм кыскартылган исемнәре

| | |
|---|---|
| Ешуа | Нун угылы Ешуа |
| I Патшалар | Патшалар (беренче китап) |
| II Патшалар | Патшалар (икенче китап) |
| III Патшалар | Патшалар (өченче китап) |
| IV Патшалар | Патшалар (дүртенче китап) |
| II Елъязма | Елъязма (икенче китап) |
| Гыйбрәтле сүзләр | Сөләйман патшаның гыйбрәтле сүзләре |
| Маттай | Маттай бәян иткән Яхшы хәбәр |
| Марк | Марк бәян иткән Яхшы хәбәр |
| Лүк | Лүк бәян иткән Яхшы хәбәр |
| Яхъя | Яхъя бәян иткән Яхшы хәбәр |
| Ягъкуб | Ягъкубның хаты |
| I Петер | Петернең беренче хаты |
| II Петер | Петернең икенче хаты |
| I Яхъя | Яхъяның беренче хаты |
| II Яхъя | Яхъяның икенче хаты |
| III Яхъя | Яхъяның өченче хаты |
| Яһүдә | Яһүдәнең хаты |
| Римлыларга | Паулның Римдагы имандашларга язган хаты |
| I Көринтлеләргә | Паулның Көринттәге имандашларга язган беренче хаты |
| II Көринтлеләргә | Паулның Көринттәге имандашларга язган икенче хаты |
| Гәләтиялеләргә | Паулның Гәләтиядәге имандашларга язган хаты |
| Эфеслеләргә | Паулның Эфестәге имандашларга язган хаты |
| Филиппуйлыларга | Паулның Филиппуйдагы имандашларга язган хаты |
| Көлессәйлеләргә | Паулның Көлессәйдәге имандашларга язган хаты |

| | |
|---|---|
| I Тессалуникәлеләргә | Паулның Тессалуникәдәге имандашларга язган беренче хаты |
| II Тессалуникәлеләргә | Паулның Тессалуникәдәге имандашларга язган икенче хаты |
| I Тимутәйгә | Паулның Тимутәйгә язган беренче хаты |
| II Тимутәйгә | Паулның Тимутәйгә язган икенче хаты |
| Титуска | Паулның Титуска язган хаты |
| Филимунга | Паулның Филимунга язган хаты |
| Гыйбриләргә | Гыйбриләргә хат |

# Эчтәлек

*Кереш сүз* . . . 3
**ИСКЕ ГАҺЕД**
Дөньяның яратылышы . . . 8
Дөньяның яратылышы (дәвамы) . . . 10
Беренче кешеләрнең барлыкка килүе . . . 12
Адәм белән Һаваның оҗмахтан куылуы . . . 14
Кабил белән Һабил . . . 16
Туфан. Нух көймәсе . . . 18
Туфан . . . 20
Туфан суларының кайтуы . . . 22
Салават күпере һәм Аллаһының кеше белән килешү төзүе . . . 24
Бабил манарасы . . . 26
Ибраһим . . . 28
Ибраһим һәм Лут . . . 30
Аллаһының Ибраһимга биргән вәгъдәсе . . . 32
Аллаһының өч фәрештәсе Ибраһим янында . . . 34
Сәдүм белән Гамураның һәлакәте . . . 36
Ибраһимның Исхакны корбанга китерүе . . . 38
Рәбика . . . 40
Исхак һәм Рәбика . . . 42
Ягъкубның Исхактан фатиха алуы . . . 44
Ягъкубның төше . . . 46
Ягъкубның Рахилә белән очрашуы . . . 48
Ягъкубның Аллаһы белән көрәшүе . . . 50
Ягъкуб белән Эсауның татулашуы . . . 52
Йосыф – Ягъкубның яраткан угылы . . . 54
Йосыфның төшләре . . . 56
Агаларының Йосыфны коллыкка сатуы . . . 58
Йосыф – сарай хезмәтчесенең йортында идарәче . . . 60
Йосыф зинданда . . . 62
Йосыфның фиргавен күргән төшләрне юравы . . . 64
Йосыф – Мисыр идарәчесе . . . 66
Җиде елга сузылган кытлык . . . 68
Кардәшләренә Йосыфның үзен танытуы . . . 70
Йосыф янына атасының һәм кардәшләренең килүе . . . 72
Исраил халкының Мисырда коллыкта яшәве . . . 74
Кәрзиндәге сабый . . . 76

Фиргавен кызының Мусаны табуы . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Янып торган күгән куагы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Муса белән Һарун фиргавен янында . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
Котылу бәйрәменә чалынган бәрән каны . . . . . . . . . . . . . 84
Раббының исраилиләрне Мисырдан алып чыгуы. . . . . . . . . . . 86
Исраилиләрнең Кызыл диңгезне кичүе . . . . . . . . . . . . . . . 88
Мисыр гаскәренең Кызыл диңгездә һәлак булуы . . . . . . . . . 90
Күктән яуган икмәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Мусаның кыядан су чыгаруы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Канунның ун кагыйдәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Алтыннан ясалган үгез бозау сыны . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Очрашу чатыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Гыйбадәтханә төзү өчен китерелгән бүләкләр . . . . . . . . . 102
Чатырны изгеләндерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Күзәтчеләрнең Кәнганга килүе. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Корах, Датан һәм Абирамның җәзага тартылуы . . . . . . . . . . 108
Бакыр елан. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Билгам пәйгамбәр һәм фәрештә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Нун углы Ешуа – Мусаның эшен дәвам итүче. . . . . . . . . . 114
Киләчәк буыннарга васыять: Раббыны онытмагыз . . . . . . . 116
Корбан китерү. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Мусаның вафаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Рәхәбнең күзәтчеләрне коткаруы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Үрдүн елгасын кичү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Әрихәне яулап алу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Аморилләр белән сугыш. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Исраил хөкемчеләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Гидеон . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Шимшон баһадир. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Шимшонның һәлакәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Рут белән Нагомия. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Рутның Богаз басуына килүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Хөннәнең догасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Хөннәнең Шемуилне Аллаһыга багышлавы. . . . . . . . . . . . 144
Раббының Шемуилгә дәшүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Рухани Элинең үлеме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Шаул – Исраил патшасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Көтүче Давыт – Раббы билгеләгән патша . . . . . . . . . . . . . 152

Давыт һәм Галиат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Йонатан. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Давытның йоклап яткан Шаул янына килүе . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Давытның бөтен Исраилдә патшалык итә башлавы. . . . . . . . 160
Аллаһы сандыгы Иерусалимдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Давытның мәдхияләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Натан пәйгамбәр – Давыт каршында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Абшалумның һәлак булуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Зирәк Сөләйман патша . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Аллаһы йорты. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Сөләйманның Аллаһы йортындагы догасы . . . . . . . . . . . . . . 174
Сөләйман һәм Шеба мәликәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Сөләйманның Аллаһыдан читләшүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Патшалыкның бүленүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Яһүдә – Көньяк патшалык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Исраил – Төньяк патшалык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
Ильяс пәйгамбәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Тол хатынның углына яңадан җан керү . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Багал пәйгамбәрләре һәм Ильяс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
Су һәм май белән булган могҗиза . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 192
Арам иленең гаскәрбашы Нагаман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Нагаманның савыгуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 196
Күзләре сукырайган баскынчылар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 198
Тәхеткә Йоашның килүе. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 200
Тәкәббер Уззия патшаның җәзага тартылуы . . . . . . . . . . . . . . 202
Исраилнең Аллаһыдан баш тартуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
Ашшурның Исраилне яулап алуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 206
Самареялеләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 208
Хизәкыйя патшаның догасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 210
Йошия патшаның анты. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
Иремия пәйгамбәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214
Иремия әйткән сүзләрне Барухның яза баруы . . . . . . . . . . . . . 216
Пәйгамбәрлек сүзләре язылган төргәкне Яһоякыйм патшаның утка салуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 218
Бабилнең Яһүдәне яулап алуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 220
Иерусалимнең һәм Раббы йортының тар-мар ителүе. . . . . . . 222
Даниил һәм аның өч дусты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 224
Алтын сын һәм кыю өч ир-егет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 226

Даниилның аңлаешсыз сүзләрне аңлатуы . . . . . . . . . . . . . . 228
Даниилның догасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 230
Даниил арысланнар чокырында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 232
Яһүдиләрнең әсирлектән кайтуы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 234
Мәликә Эстер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236
Мәликә Эстер (дәвамы) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 238
Нәхәмиянең Иерусалим диварын төзүе . . . . . . . . . . . . . . . . 240
Халыкның Аллаһыга мөрәҗәгать итүе . . . . . . . . . . . . . . . . 242
Әюбнең башыннан үткәннәре. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244
Әюб үзе кичергән авыр сынаулардан соң. . . . . . . . . . . . . . 246
Зәбур китабы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 248
Зәбурның кайбер юлларын хәтердә калдырыйк . . . . . . . . 250
Гыйбрәтле сүзләр китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
Вәгазьче китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 254
Пәйгамбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256
Ишагыйя пәйгамбәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 258
«Һәм алар кылычтан – сука төрәне, ә сөңгедән урак ясаячак» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 260
«Явызлыкка вә зыян-зарарга урын калмаячак» . . . . . . . . . 262
Һошея пәйгамбәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 264
Йоил пәйгамбәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 266
Юныс пәйгамбәр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 268
Михә пәйгамбәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 270
Мәсихнең килүе турында пәйгамбәрлек сүзләре. . . . . . . . . . . 272
**ЯҢА ГАҺЕД**
Аллаһы йортында Зәкәриягә фәрештәнең күренүе. . . . . . . . . 276
Чумдыручы Яхъяның дөньяга килүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
Гайсәнең тууы хакында Яхшы хәбәр. . . . . . . . . . . . . . . . . . 280
Гайсә Мәсихнең тууы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 282
Гайсә Мәсихнең тууы хакында фәрештәләрнең көтүчеләргә хәбәр итүе. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 284
Көтүчеләр Гайсә янында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 286
Тәкъва Шимун . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 288
Йолдызчыларның сәҗдә кылырга килүе. . . . . . . . . . . . . . . . 290
Йолдызчыларның бүләкләре. Һирудның гаепсез сабыйларны үтерергә боеруы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 292
Мисырга качу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 294
Гайсәнең Насарада үткәргән балалык еллары . . . . . . . . . . 296

Яшүсмер Гайсә Аллаһы йортында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 298
Чумдыручы Яхъяның вәгазьләве. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 300
Гайсә Мәсихнең суга чумдырылуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 302
Гайсәнең чүлдә сыналуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 304
Гайсә Мәсихнең унике шәкерте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 306
Гайсә кылган беренче могҗиза. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 308
Гайсәнең Аллаһы йортыннан сатучыларны куып чыгаруы . 310
Гайсәнең Никәдим белән әңгәмә коруы . . . . . . . . . . . . . . . . . 312
Гайсә һәм Самарея хатыны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 314
Мул табыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 316
Паралич суккан кешенең савыгуы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 318
Таудагы вәгазь: чын бәхет кануннары . . . . . . . . . . . . . . . . . . 320
Таудагы вәгазь: Муса кануны турында. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 322
Таудагы вәгазь: мәхәббәт һәм дога турында . . . . . . . . . . . . . . 324
Таудагы вәгазь: Аллаһыга мөнәсәбәт турында. . . . . . . . . . . . . 326
Таудагы вәгазь: кешеләргә мөнәсәбәт турында . . . . . . . . . . . 328
Таудагы вәгазь: хакыйкать һәм ялган. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 330
Тол хатынның үлгән углын терелтү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 332
Орлык чәчүче турында гыйбрәтле хикәя. . . . . . . . . . . . . . . . . 334
Күкләр Патшалыгы турында гыйбрәтле алты хикәя . . . . . . . 336
Гайсәнең давылны тынычландыруы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 338
Яһир кызының үледән терелүе. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 340
Гайсәнең биш мең кешене ашатуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 342
Гайсәнең су өстеннән атлап килүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 344
Гайсәнең кыяфәте үзгәрү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 346
Барысын да кичерә торган мәхәббәт. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 348
Шәфкатьле самареяле хакында гыйбрәтле хикәя . . . . . . . . . . 350
Гайсә – яхшы Көтүче. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 352
Марта һәм Мәрьям исемле кыз туганнар. . . . . . . . . . . . . . . . . . 354
Акылсыз бай турында гыйбрәтле хикәя . . . . . . . . . . . . . . . . . 356
Бай һәм Элгазар турында гыйбрәтле хикәя. . . . . . . . . . . . . . . . 358
Югалган сарык турында гыйбрәтле хикәя . . . . . . . . . . . . . . . . 360
Юлдан язган угыл турында гыйбрәтле хикәя. . . . . . . . . . . . . . 362
Махау зәхмәте кагылган ун кешенең савыгуы . . . . . . . . . . . . 364
Фарисей һәм салым җыючы турында гыйбрәтле хикәя. . . . . 366
Гайсәнең балаларга фатиха бирүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 368
Гайсәнең сукыр Бартимәйне савыктыруы. . . . . . . . . . . . . . . . 370
Зәкәйнең котылуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 372

Гайсәнең үле Элгазарны терелтүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 374
Кичерелгән гөнаһың зур булса, ныграк яратасың. . . . . . . . . . 376
Гайсәнең Иерусалимгә керүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 378
Гайсәнең Иерусалим хакында зар елавы . . . . . . . . . . . . . . . 380
«Чакырылганнар күп булыр, тик сайлап алынганнар аз». . . 382
«Кайсарныкын – кайсарга, Аллаһыныкын – Аллаһыга» . . . 384
«Беренче һәм иң мөһим әмер» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 386
Фәкыйрь тол хатын салган ике данә вак акча. . . . . . . . . . . . 388
Гайсәнең киләчәк турындагы сүзләре. . . . . . . . . . . . . . . . . . 390
Ун кыз турында гыйбрәтле хикәя . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 392
Гайсә – йөзем куагы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 394
Гайсәнең шәкертләр белән уздырган соңгы аш мәҗлесе . . . . 396
Соңгы аш мәҗлесендәге әңгәмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 398
Гетсимәни бакчасында кылынган дога . . . . . . . . . . . . . . . . 400
Гайсәнең сак астына алынуы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 402
Гайсәне хөкем итү. Петернең Гайсәдән ваз кичүе. . . . . . . . . 404
Гайсә Пилат янында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 406
«Үзенең хачын күтәреп» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 408
Гайсәне хачка кадаклау. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 410
Гайсәне кабергә салу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 412
Гайсәнең үледән терелүе. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 414
Гайсә исән! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 416
Гайсәнең Эммаус юлында шәкертләренә күренүе . . . . . . . . 418
Гайсәнең башка шәкертләргә дә күренүе . . . . . . . . . . . . . . 420
«Син Мине яратасыңмы?». . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 422
Гайсәнең күккә ашуы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 424
«Юл, хакыйкать һәм тормыш» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 426
Рәсүлләрнең эшләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 428
Изге Рухның иңүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 430
Петер сөйләгән вәгазь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 432
Аксак кешенең савыгуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 434
Петер белән Яхъяның кулга алынуы . . . . . . . . . . . . . . . . . 436
Иман хакына иң беренчеләрдән Эстефәннең корбан булуы . . .438
Филип һәм Хәбәшстан түрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 440
Шаулның иман итүчеләр бердәмлеген эзәрлекләве . . . . . . . 442
Раббының Шаулга күренүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 444
Шаулның Дәмәшкътән качуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 446
Яфу шәһәрендә яшәүче Табита исемле хатынның үледән терелүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 448

Йөзбашы Көрнили . . . 450
Фәрештәнең Петерне зинданнан азат итүе . . . 452
Яхшы хәбәрне тарату максатыннан Паулның беренче сәфәре . . . 454
Яхшы хәбәрне тарату максатыннан Паулның икенче сәфәре . . . 456
Паул белән Силас тоткынлыкта . . . 458
Паул Афинада . . . 460
Яхшы хәбәрне тарату максатыннан Паулның өченче сәфәре . . . 462
Сихерчелек – зур гөнаһ . . . 464
Паулның Эфес бердәмлегендәге өлкәннәр белән хушлашуы . . . 466
Паул идарәче Фисте алдында . . . 468
Паулны Римга озату . . . 470
Паул Рим каласында . . . 472
Рәсүлләрнең хатлары . . . 474
Хаким Гайсә истәлегенә Кичке аш . . . 476
Ягъкубның хаты . . . 478
Рәсүл Петернең ике хаты . . . 480
Рәсүл Яхъяның өч хаты . . . 482
Яһүдәнең хаты . . . 484
Рәсүл Паулның хатлары . . . 486
«Кешенең гөнаһлы табигатенә хас булган эшләр» һәм «Рух үстергән җимешләр» . . . 488
Яшь егет Тимутәй . . . 490
«Хакимебез – бер, иман – бер, суга чуму йоласы – бер». Хатлардан юллар . . . 492
Рәсүл Яхъяга булган вәхи . . . 494
«Ишек төбендә шакып торам» . . . 496
Яңа күк һәм яңа җир . . . 498
Изге Китапның соңгы бите . . . 500

Кушымта . . . 503

*Изге Язма сәхифәләре*
*Библия для детей на татарском языке*
*Children's Bible in the Tatar language (ISO: tat)*

Институт перевода Библии
www.ibt.org.ru; ibt_inform@ibt.org.ru
101000 Россия, Москва,
Главпочтамт, а/я 360

Подписано в печать 07.11.2023
Формат 60×84 1/16. Печать офсетная. Усл. печ. л. 30,69.
Тираж 5000 экз. Заказ № 11637

Отпечатано в ООО “Тверская фабрика печати”
170006 Тверь, Беляковский переулок, 46
т. (8482) 235-32-13